
# КАЗАН УТЛАРЫ

1.2000





**МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ**

**1930—1995**

# Казан утлары
# Qazan utları

*2000*

**1**

**(927)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Гариф Ахунов,**
**Харрас Әюпов,**
**Зилә Вәлиева,**
**Фоат Галимуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Гәрәй Рәхим,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Китап гасыры китәме? ........ 5

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Гамил АФЗАЛ. Үз кадерен белгән юлчы. *Шигырьләр* ........ 9
Вахит ИМАМОВ. Утлы дала. *Тарихи роман* ........ 13
Әхсән БАЯН. Гомерләрдән моң һәм сүз кала... *Шигырьләр* ........ 89
Рәдиф ГАТАШ. «Жыр—Ике Мең ишеген шакыганда...» *Робагыйлар* ........ 110
Нурия ИЗМАЙЛОВА. Мин—ялгызлар иләндә. *Шигырьләр* ........ 129

**ДРАМАТУРГИЯ**

Фәнис ЯРУЛЛИН. Бер көрәшү—үзе бер гомер. *Комедия* ........ 94

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Барлас КАМАЛОВ. Үткәннәргә борылып карасам... ........ 117

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

Сөмбел ГАФФАРОВА. Хикәяләр. *(Ф. Латыйфиның кереш сүзе белән)* ........ 134

**БҮГЕНГЕ ӘДӘБИЯТ**

Киләчәккә карап (*«Казан утлары» журналы редколлегиясенең киңәйтелгән утырышыннан)* ........ 140

**ФӘН**

Зәрия ХӘБИПОВА. «Идегәй» үткән юл ........ 155

**СӘНГАТЬ**

Бикә РӘХИМОВА. Моннар һәм уйлар *(Композитор Шамил Шәрифуллинга 50 яшь)* ........ 174

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Шамил МАННАПОВ. Язмышларыбыз уртак ........ 180

**ЯХЪЯ АБДУЛЛИНГА 80 ЯШЬ**

Фәридә ГАФФАРОВА. Милләткә хезмәт юлында ........ 182

**УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ**

Гомәр САТТАР-МУЛИЛЛЕ, Илдар КЫЯМОВ, Ринат НУРУЛЛИН *шигырьләре* ........ 185

Котлыйбыз ........ 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 190

# В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Колонка главного редактора»: Р. ФАЙЗУЛЛИН. «Уходит ли век Книги?»
«Проза и поэзия»: В. ИМАМОВ. Роман «Огненная степь» *(начало)*; стихи Г. АФЗАЛА, А.БАЯНА, Р. ГАТАША, Н. ИЗМАЙЛОВОЙ.
«Драматургия»: комедия Ф. ЯРУЛЛИНА «Одно свидание и целая вечность».
«Публицистика»: Б. КАМАЛОВ. «А в душе следы... следы прошлого».
«Новые имена»: рассказы С. ГАФФАРОВОЙ *(с предисловием Ф. Латифи)*.
«Современная литература»: Взгляд на будущее. *(Отчет расширенного заседания редколлегии журнала «Казан утлары»)*.
«Наука»: статья З. ХАБИПОВОЙ «Тернистый путь «Идегея».
«К 80-летию академика Я. Абдуллина»: статья Ф. ГАФФАРОВОЙ «Служу своему народу».
«Искусство»: статья Б. РАХИМОВОЙ посвящена творчеству композитора Ш. Шарифуллина.
«Книжное обозрение»: Ш. МАННАПОВ рецензирует книгу М. Хафизова «Нижегородские татары».
«Творчество читателей»: стихи Г. САТТАРОВА, И. КИЯМОВА, Р. НУРУЛЛИНА.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Царица Сююмбике и Казанская принцесса -работа неизвестного итальянского художника. XVI век; писатель Ф. Садриев.

# IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Column of editor": R. Faizullin «Whether leave century of book?».
"Prose and Poetry": V. IMAMOV'S novel «Fiery steppe»; verses of G. AFZAL, A. BAYAN, R. GATASH, N. IZMAILOVA.
"Dramatics": F. YARULLIN'S comedy «Certain meeting and whole eternity».
"Publicism": B. KAMALOV «And in soul trecks... tracks of the past».
"New names": tales of S. GAFFAROVA.
"Modern literature": Look on the future.
"Scince": Z. HABIPOVA'S article «Thorny way of «Idegey»».
"To 80th years academician Y. Abdullin": F. GAFFAROVA'S article «Serve my people».
"Art": B. RAHIMOVA'S article devote creative works composer Sh. Sharifullin.
The diary of social and cultural life.
In our covers: «Suumbike and Kazan princess» - work unknown Italian painter. XVI century; writen F. Sadriev.

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

---


Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 24.12.99 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70X108^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8653 Заказ 3-613
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2



© «Казан утлары», 2000 ел.

*Баш мөхәррир сүзе*

**Равил Фәйзуллин**

# КИТАП ГАСЫРЫ КИТӘМЕ?

**1999** дагы тугызлы саннарның ияклəре салынып түгəрəклəнгəч, язмаларыбызда рəттəн симез өч **«000»** күренгəч, яна гасыр быел ук башлана дип уйлаучылар да булды бугай. Ашыкмыйк: өченче менне башлаган яңа гасыр таңына тагын бер ел бар əле! (Бу хисап милади буенча, һижри белəн исəплəсəң, бөтенлəй бүтəн гасырда əле без!) Бəрəкəтсез тиз узса да, бер ел əллə никадəр хəл-вакыйгалар, көтелмəгəн үзгəрешлəрне үз эченə ала əле ул. Исəн-сау булсак, яңа гасыр бусагасын атлаганда укучылар белəн уртаклашырлык яңа уй-фикерлəр табылыр, бəлки. Ə хəзергə—язма сүз, басма китап, язмышлары сүз сəнгатенə бəйле каләмдəшлəрем хезмəте турында.

...Китап гасыры үтеп бара. Бу сүзлəрне кəгазьгə төшерəм, ə җан бəргəлəнə. Кул яза, күңел килешми. Ə нишлисен, Вакыт Галиҗəнаплəренə каршы чара юк. XX гасыр—информация-коммуникация ягыннан—телефон, радио, самолет, телевизор, кибернетика гасыры булды. Фəн казанышлары кешелəрнен рухи дөньясын бик нык үзгəртте. Шулай да, дөньяны танып-белүдə, эстетик тəрбия бирүдə Китап төп чыганак булып кала бирде. Шулай булмыйни! Китап—ничə гасырлар буе Кеше акылының могҗизасы саналды. Гомер бакый Кеше җанының сердəше булды. Ул—уйлатты, елатты, сөендерде, нəфрəтлəндерде, хыялландырды... Гомер буе сабак бирде... (Китап белəн бергə, хатлар язу-хат алышу гасыры да үтеп бара түгелме соң? Кызганыч... Ничəмə-ничə буын хат язып, хат көтеп хыялланып яшəде бит!) Ризасызланып булса да, килешергə туры килə: гасырыбызның соңгы чирегендə телевидение һəм компьютер системасы информация пространствосыннан басма Китапны шактый кысрыклады да. Бер генə мисал: кайчан гына яхшы язу машинасы булдыру турында хыяллана идек. Хəзер аларның хаҗəте бетеп бара... Фəн акылы казанышларын гавами акыл үзлəштерергə өлгерə алмый. Цивилизацияле дөнья компьютерның интернет челтəре белəн эш итə хəзер. Кешелек аңы тарихында үзе бер революция. «Виртуаль чынбарлык», «тинейджер» (компьютер «җанлы» кешелəр) дигəн төшенчəлəр барлыкка килде. Менəр чакрым ераклыктан кешелəр үзара мəгълүмат алу гына түгел, хэтта тəнни-хиссн мөнəсəбəтлəргə дə керə алалар дип сөйлилəр... Йə, ходa, илаһи дип йөргəн Китабыбыз нишлəр инде? Ахырзаман бəндəлəренен Ана ихтыяҗы булырмы?

Дөресен əйтик, күңелдə тəшвишле уйлар булса да, Китап язмышы белəн нисбəтəн килəчəккə өметсез үк карамыйм. Халкыбыз Китапның үз язмышы икəнен аңлар дип ышанам. Алга таба 200 еллап тарихы булган Америка өчен китап—бер нəрсə булса, меңəр еллык дəүлəтле тарихы булган Европа иллəре өчен, бəлки, икенчерəктер китапның миссиясе... Ə безнең өчен ул төп байлык. Ул монарчы безнең өчен—Дəүлəт тə, Дин дə, Гыйлем чыганагы да булып килде. Элгəргелəребезнең бөек сүзлəрен искə төшерик:

«Мәгъмүр Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары, бер дә булмаган төсле, кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады... Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады (....), алар сәламәт әле, алар яңгырый әле» (Г. Тукай). «Иҗтимагый ирекләрдән мәхрүм ителгән халыкта әдәбият аның вөҗдан һәм ачу авазын ишеттерү өчен бердәнбер трибуна булып тора» (А. Герцен). Болар—үткән гасырларның хикмәти җан авазлары.

Әйе, без Китаптан аерылырга тиеш түгел. Әлегә «Йосыф-Зөләйха» кыйссаларыннан, «Идегәй» дастаннарыннан килгән рухи яктылык яшәтә. Китапларга салынган җегәр-көч бик тә кирәк әле безгә. Хәзерге рәсми статистика ягыннан карасаң да, алга киткән байтак халыклар нисбәтендә, бүген дә югары белемгә ия кешеләр саны буенча без шактый түбән урында. Һәрхәлдә, киләсе гасырның байтак дистә елларында без Китап Укучы Халык булып дөньяга кереп калсак иде! Теләкнең шушы урынында бик тә мөһим бер нәрсәне дә ачыклау кирәк. Нинди китап белән киләчәккә бармакчыбыз соң? Кайларда алар? Кемнәр чыгара аларны? Авторлары кем? Укучылары кем һәм күпме? Чыннан да, чигәләренне тотып уйланырлык хәл. Бер карасаң, китапка дәрт кими бара дибез, икенче яктан—дөнья тулган китап белән. Зур форматлысы, кечкенәсе, ялтыравык тышлысы, рәсемлесе... Тик аларның күбесе, иң аз дигәндә өчтән икесе, псевдокитаплар, полиграфик ысул белән кәгазьгә төшкән опуслар, кеше җанын көчләүче язмалар, очсыз анекдот-мәзәкләр, хайвани инстинктны кытыклаучы детектив хикәяләр, порножурналлар... Югары художество кыйммәткә, тәрбияви әһәмияткә ия, эстетик зәвык белән чыкканнары да җитәрлек. Фәнни басмалар, белешмә сүзлекләр, дөнья классикасы үрнәкләре... Алар, кызганыч, азрак керә йорт түрләренә. Китапханәләр, китап кибетләренә караганда затлы банк биналары, коммерция офислары күбрәк төзелә хәзер. Әлбәттә, аларның үз дөньясы, үз китаплары, күбрәк табыш алуга файдалы методик әсбаплар... Татар дөньясының китап чыгару тарихына баксаң, бер уртак хәлгә тап буласың: гасыр башында да, гасыр ахырында да матбагада хөрлек булган: теләсә нәрсә чыгарып була! Ләкин аерма бар. Татар галәмендәге китаплар, нигездә, берничә төрдә: матур әдәбият (шул исәптән халык иҗаты үрнәкләре); дини әдәбият; дәреслекләр, фәнни-белешмә басмалар. Бәлки, китапчы-галим, академик Ә. Кәримуллин да шул фикердәдер. Ул чорда әдәпсез-оятсыз «әдәбият» үрнәкләрен таба алмыйсын. Шуңа күрә, ул замандагы китап мирасы, нигездә, милләт киләчәгенә, аның мәгърифәтенә хезмәт иткән, милли үзаңны үстергән. Р. Фәхретдин, Г. Тукай, Г. Исхакый, Дәрдеменд, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов һәм башка әдипләрнең иҗаты шул хакта сөйли. Ә хәзерге вәзгыять? Хәлнең ничеклеген алдарак беркадәр әйттем шикелле. Китап дөньясында хаос. (Рәсәйдәге яшәүнең көзгесе!) Күпләр нәрсәнең китап, нәрсәнең антикитап икәнен аера алмый. Пародокс хәл: Китапны «китап» бетереп бара. Республикада, белүемчә, китап чыгаруга лицензия-хокук алган йөзләгән нәшрият (!) бар. Нигә шулкадәр үрчегәннәр соң алар? Аларның күплегеннән бирәр нәрсә отабызмы? Төгәл җавап бирү авыр, күңел авазы—отмыйбыз,—ди. Чөнки аларның туксан фәлән проценты, ничек кенә булса да, нәрсә чыгарып булса да, табыш алу максатын куйган басмаханәләр. Миңа калса, бүгенге көндә, традицион тәртиптә, төп ике оешма—Татарстан китап нәшрияты һәм «Мәгариф» нәшрияты гына дәүләтчел сәясәт алып барып, киләчәкне күз алдында тотып, эшчәнлек алып бара. Һәрхәлдә, бу нәшриятлар чыгарган китаплар өчен, нигездә, оялырлык түгел. Кайбер чыгарма мисаллар табып була булуын. Әлбәттә, бу төп нәшриятлар тагын да нәтиҗәлерәк—күбрәк китаплар да чыгара алыр иде дә, әмма бюджет тарафыннан каралган суммаларның да өчле-тугызлы, ягъни ярым-йорты бирелүе сәбәпле бөтен тулаем көченде эшли алмый. Шул сәбәпле, байтак авторлар, очсызлырак чыгара торган коммерция басмаханәләргә мөрәҗәгать итәләр. Ә эшкуар басмаханәчеләр теләсә ни чыгарырга әзер! Андый авторлар, мең бәла белән акча юнәтеп чыгарган китапларын үзләре сатып, үзләре урнаштырып йөрергә мәҗбүрләр. Дәрдмәнд, Акмулла, яки кырыктартмачы... барсы бергә буталган...

Китапханәләргә кергәч, бөрешеп калам
Китап киштәләре алдында.
Бөек уйлар тулы изге сарайдан соң
кичке Күккә карыйм нарасыйланып.
Анда да мәңгелек йолдызлар...

* * *

Ике хәзинә бар дөньяда: саклагыз!
Каберстан аның берсе. Гел гөлдә булсын!
Китапханә икенчесе. Күңелдә булсын!
Базар болай да калыр...

...Булды заманнар—безнен халык китапларны күмәргә дә мәҗбүр ителде. Яндырылудан саклап калганнарын. Иманлы тормышка өмет өзгәч, кояш астында рәнҗетелгәнче, ичмасам, укымышлы затларның җәсәде белән изге туфракка инсен дип, үз акыллары белән дә күмделәр аларны...

Безгә, минемчә, Китапларны, Чын Китапларны саклау, үстерү, аларны яңа буыннар рухына сеңдерү юнәлешендә кардиналь чаралар кирәк. Дәүләти максат һәм стратегик планнар белән.

Беренчесе, һичшиксез, булган бөек мирасны (шөкер, ул бар! булмаса, нишләр идек!) жыеп-туплап, бастырып, һәрдаим халыкка житкерү, ирештерү, аңына сеңдерү. Бу җәһәттән, ассызыклап үтик, байтак эшләр эшләнә дә. Тел, әдәбият, тарих институты (хәзерге—Тел, әдәбият, сәнгать институты), Татарстан китап нәшрияты, соңгы ун елларда барлыкка килгән «Мәгариф» нәшрияты, «Мирас» журналы... Халыкка ирештерелгән уникаль басмалар... Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, «Идегәй» дастаны, Мөхәммәдъяр поэмалары, Утыз Имәни, Кандалый әсәрләре...

Икенчесе—дин нигезләрен ныгытуга, әхлакый тәрбиягә ярдәм итә алырлык югары кимәлдәге әсәрләрне, икенче төрле әйткәндә, иманлы әдәбиятка өстенлек бирү. Бу—җәмгыятьне савыктыруның бер юлыдыр. Бездә хәзер төрле-төрле басмаханәләрдә дини әдәбият шактый күп басыла. Тик аларның төп өлеше әлегә кустарь дәрәҗәдә. Рәшидә абыстай (Р. Исхакова) чыгарган китап-брошюралар үз вакыты өчен ярап та куядыр, алар да кемнәргәдер кирәктер. Әмма... Дин тәгълиматы ягыннан да, художество-нәфислеге ягыннан да Мәржани, Риза Фәхретдин, Муса Бигиев, Галимжан Баруди хәзрәтләренең хезмәтләре югарылыгына, һай, ерак әле бүгенге дин хадимнәренә!

Күңелдә иман булмаса—
мәчет ни дә, азан ни!
Җәһаләт белән сәрхүшлек
безне әле озак җәзалар...

Өченчедән, борын-борыннан безнең халыкның Китапны изге дип санавын истә тотып, традицион мәгънәдәге әдәби әсәрләрнең сыйфаты камил булырга тиешлеген онытмаска тиешбез. Бу—безгә, һөнәре итеп әдәбиятны сайлаган профессиональ язучыларга карый. Язучы исемен, кесәсендә шуның шаһәдәтнамәсен йөрткән күпме каләм ияләренең күпме чүп-чар «әсәрләре» дөнья күрә! Үзебездән дә ояла белик! Таләпчәнлек житми. Әзме-күпме ижади процесска йогынты ясый алырлык ижат оешмаларының, остаханәләрнең, әдәбият-сәнгать өчен җаваплы дәүләт хадимнәренең таләпчәнлеге житми. Тумыштан килгән сәләт-талант бер нәрсә, ә осталык—икенче нәрсә, аңа ирешер өчен гомер кирәк, үзеңне аямау кирәк. Дөресен әйтик, чын мәгънәсендә туган телнең нечкәлекләрен белгәннәр дә сирәкләнеп бара... Төптәнрәк уйласаң, безнең Китапның башында—дөнья цивилизациясенең җәүһәре, иң мөкәммәл китап Коръән тора. Шуны онытмаска иде!

Ярый, фәлсәфәбезне кыскартып, жиргә төшик, бүгенге яшәешебез хәлләренә, бүгенге реаль вәзгыятькә килик. Менә яна ел башланды. Газеталар,

журналлар, язылган әбүнәчеләр саны буенча яңа тиражлар белән басылып чыга башлады. Яңа дигәч, гадәттә, күбрәк, мулрак итеп күрәсе килә дә бит!—ни хәл итмәк кирәк,—татар матбугатын быелга алдыручылар ишәймәде. Димәк, милли үзанны үстерүче бер фактор кимеде. Димәк, үзбилгеләнүгә, дәүләтчелеккә, бәйсезлеккә (Декларация кабул ителүнең 10 еллыгында!) яңа адым атланмады. Хакыйкать: татар телендә чыгучы басмалар, асылда, милли идеяне халыкка сеңдерүче басмалар бит алар. Матбугатка язылуның сайлаулар компаниясе вакытына туры килүе дә безнең өчен зыянга гына булды. Депутатлыкка үтү өчен берсен-берсе этеп-таптап, саташыр дәрәҗәгә житкән кандидатларның (ә аларның абсолют күпчелеге—эш башында торучылар) үз марафоны. Күбесенә китабың ни дә, журналың ни!.. Сүз дә юк, китап алдыру, көндәлек матбугатка язылу матди житешлеккә бәйле. Парадокс: җәмгыятьтә акча күп тә, акча юк та! Галәмәт күп баскычлы, күп пирамидалы идарә структура кешеләренә акча бар һәм мул бар, гади игенчегә—юк; хоккей, машина куу ярышлары өчен акча бар, милли университет ачарга, классикларның күптомлык китапларын чыгарырга—юк; башкаладан килгән ярымшәрә, ярымнаркоман поп-«йолдыз-лар»га астрономик суммалар бирер өчен акча бар, ә өлкән бер хөрмәтле (!?) язучыга каләмхак түләргә—юк... Бәлки, кәгазьгә кытлыктыр? Кәгаз чыганагы—шау урманнар кырылып киселә бара... Алай дисәң, дөнья кәгазь белән тулган. Шәһәр жирләрендәге почта әрҗәләрендә дыңгычлап тутырылган реклама газеталары... Тик татарчалары гына юк. Хәер, сайлау өндәмәләрендә андыйлары да очрый... Безнең матбугатны укучылар, шул исәптән «Казан утлары»н да, байлар, финанс магнатлары, елгыр малтабарлар (ярый ла бертуган Кашаповлар кебек керемнәренең бер өлешен, әйтик зәкать өлешен, халык өчен кирәк китаплар чыгаручылар булса!), бар вөҗүдләре һәм гамәлләрен фәкать өстәге идарәчегә яки идарәчеләргә карап эш йөртүче марионет жирле түрәләр түгел, ә тормышларын очын-очка ялгап баручы гап-гади кешеләр—игенчеләр, авыл интеллигенциясе, пенсионерлар, укытучылар, студентлар... Алар, чыннан да, бүген ярлы катлам. Бик теләгәндә дә, язылa алсалар, бер яки ике газета-журналга язылалар. Бу очракта, жирле хакимият башлыкларыннан күп нәрсә тора. Халыкка, төрле юлларын табып (алдынгыларны бүләкләү, пенсионерларга бушлай яздыру, авыл мәктәпләренә, китапханәләргә шефлык итү һ. б.), рух хәзинәсен илтә алу саваплы да, мәгънәле дә булыр иде, хезмәт кешесенең күңелен яулау да булыр иде! Хаким кеше хәким дә булса икән! Тормышыбызда андый тәңгәллек мисаллары да бар: быел җәй Президент М. Шәймиевнең республика китапханәләренә яңа китаплар кайтару өчен 2 млн. сум акча бирдерүе—җәмәгатьчелек рухын савыктырып җибәрде. Дөрес, Президентның мөмкинлекләре гаять зур. Әмма төбәкләр жирлегендә район башлыкларының да дәрман-хокуклары шактый... Сүз уңаеннан, шуны да әйтеп узыйк: район башлыкларының туксан процентлабы Казанның авыл хуҗалыгы һәм ветеринария институтларында (хәзергечә әйтсәк, академияләрдә) укып чыккан кешеләр. Күп нәрсә аларның интеллектуаль әзерлекләренә бәйле. Шулай булгач, бу югары уку йортларында тиешле гумманитар белем бирү дә көнүзәк мәсьәләләрнең берсе булып кала.

Китап гасыры үтеп бара дидек. Гасыры үтсә дә, Китап дигәннәре бездән кул болгап тиз генә үтмәс әле, боерган булса... Ел ахырында гына татар халкының рухи тормышында бер тарихи вакыйга булды: ниһаять, күп буыннар хыялланган «Татар энциклопедик сүзлеге» дөнья күрде. Олы казаныш. Әйтүләренчә, алдагы елларда биш томда энциклопедик басма чыгачак. Күпме генә зарлансак та, олуг әдипләрнең (мәрхүмнәрнең дә, исәннәрнең дә) күптомлыклары чыгып тора. Соңгы елларда татар тарихына караган, объектив мәгълүматларга бай булган саллы-саллы фәнни китаплар халыкка иреште. Сәләтле яшь (чын мәгънәсендә яшь!) талантларның китаплары чыккалап тора. Милли мәгариф системасының тернәкләнеп килүенең бер мисалы бу. Киләчәккә өмет-ышаныч бар. Гасырлар буе тупланган генетик аңга, халык акылын һәм хакимнәрнең егәр-куәтен кушып, бергә-бергә иҗтиһат иткәндә, киләсе гасырда да Китап безнең гомерлек юлдашыбыз булыр, шәт. Амин!

# ШИГЪРИЯТ



## Гамил Афзал

### ҮЗ КАДЕРЕН БЕЛГӘН ЮЛЧЫ

#### Кыйблам

Усал диләр мине, шулай микән,
Усаллыгым да юк, акчам да...
Йөрәк өшеп, җан чымырдап китә
Кырмыскага ялгыш бассам да.

Табигать җәүһәре—канатлы җан
Очарга омтылды, ыргылды:
Күгәрчен баласын песи тоткан—
Көн буена кәефем кырылды.

Кешегә ышанмый бүре баласы,
Бүреккә салсаң да, урманга карый.
Ә менә безгә алга барасы,
Иманлы булалсаң—шул ярый!

Хозурланып болыннарда йөрдем:
Урман буйларында сукмагым,
Һәр куакны, һәр чәчәкне сөйдем,
Эткә дә, атка да сукмадым.

Алга чыгып, күкрәк кагып тормыйм,
Күләгәдә торам, ышыкта.
Намусымны уңга-сулга бормыйм,
Дәҗҗал белән Иблис кушып та!

## Күңел кошы

Шәп шомарган сәясәтче үзен сөяр,
Мәрхүмнәрнең каберенә тирес өяр,
Халык өчен тырышырга кирәк, дияр,
Һәм үзенең арбасына мөлкәт төяр.

Коммунизм төзибез дип йөз ел баргач,
Алдануыңны тоясың чәч агаргач,
Ата-бабалар да үткән шушы юлдан:
«Агыйделнең аръягында кара урман»...

Өмет белән киләчәккә барасың да,
Килеп җитә кар-буранлы гомер кышы.
Төтен иснәп, тимер-бетон арасында,
Талпынадыр, тилмерәдер күңел кошы.

Шатлык белән дөнья куып йөрмәдеңме?
Кайгы белән дус-ишләрне җирләдеңме?
...Үзең белән мәңгелеккә алып китмә
Үзең генә белгән алтын серләреңне!

## Сүрән генә көлү

Яшь гомернең алсу хыяллары
Тоныкланды... акча җитмәү белән.
Төтен исле, шыксыз урамнары...—
Яме китте, талау, көчләү белән.

Нинди юлдан кая барабыз без,
Бу—бәхеткә илткән юл микән?
Елап җавап бирә яңгырлы көз:
«Син исән бит әле, шул җиткән».

Ата-баба яшәп үткән эзләр,
Үзебезчә матур яз-көзләр,
Әрем сабагы да—туган кебек,
Сүрән генә көлә бу күзләр.

Басуларда таныш җилләр исә,
Күк болытлар белән сөйләшеп.
Бер кайгысыз каен гына үсә,
Тирә-якка ямьнәр өләшеп.

*

Кемнәр биек мөнбәр биләгән дә,
Кемнәр күктән йолдыз чүпләгән,
Елый-елый кемнәр килмәгән дә,
Янып-көеп кемнәр китмәгән.

Гомер-бакый күктә йолдыз янган,
Матур хыял булып колларга,

Бер шагыйрьнең матур җыры калган
Тугры юлдаш булып юлларда.

Аждаһаны батыр егет җиңә,
Һәр әкияттә батыр егет бар.
Күрә торып харап булдык димә,
Батыр егет барда өмет бар.

Үзен-үзе саткан имансыз кол
Арасыннан шундый кол чыга...
Үз җанында гына иманлы юл—
Үз кадерен белгән юлчыга!

## Империя түрәсенә

Бүлгәлә дә, хакимлек ит, тиран,
Кемгә—камчы, кемгә прәннек күрсәт,
Холуйларга елмаерга тырыш,
Зыялылар йөрсен хәер эстәп.

Бүлгәлә дә, хакимлек ит, түрә,
«Оҗмах капкалары»н ачалмадың...
Җиңүче—хак: чөнки, үзеңә күрә
Елмаешып тора вассалларың...

## Акыл җыйдык

Безнең яшьлек әрәм үтте, дисең,
Чираттан-чиратка чайкалып,
План-фәлән куып иртә-кичен,
Йөгергәләп йөрде бар халык.

Ә план ул бер дә тулмый икән,
Без—йөк аты гына булганбыз,
Ярты гомер бәхет өмет иткән,
Яшел яфрак ярган урман без.

Кысыла-кысыла, тар кысага сыйдык,
Түбәнсенеп намус елады.
Миллион корбан биреп, акыл җыйдык:
Безнең гомер бушка узмады.

Ил алдында үлүе дә җиңел—
Шулаен ул, бәлки, шулайдыр,
Һәр көнеңдә яңа үргә менеп,
Йөзгә чаклы яшәү кулайдыр.

Биек таулар, чүлләр кичәрсең син,
Ярга ятып сулар эчәрсең,
Яңа заманнарны төзеп, бизәп,
Матур булып искә төшәрсең...

*

Тыныч еллар, имин чорлар килер-килмәс,
Олуг хаким менбәренә менер-менмәс,
Үткән дәвер даһиларын буржуаз, дип,
Яңа гыйлем өйрәттеләр белер-белмәс.

Даһиларга горур башны ияр-имәс,
Череп беткән Европадан көләр-көлмәс,
Һәр тишектән, һәр ярыктан дошман эзләп,
Юлсыз-нисез алга бардык иләс-миләс.

Алдынгылар бүләк алган, медаль алган,
Тырыш икән, өлгер икән, алсын әйдә.
Безгә дә бер тыйнак кына өлеш калган:
Шөкер дибез шикәр белән ипи-чәйгә!

Дөнья йөзен агартам дип, чабып йөреп,
Даһилар да ач-ялангач гүргә кергән.
...Тагын берәр сылтау табып, дошман күреп,
Явыз язмыш аермасын туган җирдән!

## Күңел эзләнә

Ярлының ярмасы булса,
Салырга савыты булмый.
...Язарлык фикерең булса,
Язарга вакытың булмый.

Яхшы гына яздың кебек,—
Күңел канәгатьлек тоймый.
Шәп шагыйрьләр булган элек,
Бездә—нидер җитми... булмый!

*

Кайчан көләч, кайчан иләс-миләс
Нидер телә, нидер теләмә,—
Ни эзләгәнеңне белер-белмәс,
Гомер буе күңел эзләнә.

Уйланасың ялгыз иртә-кичен,
Менә түрең, әнә бусага.
Сокланырлык булсын герой-кешең,—
Дус булса да, дошман булса да!

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



## Вахит Имамов

# УТЛЫ ДАЛА

ТАРИХИ РОМАН

### Беренче бәйләм

1

Суздаль урамнарын көтелмәгән һәм хәвефле тояк тавышлары уятты. Кала капкасының сакчылары каравыл йортында изрәп йоклый, борын астын аксыл төк каплаган бер яшүсмер генә калканына таянып баскан көенчә имән дивар өстендә уяу тора иде. Киев каласы ягыннан җан-фәрманга куып килгән җайдакны күрүгә үк, ул каравыл йортының карындык тарткан тәрәзәсенә иелеп, сөрән салды:

—Петро, уян! Киев юлыннан ут капкан шикелле бер җайдак килә. Юрий кенәз юллаган чапкын булмагае.

Беренче булып биек дивар янына кышкы салкыннан аты ап-ак бәскә капланган җайдак килеп җитте һәм, ияреннән төшеп тә тормыйча, имән капканы сөнге сабы белән төя башлады.

—Мондагы торгакларны җир йотканмыни сон, эт еккыры? Ачыгыз капканы, тизрәк ачыгыз, дим!

Алтмыш яшьләрдәге, чал сакаллы Петро билен тота-тота өстерәлеп кенә өйдән чыкты. Әүвәл мунчадагы төнлек юлы сыман кечкенә капкачны ачып, җайдакка күз төшерде, шуннан соң гына, чыелдатып, тимер эшермәләрне шудырды. Үзе һич тә исе китмәгәндәй сөйләнүен белде:

—Үзенне шәрә хатын көтеп тилмерми торгандыр бит әле, кая ашыгасың?

Капкада ат сыярлык ара ачылуга, җайдак эчкә узды. Кыяфәте ярсу да, бик вәкарьле дә иде.

—Кенәз чапкыны мин!—дип, ул йөзенә әүвәл эре төсмер чыгарды. Ләкин чал сакаллы, өтек гәүдәле каравылбашны күргәч, андагы эрелек

---

Вахит ИМАМОВ (1954)—*Прозаик. «Нәзер», «Сәет батыр», «Татарлар Пугачев явында» һ. б. китаплар авторы, Гаяз Исхакый исемендәге премия лауреаты. Чаллыда яши.*

кимсеткеч һәм мәсхәрәле карашка алмашынды.

—Син картлач та шәрә хатын турында сөйләгән буласың бит, телеңне корт чаккыры!

Һавада усал булып чыелдаган камчы икенче мизгелдә каравылбаш Петроның маңгаен һәм йөзен ярып үтте. Картлач авыр ыңгырашып, җиргә сыгылып төште. Тәкәббер, кансыз җайдак, артына әйләнеп тә карамыйча һәм чаптар тоягы астыннан кар чәчрәтеп, урыныннан алга ыргылды.

Кенәз сарае янында аны озын көбә, тимер очлымнарга төренгән дүрт ир каршылады. Болар кенәзнең шәхси алаеннан, тамак ертып кына аларның өнен алу мөмкин түгел иде. Җайдак тыенкы сөйләште.

—Юрий кенәздән. Угылы Андрей янына. Ашыгыч фәрман белән.

Кала өстендәге зәңгәрсу эңгер-меңгер әле таралмаган, шулай да Клязьма елгасы ягында офык алсулана башлаган иде инде. Кораллы ирләрнең берсе—күрәсең, унбашыдыр—шул якка ым какты.

—Таңга ерак түгел. Көтсәң ярамыймы?

—Юрий кенәз шәхсән үзе юллады. Һәр минут—баш бәясе, ашыгырга кушты.

—Һе, кем башы хакында сүз бара бит. Синең яки минем баш икән, кенәз төкереп бирә.

Унбашы бу сүзләрне пышылдап диярлек дәште, аннан гына сарай ягына борылды.

—Әйдә, керик. Аларның кул кыска, талканнары коры. Андыймондый бәла була калса, баштан сыйпамаслар.

Андрей кенәзнең йокы бүлмәсе янында, ишекне аркылы бүлеп, бер ир ята иде. Келәм буйлап сак кына атлаган аяк тавышлары җитә калды, эт шикелле ыргылып, җансакчы шундук аягына басты. Куллары «ә» дигәнче кылыч сабына ятты, күзләре бөтен коридорны энә күзеннән кичергәндәй капылт айкап чыкты.

—Бу мин әле, Прокопий,—дип, унбашы телгә килде. Юрий кенәз ашыгыч фәрман юллаган. Менә бу чапкынга Андрей кенәз кирәк. Бар, кер, уят.

Прокопий сынаулы караш белән янә бер мәртәбә чапкынны капшап алды. Шуннан соң гына ишеккә борылды, әмма кулын тотка сабына салып өлгермәде. Капылт ишек ачылды һәм тупсада Андрей кенәз үзе пәйда булды. Ул озын, ак күлмәктән, инбашына кызгылт төстәге юка кафтан элгән, әмма шундый киң киемнәр дә кенәзнең мәһабәтлеген һәм гаярьлеген каплый алмый иде. Чапкын аңа текәлде дә катты. «Курку белмәс, кушйөрәкле кенәз. Аның куллары тимер герләр сыман. Кылыч белән бер селтәнүдә теләсә кайсы атның муенын чабып өзә. Үзе гади, гадел. Яу чапканда укчылары белән бер казаннан ашый»,—дип юкка гына сөйләмәгәннәр. Менә нинди баһадир гәүдәле икәнсең син, кенәз!»

Чапкынның уйларын Андрей кенәз бүлде.

—Мин тояк тавышларын ишеткәч тә уянган идем инде. Суздаль җиренә нинди фәрман китерден? Сөйлә, чапкын.

Кырт борылып, унбашы юкка чыкты. Чапкын әле кенәзгә, әле аның җансакчысына төбәлеп, сүз әйтә алмыйча торды. Кырыслана төшкән тавыш белән Андрей әмерен янә кабатлады.

—Нинди фәрман китердең? Мин сөйләргә куштым.

Чапкын ашыга-кабалана тезә башлады.

—Юрий кенәз дружинасы белән Остер каласында тора. Ул бәйнәбәйнә тапшырырга әмерләде. Энекәше Владимир алып килгән венгр полкларын олуг кенәз Изяслав янә өйләренә кайтарып җибәргән. Аның каравы, Вышегород каласыннан сезнең абзыегыз Вячеславны чакырып китергән дә, Изяслав аңа: «Минем икенче атам бул, Киев белән икәү идарә итик»,—дип ялварган. Бер-берсенә ата һәм ул булырга антлар эчеп, алар София соборында тәре үпкәннәр. Мәгәр Изяславның эче тулы кара уй, яз җитүгә үк ул венгрларны кабат чакырачак та сезнең

нәселгә һәм Галич кенәзенә каршы яу чыгачак икән.

Андрей түзеп тора алмыйча, сүз кыстырды:

—Әткәй аннан алдарак кузгалырга жыена инде, димәк. Мәгәр бу юлы үз ягына ул кемнәрне аудармакчы була?

—Юрий кенәз, беренче эш итеп, кыпчак ханы Бәнәк белән сүз беркетеп куйды. Бәнәк үзенен углы Сөенечне жибәрәчәк. Хак булса, шул Сөенеч «Киевнен Алтын капкасын кылыч белән чабып өзәм», дип шапырынган икән.

Андрей шаркылдап көлүдән көчкә тыелып калды, әмма, барыбер, ирен читләре буйлап таралган мәсхәрәле елмаюын яшерә алмады. Чапкын, үзенең артыграк сөйләнә башлавын анлады күрәсен, кырысланды.

—Чернигов кенәзләре үзара яман бозылышкан. Өлкәннәре, Изяслав Давид углы, олуг кенәзнен ярлыкавына өмет баглап, Киевкә качып киткән. Анын энекәше Владимир үз гаскәре белән инде күптән әтиеӊ янында тора. Юрий кенәз тагын Олег углы Святослав һәм анын туганнан-туган энесе белән дә бәйләнешкә керде. Алар да боз ташудан сон елгалар ачылуга ук Юрий кенәз кул астына килергә ант эчкәннәр.

—Әткәй минем үземә шәхсән ни боерды?

—Әле язгы ташу башланганчы ук Юрий кенәз сине үз янына көтә.—Чапкын тирән итеп тын алганнан сон гына өстәде.—Биш мен, алай ук булмаса, ким дигәндә өч мен жайдак белән.

Андрейнын йөзендә бер кыл да селкенмәде, кыяфәте таш сын шикелле үзгәрешсез калды. Чапкын башын иеп чыгып киткәч кенә, ул Прокопийга таба борылды һәм авыр сулап дәште:

—Менә, тагын яу көтә безне, Прокопий туганкаем. Тагын күпме ана улын югалтачак, күпме сабый ятим калачак. Син әйтмешли, ул Ходай каргаган Киев тәхете өчен кан коюлар кайчан тукталыр сон? Ата—улына, энесе абзыйсына каршы кылыч күтәреп бертуктамый жан кыя торган, акылларын көя кискән нинди халык сон без? Бу коточкыч һәлакәттән котылу өчен нишләргә сон безгә, нишләргә?!

Ир уртасы булып житлеккән һәм шушы көнгә кадәр әтисенен кул астында йөреп, үзенә туену өчен аерым бер биләмәгә дә хужа булуга ирешмәгән бу кенәзне әлеге сорауларнын күптән газаплавын яхшы белсә дә, Прокопий эндәшмәде. Анын анык билгеләгән үз мәсләге бар, ләкин Андрейны да шуна индерү өчен кенәз йөрәгендәге әче чүпрәнен тулып ташуын көтә һәм хәтта аны әле кыздыра белергә дә кирәк иде.

## 2

Соңгы көннәрдә Андрейнын кәефе кияү мунчасыннан парланып чыккан яшь ирнеке сыман дәртле, күтәренке иде. Аллага шөкер, менә яз да житте. Газаплы кыш айлары нык туйдырган иде. Юрий балалары һәммәсе дә аны, аю сыман, өннәренә бикләнеп үткәрделәр. Әтиләре генә, бер-ике мәртәбә ауга дәшеп, арадагы бозны эретмәкче булды. Сәбәп тапкан булып Андрей бармый калды. Ә сәбәбе чыннан да бар иде бит. Йә, Хода! Кавышуларына биш ел үткәннән сон, ниһаять, хатыны Байгөл генә түгел, хәтта кайнешләре дә Андрей белән бер өстәл артына утыра, гәпләшә башладылар. Өлкәннәре Яким бик еш кына кенәздән кинәш сораштырды. Аларнын эшләре барсын дип, Андрей тауар яки алтын тәкъдим итсә, Байгөл туганнары беренче тапкыр анын ярдәменнән баш тартмады. Дөрес, тиешле керемне алар һәр очракта Андрейга гадел рәвештә кайтарып бирә торган булды. Әмма биш ел буе ике арада яткан упкын өстендә күпер хасил булу Андрей өчен барыбер дә олы жиӊү иде.

... Андрей коточкыч кан өстендә туй үткәрде. Моңа һаман да шул әтисе гаепле иде. Илле бишенче елда[1] Суздаль жиренә Изяслав яклы Рязань кенәзе Ростислав бәреп кергәч, Юрий кенәз, бер йөз кешелек

дружина таләп итеп, Мәскәү елгасы буенда утырган Кучкәй бистәсенә дә чапкын куды. Чапкын канга батып, кыйналып кайтып керде. Анысына төкерәсе, әмма Кучкәй юллаган җавап Юрий кенәзнең үтен сытарлык дәрәҗәдә мәсхәрәле булып янгырый иде:

—Мин Болгар ханының бәге. Ә бер ук дәрәҗәдәге Юрий, угыр, нишләп әле миңа йөгән киермәк була? Моннан егерме жиде ел элек Болгар мәмләкәтенә борынын тыккач, без аның койрыгын өткән идек бит инде. Шуннан бирле тычкан сыман тын да чыгармыйча яши, Болгар ягына борылып караудан да өне алына иде. Әллә Юрий, угыр, алган сабагын оныта башлаганмы?

Кучкәй Юрий кенәзнең егерме сигезенче елгы[2] походына ишарәли иде. Әйе, болгарлар, кунакка чакырып, кыпчак ханы Әюпне агулагач, Юрий алар жиренә яу белән басып керде. Ул—Әюп хан кияве, әмма бабасының үлеме өчен үч алу бары сәбәп кенә, ә асылда аның исәбе Болгар җирен талап кайту иде. Юрий улчак үзенә ярдәмгә Ростов кенәзе Глебны да дәште. Икесенә ун меңлек гаскәр туплап, алар егермешәр ишкәкле зур-зур каекларда Клязьма буйлап Укага төштеләр. Әлеге елга борын-борынгыдан бирле рус җире белән Болгар иле арасындагы аергыч чик булып исәпләнә иде. Ләкин моннан нәкъ йөз ел элек Болгар ханы Ибраһим Мөхәммәт углы Уканың Иделгә коя торган тамагына килеп, текә, биек Тукрантау өстенә имән койма, сулы чокыр, ташлы ур, бүрәнә чөйләр белән ныгытылган усал кальга төзеткән. Чикләре болай да җәя тәтесенә охшап торган Болгар дәүләтенең әлеге шәһәре менә инде йөз ел буе рус кенәзләрен шул тәте өстенә корылган ук шикелле гел өркетеп торды. Рус кенәзләре, кыюланып китеп, Болгар дәүләтенең чиге аша үтсә, «җәягә корылган ук» шул мәлдә үк хәрәкәткә килеп, әле Рязань, әле Муром яки Суздаль жирләренә ярып керде. Утыз ел элек болгарлар Муром каласын яулап, хәтта аны дүрт-биш ел буе үз кулларында да тоттылар. Кыскасы, Ука тамагына корып куйган кальга руслар өчен һәрчак табан астына кадаган энә сыман булды, гел онытгырмыйча, сызландырып торды. Болгарлар үзләре бу кальганы әле «Ибраһим кирмәне», әле «Калачык» дип йөртә башладылар. Алар ничек кенә дип атамасын, әмма бу кальганы кулга төшерү һәр рус кенәзен дан-шөһрәткә илтә торган олы баскыч иде.

Руслар бәхетенә, әлеге ук-кальгада болгарлар аларны һич көтмәгән булып чыкты. Аны рус гаскәре беренче һөҗүмнән соң ук яулады. Нигездә рус шәһәрләре белән алыш-биреш итүче сәүдәгәрләр яши торган кальганы тәүлек буе талап, аннан җыелган байлыкны Суздалга озаттылар да, үзләре Идел буйлап түбән юнәлделәр.

Болгар ханы Сәгыйть бу вакытта башкорт даласы аша һөҗүм белән килгән кара-аймыкларга каршы яу алып бара иде. Рус гаскәрләренә каршы чыгарга ул өлгерми калды. Шуннан файдаланып, Юрий белән Глеб Чулман тамагына каршы ярда утырган Ашлы каласын да иркенләп таладылар. Алтын-көмеш, ганимәт, коллар белән тулган каеклар янә Суздальга юл алды.

Яусыз җиңүләр белән һаваланган кенәзләр инде пайтәхетне—Болгар каласын эләктермәкче булды. Ләкин Чулман елгасы тамагының сулъяк ярында, Ага-Базар инкүлегендә, аларны инде Сәгыйть ханның хисапсыз җайдаклар гаскәре каршы алды. Өшәнеп калган Юрийның кенәзе Глеб дуамал булып чыкты—барча сугышчыларына һөҗүмгә ташланырга әмер бирде. Ростовлылар каеклардан төшеп беткәч кенә, болгарларның хәйләсе ачылды. Чулманның уң ягында тар, тиз йөрешле йөзләгән көймәләр пәйда булды. Алар Сәгыйть хан янына ярдәмгә ашыгучы Кашан бәге Шәмгуннын укчылары иде. Беркадәр вакыттан соң кашанлылар Юрийның каекларын урап алды, Сәгыйть җайдаклары Ростов дружинасын туракльй

[1]6655, ягъни милади белән 1147 ел.
[2]1120 ел.

башлады. Калкандай ныклы һәм биек диварлы каеклардагы суздальлылар әүвәл бик гайрәтле каршы тордылар. Ул арада кашанлыларның бер төркеме Глебның саксыз калдырылган дистәләгән каекларын эләктереп юкка чыкты. Ә бермәлне инде яу кырын ташлап качкан ростовлылар Суздаль каекларына ургыла башлады. Үзара талаш, изеш купты. Әллә ничә каек капланды. Ул да түгел, болгарлылар каеклар өстенә очына ут элгән ук яңгыры коя башлады. Елга өстен зәһәр төтен каплады, янгын купты. Рус гаскәренең нәкъ яртысы гына качып котыла алды. Болгарларның кулына әсирлеккә төшүчеләр генә дә меннән арткан иде. Рус жирендә корбаннар өчен кайгыру гел булмады. Калачык, Ашлы шәһәрләреннән таланган байлык һәммәсенең күзен каплады. Юрий белән Глебның Болгарга ясаган явын мәртәбә дип кабул иттеләр. Әмма шуннан бирле Юрий кенәз Болгар юлын гомергә онытты. Ә менә Кучкәй бәк хәзер аның шул хурлыклы походын искә төшереп, Суздаль кенәзен ачыктан-ачык мәсхәрәли иде.

Моннан унбиш еллар элек энеләре, кардәшләре белән Болгар иленнән килгән бу кешене Юрий кенәз Суздаль жиренә үзе кертте. Аның хакында сонрак «ул Болгарда нииндидер тарханны әллә үтереп, әллә бөлдереп качкан», дип тә, «Болгар ханы рус жиренә махсус жибәргән шымчы», дип тә сөйләделәр. Юрий кенәз имеш-мимешләргә төкереп бирде. Килмешәкләр бу вакытта Мәскәү елгасы ярына барып бистә корган һәм, иң мөһиме, рус халкы күптән күрергә тилмергән сәхтиян читекләр, Чин ефәге, ике төрәнле сабан, дегет, Шам кылычы, чуен казан кебек дистәләгән затлы тауар белән сату итүне жәелдереп жибәргән иде инде. Чын аты Мостафа булса да, үзе барып сәүдә иткән Суздаль, Владимир, Ростов, Муром боярлары ана һәрвакыт Степан дип эндәштеләр. Кесәсе калынаеп, абруе арткач, ул Иван углы Степанга әверелде. Бистәсенең генә исеме үзгәрмәде. Мәскәү елгасының йөзъяшәр нарат, каен, карагайлар белән уратылган зур аланлы ярын барча кеше, әлеге килмешәкләргә багышлап, «Кучкәй кыры, Кучкәй бистәсе» дип кенә атап йөртте.

Инде, менә, заманында Юрий аны кунак сыман кабул итеп ачык йөз белән каршылаган, үзенең куенында аңа иң затлы, иң аулак жирне бүлеп биргән килмешәк тә кенәз хәтле кенәзне—атаклы Мономахның улын мәсхәрәли. Моны башка боярлар да ишетеп алса, рус жирендә Суздаль хакименең сүзенә колак салучы да калмаячак. Бөгелмәгән агачны сындыралар. Тәкәббер, әрсез Кучкәй бистәсен тез чүктереп, ул бөтен рус жиренә сабак бирергә тиеш.

Шул рәвешчә фикер йөртте дә, кул астындагы бер мең жайдаклы дружинаны алып, Юрий кенәз Мәскәү ярына ябырылды. Кучкәйнекеләр аны көтми иде. Тимер көбәләргә төренгән бер мең жайдакның авылны камавын күрүгә үк өнсез калдылар. Авылда коралга ябышучы кеше табылмады. Кучкәй бәк алтын-көмеш биреп аның күзен капламакчы иде. «Бу байлык һәм авыл болай да минеке»,—дип, Юрий кенәз ихахайлап бер көлде дә, сугышчыларына борылып, ялгыз каен тарафына ияк какты. Кучкәй бәкне шундук каен ботагына асып куйдылар. Гәүдәсе һаман тартыша иде әле. Шулвакытны ачыргаланып, өзгәләнеп кычкырган әче, тетрәндергеч тавыш йөзьяшәр карагайларны сискәндереп узды:

—Әт-кә-әй! Ә-те-кә-ем, жа-ным!

Тавыш иясе әле унбиш-уналты яшьләрдәге генә бер кыз иде. Ялгыз каен төбенә йөгереп килеп, әтисенең аякларын кочкан мескен кызның газаплануларын күрмәс өчен барча ирләр йөзләрен түбән иде. Юрий кенәз мондый очракта да кансыз булып чыкты. Каен янына килде дә, камчы сабы белән иягенә төртеп, кызның йөзен үзенә күтәрде. Чык тамчысы кебек әле керләнмәгән, тулган ай шикелле тансык бер чибәр иде ул.

—Атың кем?—дип, Юрийның әрсезләнеп соравына каршы тора алмады. Авылны чолгап алган сугышчылардан бөркелгән дәһшәт, газиз

әтисенең үлеме, хәтта, мәрҗәнле, гәрәбәле япмага төренеп баскан кансыз кенәз кыяфәте дә бу самими, садә кызны һушсыз иткән иде. Ул, куркулы карашын кенәздән аермыйча, җавап бирергә мәҗбүр булды.

—Байгөл.

—Минем киленем булырсың,—диде ана кенәз. Аннары каенлыкка таба борылып сөрән салды.

—Андрей, бирегә кил!

Әйе, Андрей да әтисенең таләбе буенча походка барган иде. Шуның өчен бүгенгәчә үкенеп бетә алмый. Әмма ул чагында...

Андрей Юрий кенәзнең болгар сәүдәгәрләренә рәхим-шәфкать күрсәтмәячәген юлда вакытта ук аңлап барды. Кучкәй бәкне каен ботагына аскан чагында Андрейның керфеге дә селкенмәде, җаны да әрнемәде. Чөнки ул балачактан бирле инанып үсте: хаким кеше халыкка үзенең уч төбен күрсәтергә тиеш түгел! Дәүләтнең нигез ташларын кан белән беркетсәң, алар ныграк була. Кенәз өчен коллар—ком бөртеге. Рус җиренең бөтенлеге хакына ул коллар гомерен кызганмаска, үз ихтыярына каршы чыгучы һәркемне чүп үләне сыман йолкып атырга тиеш. Тиеш! Тиеш!

Әмма ул чагында әтисенең әмере буенча каен янына килде дә, Андрей тынсыз калды. Кара, озын толымлы, куе керфекле, сыгылмалы кашлы, тамчылы гөлдәй мөлдерәмә күзле, алсу йөзле бу садә кыз уч төбенә алган карлыгач баласы шикелле гаҗәеп сылу да, кызганыч та иде.

Андрей үзе дә унөч-ундүрт яшьләр чамасында әнисез калып үсте, ялгызлык газапларын нык татып өлгерде. Юрий кенәз җарияләр янында югалып йөргән чакта Андрейны бертуган абыйлары да «Кыпчак баласы! Кыргый кыпчак, кыпчак!»—дип яман мыскыл итте, тиуннар да байтак тәпәләде. Шуңа күрә Андрей үзалдына йомык егет кенә түгел, ә күп кешегә ачулы һәм үчле дә булып үсте...

—Хатыныңның үлеменнән бирле ничә ел буйдак булып йөргән иден. Менә сиңа кәләш. Әниең кыпчак иде, хатының болгар кызы булыр. Үкенмәссең, мөселман кызлары кайнар була алар. Әниең дә, әнә, оҗмахка күченгәнче ничә угыл табып өлгерде. Бу болгар хатыны синең ике ятимә кызыңа да ана булыр.

Юрий кенәзнең әлеге сүзләре Андрейдан бигрәк Байгөлне сискәндерде. Мономахныкылар искәрми дә калды, ә болгар кызының кулында җиң эченнән төшкән нәни генә хәнҗәр хасил булды.

—Мин үз-үземне суям, мәгәр әткәмне үтергән ерткычка килен булып төшмим!—диде ул нык итеп һәм хәнҗәр очын бугазына терәде.

Юрий кенәзнең йөзендә бер җепсел дә селкенмәде.

—Төшәрсең, күгәрченкәем, әле сөенечеңнән елап, ялына-ялвара төшәрсең.—Юрий читән буена тезелешеп баскан кучкәйлеләргә таба ияк какты.—Агай-энеләреңне, барча авылдашларыңны суеп чыкканны теләмисең лә син.

Капылт агарынган Байгөлнең хәнҗәре кулыннан төшеп китте. Бераздан ул инде йөзтүбән капланган көенә өзгәләнеп-ярсып җирне төя иде. Читән буендагы төркемнән аерылып, үзе шикелле үк үкси-үкси янына килеп тезләнгән бертуган сеңлесе Осланбикәнең иркәләп кочулары, үгетләүләре дә ярдәм итмәде. Байгөл соңрак, әтисе Кучкәй бәкне авылдашлары элмәктән төшергәч кенә, җир өстеннән купты...

Шул ук атнада Андрей белән Байгөлнең туе булды. Үзе белән сеңлесе Осланбикәне алып Байгөл калага, кенәз йортына күченде. Суздаль халкы өчен яшь бикә Василисага әверелде, Андрей өчен Байгөл булып калды. Ләкин әллә ничә атна буена ул кенәзгә үз бүлмәсенең келәсен ачмады, аш өстәле артында очрашканда бер дә елмаймады. Ятим калган кызның халәтен аңлый иде, Андрей түзде. Берзаманны Байгөлнең энеләре дә, Суздальга килгәч, кенәз җизнәләренең йортына кергәли башладылар. Ә беркөнне Байгөл тыелып кына аңа күз сирпеде. Кичен йокы бүлмәсенең ишеге дә, ниһаять ачык иде...

Андрей иртән айный алмый интекте. Сигез ел көтеп-көтеп тә

малай табып бирә белмәгән тәүге хатынын искә алып та тормады ул. Ләкин Андрей гөнаһсыз түгел, анын жарияләре бик күп булды. Әмма Байгөл кебек үк кайнар тәнлесе, жан жылымлысы очрамады ана. Шул бер төндә үк сихерләде ул аны...

Ә аннары инде Байгөл ана бер-бер артлы ике угыл табып бирде. Икенчесе шушы кышта туды. Андрей, әлбәттә, чиксез канәгать иде, Байгөл дә үзен бәхетле итеп тоя башлады бугай. Ул хәзер инде әтисенен үлемен дә искә алмый, ярсымый да иде. Сонгы көннәрдә ул гел күгәрчен сыман гөр-гөр килеп торды, кайнар кочагын һәм назын кызганмады. Ә бер танда, судагы балыкларга жим ташлаган шикелле генә әйтеп узды:

—Безнен еракта калган кардәшләр дә бик күп. Үз гомерендә бер тапкыр булса да туган иленне—Болгар жирен барып күрсән иде ул!

Хатынынын кинаясен Андрей, билгеле инде, бик тиз анлап алды. Нинди жавап бирергә икәнен анык белми иде, озак уйлап йөрде. Аптырагач, үз янына Прокопийны дәште. Ә тегесенен фикере искитмәле кыска да, мантыйклы да иде.

—Төнге күке барыбер үзенекен итә инде ул, кенәз. Болгар иленә бар син. Олуг кенәз буласы, ил тотасы кешегә чит дәүләт тормышын да белеп тору кыйммәт. Өстәвенә анда сабак алырдай, рус жиренә күчерердәй үрнәкләр дә күп булырга тиеш. Ул дәүләтне юкка гына Бөек Болгар иле дип йөртми торганнардыр. Тәвәккәллә, кенәз.

Андрей бераз гына вакыт икеләнеп торды да, шундук өзеп салды:

—Алайса, бар, каекларны әзерләргә фәрман житкер. Койрыгынны сыртына салып, куләгәдә калырга өметләнмә. Мин сине дә, Козьманы да үзем белән алам. Бер атнадан—юлга!

## Икенче бәйләм

### 1

Суздаль кенәзе улынын кунак сәяхәте турындагы хәбәр Болгар мәмләкәте буйлап инде Ука тамагындагы Калачык кальгасыннан ук чыгып киткән иде. Яраннарын алып, бүләк төяп, дүрт олы каекта барган Андрейны юлда тоткарлаучы булмады.

Байгөлнен туганнары Кашан каласында яши икән, шуна йөз тоттылар. Ләкин Чулман елгасы тамагына кергәч, Болгар каласы янында узасы бар иде. Елганың сул ярында калкып чыккан биек-бик йортларны һәм хисапсыз манараларны күргә үк Андрейнын ис-акылы китте. Болгар эссе мунчадан сон изүен ачып, тымызык кичтә тын алып утыручы мәгърур ир-ат сыман. Дөньяда дошман да бардыр, дип уйламый да бугай. Шәһәр елга ягыннан берниндн өстәмә дивар белән дә капланмаган. Әмма Чулман яклап анда һөжүм итү гомумән мөмкин түгел. Гажәеп текә һәм биек яр каланы ин куәтле дивардан да ышанычлырак саклый. Өстәвенә, нәкъ елгага каратып, болгарлар яр өстенә катлы-катлы йортлар, сөнге сыман үткен очларын күккә сузган түгәрәк манаралар төзегәннәр. Шул йортларны, манараларны каплап, елга ярына икешәр катлы имән диварлар килеп терәлә. Диварларнын Чулман ягындагы очларын үтә дә биек каланчалар саклый. Түбәсе бүрәнәләр белән капланган ул каланчалар өстендә әллә ничәшәр кизү әрле-бирле йөренә. Имән диварларнын азагын бөтенләй күреп тә булмый. Алар каядыр, дала ягына китеп югала. Диварлар каршына кин һәм тирән ерым казылган. Ерымнан алда кылыч йөзе кебек теп-текә ур һәм... тагын ерым... Анысы инде чөй сыман очлап һәм бер-берсеннән кул сузымы кадәр ара калдырып утыртылган имән бүрәнәләр белән шыгрым тулы. Ул чөй кагылган, су тутырылган ерымнар, кылычтай текә ур уртасында фәкать ике арба сыешлы гына ара калдырган. Ләкин әлеге юл да биек каланчалардан тимер чылбырлар белән асылган имән күперләргә барып төртелә.

Андрей шушы ныгытмаларның һәммәсен дикъкать белән барлап чыкты, бераздан исә тәненә боздай салкын җил үткәндәй булды, калтыранып куйды. «Йә, Ходаем!—дип әрнеп уйланды ул.—Нишләп рус җирендә мона тиң торырдай бер кальга да юк соң? һәм Юрий кенәз белән Глеб теге чакны нишләп шушындый кыядай кирмәнне алырга хыялланды икән? Әтисе тарафыннан коточкыч әтәчләнү һәм сукырлык бит бу. Мондый диварлар аша кош та очып керә алмый. Аны ук очырып, сөнге селтәп кенә яулау мөмкинмени?!»

Кенәз йөрәгендә янган утны Прокопий да тоя иде, ахры. Әмма аның көтелмәгән сүзләре шул ялкынга кисәү генә өстәгәндәй булды.

—Бу кальганың эчке төзелешен карап чыкканда да ярар иде. Мәгәр кала бәге рөхсәтеннән башка ана үтү мөмкин эш түгел, ахры.

—Нинди юл кала соң?

—Кашан бәгенә бүләкләрне мул бирмичә булмас. Ә ул, бәлки, үзе ачкыч табар...

Әтисе Юрий Озын-Кул ясаган һөҗүмнән соң пайтәхетнең дәүләт эченәрәк, тыныч төбәккә урнашкан Биләргә күчерелүен дә, Болгарның хәзер мәмләкәттәге гади, әмма изге шәһәр булып кына калуын да Андрей, әлбәттә, инде белә иде. Кала диварларыннан күзен алалмыйча ул һаман саен уйлануын белде.

«Дәүләт өчен шулай кирәк дип тапкач, менә, болгарлар пайтәхетне бер каладан икенчесенә күчергән дә куйган. Бернинди ызгыш-талаш та чыкмаган, һәммәсе килешкән, күнеккән. Ә рус җирендә дә шул ук эшне эшләү мөмкин түгелме соң? Әйтик, Киевны калдыру да, әткәй утырган Суздальны пайтәхет итеп күтәрү?..»

Андрей үзенең уйларыннан үзе куркып китте. «Уйларымны ялгыш кычкырып әйтмәдемме?»—дигән сыман итеп, әле Прокопий, әле каенэнекәшләренә таба карап алды. Әмма юлдашларының һәммәсе дә фәкать Болгар өстенә төбәлеп бара иде. Байгөл, Осланбикә, Яким карашыннан, әнә, ямансулау, монсулык бөркелеп тора.

«Болгарлар, менә, гади генә дип саналган калаларын да ничек ныгытканнар. Кирмән генә түгел, кыя бит бу! Гади калалары кыядай булгач, яна пайтәхеткә әверелгән Биләр кайда урнашкан да, анысы ниндирәк икән соң? Мантыйк буенча фикер йөрсәң, анысы бөтенләй якын да килә алмаслык тау булырга тиеш. Кызганыч, Андрейга ул пайтәхетне барып күрергә насыйп булмас инде. Ичмаса, шушы Болгарын булса да эчтән күреп, капшап китсәң иде!..»

Чулман өстендә аларга әле җилкәнле, әле ишкәкле зур-зур каеклар торган саен ешрак очрый башлады. Беришеләре капчык белән икмәк, икенчеләре күн йә тире төягән. Сирәк кенә булса да арада төргәк-төргәк итеп постау, ефәк, бәз төягән каеклар да очрап тора. Иң гаҗәбе—бер генә каекны да кораллы ир сакламый, хәрби кием элгән кеше бөтенләй юк.

Андрей, түзмичә, шул хакта өлкән каенэнесенә сүз каткан иде. Якимнең җавабы тәмам аптыратты.

—Бөек Болгар—игенчеләр һәм сәүдәгәрләр иле бит ул, җизни-кенәз. Монда сәүдәгәрләр кәрванын талау кебек хәлнең бөтенләй булганы юк. Хан житкергән кануннар бик коры. Вак-төяк малга кызыккан угрының кулын киссәләр, сәүдәгәрне талаган юлбасар шундук башсыз кала.

—Вәт, әкәмәт! Шул канун үтәләме?

—Байтак юл үттең, менәрләгән кешеләрне күрдең. Арада чулаклары күп очрадымы соң?

—Берне дә шәйләмәдем.

—Менә, илбашының сүзе үтәлүгә җавап шул буладыр инде, җизни-кенәз.

«Йә Хода, йә Хода!—дип, Андрей янә эчтән генә сызарга мәҗбүр булды.—Рус җирендә җансакчылар ияртмичә ауга да чыгып булмый. Ә сәүдә белән көн күрүче бояр һәрвакытта сакка аерым бер дружина яллап

йөри. Әле шул да житми. Юлбасарлар, ушкуйлар, ач холоплар күпме сәүдәгәр һәм боярның гомерен кыеп тора...»

Кашан каласына терәлеп торган яр буен эреле-ваклы, жилкәнле-ишкәкле дистәләгән каек һәм көймәләр сырып алган иде. Сәяхәтчеләр аларны беркадәр ары узып, кызыл ком каплаган ярга тукталдылар. Каектагылар ком өстенә агач басма салып та өлгермәде, алар янына ияр менгән биш-алты жайдак килеп житте. Арада берсе яшел, затлы чапан кигән. Ак чалма уртасында зиннәтле таш елкылдый. Аты да бик гаярь, гел уйнаклап тора. Башлап, шул сүз катты.

—Әссәләмүгаләйкүм, кунаклар! Кашан вилаятенә төкле аягын илә генә узарга насыйп әйләсә иде, мөхтәрәм Сүздәл бәге!

Кашанлыларның үзен алдан ук белеп каршы алуларына Андрей әлләни гажәпләнмәде. Әйе, ертауллары уяу йөргән, тәртип дигәннәре катгый куелган илдә шулай булырга тиеш. Хәтта, Андрей әле затлы киемдәге бу жайдакны күргәч, аны каршыларга Кашан бәге үзе килгән икән, дип тә һаваланган иде. Әмма өмете акланмады. Затлы кием иясе кала бәгенең наибе булып чыкты. Ияреннән төшеп һәм ике кулын сузып Андрей кенәзне сәламләүгә үк, ул колачын ачып Күчкәйнекеләргә каршы атлады.

—И-и, карендәшләр! Сезләр илә Болгар тупрагында очрашырга да насыйп булыр икән. Күчкәй-борадәрнең аяныч вафаты хакында күптән хәбәрдармыз. Авыр тупрагы жинел булсын. Ә сез туган вилаятегезгә рәхим кылыгыз... Саумы, Байгөл бикә! Әссәламегаләйкем, Хәким-борадәр! Йә, Раббем! Әллә монысы Осланбикәме? И-и, син дә нинди сылу карлыгач булып үсеп житкәнсен бит, сенелем!

Яр буенда беркадәр ыгы-зыгы, елашу-сыкташу булып алды. Якимкайнеше тезләнеп, кызыл комны үпте. Аннары ирләр каршына көмешләнгән ияр, бәрхет жәймә ябылган атлар китерделәр. Байгөл белән Осланбикә өчен биек аркалы, жинел арбалы жигүле ат әзерләнгән иде. Нарасые Мстиславны алып, Байгөл шуна утырды. Ә өлкән улы Изяслав әле дүртенче яше белән генә барса да, арбага утыртулары белән килешмәде. Күз ачып йомганчы үрәчәдән шуышып төште дә, әтисе янына йөгерде. «Бу да ир-ат, имеш! Вәт, тәкәббер!»—дип, масаеп көлә-көлә, Андрей аны тезләренә алды.

Кашанлыларга бик сиздерергә теләмәсә дә, Андрейның күзләре юл буе гел ялт-йолт килеп барды. Әйе, бу кала да имән диварлар белән уратылган. Ике якта капка, янында манаралар. Урамнары кин, таш түшәлгән. Һичнинди чүп әсәре күренми, зәһәр ис сизелми. Чисталык, пөхтәлек буенча кая инде ул боларга якын килү? Мәнге буласы юк... Йортлары таза. Кайсылары зур-зур яссы ташлардан, кайсылары нарат бүрәнәдән салынган. Гажәп, боларда һәрбер ихатаны, һәрбер йортны икенчесеннән биек коймалар аерып тора. Димәк, бирелә һәр йорт кирмән рәвешендә. Бар, орышсыз-нисез генә яулап кара.

Кин мәйдан аша үткәндә Андрей тагы да гажәпләнде. Базар иде, ахры. Рәт-рәт булып хисапсыз чатырлар, гөмбәгә охшаш япмалар сузылган. Бер рәттә балчык чүлмәкләр, карчагалар, су савытлары тезелеп китсә, башкаларында сугыш кораллары, алтын-көмештән ясалган бизәнү әйберләре, тимер йозаклар, төрәнле сабаннар, балта, чалгы герләр, агач өстәлләр, камыт, сәхтиян читек һәм күн чүәкләр, тире, бал... Андрей кат-кат игътибар итте, муенын суза-суза әзләнде. Ләкин, ни гажәп, базарның үзендә дә, хисапсыз урамнарда да бер генә кизү яки сугышчы да очрамады. «Сәер табышмак бу,—дип уйлады ул аптырагач.—Болгарлар чыннан да тыныч хәят халкымы, әллә инде болар бөтенләй дә пошмас, гамьсез бер кавемме?»

Шәһәр бәгенең сарае ике биек манаралы зур мәчет янында урнашкан булып чыкты. Капка төбендә билләренә жинел кылыч аскан ике генә сакчы тора иде. Әмма ихата эче кунакларны шау-гөр килгән халык төркеме белән каршылады. Андрей шаккатты. Ачык мәйданга ярымтүгәрәк

ясап баскан ирләрнең күбесендә таушалган кием, ямаулы тун, табаны купкан итек. Мондагы һәр ир иненә биштәр аскан. Капчыкка охшаш ул биштәрләрдәге ертык аша балта, чүкеч, кәйлә, ышкы, өтергеләр күренеп тора. Ул гына да җитмәгән, байтак ирләр кулларына казан, пычкы, көрәк тотып баскан. Болар арасында (ниһаять!) унбиш-егермеләп сугышчы да күренә. Ихатадагыларның һәммәсе сарай баскычына чыгып баскан иргә төбәлгәннәр. Әллә үзләре аңа нидер аңлаталар, әллә даулыйлар—һич төшенерлек түгел. Ә теге ир билендәге кара каешына ике кулын тыгып баскан да, елмаеп тик тора.

Андрей аптыраудан тәмам гаҗиз булып Якимга сорау бирде:

—Кемнәр болар? Нинди кәмит уены бу? Нәрсә бүлешәләр?

Суздаль кунагының шактый сәер хәлгә калуын наиб та чамалап өлгерде, әлбәттә. Ашыга-кабалана ул Якимга нидер сөйләде, тегесе тәрҗемә итте.

—Әле бер сәгать элек кенә Чулман буйлап ун каек кайтып төшкән. Бу кешеләр моннан бер ел элек чыгып киткән булган. Хан фәрманы буенча. Алар Чулманнан Нократка кучеп, арлар һәм висулар яшәгән мәңгелек урманлыкларга таба күтәрелгәннәр. Нократ белән Чипса елгалары тоташкан җирдә, биек тау башында яңа кала төзеп кайтканнар.

Әлеге хәбәр дә Андрей өчен аяз көнне яңгыраган күкрәү авазы сыман булып ишетелде. Аның тагын ачынулы нәтиҗә ясамыйча чарасы юк иде. «Йә, Хода! Безнең кенәзләр тегендә һичнинди тынышу, җайлашу белмичә берсен-берсе кыра. Изяслав, имгәк, рус җиренең хакиме була торып Остер кальгасын яндырып юкка чыгарды, җир белән тигезләде. Ә болгарлар, әнә, яңа өлкәләр били, яңа калалар нигезли. Алар дәүләт ныгыта, ә без җимерәбез. Тагын күпме мөмкин? Рус җирендәге канкоюлы мәхшәрне кем генә туктатыр соң?..»

Ниһаять, сарай баскычына баскан ялгыз ир Суздаль кунакларын да шәйләп өлгерде. «Ә» дигәнче ул басмалар буйлап йөгереп төште. Сарай янындагы түгәрәкне ярып Андрей каршына килеп басты. Бер кулы белән атның тезгенен тотты, икенчесен күкрәгенә куйды. Елмая-елмая сәламләргә тотынды.

—Әссәламегаләйкем, Әндри кенәз! Гафу кыла күр, Идел буена төшеп үзем каршылый алмадым. Синнән алда гына һөнәркяннар вә мигъмарлар фиркасе кайтып төште. Менә, күрәсең бит. Ә алар—Кашан вилаяте терәкләре. Аларны санга сукмыйсың икән, хәят бармый. Хәер, үзең аңлыйсыңдыр. Инде рәхим итеп, йортыма узыгыз. Сез мәнем иң мөхтәрәм кунакларым.

Яким тәрҗемә итә башлады. Андрей тарта-суза гына ияреннән төште. Ә инде тәрҗемәнең тулы мәгънәсен аңлагач, Андрей тагын уклау йоткан сыман катып калды. Менә сиңа мә! Гап-гади күлмәк-чалбар кигән, бер җансакчы да алмаган килеш чыгып, бер көтү өтек ир, ягъни үз коллары белән япа-ялгыз көенә һәм авыз ера-ера сөйләшеп торучы шушы бәндә—мәшһүр Кашан каласының бәге!

—Әмир Колын бу, Колын!—дип, яна-пешә пышылдады янда торган Яким.

Андрей телсез калды. Ул нишләптер биредә заманында әтисенең каекларын яндырган, аның ярты гаскәрен кырып салган шанлы баһадирны—Шәмгун бәкне очратырга өметләнгән иде. Менә, аның урынына Андрей каршында кырык яшьләр чамасындагы көләч ир басып тора. Кап-кара түбәтәйле, пөхтә тар мыеклы, чандыр буйлы, кара-кучкыл йөзле. Бер яңагында кечкенә, әмма кайнар җамаяк тигәннән калган сыман түм-түгәрәк җәрәхәт эзе дә бар. Нинди хаким соң бу тамгалы әмир? Илдәге абруе нindирәк дәрәҗәдә?

Әнә шундый туктаусыз уйлар эчендә яна-көя Андрей сарай эченә узды. Һәр тарафтан пөхтәлек, тәртип балкып тора, әмма йортның күренеше әлләни бай түгел. Идәннәрдә келәм, тәбәнәк, зур өстәлләр, һәр бүлмә саен мич һәм сәке, аларда катлы-катлы ястык-юрган, тәрәзәләрдә чигүле

ак пәрдәләр, ишек өсте саен шәмаил.

Икенче катка менгәч, әмир Колын бер-бер артлы ике бүлмәнең ишеген ачып куйды.

—Менә, жаның кайсын тели, шунысын сайлап урнаш, Әндри кенәз. Икенчесенә оланнары вә сенлесе Ослан илә байбикә рәхим кылсын. Яраннарына урын беренче катта булыр.

Андрей озын коридор буенча күз йөгертеп чыкты. Яшерен ишекләр эзләде, таба алмады. Дәшми торуын белде.

—Сез урнаша торыгыз, юл тузаннарыннан арыныгыз,—дип, әмир Колын баскычка таба чигенә башлады.—Ул арада олы кунаклар өчен сый табыны да әзер булыр...

Табын янына дәшәргә наиб керде. Сый-нигъмәтне беренче катта иң зур бүлмәгә әзерләгәннәр икән. Суздаль кунаклары кергәндә әмир Колын күлмәк-чалбарын да алыштырган, инбашына якалары алтын-көмеш жепләр белән чигелгән затлы чапан да киеп алган иде. Яшел чалма чите буйлап тезелгән якут ташлар тәрәзәдән төшкән кояш нурларында ялт-йолт килеп уйный. Беленә таккан киң каеш аелын да мәржән, бәрәзә, гәрәбә ташлар бизи. Юк, сарай баскычында очраткан өтек ир түгел иде инде әмир Колын. Вәкарь килеш-килбәт, мәгърур гәүдә, каш астыннан текәлгән горур караш—һәммәсе аның ил тоткасы икәнен кычкырып тора. Залның түренә урнашкан мич буенда яшел чапан кигән өч-дүрт ир тезелеп баскан. Андрей ишектән инүгә үк әмир Колын аларга таба караш ташлады да, горур атлап Суздаль кенәзенең каршысына килде. Озын, ябык, әмма тимер кыскычтай каты куллары белән ул кенәзне кочагына алды. Ягымлы сүзләрен дә онытмады.

—Әйдүк, Әндри кенәз! Урыс мәмләкәтенең абруйлы кенәзләре, кунак булып, безләр әтрафына бик тә сирәк килә. Болгар хозурына сәяхәт кылуыңны да без дустанә, килешеп яшәү өчен басма салырга омтылуың дип кабул кыламыз. Арадагы ераклык вә салкынлык боздай эреп юкка чыксын, безне борадәрләргә әверелдерсен иде.

Әмирнең аны тулы хокуклы Суздаль кенәзенә санап кабул итүе дә Андрейның күңеленә горурлану, жылылык өстәде. Бирегә чакырылган чит ирләрнең кем икәнлекләрен белмәсә дә, алар каршында Колынга ихтирам белән жавап кайтарырга омтылды ул.

—Ялгышмасам, минем Байгөл бикәм сиңа шактый якын кардәш туры килә бугай, хөрмәтле әмир.—Сак кына терсәгеннән алып, Андрей Байгөлне әмир Колын каршына китереп бастырды.—Шулай икән, без әле синең белән кодалар да булып чыгабыз. Менә шундый туганнар яшәгән жирне без юксынып килдек. Кунак кеше, билгеле ки, күчтәнәчсез йөрми. Ә хәзер гаепкә санамыйча гына син шуларны кабул итсәң иде, әмир Колын.

Бүләк чыгару шартларын Андрей белән Прокопий инде күптән килешеп куйганнар иде. Кенәз бил каешы өстенә бер бармагын салса, Прокопий бер тәпси тулы зиннәт китерергә тиеш. Ике бармагын куйса—ике тәпси. Кенәзнең ишарәсен көткән Прокопий карашын каешка юнәлтте. Ни гажәп, каеш өстенә Адрей өч бармагын куеп тора иде. Менә шул сәбәпле бүләк чыгару беркадәр сузыла төште. Хужалар авырсынмыйча көтте. Бераздан гына ишектә бер-бер артлы Прокопий, Яким, Козьма пәйда булды. Аларның ике кулларына күтәргән зур-зур тәпсиләре өстендә якут, мәржән кебек асылташлар, алтын-көмеш жиһаз күз яуларын алып жемелдәшә иде. Мич буена тезелешкән ирләр «аһ» итте. Прокопий тоткан тәпси өстендәге кызгылт якут белән алтын хәнжәр һәммәсенең игътибарын тартты. Әлеге якут таш иң дәү йодрыктан да олырак һәм аз гына кыймылдаган саен көлтә-көлтә нурлар чәчә иде. Әмир Колын да бик канәгать калды.

Ниһаять, сый-нигъмәт белән тулы тәбәнәк өстәлләр артына утырыштылар. Әмир Колын Андрейны иң түргә уздырды, келәм өстендәге нәни мендәрләрне иплән куйды. Әмир үзе кенәз белән янәшә чүмәште. Аның

аръягына моңа кадәр мич буенда басып торган ирләрдән аерылып, егерме яшьләр тирәсендәге Алыптай зур һәм иләмсез гәүдәле, кырыс йөзле, шакмактай киң иякле бер егет килеп тезләнде. Шуннан соң гына уңъяк ишектәге пәрдә артыннан өч хатын залга инде. Иякләрен, иреннәрен яулык очы белән каплап кына, алар әмир янәшәсенә утырыштылар. Мич буенда торучы ирләр һәм Андрейның яраннары өстәлнең каршы ягына тезелеште. Ашны болгарлар дога кылудан башлады. Өстәлдәге йөзем, анар, алмортлардан чемченеп авыз иткәч, әмир кенәзне үз кунаклары белән таныштыруны да кирәк тапты. Әмма ул сүзләрен тавыш күтәрмичә, Яким колагынарак әйтте.

—Кунакларның күбесе Шәмгун ханның яраннары. Хәйдәр би шанлы Ага-Базарны тотучы баш базаркян. Аның кәрваннары Чингә тиклем барып йөри. Бәдретдин хаҗи исә Болгар мәмләкәтендәге мигъмарлар бие, баш оста. Кәрамулла хаҗи да, шулай ук, мәмләкәттә абруй иясе—ул да баш оста, булат вә чуен коючы һөнәркяннар бие. Аларның өчесен күрүемә дә күңелем мәмнүн. Хәйдәр би миңа сәрмая илә ярдәм кылды.

Башкаларга сиздермәскә тырышып пышылдаган Якимнең сүзләре Андрей өчен дә кызык булып тоелды.

—Колын сүзе «ат баласы» дигәнне аңлата. Җизни-кенәз, сора әле, әмиргә ни өчен андый кушамат тактылар икән?

Шушы ук сорауны Андрейдан соң Яким янә кабатлагач, әмир Колын, бөкесен аткан кымыз шешәсе шикелле кайный-кайный, пырхылдап көлә башлады.

—Әллә нинди сере юк ла аның. Мәнем илә көмәнле чагында инәйгә колын типкән. Мәгълүм ки, инәй гайре нык курыккан. Шуның нисбәтедер, менә, мән җиһанга тамгалы булып туганмын. Шәмгунь атам озак баш ватмаган. Берьюлы ике намь таккан да куйган. Берсе—Колын, икенчесе Хисам. Мәгәр минем Хисам дигән атымны искә алучы да юк. Туганнан бирле Колын да Колын. Мән күнектем инде.

Әмиргә кушылып, һәммәсе дә эчкерсез көлештеләр. Шуннан соң гына Колын, «менә, минем әле мондый бүләгем дә бар» дигән сыман итеп, үзенең уңъягында утырган яшь егет инсәсенә кулын салды.

—Монысы мәнем өлкән угылым Хәмбәл булыр, Әндри кенәз. Ходайныкын алдан белеп булмый. Синең илә миңа янә дә күрешергә насыйп әйләрме, әллә юкмы? Ә угылым илә танышып калуың хәер. Кем белә, икенче юлы миһман булып килгәндә, шаять, сәне Хәмбәл каршы алыр. Шаять, йә синең үзенә аны Сүздәл кенәзлегендә каршыларга туры килер.—Әмир улының җилкәсенә шап-шоп сугып алды.—Һичбер тәкәллефсез көе игълан кылырга җөрьәт итәм: моңа кадәрге асла орышта да әле мәнем угылымны галәбә кыла алган пәһлеван булганы юктыр.

Инде моңа кадәр дә Андрей кенәз күз кырые белән ара-тирә әлеге егеткә караш ташлый иде. Хуҗа сүзләреннән соң Хәмбәл тарафына ул тәмам йөзе белән борылды һәм... бөтен тәне кинәт көзән җыергандай эсселе-суыклы булып китте. Әйе, сүз дә юк, Хәмбәл Алыптай зур гәүдәле. имән кәүсәсе сыман буынланып күпергән инбашлары, аюныкына охшап, сөзәкләнеп тора. Уч төпләре көрәктәй, беләкләре буйвол мөгезе сыман кәкре һәм нык. Болары гына шаккатмалы түгел, рус җирендә дә пәһлеван ирләр байтак. Әмма кыяфәте... Җилпучтай киң йөз шакмаклы ияк. Чылгыйлары ирен өстенә яткан куе мыек. Иреннәр астына сыймыйча тырпаеп торучы эре, казык тешләр. Хуҗасы яшь кенә булуга карамастан тирән буразналар белән сыргаланган тап-тар маңгай. Дәү һәм кәкре борын. Шул борын өстенә килеп бөгәрләнгән кара, куе кашлар. Һәм һәрчак кашлар астыннан гына сөзеп текәлүчән соры күзләр. Хәмбәл дөньяда елмаю, көләчлек тә барлыгын бөтенләй белми сыман. Аның мыек чылгыйлары урыннарыннан һич кузгалмый. Йөзе дә кешеләрне өркетү, өшәндерү өчен ясап куелган таш сынныкы сыман.

Андрей капылт кына шулчак Байгөлнең туйдан соңгы тәүге көннәрдә

бик еш кабатлый торган усал кисәтүен исенә төшерде.

—«Әтисен дөмектердек, кызын хатынлыкка алдык», дип, тантана итәргә ашыкмагыз әле. Берегез дә ошбу җиһанда мәңгелек түгел, сез дә—Аллаһы Тәгалә коллары. Бервакытны сез катилләр каршына да Газраил фәрештә килер. Катиллегегез өчен сез шулчак үкенерсез, мәгәр, ә-ә-әй, соң булыр.

Шушы кисәтүне хәтерендә яңартты да, Андрей янә Хәмбәлнең нурсыз йөзенә төбәлде һәм имәнеп куйды. «Мөселманнарның ул Газраил дигәннәре, мөгаен дә, менә шушы аю кыяфәтендәдер. Ходаем, үзең сакла...»

Сый артыннан сый яңарып торды, табын озак барды. Кунаклар буза һәм чәй эчеп аргач кына, әмир Колын танбурчылар һәм чәңчеләрне[1] дәште. Калфак, хәситә, чулпылар белән бизәнгән япь-яшь кызлар үзләре дә сылу, ымсындыргыч иде. Алар тәүге итеп сузган моңлы җыр да Андрейның күңеленә бик хуш килде.

## 2

Икенче таңда ук әмир Колын Андрейны ауга чакырды. Төн гаҗәеп тыныч үтте, һичнинди дә мәкерлек-усаллык сизелмәде. Андрейның күңеле тыныч, кәефе шәп иде. Ул шундук ризалашты. Шулай да үзе белән Прокопийны, Козьманы, кайнешләрен дә алды. Чулманны сулда калдырып, Иделгә таба юл тоттылар. Атлар гаярь иде, гел тыеп барырга туры килде. Андрей күбесенчә тирә-юньне күзәтү белән мәшгуль булды.

Чулман ягыннан күтәрелгән кояш нурлары туктаусыз лепердәгән агач яфракларында кайтарылып уйный. Чулман яры буйлап Иделгә чаклы тын һәм сихри урман сузылган.

Әнә, офыкларга кадәр сузылып иген басуы җәйри. Җиргә сыгылып төшкән тук башаклар өстендә рәшә уйный. Идел буен иге-чиге күренмәгән болыннар сарып алган. Болыннарда түбәтәй-түбәтәй булып тузганак, күкбаш, энҗе чәчәкләре сибелеп ята. Киң, талгын, чал Идел өстендә җилкәнле кораблар, ишкәкле каеклар чайкала, ялгыз балыкчы көймәләре нокта сыман һич селкенми тора. «Йә, Аллаһ! Иркен төбәк, кызлар сыман купшы мәмләкәт кенә түгел, мөселманнар яратып кия торган чигүле түбәтәй бит бу. Синең дә шулкадәр күңел биреп яраткан җәннәт бакчаларың булыр икән!..»

Ау унмады. Кашанга таба бик кәефсез кыяфәттә кузгалдылар. Төркем озын чылбыр булып сузылды. Ниндидер «Кискә» атлы авыл янынннан да ирләр шулай таралып, үзара сөйләшмичә диярлек үттеләр. Йөрәгә урынына бизмән куелган сыман Андрей кенәз Болгар җирендәге һәр тарафны гел-гел үзенчә үлчәп, чагыштырып барды да, тагын хәйран, мөкиббән калып узды. Менә монысы да гап-гади бер авыл бит инде, югыйсә. Ә барыбер ул, әнә, һәрьяктан биек ур, тирән чокыр, куе читән белән әйләндереп алынган. Читән дивар артында ук иген басулары башлана, авылга капка аша гына керәсе. Авылны әйләндереп алган читәнле ур белән йортлар арасында ике-өч ук арасы яланкыр ята. Болгар авылының йортлары да шәрә хатын кебек тырпаеп утырмый шул. Алар умарта оялары шикелле тезелешеп тора. Авыл үзе тигез, җыйнак түтәлләргә бүленгән бакча төсле—ике-өч йорт саен киң тыкрык. Һәм шул түтәлләрнең һәркайсы аерым рәвештә тыгыз читән белән уратылган. Һәр йортның ихатасы, лапасы, мунчасы, келәтләре аерым. Күп кенә ихаталарда лапас түбәләре ишегалды буйлап та сузылган. Ук яки сөңге очыра башласаң, алар ихата эченә үтеп кермәле түгел. Инде тыштагы басу читәнен узып керсәң дә, авылда һәр тыкрык, һәр йорт саен тукталып орышырга кирәк.

[1]танбур—кыллы, чәң—арфага охшаган музыка коралы.

һәр утарын, һәрбер ихатасын аерым кирмән итеп төзи белсә дә белер икән бу болгар халкы!

Шушыларны уйлап, Андрейның янә йөзе сытылды, «Кискә» дигәннәре тәмам күздән югалганчы башын чайкап барды. Ахырда ялгызлык та туйдырды, күрәсең, кенәз әмиргә якынлашты, аның белән иярга-ияр басып бара башлады.

—Сүзләрем сине мактау яки ясалмалык булып ишетелмәсен, шөһрәтле әмир,—дип һәм тәүге тапкыр чын күңеленнән хөрмәт күрсәтеп, Андрей Колынны яңа әңгәмәгә чакырды.—Болгар җиренең әлләни күп почмакларын күреп өлгермәдем. Мәгәр күргән кадәресеннән чыгып та нәтиҗә ясый алам. Дәүләтегез—имин, халкыгыз мул яши. Сезнең кенәзләр безнекеләр шикелле үзара сугышып, кан коеп та ятмый, күрәсең, һәрхәлдә—ишетмәдем. Дәүләт җимерердәй сер түгелдер, миңа аңлат әле. Сездә дәүләт нинди тылсымга таянып яши ул? Кенәзләрегез ничек билгеләнә? Кенәзләрегез ничек билгеләнә? Хан сезне нинди көч белән буйсындырып тота? Гаскәрегез кайда?

Яким тәрҗемәсеннән соң әмир Колын әүвәл тирә-юньне сискәндереп көлә башлады, бераздан гына йөзе житдиләнде.

—Бәгъзе дә тылсым тотмый безнең мәмләкәтне, Әндри кенәз, күз тидерә күрмә. Һәммәсе дә сезнең жирдәгечә, аерма бик аздыр. Ханның тәхете, тач сездәге кеби, йә аның борадәренә, йә углына кала. Мәгәр, ханнар тәхетне васыять итеп китә, соныннан инде җәдид хакимемезне, Коръән үбеп, бәкләр, тарханнар вә сәетләр раслый.

—Әйе, бу кадәресе нәкъ бездәге кебек. Әмма ханның угыллары үзара ничек сугышмыйча яшиләр соң?—дип, Андрей кенәз инде сабырсызлануын да күрсәтте.

—Аермасы шулдыр, Әндри кенәз, бездә ханның һәр углы да хаким тәхетенә дәгъва итә алмый. Үзең үк уйлап бак. Безнең ханнар кәм дигәндә өч-дүрт хатынга өйләнә. Алар җәмгысы унлап угыл таба. Ул угыллардан йөзләп оньк тууы да ихтимал. Шулай икән, ул угылларның вә онькларның күңелен күрәм дип, алар асыл зат дип, һәркайсына вилаять илә бәйлек бирә башласаң, Болгар мәмләкәтен йөзгә туракларга кирәк булыр иде.

Андрей кенәз һаман кызулатты.

—Хан угылларының язмышы ничек хәл ителә соң?

—Бер уйласаң, гап-гади, Әндри кенәз. Тәхет варисы булмаган угылларының берсенә дә хан хосусан вилаять бүлеп бирми.

Андрейның гаҗәпләнүе йөзенә чыкты:

—Шулай, Әндри кенәз. Вилаять бирми, аздырмый, үсендерми. Тәхеткә дәхеле булмаган һәр угыл ханның курсыбаенда, ягъни шәхси сак алаенда йөзбашы, хәтта гап-гади бер гази булып тәгаен ителә. Шуның белән вәссәлам.

Ризалашасы килмичә Андрей каршы төште.

—Хан угылын колчурага әйләндерү бит инде бу. Ничек түзмәк кирәк? Ә әгәр шул курсыбайда йөргән йөзбашы, түнтәреш оештырып, ханның җанын кыйса? Яки, һич югы, курсыбайның бәге булып алса?

Әмир Колын көлеп баш чайкады.

—Юк, Әндри кенәз, аның ише хәлләр мөмкин булмас гамәлдер. Бердән, курсыбайга сәрдәр итеп хан үзенә үтә дә садыйк җанлы булган бәкне тәгаенли. Хан сөләләсеннән булган углан сәрдәр урынына менә алмый. Курсыбайда йөзбаш булган угланның түнтәреш оештыра алуы да бик икеле. Сукыр мәче бардыр, дип бер сычкан да уйламый. Шуңа күрә сәрдәр үзе дә, хан да курсыбайдагы йөзләгән газигә җасуслык[1] өчен биниһая сәрмая түләп тора. Ары да килсәк, гыйсъянлык кылып инкыйлаб корган катилне мәмләкәт хакиме дип кем танысын? Миндәй вилаять бәкләре, тарханнар, сәетләр—җәмгысы ул катилгә каршы чыгачак бит.

—Шулаен-шулайдыр,—дип, Андрей кенәз әүвәл ияк какты, әмма бераз баргач, барыбер үзенекен сукалады.—Тик син ни генә әйтмә, мәгәр

дөньяда ханның сәрдәрен дә, бөтен курсыбайны да сатып алырлык байлыклар бар бит ул. Димәк, сездә дә түнтәреш ясау бөтенләй үк, төбетамыры белән өметсез эш түгел.

—Ул рәвешчә фикер сөрсән, йоклап яткан мәче авызына сычкан үзе килеп керми инде ул, Әндри кенәз. Анысы мәгълүм. Мәгәр, валлаһи дип әйтәм, бездә курсыбай газиләренен ханны алыштыра алганы юк әле.

—Ә күпме соң алар?

—Кайчан ничек инде. Җәмгысы да хан ихтыярында. Кайчак өч мең гази яллый, кайчак биш мең. Мәмләкәт тыныч гомер сөргән бәгъзе сәнәләрдә бәр мене дә житә.

Андрей гажәпләнүдән чигәләренә ябышты, башын унлы-суллы борып, иярендә чайкалып ук куйды.

—Әкәмәт! Бөтен илне, барча бәкне йөгәндә тотарга бер мең сугышчы житәме?

Әмир Колын, жинелчә генә көлемсерәп куйды. Андрей исә кызыксынуыннан туктамады.

—Ә дәүләтегезнең чикләрен кем саклый?

—Нигездә казаклар, ягъни дә килеп, акча бәрабәренә ялланып көн итүче ирләр. Мәгәр яллы булганнары өчен аларга гына ышанып бетмимез. Араларына субашларны да һәр вилаятьтән туплап жибәрәмез. Алары—игенчеләр илә һөнәрчеләр. Субашы биргән йорт салымны аз түли.

—Яу куркынычы туса ничек?

—Ул чакта хан һәр вилаятьтән мөхсусан чирү туплый. Аларны казан-чылар дип тә, азатлар дип тә йөртәләр. Чөнки казаннары—уртак. Чирүгә баскач салымнардан тулысынча азат ителәләр, шуна күрә «азат» дип аталалар.—Бераз тын торганнан сон, Әмир колын сүзен дәвам итте:—Ә болай без бит тыныч, иминлектә хәят кичерүче халаек, чит жиргә яу чапмыймыз, талап жыйган байлыгымыз асла юктыр. Бәгъзе мәмләкәткә безнең сәүдәгәрләр генә үтеп керә. Алар сезнең урыс жирендә дә бик күп йөри, Хәрәзем, Солхат, Саксин, Бохара калаларына, хәттин Шам, Чин базарларына ису-вису[2] ырулары эргәсенә дә барып житә. Күп байлыкны хания казнасына шулар ташый. Кыскасы, ошбу рәвешчә тупланган сәрмая илә калалар торгызамыз, мәчетләр жалислыймыз булыр, Әндри кенәз.

Яким тәржемәсенең һәрбер сүзен Андрей йотлыгып тынлады, аннары байтак ара дәшми-тынмый барды. Алда, еракта, Кашан каласының сөнгедәй очлы мәчет манаралары, гөнаһсыз яшь кызларның алмадай тыгыз һәм түгәрәк күкрәкләрен хәтерләтүче бихисап гөмбәзләр пайда булгач кына, ул үтә уйчан тавыш белән әңгәмәне очлап та куйды.

—Яу йөрмәгән көе дә дәүләт тота аласыз. Сәер халык сез шулай да, гажәп халык...

## 3

Шәһәр читендә аучыларны һич тә көтелмәгән яналык каршылады. Ирләр әле кала капкасына житмәгән дә иде, ә каршыларына алмачуар төстәге тулпар атта ялгыз жайдак уктай очып килә башлады. Прокопий шундук кырыс кыяфәткә керде, кулы сөнге сабына ятты. Анын каравы, әмир Колынның ирен читләре күмәч шикелле кабарып чыкты, карашында очкын кабынды. Икенче мизгелдә ул да, чаптарын кырт кузгатып, ялгыз жайдак каршына оча иде. «Ике-өч кул сузымы ара калды, инде бәрелешәләр», дип, аучылар хәвефкә чумганда жайдаклар иярләреннән сикереп төште һәм, жилкәләренә шап-шоп китереп суга-суга, берсен-берсе кочаклый да башлады. Ләкин Андрей өчен иң гажәбе шул—әле генә очрашкан ике ирнең чаптарлары да, берсенең муенына

[1]жасус—шымчы.

[2]Ису-вису—борынгы төньяк халыклары.

[3]гази—сугышчы.

икенчесе ышкыла-ышкыла, рәхәтләнеп кешнәп тора иде. «Әмир белән яна кунак үзара туганнар, йә дуслар, ахрысы»,—дип нәтиҗә ясарга ашыкты Адрей. Ялгышмаган икән.

Таныш түгел ир-ат Андрейга каршы юнәлде. Өстендә әлләни бай булмаган кием. Яше утыздан артык түгел. Колачларын җәйгән, авызы ерык. Киң күнелле, көләч, үз кеше икәнлеге әллә каян күренеп тора. Тик беренче караштан ук сискәндерә, кызгандыра торган кимчелеге дә бар икән шул. Таныш түгел ир-атның бер аягы гарип, ахрысы. Симез үрдәк шикелле ул бичара гел бер якка янтаеп, аксап килә.

Андрей да ияреннән төште, дикъкать белән рәк текәлде. Шул ук чандыр гәүдә, кара-кучкыл яңаклар, көләч караш, яшереп булмас гадилек. Әмма буе бер карыш биегрәк, җилкәләр куна тактасы шикелле киң, куллар озын, ләкин ишелгән бау шикелле көчле һәм төенле. Бу ир-егетнең әмир туганы булуына шиге гел калмагач, Андрей кафтан итәкләрен, каешын төзәткәләде, яңа кунакны рәсмирәк төстә каршыларга әзерләнде. Әмма бары да юкка гына булып чыкты.

Атлап килешкә, туктап та тормастан, таныш түгел ир аны әүвәл кочагына алды, аннары гына, кулларын күкрәк янына күтәреп, баш иеп сәламләде.

—Хуш килдең мәмләкәтебезгә, Андрей кенәз. Безнең халыкта канатлы бер сүз бар. «Алты яшьлек читтән кайтса, алтмыш яшьлек күрә килер»,—ди. Менә, сезнең кунакка төшү хәбәрегезне алгач, мин дә очып килдем. Син безгә туган тиешле Кучкәй кызын алдың. Димәк ки, син миңа кода буласындыр.

Ир-егет һәммә сүзләрен саф рус телендә ярып салды. Моны ишеткәч, Андрей инде отыры гаҗәпләнде. Әмир энекәше исә тын алырга да ирек бирмәде.

—Кунакка килеп, дөрес эшләгәнсез. Туганнар бер-берсен табышырга тиеш. Дөнья бит бу. Гомер сөрешендә туганнарның гына түгел, ерак танышларның да кирәк булуы бар,—дип өзлексез сөйләнде дә, ул Андрейны янә бер мәртәбә кочагына алды. Хәмбәл, Яким белән дә бик җылы күреште. Шуннан соң ул аучылар арасына китеп барды.

Андрейның беркадәр югалып калуын тойды бугай, әмир Колын пышылдап сүз башлады:

—Төпчек борадәр ул минем. Наме—һәрбәдән. Һәр ягы да камил булсын дип, атаемыз аңа шулай кушкан. Нә үкенеч, Ходай Тәгалә атаемның ялваруларын гына ишетмәгән. Энем тумыштан ук, менә, чонтык[1] булып калган.

Яким тәрҗемә итеп бетергәндә Андрейның йөзендә үкенү катыш теләктәшлек чаткысы пәйда булды. Ул әмир энекәшен чын күңелдән кызгана һәм моңа үзе дә аптырый иде. Колын шуны сизде, күрәсең, алдагы сүзен инде көлемсерәп кенә дәвам итте.

—Бәләкәй чакта без аның наменнән дә, төпчек булуыннан да «арбадан төшеп калган, арбадан», дип кенә көлә идек. Намен тутырып әйтергә күнегә алмадык. Ул менә мондый чактан бирле һәмишә инсан өчен Әрбәт булып йөрде. Кып-кыска—Әрбәт. Шуның илә вәссәлам.—Әмир Колынның күңеле күтәренке иде, ул инде кычкырып ук көлеп җибәрде.—Мәгәр чонтык булса да, ай-һай, гайрәтле ул. Кылыч орышында вә мәргәнлек бәйгесендә аны узган инсан юк әле.

Яким тәрҗемә иткәнче Колын тын торды. Ләкин шул арада аның йөзе караңгыланып та өлгерде.

—Әле кайчан гына без биш борадәр идек,—дип, үзалдына сөйләнгән шикелле монсу итеп әйтте ул.—Өчесе инде вафат. Әрбәт илә икәү генә калдык. Атай олыгайды. Борадәр өчен гайре хафалана. Үзенең эргәсеннән җибәрми. Гел Биләрдә тота. Сирәк күрешәмез. Сагынылган...

Кабат иярләргә менеп алгач, Әрбәт Андрейның янына ук килеп

[1]чонтык—бер аягы кыска.

басты. Иреннәреннән елмаю китмәгән, эчкерсез шатлануы күз карашларында чагылып тора.

—Юл уңаенда мин Ибраһим бәк янына да кагылдым,—дип, Әрбәт күптәнге танышлар шикелле, керешсез-нисез генә сүз башлады.—Сездәй олы кунаклар килүе турында хәбәр иттем. Ул сине кабул итәргә ризалыгын бирде.

Андрейның һични аңламыйча текәлүе сәерсетте, Әрбәт инде бәйнә-бәйнә тәфсилләүгә күчте.

—Сүзем Болгар каласы турында, Андрей кенәз. Менә егерме ел буе анда хуҗа булып Ибраһим бәк утыра. Ул әмир Колын белән миңа гамуҗә тиешле. Ягъни, ага, атабызның энесе.

Әлеге яңалыкны ишеткәч, Андрей кенәзне корт чаккан кебек булды, колаклары сагайды. «Туктале син, әмир. Сезнең дәүләттә дә шактый шомлы хәл туган түгелме соң? Кашанга әмир Колын хуҗа, Болгарга—Ибраһим. Биләрдә, мөгаен дә, син үзең идарә итәсеңдер. Алай-болай булып Шәмгунь хан көтмәгәндә мәңгелек дөньяга китсә, өстәвенә әле варисын да әйтеп өлгермәсә, сез өч туган арасында да яу чыгуы бар бит. Әмир Колын: «Хакимнең варисы берәү генә, башка туганнар тәхеткә дәгъва итә алмый»,—дип үз-үзен юата да бит. Ләкин Ибраһим бәк белән синең шайтан коткысына бирелмәсегезгә кем ышана?»

Үз уйларын сиздерүдән шөлләде, күрәсең, Андрей кенәз ашыгып сорау бирде:

—Ул Ибраһим бәк дигән агаң ниндирәк кеше соң? Тыйнак бәндәме, әллә данга-малга кызыгучымы?

Әрбәт һичнинди киная сизмичә җавап тотты.

—Холкы коры, тик торуны белми. Сараенда бик сирәк утыра. Бар белгәне—төзелеш. Моннан йөз кырык-йөз илле еллар элек хаким булып торган адашы—Ибраһим бине Мөхәммәт хан аның өчен ин зур өлге, ахры. Кызганыч, ул шөһрәтле ханның үз балалары булмаган, нәселе юк. Бәлки, шунадыр ул үзеннән соң җиребездә бик күп яңа кала калдырып киткән. Ука елгасы тамагындагы Калачыкны үзең дә күргәнсеңдер. Ул кальга да, Чулман ярындагы Алабуга да ул төзеп калдырган зур кирмәннәр. Идел буендагы Богылтау кальгасын да шул ук Ибраһим хан җалисләгән, диләр. Менә, хәзер Болгарда утырган гамуҗә агамда да шул хан чире. Элеккерәк елларда кәрван-сарайны өр-яңадан салу, диварларны яңарту, ерымнарны киңәйтү, мәчетләр төзү белән генә шөгыльләнгән иде. Хәзер инде кала уртасында махсус кальга—таш кирмән тергезәм дип җенләнә.

«Без үзара сугышып булганын җимерәбез, ә болар һаман яңа кальгалар да төзи, искесен дә ныгыта»,—дип, Андрей янә ачынып уйланды. Ахырда җанын кычыттырган сорауны бирмичә түзмәде.

—Ә сез ул таш кирмәннәр төзүче Ибраһим агагыз көннәрдән-беркөнне үзен—хан, ә Болгарны пайтәхет дип игълан итүдән курыкмыйсызмы?

Әрбәт нәкъ Колын шикелле үк туарылып, рәхәтләнеп көлде. Бераздан соң гына җитдиләнде.

—Сыңар бармак белән җәя бөгеп булмый бит ул, Андрей кенәз,—дип, көтмәгәндә Әрбәт үзе дәвам итте.—Баш хакимгә буйсынмый торган, мөстәкыйль вилаять төзү өчен генә дә әллә никадәрле шарт үтәлү кирәк.

—Нинди шартлар?—дип, Әрбәтнең беләгенә капылт тотынуын Андрей үзе сизмичә дә калды. Аның күзләрендә шашкын бер ут яна, әмма үзе шуны яшерә алмый иде.

—Беренчесе—вилаятең яки кенәзлегең дәүләтеннең читендәрәк торсын. Икенчесе—кул астында бер генә түгел, ә биш-алты шәһәр булу отышлырак. Ләкин аларга хуҗа итеп туганнарыңны һәм кардәшләреңне утыртырга ярамый. Бәк, кенәз нәселеннән булмаган үз яраннарыңны наиб итеп кую файдалырак. Өченчесе, әлбәттә, көчле гаскәр. Биш-алты шәһәрдән тупланган һәм башка беркемгә дә түгел, фәкать сиңа гына буйсына торган гаскәр. Ул синең мөстәкыйльлегеңә ризасызлык белдергән күрше-дәге һәр кенәзне бик тиз арада барып бастыра алырга тиеш. Шул

ук вакытта саклану турында да кайгыртырга, үз жирендәге калаларны дошман яулап керә алмаслык таш кирмәннәргә әйләндерергә, өстәвенә яшерен тозаклар да төзеп куярга кирәк. Һәм сонгысы. Моннан ары үзеннән беркемгә дә буйсынмаячаксын икәнлекне илдә нинди дә булса көчле яу барганда игълан итү файдалы. Илен имин икән, димәк, башка бәкләр, кенәзләр җыелып синен өскә килү хәвефе бар. Ә үзара кан кою, яу барса, мондый чакта бәк-кенәзләр бергә туплана алмый...

Әрбәт һәммә сүзен Андрейнын йөзенә текәлеп сөйләде. Ә Андрейнын эчендә болай да ут иде. Эчтәге шул утны чит бер дәүләт әмиреннән үтәдән-үтә күрә белүен анлау рус кенәзе күнелендә ярсу да, кыенсыну да уятты. Андрейнын башы торган саен ныграк иелде. Әле ярый әмир сараена кайтып життеләр. Кенәз зиһененә капкан ялкын кичке мәҗлес барышында гына, ниһаять, онытылды.

## 4

Икенче көнне тан белән Болгарга көймәләр кәрваны белән кузгалдылар. Чулман өсте зур-зур каеклар, җилкәнле кораблар, эреле-ваклы көймәләр белән чуарланган һәм аларнын барчасы да Болгарга таба агылалар иде.

... Болгар урнашкан калкулык өстенә күтәрелгәч тә, Андрейнын күз алдында яна манзара ачылды. Айкапудан чыккач та, ерым аша гына, имән бүрәнәләр белән ныгытылган аерым бер кирмән шәһәргә терәлеп диярлек үк тора. Кин итеп ачылган капкалары аша кирмән эчендә икешәр катлы таш һәм агач йортлар, эреле-ваклы кибетләр, ихата уртасында мал яба торган араннар, ат эчерү өчен ясалган улаклар, сиртмәләрен күккә чөйгән коелар күренә. Ихата түрендә вак-вак кызыл кирпечләрдән салынган икешәр катлы ниндидер аерым йортлар да бар.

—Кәрвансарай бу безнен,—дип, Әрбәт анлата барды.—Чит мәмләкәтләрдән килгән барча сәүдәгәр биредә туктала. Тиешле салымнарын түләп, шушында ук тамга да алалар. Ярминкә юк көннәрдә калада сату итәләр, кичләрен әнә теге мунчаларда үзара гәп коралар, танышалар, бәхәсләшәләр.

Кәрвансарайны үткәч, шәһәр читендә бер-бер артлы тезелешеп киткән яна бистәләр күренде. Һәркайсын йә тәбәнәк урлар, йә агач коймалар ураткан, шунадырмы алар аерым бер утрау булып тоела.

—Монысы—әрмәннәр бистәсе,—диде Әрбәт, кәрвансарай артындагы беренче ихатага кулын төбәп. Андрейнын гажәпләнеп төбәлүен күргәч, янә шәрехләде.—Әйе, Болгар җиренә килеп көн күрүче әрмән һөнәрчеләре нигезләде аны. Йортлары да, алачыклары да шунда. Су ташый торган зур чүлмәкләр, вак-төяк савыт-саба, шәп хәнҗәрләр, күн җиләннәр һәм үкчәле кәвешләр ясап сату итәләр. Хәтта, шушында ук мәгъбәдләре[1] дә бар.

—Сез чит халыкларга үз җирегездә үз динен тотарга ирек бирәсезмени?—дип сорады Андрей шаккатып.

—Ә көчләп тыюда ни файда?—диде Әрбәт үз чиратында, ана сорау белән.—Көчләп тыю, җәза, эзәрлекләү—киресенчә, кешене үзе сайлаган иманнын хаклыгына ышандыра гына. Кайсы дингә табыну—кешенен ин изге һәм ирекле гамәледер. Дин—ул бәйге төсле. Үз ягына түндерү өчен һәрбер дингә бердәй мөмкинлекләр тудыру лазим. Менә ни өчен безнен калабызда мәчетләр дә, әрмән мәгъбәде дә, шулай ук нәсара чиркәве дә бар.

Үз колакларына ышанмыйча, Андрей ияреннән күтәрелә төште.

—Христиан чиркәве?

—Әйе, чиркәү дә, рус сәүдәгәрләре һәм һөнәрчеләре тупланып

[1]мәгъбәд—гыйбадәтханә.

утырган аерым бистә дә бар бездә. Анысы каланың көньягында, моннан күренми генә.

Андрей күкерт шикелле кабынгандай булды.

—Анда кем яши соң? Саугатлармы[1], әллә качакланмы?

Әрбәтнең йөзендә мәсхәрәле көлү чагылды.

—Саугатлар гына яшәсә, без аны «коллар бистәсе», дип атап йөртер идек. Аннары, кол итеп тотылган бистәнең, барыбер, берзаманны синең аркаңа хәнҗәр кадавы бар. Әйтик, берәр кенәзегез яу белән килсә... Шулай булгач, Андрей кенәз, кол ителгән яугирләр һич яшәми анда. Күпчелеге—сәүдәгәрләр белән һөнәрчеләр. Яшермим, араларында качаклар да шактый. Кенәзләр белән боярлар талавына түзмичә качып килүчеләр. Гафу ит, монысына инде без гаепле түгел.

Шәһәр эченә керүгә, Андрейнең игътибары җәя кереше кебек киерелде. Киң юл кала үзәгенә таба алып бара. Як-якта икешәр катлы йортлар. Күпчелеге таштан салынган. Бер катлылары да бар. Алары биек койма белән әйләндереп алынган. Йортлары ихатаның түренә урнашканнар. Гөмбәз түбәле ташпулатлар бик күп. Келәтләрме алар, идарә йортларымы—һич тә аңлап булмый.

Юл азагында зур мәйдан ачылды. Нәкъ каршыда гына һәр почмагына таш манара бастырылган мәһабәт сарай күренде. Янәшәдә биеклеге унбишегерме аршынга җиткән гаҗәеп биек манарасы бар. Андрейнең үз гомерендә мондый биек бинаны күргәне юк иде. «Сарае—бәк йорты, ә манарасын тирә-якны күзәтү өчен төзегәннәр, ахры»,—дип нәтиҗә ясарга ашыкты ул. Аның уйларын Әрбәт кире какты.

—Җәмигъ мәчет бу безнең. Зур залына бер мең кеше сыя. Манарасына мөәзиннәребез менеп, көн дә азан әйтә. Ошбу манараны без күрәчәк Ибраһим бәк төзеде.

Андрей хатасын кабатламас өчен, мәчет янәшәсендә торган икенче бер сарайга таба кул изәп сорады.

—Бу таш сараегызга кем урнашкан?

—Анысы дарелголүм, ягъни гыйлем йорты. Бездә һәр мәчет каршында махсус мәдрәсә бар. Анда һәммә сабый бала укырга-язарга өйрәнә. Ә гыйлемгә омтылганнары, аеруча сәләтлеләр, мәдрәсәдән соң шушы дарелголүмгә килеп белем ала. Биредә алар гарәп, фарсы телләрен дә су кебек эчә башлыйлар. Коръәнне турыдан-туры тәрҗемә итеп тәфсилләр дәрәҗәгә ирешәләр.

—Мәчеттә мулла булу өчен шушында уку шартмы?

—Әйе, авылларда мулла булу өчен шушында уку да җитә. Ә инде вилаятьләрдә имам-хатыйб яки сәет булырга теләгәннәр, тагын Бохара, Үргәнеч, Харәземгә барып, андагы шанлы мәдрәсәләрдә дә укып кайталар. Табиб, мөәррих яки гыйлем иясе булырга омтылганнар да шунда барып укый.

—Ул укулар күпмегә сузыла инде?

—Җәмгысы егерме елга кадәр барып җитә.

Үз колакларына үзе ышанмыйча, Андрей баш чайкады.

—Егерме ел? Шулкадәрле гомерне кызганучы юкмы? Аннары монда укучылар ничек көн күрә соң? Нинди хисапка яши, дип соравым.

—Дарелголүм шәкертләренең һәркайсына йә казна акчасыннан, йә вакыфтан[1] өлеш чыгарыла. Гыйлем һәм акыл иясе—һәр мәмләкәт өчен иң кыйммәтле байлык. Ни кызганыч, аларны алтын яки җәүһәр ташлар белән дә сатып алып булмый...

Ул арада инде асылмалы күпер һәм киң капка аша үтеп, иркен ихата эченә керделәр. Як-якта кулларына җинел калкан тоткан, дәү кылычлар аскан шыгавыллар[2] басып калды. Шулар ук ишегалдында йөреп тора иде. Андрей күзе белән бөтен ихатаны айкап чыкты. Бер якта ялгыз

---

[1]саугат—сугыш, яу тоткыны.

[2]шыгавыл—ишек сакчысы, эчке сакчы.

манаралы агач йорт утыра. Манара сөнгесе өстенә ай куелган. «Монысы мәчет, ахры». Бер як читтә кайсы агач, кайсы таш, әмма һәммәсе дә тәбәнәк йортлар тезелешкән. «Болары келәт яки мал лапасы бугай». Андрейның фикерен раслагандай шул лапасларның берсеннән ат кешнәгән тавыш ишетелде, кенәз елмаеп куйды. Кунак шуннан соң гына ишек катына шыгавыллар баскан сарайга игътибар итте. Ике катлы зур гына таш сарай. Гөмбәз шикелле өсте түгәрәкләнеп эшләнгән тәрәзәләре төсле пыялалар белән бизәкләнгән. Сарай түбәсе дә гөмбәз белән капланган. Стеналары калын. Түбәгә тышкы яктан менүче баскычлар юк. «Һе, тышкы ягы таш диварлар белән уратылса да, ихата эчендәге байлык зур түгел икән шул. Күрәсең, менә шушы келәтләрне җимереп, Ибраһим бәк яңа сарай төзергә жыенадыр...»

Ишек төбендә кунакларны Ибраһим бәкнең наибе каршы алды. Хужа үзе юк икән. Тәнкәле тауда эшләгән өч ирне таш баскан, Ибраһим бәк, ут капкандай, шунда чыгып киткән.

Күнелсез кыяфәт белән генә залга үттеләр. Байлык-бизәлеше буенча ул әмир Колын йортыннан бик үк аерылып тормый. Шул ук йомшак келәмнәр, парча пәрдәләр, бәрхет чаршау. Кунаклар ике як стена буена тезелеп утырышты. Бәллүр савытларга өрек, йөзем, чия чыгардылар. Кайнар чәй дә килде. Әмир Колын белән Әрбәт әлләни ис китмәгән кыяфәттә үзара сүз алышты. Андрейның кәефе юк иде, үзалдына йомылды, эндәшмәде.

Байтак вакыт үтте. Ниһаять, берзаманны ихатада ат юыртып кергән тавыш ишетелде. Кылыч кыны таш баскычка тиеп үтте бугай, корыч зеңләп алды.

—Ибраһим бәк атлап йөри белми,—дип, елмая-елмая, Әрбәт шәрехләде.—Үз артында халык аны юкка гына «Үтбәк» яки «Чакматаш» дип атап йөртми инде.

Залдагылар аягурә күтәрелергә дә өлгермәде, җилкәсе белән ишек яңагына бәрелә-сугыла хуҗа килеп керде. Башкалар искә-анга килеп өлгергәнче ул җил-җил атлап зал түренә узды. Башын кырт-кырт бора-бора кунакларның йөзен айкады. Менә ул үтәли яндырып чыгардай сынаулы һәм утлы караш белән Андрейга текәлде. Бу кешенең карашы артыгы белән житди һәм нәкъ бораy шикелле, торган саен сыта, аны күтәреп тору гаять авыр иде. Әмма икенче мизгелдә үк инде бәкнең ирен читләрендә елмаю чагылды, тик, барыбер, аның йөзе агачтан юнып ясаган битлеккә охшый иде. Иңенә потлы-потлы герләр яткан сыман Андрей урыныннан кузгала алмый торды. Ә Ибраһим бәк атылган ук кебек кузгалды да, Андрейны инде кочагына алды. Залга шап-шоп суккан тавыш яңгырады, шул мизгелдә үк тузан күтәрелде. Ат өстендә туктаусыз чабып йөргән бәкнең җиләне шау тузанга баткан, селкенде исә, шул өермәгә охшап күтәрелә иде. Хужа моны үзе дә тоеп өлгерде, ләкин һич аптырамады.

—Фу!—дип, кул аркасы белән йөзе каршындагы тузанны куып алды, шундук дөнья мәшәкәтенә дә кереп китте.

—Кием алыштырырга да ара юк бит, һич тынгылык бирмиләр. Иртән Касыйм остага күпме тукып киттем. «Чамасыз куалама, чокырдан һәр ташны дилбегәләр белән бәйләп күтәр, инсаннарны сакла, сакла!»—дидем. Юк кына бит, әй. Мин китүгә үк, авыш бүрәнәләр өстенә берьюлы ике таш мендерткән. Берсен дә бәйләтмәгән. Ә бүрәнәләр читкә янтайган да, ташлар, бер-бер артлы кубып, астагы ирләр өстенә килеп төшкән. Берьюлы өч мәет. Берьюлы! Һәр эшче кул жан бәһасе торган вакытта бит!

Залга тагын кайнар чәй чыгара башладылар. Пар бөркелеп торган касәләрнең берсен Ибраһим бәк кулларына алды. Әз-мәз генә өргәләде дә, голт-голт китереп эчә үк башлады. «Кайнар чәйне ике дә уйламый эчә бу. Холкы да кайнар, ахры»,—дигән нәтижәгә килде Андрей һәм хужага игътибар беләнрәк күз ташлады.

Ибраһим бәк төс-кыяфәте буенча Әрбәт белән Колыннан әлләни

аерылмый. Шул ук какча, ябык гәүдә, кояшта янган йөз, кап-кара куе каш, кылыч борын. Әрбәт белән Колын өчен ага саналса да, яше кырык биштән артык түгел бугай. Мәгәр күз төпләре сары, янак тиресе жилдә яргаланып беткән. Муены жете кара. Ә куллары? Алар тоташ сөялләрдән тора. Һәр бармагы саен жәрәхәт. Ул жәрәхәтләр тузан тулган сыман каралып чыккан. «Минем холопларымның да бу кадәрле кара куллы була алганы юк»,—дип сөенеп куйды Андрей.—«Ә бу таш белән балчыкны да үзе актара икән. Бәк димәссен!»

Ибраһим бәк Андрейның каршына килеп туктады, карашы белән янә бораулап алды. Соравы да көтелмәгән рәвештә килеп чыкты.

—Калачык кальгасы ничек утыра анда? Диварларын таштан сала башламаганнармы, кенәз?

—Юк, имән бүрәнәләр эчендә утыра әле ул.

Андрейның шул жавабы да житә калды, Ибраһим бәк кулы белән ботына чаба-чаба тезә башлады.

—Менә, күрдегезме?—Аның сүзләре тагын энекәшләренә юнәлтелгән иде.—Атагыз Шәмгунь хан ничәмә-ничә кат әйтә килде ана. Мин күпме тукыдым. Ә Бәшәр бәк төкереп тә бирми. Муромныкылар илә рязаньлылар ничә кабат кальганы талап вә яндырып китте. Ә монын бер гаме юк. Мәнсез!..

—Кенәз! Сездә...

Ибраһим бәк ниндидер сорау бирергә жыенган гына иде, шулчак кинәт ишек ачылып китте һәм залга чалмасы шикелле үк ап-ак сакаллы бер карт килеп керде. Ана әле илле генә тирәседер, гәүдәсе төз, таза, ләкин шул чал сакалына, тирән жыерчыклар яткан йөзенә карап, аның яшен дөрес чамалау шактый читен иде.

—Әссәләмүгаләйкүм вә рәхмәтулла, әмирләр!—дип, ул иң әүвәл ил-йортның хужаларына сәлам бирде. Аннары уң кулына тоткан сөян таягын ишек катына сөяде. Ул кунакларны бертын күздән кичереп чыкты да, башлап, һич тә ялгышмыйча Андрейга таба атлады. Картның керфекләре тирәли һәм ирен читләре буйлап эчкерсез елмаю таралган, күзләре дә садә, самими караш белән нурланган иде.

—Чит мәмләкәттән олуг кунак килгән, ә сез эндәшмисез дә,—дип, атлап килешли үк зарланды ул. Аннары ике кулын да Андрейга сузды, гәүдәсе дә беркадәр иелгәндәй булды.

—Әссәләмүгаләйкүм, кенәз. Ошбу сәфәрен соңгысы булмасын, Болгар илә Суздәл кенәзлеге арасында монафикълык[1], хыйлаф гамәлләр юкка чыгып, аларны санәгать[2], тәжарәт[3] вә гыйлем өлкәсендә бәгланышлар гына алыштырырга насыйп әйләсә иде.

—Амин!—дип, әлеге карт сүзен башкалар да мөһерләп, жөпләп куйды.

—Ә син атаңа бик тә охшагансың, кенәз.—Андрей Яким тәржемә иткән сүзләрне тыңлый иде, шунадыр карт беркадәр тын торды.—Моннан утыз сәнә элгәре мина Юрий кенәзне хозурларга насыйп булган иде. Син тач шул икәнсен. Атасына охшаган бала бәхетле була, диләр. Ходай Тәгалә һәр икегезгә озын гомер бирсен.

Шул сүзләрдән соң гына, ак сакаллы карт хужаларга таба атлады, һәркайсы белән кул биреп һәм бөгелеп исәнләште. Ләкин сәер хәл: әмирләр бил бөгеп кенә калмый, иелеп, чал сакаллы картның кулларына иреннәрен дә тидереп ала иде. Әлеге сәерлекне Андрейның янына килеп баскан Әрбәт ачып салды.

—Давыт сәет бу, мәмләкәтебездәге дин башлыгы.

Дога укырга дип болгарлар келәм өстенә чүккәч, суздальныкылар да стена буена жәйлап утырдылар. Догадан соң, һәркайсының карашы сәеткә төбәлде. Һәммәсе дә аннан хикмәтле берәр сүз көтә иде. Ләкин

[1]монафикълык—икейөзлелек.
[2]санәгать—һөнәрчелек.
[3]тәжарәт- сәүдә.

чал сакаллы сәет авыз ачарга да өлгерә алмый калды. Янә кинәт ишек шыгырдады һәм залга җилән итәкләре яртылаш янып беткән, үзе кара корымга баткан бер ир килеп керде. Ул залда ике дистәгә якын ир-атны, хәтта сәетне күрүдән дә каушамады. Атыла-бәрелә түргә узды да, Ибраһим бәк янына тезләнеп, аның колагына яна-пешә нидер пышылдарга кереште. Берничә мизгелдән соң ук Ибраһим бәкнең йөзе кара көеп чыкты, кашлары борын өстенә дугаланып килде, йөзеннән нур качты.

—Ә Хәнәфи углан анда ни караган?—дип ачгырып дәшкән беренче соравы бөтен залга яңгырап ишетелде.—Корымга баткан ир-ат эндәшмәгәч, Ибраһим бәк сүгенә-сүгенә урыныннан купты. Кунаклардан бигрәк сәет тарафына борылып, өч-дүрт җөмлә ташлады.

—Яңа утчагыр[1] ясарга фәрман биргән идем. Шәрҗир[2] шартлаткаиннар. Бер гази һәлак булган. Янына бармый булмый. Син монда үзең кара инде, сәет хәзрәт.

Ибраһим бәк артыннан шалтырап ишек ябылды. Зал кабер тынлыгы эченә чумган сыман булды. Сәет ниндидер дога укып алды, аңа кушылып барча ирләр йөзләрен сыпырып куйды. Тынлык, ниһаять, кунакларга яңа чәй, хәлвә, җимешләр китергәч кенә тарала башлады. Андрей сорашмаса да, чәй артында, пышылдап кына, Әрбәт үзе сәет турында сөйләүне кирәк тапты.

—Бездә ахирәткә күчкән кешеләрне генә изгегә санап искә алу гадәте бар. Ә менә сәет Давытны инде хәзер үк мәмләкәттә күпләр изгегә санап йөри. Үзе дә гаять гыйлемле һәм гадел. Өстәвенә, сәетебезнең каны да изгеләрдән. Аның шәҗәрәсе Мөхәммәт пәйгамбәргә үк барып тоташа, диләр. Ни дәрәҗәдә хактыр, анысын мин белмим. Мәгәр үз бабасы—Якуб ибне Ногман, валлаһи, изгеләрдән. Ул шушы калада казый булып торган. Гаделлегенә таң калганнар. Ханнарны да һич курыкмый тетә торган булган. Менә шул Якуб карт халкыбызга «Болгар тарихы» дигән искитмәле китап язып биргән.

«Тарих» сүзен ишетүгә үк Адрейның колаклары үрә торгандай булды. Хәтерендә шундук Киев монахы Нестор исеме яңарды. «Кызык, бездә дә, боларда да ил тарихын дин әһелләре язган икән,»—дигән уй зиһеннән капылт йөгереп узды.

—Мәдрәсәләрдә барча шәкерт хәзер шул «Болгар тарихы»н укып гыйлем эсти.

Әрбәт туктап калды, йөзенә сагыш инде. Чәе инде суынып бетсә дә, шуңа өргән булып байтак тын утырды. Тавышы да яңадан зәгыйфьләнеп, калтырап ишетелде.

—Якуб ибне Ногман унбиш-уналты ел элек гүр иясе булды. Андый аяныч үлемнән Ходай Тәгалә берүк саклый күрсен.

Әрбәт тын алгандай итте, шул арада Андрей зиһенендә яңа ачыш пәйда булып узды. «Менә гаҗәп! Безнең Нестор да илле еллар элек дөнья куйган. Димәк, бу ике гыйлем иясе дә бер үк заманда гомер иткән. Шулай да безнең Нестор үзенең елъязмасын алдарак язып өлгергән».

—Егерме еллар элек Болгарда Тулгак Хәйдәр атлы хан утыра иде. Юк, аты «Тулгак» түгел, ә лякабе шундый. Анысын халык кушкан. Чамадан тыш дәү корсаклы булганы һәм бертуктаусыз игенчеләрне талаганы өчен... Мин ул чакта Бохарада укып ята идем. Һәммә нечкәлекләрне белеп тә бетермимдер. Шәмгунь атамнан ишеткәннәремне генә сиңа сөйлим... Тулгак Хәйдәргә кадәр утырган ханнар заманында игенчеләрне «субаш» һәм «ак чирмеш» дигән катламнарга теркәп йөрткәннәр. Алар шул катламга карап еллык салымын түләгән. Ә Тулгак Хәйдәр тоткан да бер елны субашларны—ак чирмеш, ә тегеләрен кара чирмеш дәрәҗәсенә төшергән. Болай иткәч, салым түләү күләме икеләтә арткан. Әлбәттә

[1]утчагыр—утлы чүлмәк ыргыта торган җайланма, катапульт.
[2]шәрҗир—нефть тутырылган металл чүлмәк. Аны нефтенә ут төртеп очыра торган булганнар. «Шәрә җир» сүзеннән ясалган.

инде, субашлар һәм ак чирмешләр фетнә кутәргәннәр. Хәйдәр хан аларга каршы казанчыларны юллаган. Яу артыннан яу купкан, бик күп кан коелган. Менә шул чагында инде Якуб ибне Ногман да түзеп кала алмаган. Баш казый булып утырган шушы изге кеше халык алдына чыгып Хәйдәр ханны сүгә башлаган. Аны комсызлыкта һәм кансызлыкта гаепләп оялтмакчы булган. Мәгәр чылбырын салган этне сүз белән генә кабат оясына кертеп буламыни? Житмәсә, жилгә каршы очырган төкерек тә йөзенә ләм булып кайта бит ул. Мөгаен, Якуб казый да анлагандыр моны. Мәгәр курыкмаган, һәр жирдә Хәйдәр ханны золымлыкта гаепләп сөйли биргән.

Әрбәтнең йөзенә кара күләгә ятты, ул хикәянең ахырыннан курка иде бугай. Туктап чәй чөмерде. Салкын чәй янган йөрәген баскан кебек булды.

—Ә кансыз Хәйдәр хан тәмам шашкан, ахры. Ул беркөнне Якуб казыйны зинданга ыргытырга, дип әмер биргән. Казый анда да тез чүкмәгән. Зиндан тәрәзәсенә килеп, узгынчылар каршында һаман ханны сүккән. Шуннан соң хан әмере буенча башта аның күзләрен чокыганнар, аннары инде телен дә кисеп алганнар.

Безнең явыз Давид Теребовль кенәзе Василькоңың күзләрен генә чокыган. Ә боларның ханы безнең Давидны да уздырган икән»,—дип уйлады Андрей. Сагышлы тавыш белән Әрбәт хикәясен очлап куйды.

—Үзенең соңгы көннәрендә Якуб казыйны базарларда думбыра чиертеп жан асраган, диләр. Вафат булгач, аның женазасын да ханнан яшереп кенә жирләгәннәр, ди. Изге кабере кайсы тарафтадыр—безгә әйтүче юк. Мәмләкәт тарихын язган гыйлемдарның аянычлы вафаты әнә шундый.

Әрбәткә генә түгел, Андрейга да моңсу, авыр иде.

—Ә теге ханыгыз хәзер кайда инде?—диде ул.

—Якуб казый вафатыннан соң вилаятьләрдәге байтак игенчеләр коралга тотынганнар. Шул игенчеләр хан алаен куып тараткан. Тулгак Хәйдәр үзе кыпчак даласына качып киткән.

Икесе дә, сиздермичә генә, сәет Давытны күзәтеп утырдылар. Беркадәр вакыттан соң Әрбәтнең йөзенә елмаю инде. Ул, ияк белән генә кагып, сәет Давытка таба ымлады.

—Безнең сәетне бабасына бик охшаган, диләр. Әллә шуна инде, халык аны һәр жирдә жылы каршылый. Ходай Тәгалә Якуб казыйның бу оныгын бәла-казалардан саклый күрсен иде.

Әрбәт белән Андрей—икесе тин соклану белән сәеткә төбәлделәр. Әрбәтнең теләге изге, әмма Якуб ибне Ногман оныгын да бу жиһанда никадәр үкенечле һәм аяныч язмыш көтүен әлегә беркем дә белә алмый иде шул.

## Өченче бәйләм

### I

Тагын ике кыш та үтеп китте.

Болгардан әйләнеп кайтканнан бирле Андрей нәкъ өненә кереп качкан аю сыман гел үз йортында бикләнеп яшәде. Дөнья белән алыш-бирешне ул туктаткан, яшәү рәвеше дә ялгыз монахныкыннан кайтыш түгел иде. Сенелесе Осланбикәне Хәмбәлгә калдырып кайтканнан соң, Байгөл дә канатлары каерылган аккошка охшый башлады. Ул күпчелек вакытын үз бүлмәсенә бикләнеп үткәрә, күнеле ятим калган баланыкыдай боек, аздан гына да ярсый һәм көчләп тартылган имчәк сыман савылып-савылып елый башлый иде. Апаларының газапларын тоеп, янына энекәшләре ешрак кереп йөрде. Ләкин алар да Байгөлне юатырдай сүзләр таба алмый, күбрәк вакытларын Андрей белән әнгәмәдә үткәрәләр иде.

Андрей үзе ишетергә һич теләмәсә дә, ишекләрне, ярыкларны

табып, колакларны сытып, йорт эченә яңалыклар һаман агыла торды. Киевтагы олуг кенәз Изяславның азынуы житкән, ул зур гаскәр белән барып, Төньяк Новгород каласын тимер божра эченә алган икән. Икейөзле, аумакай Святослав солых тәкъдим иткән, олуг кенәзгә тугры булырга дип алтын тәре үпкән. Шуңа күрә генә Изяслав Төньяк Новгород каласын жимермичә калдырган. Ләкин олуг кенәз Киевка мондый ярты-йорты жиңү белән генә кайтырга теләмәгән. Святослав биргән Новгород дружинасын да ияртеп, Изяслав хәзер инде Галич жиренә юнәлгән, үзенең кан дошманы Владимирко кенәздән үч алмакчы булган. Әмма өлгермәгән. Нинди гажәеп хәл: нәкъ Изяславтан илче килгән көнне моңа кадәр чир һәм сырхауларның ни икәнен дә белмәгән Владимирко бик сәер рәвештә, кинәт вафат булган. Чит куллар агулап үтергәнме аны, әллә үзенең улы Ярослав этлек эшләгәнме?—бу кадәресен Ходай Тәгалә үзе генә белә. Ләкин икенче көнне үк инде Галич тәхетенә Ярослав менеп алган һәм, ни гажәп, ул да олуг кенәзгә баш иярга катгый каршы килгән. Изяслав белән Ярослав гаскәрләре Серет елгасы буенда бәрелешкәннәр. Ике яктан да меңәрләп ирләр үлгән, жиңү яуланмаган. Ярослав Теребовль каласына кереп бикләнгән. Изяслав үз кулына әсирлеккә төшкән йөзләрчә галичлыларны шәһәр стенасы каршына алып килеп, Ярославның күз алдында кырдыртып бетергән. Үзе шушы вәхшилекне бик зур жиңү дип кабул иткән, ахры. Киев каласына кайтып, ул инде туй үткәрә башлаган. Алтынчы дистәгә аяк баскан Изяслав унжиде яшьлек абхаз кенәзбикәсен хатынлыкка алган. Әмма канында ут шикелле Кавказ дәрте кайнаган яшь бикә карт кенәзнең желеген нык суырган, ахры. Изяслав инде, сырхауга сабышып, түшәккә дә егылган.

Ярымхакыйкать, ярымгайбәт булып янгыраган мондый хәбәрләрне ишетү Андрей өчен аянычлы да, көлке дә иде. Ә Изяславның «мәрхәмәте» белән Ростов каласына күчкән Юрий кенәз, әнә, әсәренгән. Тиздән мәетләр буласын сизенгән карга сыман ул инде Козельск шәһәренә чыгып киткән. Шунда туктап, үз канаты астына яңа гаскәр туплый башлаган. Әтисе юллаган чапкын Андрейга да килде. Ә Андрей, үзен сырхау итеп танытып, һаман өй эченә бикләнеп ята бирде. Әмма тәкъдирдә язганы—ул тау түгел, кыя, аны урап үтү мөмкин түгел икән.

Жир өстенә яңа кар ятуга, энекәше Глеб юллаган гаярь чапкын килде.

—Хаким Изяслав вафат! Киев боярлары аның урынына Бөек Новгородтан бертуган энесе Ростиславны чакырып китергәннәр. Сезнең агагыз—карт Вячеслав—Ростислав ягына ауган. Юрий кенәз дәгъвасыннан шөлләп, шулар Киевка угыз, бәрәндиләрне дә чакырып китергәннәр. Козельскига килеп, атагызга кушылган Святославны да сатып алганнар. Олуг кенәз урынына менгән Ростивлав Пинск һәм Туров калаларын биргәч, теге хыянәтче синең атаңны ташлап киткән. Глеб энекәшең, чапкын юллап, кыпчакларны дәште. Алар килүгә үк Ростиславка каршы яуга кузгалачак. Глеб сине үз янына дәшә. Синнән кичектергесез һәм олы ярдәм кирәк, батыр кенәз.

Чапкын тезгән әлеге хәбәрләрне ишетүгә үк Андрейның йөрәгендә ярсу-нәфрәт язгы ташкын булып күтәрелде. Киевның жыен кол бояры инде ничәнче мәртәбә аның әтисен усал мәсхәрәли. Күпме түзмәк кирәк? Юрий кенәз—Мономахның асрауга алган чит-ят углы түгел. Аның абыйсы Мстиславныкылар гына ала карга да, Киев тәхетенә фәкать алар гына лаекмыни? Гел башын иеп йөргән кешенең түбәсенә төкеріләр бит ул. Әгәр һаман-һаман түзеп торачак икән, Юрийныкылар, үз колагын күрә алмаган кешеләр сыман, Киев тәхетеннән мәңгелеккә мәхрүм калачак.

Өненә кереп качкан аю тормышы белән яшәү дә нык туйдырган иде. Андрей ашыгыч рәвештә походка хәзерләнә башлады. Һәр тарафта йокысы туеп уянган кешедәй каударлык күрсәтте, тиз арада үз кул астына мең кешелек дружина туплап куйды. Шулай да, Козельск каласына барып кушылганда кышның яртысы инде үткән иде. Әтисе аны көтмәгән,

хәйран салмыш, ул яна гына туган улгынын «тәпиен юып» ята булып чыкты.

—Үги анан яна төпчек тапты. Минем угылым бар, унберенче угыл! Исемен Всеволод куштым, Всеволод!—дип, Юрий кенәз селәгәйгә батып беткән иреннәрен Андрейнын янагына төртте. Хәйран калырлык хәл—атасында тәхет, ил кайгысы бөтенләй юк иде.

Глебтан Козельскига да чапкын килеп житте.

—Кыпчаклар килүгә, алар белән барып, Глеб кенәз Переяславль каласын камалышка алды. Мәгәр калага бикләнгән Мстислав—вафат булган олуг кенәз Изяславнын углы—төп шикелле бик нык утыра. Өстәвенә, Киевтан ана ярдәмгә Ростислав та чыккан. Глеб кенәз сезнен Переяславльгә килеп житүегезне катгый таләп итә.

«Таләп итәргә башы бик яшь әле,—дип фикер йөртте Андрей, һич тәгәрәп төшмичә.—Бик елдам хәрәкәтләнә башлады бу энекәш. Әтисен дә, абыйсын да узып, Киев тәхетенә утырмакчы бугай. Урманга ашыкма, кәжә, барча бүре синеке», дигән сыман артык каударланма, туган. Сиңа дигән тәхет дөньяга да яралмаган әле».

Андрей кенәз әтисен айнытуны, үгетләүне дә кирәк санамады. Һаман көтә бирде. Бу көннәрдә ул, чыннан да, чит кеше кулы белән утлы күмер тотарга хәзерләнгән хәйләкәргә охшап калган иде.

Атна-ун көннән сон яна хәбәр килеп ирешге.

—Глеб кенәз, Переяславльне калдырып, Чернигов жиренә чигенгән. Андагы кенәз Изяслав Давид углы да Ростиславнын хаким булуына нык ачулы икән. Глеб кенәз белән Изяслав дружиналары бергә кушылганнар. Мәгәр Киевка һөжүм итә алмыйлар, Вышегородка килеп, Ростислав аларнын юлын капылт бикләп куйган.

Икенче танда ук килеп житкән өр-яна бер хәбәр һәммәсен сискәндерде.

—Мономах нәселендәге ин-ин өлкән вәкил—карт Вячеслав вафат! Кичтән үз дружинасы белән лыкынганчы эчкән. Түшәккә күтәреп кенә кертеп сала алганнар. Төнлә акырып-бакырып аптыраткан да, аннары жан биргән. Ростислав аны жирләү өчен Киевка кайткан, диләр.

Андрей бу хәбәрне яшерен сөенеч белән каршылады. Әлеге карт бертуган энесе Юрий кенәзне гомер буе китмәс нәфрәт белән тинтерәтте. Нинди сәбәптәндер ул һәрчак Мстислав атлы туганын яклап чыкты, ә Юрийга һаман аяк чалды. Инде, менә, вафат. Аннан котылдылар. «Синен хокукың юк, канун бозасың!»—дип Юрий кенәзгә тәхет юлын бикләргә хәзер һичкем жөрьәт итә алмый. Алтмыш дүрт яшьлек Юрий—Мономах нәселендә бүген ин өлкәне. Олуг кенәз урыны, барысыннан элек, ана тиеш. Ләкин уяу булырга, йокламаска, көрәшергә кирәк!..

Юрий кенәзне айнытып, походка жыенганчы байтак вакыт узды. Ул арада яна хәбәр алдылар.

—Ростислав, киевлыларны, угыз бәрәндиләрне жыйнап, Чернигов жиренә юнәлгән. Изяслав Давид углы белән Глеб гаскәре аны Белоус елгасы буенда каршылаган. Глеб кул астындагы кыпчакларны күреп, Ростиславнын тәмам коты очкан. Ул Глебка—солых, Изяславка Переяславльне тәкъдим итә башлаган. Агасы күрсәткән куркаклыкны шәйләп, элеккеге олуг кенәзнен улы Мстислав яу кырын ташлап киткән.

Шул сәгатьтә үк Юрий белән Андрей Козельскига тупланган бар гаскәрне иярә күтәрделәр. Вакытны сузарга ярамый, һәр минутнын тау-тау алтыннардан да кыйбатрак чагы иде. Атларны-арбаларны кызганып торучы табылмады, һәр кенәз, артына ут капкандай, дружинасын Киевка таба куды. Әмма табигатьтә яз уянып килә, шул хәрәкәтне нык тоткарлый иде.

Күмәк гаскәр Смоленскига якынлашкан чакта атын шабыр тиргә батырган чапкын аларны ут шикелле, көтелмәгән, хәбәр белән каршы алды.

—Глеб әллә сезне көтеп, әллә Чернигов кенәзе Изяславнын көчәюен-

нән шөлләп, үз дружинасын яуга кертми торган. Шул арада Изяслав үз кул астындагы көчне күтәргән дә, киевлылар гаскәрен пыран-заран китергән. Ростислав олуг кенәз булудан баш тарткан, аны Смоленскига кайтарып җибәргәннәр. Киевнең мәкерле боярлары хәзер Изяслав Давид углын олуг кенәз итеп чакыра икән. Ә Изяслав, үз ягына аудармакчы булып, Глеб кенәзгә Переяславль каласын биргән...

Юрий кенәзне дә, аның янәшәсенә баскан барча улларын да аяз көнне яшен суккан кебек булды. Хәбәр—коточкыч; ашыгыч чара күреп өлгермәсәләр, Киев тәхете янә Юрий кенәзнең борын төбеннән ычкыначак иде. Атларны, олауларны тагын аяусыз рәвештә куалый башладылар. Чакрым саен дистәләгән чаптар ябып ава барды. Ярларыннан ташыган инеш-елгаларны кичкәндә атлар гына түгел, сугышчылар да батып харап булды.

Смоленскида аларны инде олуг кенәзлектән куылган Ростислав белән мәңге икейөзле булып, әле Юрий, әле Мстиславныкылар ягына авып йөргән «умырткасыз» Святослав кенәз көтә иде. Аларның кул астында да дружиналар бар икәнен белгәч, Юрий кенәз икейөзлеләнеп, уйнап маташмады, максатын турыдан ярып салды:

—Мономах нәселендә мин бүген—иң өлкәне. Зирәк Ярослав кануннары буенча, олуг кенәз урыны миңа тиеш. Дружиналарыгыз белән миңа кушылыгыз. Туену өчен һәркайсыгызга өстәмә калалар бирергә вәгъдә итәм. Киевка юнәлик тә, аны тизрәк яулыйк. Һәммәсе дә сез дигәнчә булыр...

Тагын да көчәеп алган гаскәр егерменче мартта Киевка килеп җитте. Шәһәр аларны капкаларын бикләп каршылады. Юрий кенәзнең котырынуына чик-чама юк иде. Нинди нәгаләт төшкән кала булды соң бу?! Моңа кадәр дә Юрий аны өч мәртәбә камалышка алган, икесендә шәһәрне яулаган да иде бит инде. Менә, дүртенче кат камау. Бәреп керә калса, монысы инде Киевны өченче тапкыр яулап алу булачак. Өченче кат яулау! Иң изге сан! Кешелеген сынау өчен һәркемне өч кат сынау кирәк, ялгышса да адәм баласына төзәлү өчен өч мөмкинлек бирергә кирәк, диләр. Алтмыш дүрт яшенә җиткән Юрий кенәз—Мономахның улы!—инде бу юлы да изге атасының урынын яулый алмасмыни?!

Киевка илче итеп Юрий үз тиунын юллады.

—Изяславка тапшыр,—диде ул аңа катгый тавыш белән.—Мин күп түздем. Киев миңа тиеш. Үз ихтыяры белән ташлап чыкмый икән, мин Киевтан көл генә калдырачакмын. Ходай шаһит, хакыйкать минем якта!..

Әлләни озак көтеп җәфа чикмәделәр. Әүвәл Юрийның тиуны күренде, аннары чит-ят күзләр каршында нарасыен имезергә читенсенгән яшь ана сыман көттереп-ялындырып кына шәһәр капкалары ачылды.

—Изяслав синең гафу итүеңне сорый,—дип, тиун Юрий каршында, беренче булып, сынар тезенә чүкте.—Котлыйбыз, Киев синеке, олуг кенәзебез!

Капкалар каршында кулларына алтынланган, көмешләнгән зур-зур иконалар, ипи-тоз, мул бүләкләр тоткан руханилар һәм боярлар төркеме пәйда булды. Шәһәр өстен чиркәү манараларындагы бакыр чаңнар шавы күмеп китте. Юрий кенәз янакларына бәхет сытып чыгарган яшьләрне яшермәде.

Бу көн тарих тәгәрмәчендәге бер мең йөз илле бишенче ел әйләнәсе иде.

## 2

Андрей алда ярылып яткан такыр юлны ташлап, читтәге биек калкулык өстенә менеп басты. Прокопий белән Козьма да аның эзенә басып килә иде. Андрей аларга юлда туктап калырга әмер бирде. Тегеләр «кенәз яңа биләмәсенә күз төшерергә җыена, күрәсең», дигән нәтиҗә ясадылар да, сүзсез буйсындылар. Калкулык алдында, чыннан да, уч төбендәгедәй аерым-ачык булып, Андрейның яңа биләмәсе—

Вышегород каласы ята иде. Әмма ул кала кенәзне һич тә кызыксындырмый, Андрейның бар теләге япа-ялгыз калып, күнелендәге иң яшерен уйларны, иң олы ниятләрне ахыргача ерып чыгу иде.

Менә, бер атна буе айныр-айнымас көе тантана иткәннән соң, Юрий кенәз үзенең улларына янадан-яна кала-биләмәләр бүлеп чыкты. Үзе өчен кечерәйгән, искергән киемнәрне энеләренә өләшүче «мәрхәмәтле, юмарт» өлкән ага кыяфәтендә бүлде ул аларны. Әйе, артык та, ким дә түгел, нәкъ иске киемнәрне өләшкән кебек бүлде. Гәрчә инде Изяслав тарафыннан бүләк ителгән булса да, әтисенең «юмартлыгы» белән Глебка шул ук Переяславль эләкте, ягъни кат-кат тамгаланды. Андрейның башка туганнары—Борис, Василий, Мстислав—Рось елгасы буен, Туров, Бөек Новгород калаларын алды. Башка «тугры көрәштәшләре» дә Юрий кенәзгә рәнжеп китмәгәндер. Кичә хаким булып йөргән Ростислав шул ук Смоленск каласына тәгаенләнде. «Күндәм» Изяслав Давид углы үзенең Чернигов каласына «шат» кыяфәт белән кайтып китте. «Умырткасыз» Святослав Олег улының да үпкәсе калмагандыр. Олуг кенәз ана «тугрылыгы» өчен Снов, Воротынск, Карачев калаларын «бүләк итте».

Әлбәттә, Юрий кенәзнең Андрей кылган «изгелекләрне» онытырга да хокукы юк иде. «Ярдәм кирәксә дә кул астымда гына, өстеннән күзколак булу өчен дә унайлырак»,—дип уйлагандыр инде. «Кушйөрәкле» улына ул пайтәхеткә иң якын урнашкан Вышегородны бирде. Андрей Бөек Новгородка утырырга лаеклырак идеме, әллә Переяславльгәме?—анысы вак мәсьәлә. Иң мөһиме шул: әтисе кала-биләмәләрне үзеннән артып калганга күрә генә өләште. Туров, Смоленскиларның ана шәхсән кирәге юк, аларны «тугры» кенәзләргә бүлеп бирүе дә фәкать яхшатлану, тегеләрне үзенә буйсындырып тоту өчен генә. Житмәсә, әле шулары да вакытлыча гына. Святослав, Михаил, Ярослав, Всеволод кебек төпчекләре үсеп життеме, Юрий кенәз рус жирендә шундук янабаштан бүлү куптарачак. Бүген канәгать елмаеп киткән кемдер рәнжетеләчәк, кемдер таланачак... каннар коелачак! Ә бүген елмаеп киткән кенәзләрнең берсе иртәгә Киев хакименә кырын карый башласа яки тураебрак басарга жөрьәт итсә, андый бәндә турында гоманлап торасы да юк—ана якты көн бетәчәк. Шулай булгач... инде шулай булгач, кичәге тантаналар, ант эчүләр, биләмә өләшүләр—болар һәммәсе дә санаулы айларга гына исәпләнгән уен түгелме соң?

Ярар, Андрейның үзенә жил тимәсен, ул әтисенең куены астында «үгез үлсә—ит, арба ватылса—утын», дип кенә яшәсен дә ди. Ләкин берзаманны аның үз уллары—Изяслав белән Мстислав үсеп житәчәк һәм көннәрдән бер көнне аларга да биләмә кирәк булачак. Ә Андрейның бүген исән-имин көе яшәп ятучы туганнары гына да сигезәү. Алардан туган балаларның утыз-кырыкка кадәр житүе дә мөмкин. Ходай Тәгалә каршында аларның һәммәсе бертигез, һәркайсының Юрий кенәздән аерым биләмә дәгъваларга тулы хокукы бар. Ул чакта бабалары нишләр? Олегныкыларга, Святослав, Мстиславныкыларга каршы яу чыгармы? Тик ул бүген Чернигов, Туров, Смоленскига хужа булып утырган кенәзләр дә кайчандыр Киев хакимнәре булган Мономах, Зирәк Ярослав, «Кызыл Кояш» Владимирдан туган уллар-оныклар бит. Һәрбер буын саен дүртәрбишәр мәртәбә ишәя баручы кенәзләргә янадан-яна йөзәрләгән кала төзеп өлгертү һич мөмкин түгел. Әле киресенчә, аның булганнарын да жимереп торалар бит. Үзара яу, талау һич тукталмый һәм рус жирендә тормыш кору шул көенчә барса, ул мәнге дә тукталачак түгел.

Андрей бу фикер-мөмкинлекләрнең һәммәсен дә, менә, Ходай Тәгалә аның әтисенә озын гомер бирер дигән күзлектән чыгып гоманлады. Ә Юрий кенәз әгәр ике-өч елдан соң ук дөнья куйса? Ул чагында шул ук бүген Мономах нәселенә тугры булырга ант эчкән Олег-Святославныкылар башларын калкытачак. Хәтта, Глеб энекәше дә, Андрейны узып, Киевка ыргылачак. Яна яу, коточкыч кан кою чыкмасына бер кәррә ышаныч та юк бит. Киев тәхете әле беренче елында ук кара канга батып

өлгергән. Шуннан соңгы өч йөз ел буена ат үләксәләре астында изелеп үлгән Олег, сөңге белән кадалган Борис, кылычлардан туралган ике Ярополк, пычак белән суелган Глеб, сукырайтылган Василько, агуланган Ростислав һәм тагын меңнәрләгән-меңнәрләгән бичараларның канын суырып торган бит ул. Киев каласы үзе дә, нигезләнгәннән бирле, тоташ кан эчендә. Барча мәхшәр, һәммә кан коюлар шушы каһәр суккан Киев белән тәхет аркасында гына килеп чыккан. Ходай Тәгалә бу шәһәрне мәңге ярлыка-маслык итеп каргады микәнни соң?..

Прокопий, тугры дус, «урыс жирендә өч йөз ел элек тә тәртип булмаган, хәзер дә юк», дигән сүзләрне кабатларга ярата, әледән-әле искә төшереп тора. Сүзләре хакыйкать шул, берни әйтеп булмый. Тәртип, тынычлык, байлык урыс жирендә мәңге булмаган һәм бик тиз генә булырга охшамаган. Кенәзенә тәхет даулашам дип, һәр ел саен меңнәрләгән урыс ирләре берсен-берсе кыра, кол итеп читкә озата, йөзәрләгән шәһәр-авылларны талый һәм яндыра. Ә шул ук вакытта күршедә генә урнашкан Болгар иле күкрәк киереп, чәчәк атып утыра. Дистә еллар буена үзара яу чыкканнары ишетелми. Һәммә бәк-әмирләр, бер гаиләдәге балалар шикелле, ханга буйсынып яши. Хан кайсын кая тели, шунда күчереп куя. Ә бәкләрнең шылт иткән тавышлары да юк. Алай гына түгел, шул ук хан, әгәр кирәк тапса, пайтәхет кадәр пайтәхетне бер каладан икенчесенә күчереп куя. Ничек шулкадәр килешеп, тату итеп яши белә икән болгар халкы?

Пайтәхет... Башкала... Әллә соң безгә дә пайтәхетне, алар үрнәгендә, икенче калага күчереп куяргамы? Ходай Тәгалә каргаган, тоташ канга баткан Киев каласыннан шулай котылыргамы? Ләкин кайсы шәһәргә? Иң мөһиме, ничек итеп? Бу хакта сүз кузгатсаң, Юрий кенәз мәңге риза булачак түгел. Ул Киевны дүрт мәртәбә камалышка алып, өч кат бәреп керде. Җинүне бик авыр яулады. Шуна күрә аның өчен Киев—изге, кадерле бер шәһәр.

Аннары, аннары... Тиктомалга гына пайтәхетне алыштырудан да һичбер файда юк бит. Тәхет өчен үзара яу туктатылмый икән, яңа башкала да биш-ун ел эчендә тоташ кара канга күмеләчәк. Димәк, иң элгәре, тәхет өчен кан коюны туктатырга кирәк. Ничек? Әнә, нәкъ болгарлар кебек. Тәхет варисы булмаган балаларга аерым биләмәләр бирүне катгый тыеп. Менә шул чагында урыс кенәзләре арасында да үзара яу йөрүләр бермәлне тукталачак. Аннары инде һәрбер биләмәнең хуҗасы олуг кенәз авызына гына карап торачак. Кан коюлар булмагач, халык ишәячәк. Игенчелек, һөнәрчелек, төзелеш, сәүдә фәкать үсешкә таба гына юл алачак. Ниһаять, урыс жирендә дә чып-чын дәүләт хасил булачак!

Бик якты, җылы хыяллар бу. Ләкин, ләкин... Безнең берәр генә кенәзне булса да балаларына биләмә бирүне туктату хакында үгетләү, шул юл белән китсәк урыс жиренең чәчәк атасына ышандыру мөмкин хәлмени? Бу турыда сүз кузгалтуга ук теге кенәз шундук Андрейны суеп үтерәчәк, хәтта, инде качып котылса да, җүләргә чыгарачак бит. Нинди юл кала соң? Әрбәт әйткәнчәме? Ул ничек дип аңлатты соң әле?

—Кенәзлегең дәүләтнең читендәрәк торсын.

—Кул астыңа биш-алты шәһәр тупла. Аларның берсен дә туганнарыңа бирмә.

—Фәкать үзеңә генә буйсына торган көчле гаскәр булдыр.

—Кенәзлегеннең чикләрен һәм калаларын кирмәннәр төзеп ныгыт.

—Мөстәкыйль кенәзгә әйләнүеңне башкалар арасында үзара яу барган чакта игълан ит.

Әйе, әйе! Аягы чонтык әмир һәммә шартны нәкъ менә шул рәвештә санап чыккан иде. «Эре балыкны су болганчык чакта эләктерәләр!»—дип тә өстәде бит әле. Димәк, ул Андрей күңелендә янган утны әле шул чагында ук үтәли күреп торган. Әмма дошман дәүләт әмире булса да, чонтык Әрбәт икейөзлеләнеп маташмаган. «Рус кенәзлекләрен бер йодрыкка төйнәп, камил дәүләт төзим» дигән максат куйса, Андрейга

Әрбәт санаган шартларны үтәргә генә кала. Беренчесе—чит-ят күзләрдән, көндәшләр үченнән читтә утырган кенәзлек. Сайланып тору юк, димәк, Суздаль.

Вышегород ягыннан чиркәү чаннары чынлаган аһән ишетелде. «Минем максатымны чиркәү дә хуплый түгелме сон?»—дигән кайнар өмет Андрейның зиһенен яндырып узды. Ин биек чиркәү ягына борылып чукынды да, аргамагын чаптырып, Андрей калкулыктан төште.

—Вышегородта, чиркәүгә кереп, гыйбадәт кылу өчен генә тукталабыз,—дип кычкырды ул үзенең дистәләрчә яуларда сыналган дружинасына.—Аннары безне изге юл, олы максат көтә.

Вышегород чиркәвендә Андрей попка ялваргандай итеп гозерләде:

—Мин бик тә авыр, әмма изге юлга чыгам, атакай. Бик күп җәфа кичәргә, гел түзәргә туры килүе бар. Бәлки, минем хакта «акылдан шашкан», дип әйтүчеләр дә табылыр. Ләкин күнелемдә һичбер мәкер юк. Мин халкымның кан коюлардан азат, тыныч, мул, камил дәүләт булып яшәвен телим. Әгәр син дә шуны теләсәң, изге юл башында фатиха бир һәм хәерхаһ бул мина, атакай.

Андрейның янаклары буйлап тоташ яшь ага иде. Мәһабәт гәүдәле поп әүвәл аны күкрәгенә кысты. Аннары чиркәүнең альтарына таба юнәлде дә, стенадагы ин-ин затлы—алтын, көмеш, җәүһәр асылташлар белән бизәлгән иконаны алып, янә кенәзнең каршына килеп басты.

—Син иң изге юлга аяк баскансың, кенәз. Тулы җинүне син, бәлки, бер үзең генә яулый да алмассың. Башлап йөрүчегә һәрвакыт авыр. Тик, шикләнмә, кенәз. Син кузгаткан изге эшне үзеңнән соң килгән энеләрең, угылларың дәвам итәр. Һич югы оныкларың булса да җиңеп чыгар. Син менә бу иконаны үзең белән ал. Шушында сурәтләнгән Изге Мария сине ялгыш адымнардан, кызулыктан, дошманнарың үченнән сакласын. Тагын шунысын да онытма. Дәүләтләрне, халыкларны көчле дин берләштерә. Денсез дәүләтнең юлы җинелүгә илтә. Изге сәгатьтә, кенәз. Ходай Тәгалә сине ярдәменнән ташламасын.

Шул көнне үк дружина Суздаль каласына төбәп юлга чыкты.

## Дүртенче бәйләм

### 1

Ясүгәй баһадир бүген Онон елгасы буена ауга чыкты. Башка чакта, ауга дисән, кыят ыруындагы ирләрнең берсе калмый, өстәвенә алар әле үзләре белән жинел тирмәләр, оста бавырчылар гына түгел, хәтта төнлә ат каравыллау өчен коллары—тотыкларны да ала торганнар иде. Ә бу юлы Ясүгәй үзе белән жиде-сигез генә ир ияртте. Чөнки аңа буйсына торган ыруның байтак күремнәре* Онон белән Керулен елгалары арасында жәйләүләр буйлап таралган, Ясүгәй янында аның энеләре Дәритай, Тайчу, Канун карамагындагы бер нәсел кавемнәре генә калган иде.

Кыятлылар аз түгел-түгелен, жәмгысы унбиш меңләп тирмә исәпләнә. Тик шулай да саклык комачауламый. Моннан кул сузымында гына агып яткан Керулен елгасы да, аның сулъяк яры буйлап жәелгән сусыл үзәнлекләр дә—кара татар ыруының жирләре. Ул гына да житми, шул татар ыруының йә төрбән, йә жыен кабиләсе магуллар хужа булган Онон янына да килеп чыккалый. Төрбәнлеләр килсә, әлләни шөллисе юк—алардагы арба-тирмә саны искитмәле түгел. Мәгәр инде жыенлылар күренсә, алар белән орышка керүдән Мәңгелек Күк Тәнре берүк үзе сакласын. Кара татар ыруының әлеге иң хәтәр кабиләсендәге тирмәләр саны утыз меңнән арта. Ким дигәндә утыз күремлек кабилә! Шул күремнәр санына карап әлеге кабиләне «утыз татар» дип йөртәләр дә инде. Кара

татарларның саны анда гына да бетми. Аларның тагын Далай, Буир күлләрен тирәләп утырган коңгырат, әбрибуир дигән кабиләләре дә бар. Аларга да Керулен, Аргын елгаларын кичеп магул җәйләүләренә керү берни тормый. Дөрес, соңгы елларда кара татарлар мүкләк сыер сыман әлләни сөмсезләнми. Ясүгәйнең әтисе Бәртән баһадир белән бертуган Кабул хан үз заманында аларны чит җирләргә борын тыгу гадәтеннән нык биздерде. Кара татарлар хәзер койрыкларын кыскан куян сыман тавыш-тынсыз яши. Тик шулай да... бер җыен кабиләсендә генә дә утыз күрем хәтле көч туплаган ул азгын татарлар магул җәйләүләренә дә нәфес сузмас, дигән ышаныч юк бит. Уяу булу, саклык күрә белү һич тә артык түгел. Менә ни өчен Ясүгәй баһадир кыятлыларны өлкән энекәше Дәритай кулына калдырды да, бер күнел ачып алырга, дигән карар кылып, ауга ялгызы диярлек кенә чыгып китте.

Ирләр инде күптән Ононның камышлы-таллы ярлары буенча таралдылар. Ясүгәй янында балачактан бирле аерылгысыз дусты Бүчек кенә калды. Алар атларын тышаулап өрәңгеләр арасына утларга җибәрделәр дә, аткы дип аталган җиңел җәяләрен генә алып, үзләре Онон яры буйлап киттеләр.

Күк йөзе чалт аяз, Ононның йөгерек дулкыннары өстендә кояш нурлары күзләрне камаштырып җемелдәшә иде. Тирә-юньдә шылт иткән аваз да юк. Камышлар арасыннан ара-тирә сөрән салган үрдәк, казгыш, торна тавышлары гына түгел, дулкыннан дулкынга сикереп уйнаган чөгә, чабак, корбан балыкларының чупылдавы да Онон өстендә яңгырап ишетелә. Ирләрнең аяк тавышыннан куркып уянган кондыз камышларны чыжылдатып уза, бераздан быгыр-быгыр килеп суга чумган аваз яңгырап ала.

Онон бу урында күл сыман киң булып җәелгән. Кызлар чәче сыман куе, көяз булып үскән камышлары-таллары арасында җайдак югалырлык. Һәр җәй саен биредә җәйрәннәр, кулан, поши, кыр кәҗәләре мыжгып тора. Саксызрак йөрсәң бүре, бурсык кына түгел, барс яки юлбарыс каршына да килеп чыгуың бар.

Ук һәм җәяләрен әзер тоткан хәлдә селәүсенгә охшап бик сак барсалар да, Ясүгәй белән Бүчеккә берни очрамады. Инде камышлар-таллар да сирәгәйде. Ононның кисәк борылып Хинганга таба юл алган терсәгенә килеп җиттеләр. Монда Ононның ярлары инде тоташ таштан тора. Ә бер ук очышы кадәрле ара узуга елга, кисәк сынган сыман, текә шарламага әверелә. Бер дилбегә буе биеклектән тирән чоңгыл өстенә аккан су гүләве Алатау кыяларына бәрелеп тагын да көчәя. Ләкин шушы шарламаны узуга елга кабат тына. Аскы якта ул тагын да киңрәк булып җәелә. Ярларының бер ягын вак ташлы комлыклар били, икенче ягы буйлап янә камышлыклар, куе таллык, яшел үзән сузыла.

Шарлама янына житкәч, һава җиләсләнде. Җәя тотып йөрү артык иде, уклар садакка салынды. Ясүгәй шарлама кырындагы шома ташларга тезләнде, очлы башлы кәпәчен салып озаклап су эчте, кулларын юешләп яңакларын, баш артына тарттырып бәйләнгән чәчләрен, култык асларын, күкрәген сыпырды. Шарлама өстеннән тирә-юньне, биек Алатау буйларын беркадәр күзәткәч кенә ул урыныннан кузгалды. Чаган, тупыл, карагач ботакларына ябыша-ябыша түбән төштеләр. Алда Соры-Айгыр үзәнлеге башланды.

Бер казан асарлык та вакыт үтмәгәндер, ирләр, сәер авазлар ишетеп, сагаерга мәҗбүр булды. Икесе тиң куе таллыкларны аралап су буена килделәр дә, каршы яктагы ярга текәлделәр. Онон өстендә әүвәл ат пошкырган, кубыз зеңгелдәгән, дөмбак дөңгердәгән тавышлар ишетелде. Бераздан гына Алатау өркәчләре арасында кәрван пәйда булды.

Өсләренә ап-ак киезләр тарттырып каплаган җиде арбадан хасил иде ул. Һәр арбага пар ат җигелгән, алар белән арбакашлар идарә итеп бара. Кәрванның алдына да, артына да бишәр җайдак тезелгән. Ләкин арбаларда да кешеләр шактый бугай. Һәрхәлдә, алдагы дүрт-биш арбадан

әле талга кунган кошлар шикелле чыркылдашкан кыз-кыркын, әле тыелып кына сөйләшкән ир-ат тавышлары ишетелеп куя.

Нәкъ Ясүгәй белән Бүчек поскан таллар каршына житкәч, алдагы жайдаклар тукталып та тормыйча елгага керә башлады. Атлар муеннарын сузып су эчәргә тотынды, шул хәл кәрванны тукталырга мәжбүр итте. Бу тукталуны сүзсез әмер дип кабул иттеләр, күрәсен, ташлы ком өстенә һәр арбадан егетләр, кызлар сикерешеп төшә башлады. Яшьләрнен һәркайсы пөхтә, бәйрәмчә киенгән, кызларнын чәчләрен чәчәкле такыялар, тәнкәле чулпылар бизи иде. Егетләр дә сынатмаган: һәммәсе дә баш очына ак киез кәпәчләр элеп алган, чигүле күлмәкләрен күбесенчә кызыл төстәге кушак буып тора.

«Туй»,—дип нәтижә ясады Ясүгәй. Ул инде алдагы арбага эленгән тураадагы болан мөгезе сурәтенә карап та кәрван ияләрен чамалаган иде. «Мәркетләр кәләш алып кайта».

Мәркет кабиләсе Байкүлгә кадәр сузылган Сәлингә елгасы ярларында, Камәр-Табан дип аталган тау буендагы үзәнлекләрдә яши иде. Онон буеннан ким дигәндә тагын ике атналык юл. Элекке заманнарда мәркетләр магул белән бер тугъма булса да, сонгы байтак елда алар кара татарлар белән кан алмашып яши. Алай гына да түгел, татарлар чакыру салса, шул мәркетләр хәзер шундук магулларга каршы күтәрелә. Чиннарга кушылып, шул ук мәркетләр дә магул кардәшләрен «кыргый татар» дип мыскыл иткән була. Әнә шундый хыянәтләре, якын тугъмаларыннан йөз чөергәннәре өчен магуллар мәркетләрне аеруча гафу итә алмый. Жай чыккан саен магуллар мәркет кабиләсен аяусыз талап тора. Дөрес, алар магуллардан шактый ерак яши. Ясүгәй шул ара ераклыгы турында кат-кат уйлады да, тәмам аптырап китте. «Жир арьягына килеп йөрмәсәләр, үзләрендә кәләш беткәнме? Әллә... әллә кәләшләре жәйрәннәргә дә биргесез бер сылумы?»

Ул арада кәрвандагы яшьләрнен күпчелеге аякларындагы күноек һәм тулаларын салып ташлаган, кызлар исә чыр-чу килеп елга суына кереп баскан иде. Баш арба янында бер-берсенен кулларыннан тотышкан егет белән кыз гына аерым басып калды. Болар киемнәре белән үк башкалардан нык аерыла иде, Ясүгәй әсәренеп текәлде. Киявнен аякларында күн итек, чигүле ак күлмәк өстеннән ул иннәренә кара төлке тиресеннән тегелгән кин бишмәт ябынган. Алтын йөгертеп бизәлгән билбавы кояш нурларында ялт-йолт килеп тора. Кәләш тә ярлы түгел. Зәнгәрсу төстәге ефәк күлмәк өстеннән сусар тиресеннән тегелгән жиңсез камзул кигән. Башында энже бөртекләре белән бизәлгән ак калфак.

«Берсе—мәркет, икенчесе кара татар булса да, кара кешеләр генә түгел инде болар»,—дип уйлап алуга ук Ясүгәйнен йодрыклары усал йомарланды. Анын уйларын раслагандай Онон өстендә чыр-чу килүче кызлар тавышы янгырап ишетелде:

—Чилу бәй, Айлы бикә! Бер-берегездән һаман туя алмыйсыз. Юыныр өчен генә булса да аерылыгыз инде!

«Әһә! Чилу дигәннәре мәркет бәге углы, кәләшен кара татарларнын бер кабилә башлыгыннан барып алган. Мәркет белән татар жүләр түгел, ике арада жиде дәрья ятса да туганлык жепләрен һаман ныгыта бирә. Шуна күрә аларны жину, буйсындыру кыен».—Ясүгәй беравык уйга чумып торды.—«Ә кәләшнен исеме бик матур икән. Айлы бикә, Айлы...»

Ясүгәй дикъкать белән яшь кызга текәлде. Айлы бикә инде сусар камзулын да, ак калфагын да салып ташлаган һәм ул, су эченнән акрын гына атлап, һаман Ясүгәйгә таба якыная иде. Ясүгәй ана төбәлде дә, агарынып калды. Анын үз гомерендә мондый чибәрне күргәне юк, Айлы бикә ана күктәге Мәнгелек Тәнре яныннан төшкән бер алиһә, фәрештә булып күренә иде. Гәрәбәдәй саргылт озын толымнар, саф күк йөзе кебек зәнгәр күзләр, алсу, тулы иреннәр һәм аккош канаты шикелле апак куллар. Ясүгәй яшь кызнын гәүдәсен-сынын да күрмәде, ул карашын аера алмыйча һаман-һаман шул аккош канатларын, житендәй аксыл-

сары чәч толымнарын гына күзәтте. Кабиләләр арасында сугышлар һич тукталмый, Ясүгәй кулы аша да күпме кырнак, күпме кәнизәк узды, әмма аның мондый саргылт чәчле, зәңгәр күзле, ап-ак тәнле хатынкызны күргәне юк иде. «Әллә күземә генә шулай күренәме? Тәңре сынамыймы?»—дип, куллары белән алиһә сурәтен куган кебек итте, яшь кыз югалмады. Алай гына да түгел, ул нәкъ башкалар шикелле үк су өстенә иелеп ап-ак кулларын, яңакларын юа башлады. Аның өстендәге зәңгәрсу күлмәк изүе кайтарылып төште, изү астында тулып ташкан алсу, зур имчәкләр сихерләп уйнаклады. Ясүгәй үз күкрәгендә тышауларын өзеп качкан ярсу ат шикелле кисәк шашып кабынган кайнар хисләргә түзә алмыйча күзләрен чытырдатып йомды, авыр ыңгырашып, куе таллар түбәнә чүгәләде.

Аны Бучекнең сак кына итеп иңбашына кагылуы айнытты. Ул ияге белән Онон өстенә ымлый, ә анда кәрван нәкъ Ясүгәйгә таба турылап елга аша чыгып килә иде. Ясүгәй барс житезлеге белән урыныннан купты һәм шылт иткән тавыш та чыгармыйча, камышларны артта калдырып, карагач, чаган куләгәләре астына кереп яшеренде. Туй кәрваны бу як ярга чыгуга тукталып тормады, Соры-Айгыр үзәнлеге буйлап Кәмәр-Табан тауларына таба юл алды. Ясүгәйне котырткан шикелле арбалардан һаман әле кубыз, әле дөмбак тавышы ишетелә, ул авазларның һәркайсы баһадирның йөрәген телеп уза иде.

Кәрван саксавыл, дуләнә, чаган агачларыннан торган куе чытырманлык артына кереп югалгач, Бучек телгә килде:

—Ә кәләшләре күз явын алырдай мал бит боларның, Ясүгәй. Моның ише сылуны жарияң итеп тотар өчен бер көтү елкы бирү дә кызганыч булмас иде. Мәркетләргә шундый карлыгачны биреп жибәрү дә харам.

Ясүгәй болай да башына авыр күсәк төшкән кебек миңгерәгән иде. Юлдашының сүзләре аңа өстәмә үчекләү булып ишетелде.

—Сиңа ул кәләшне кем бирергә тора?—дип, ярсып кузгалды ул.

Бучекнең тавышы жилсез көннәрдә дә лепердәшеп утыручы усак яфракларының моңын хәтерләтеп ипле, талгын акты:

—Үз ирке белән утарга мал да керми. Кәләшләрен талап алырга кирәк. Юкка гына баһадир түгелсең бит. Тирмәңдә сөеп туйгысыз жарияң булыр иде.

Бучекнең соңгы сүзләре Ясүгәйне тәмам чыгырыннан чыгарды.

—Шушының ише бала-чага жәясе белән талап алыргамы?

Ясүгәй үзен-үзе белештермичә аткыны тезенә бәргәли башлады. Кәжә мөгезе белән ныгытылган жәя шыгырдап куйды, әмма сынарга өлгермәде. Ясүгәй кулыннан аны Бучек тартып алды.

—Ашыкма, баһадир,—диде ул гыжлый төшеп.—Иң жүнсез корык та кайвакытта жебегәнне куркытырга ярый. Аннары үзеңнең зирәк Байшоңкар сунарчы, ут-күз Томавыл мәргән сөләләсеннән булуыңны онытма.

Бучек ныклы карарга килеп өлгергән иде, ахры. Ул Ясүгәйнең жәясен яшел чирәм өстенә ташлады да, бик тиз юкка чыкты. Аның соңгы сүзләре Ясүгәйне дә айнытып жибәргәндәй итте. Чирәм өстендәге сөяк аткыга текәлеп, баһадир уйга калды.

Әйе, кыятлылар бүген дә олылап искә ала торган ерак бабалары булган аның. Бабасының бабасы Байшоңкар, аның улы Томавыл мәргән турында Ясүгәй баһадир әткәсе Бәртән хәтирәләре буенча ишетеп кенә белә. Ерак бабасының чын исеме Бәдуанчар булса да, сунарчылык белән көн иткәне өчен кыятлылар аңа «Байшоңкар» дигән кушамат таккан, диләр. Имеш, ауга юнәлгәндә ул үзе белән аткы-жәя йөртмәгән, гел карчыга һәм шоңкарлар гына алып чыга торган булган. Шактый күп сандагы гаилә жанын түкми-чәчми асрап бара алгач, ул карчыга-шоңкарлар белән ау итүе табышлы булган, ахры. Әнә шулай—юлы һәрчак уң булган сунарчыны кыятлылар зирәк акылы өчен дә бик нык хөрмәт иткән. Байшоңкар бабасы һәрчак бер сүзне—магул кабиләләрен бер тугра, бер

кул астына тупларга кирәклеге турында тәкърарлаган. Шушы максат өчен ул үзе гомерен биргән, Томавыл углына да шуны әманәтләгән. Шул бердәмлек мәзһәбе өчен кардәш-туганнары күнеленә якын булгандыр ул. Кыятлылар Бәдуанчарның сөекле кошы ак шонкарны юкка гына ыруг туграсының иң изге билгесе итмәс иде.

Гаҗәеп сәер хәл: ә Томавыл бабасы, менә, карчыга-шонкар белән ау итүне күз чалымына да китерми торган булган. Анысы һәрчак кыр кәҗәсе мөгезеннән тарттырылган җәяне һәм тигез башаклы ткы-укларны гына үзенә тугры юлдаш иткән. Горурланырдай нигезе дә булган—Томавыл мәргән очырган ук берчакта да ялгышу-адашуны белмәгән. Ауга йөрү—анысы уен гына. Иң мөһиме: Томавыл мәргән яшь чактан ук яу кырында үзен курку белмәс, иң азамат яугир итеп танытткан. Нәкъ шул бабасы ыруг батыры булып торган чакта кыятлылар магулларның тугыз кабиләсен дә үз тирмәләре янына туплауга ирешкән. Ахырда инде Томавыл мәргән үзенең улы Кабулны магул кабиләләренең бердәм ханы итеп ак киез өстенә күтәрткән. Ул көнне Балдак Дала үзәнлегенә җыелган магуллар олы учак ягып, шуның тирәсендә дөмбак кага-кага биегән, ыруг пәһлеваннары көч сынашкан, яшь егетләр-ирләр ярсу чаптарларда узышкан.

Билгеле инде, магулларның аерым дәүләт тотарга дәгъва кылып бер тугра астына тупланувы чиннәргә* һәм кара татарларга һич тә ошамаган. Магулларның куәтләнүе аеруча чиннәргә аяк табанына кадалган шырпы сыман тәэсир иткән. Ясүгәй тәгаен белә: чиннәр элек-электән үк магуллар белән дә, кара татарлар белән дә үзара гел яу йөрешеп көн иткән. Әллә ничә гасыр элек үк чиннәр Далай белән Буир күлләре буенда яшәгән җыен, төрбән, коңгырат, әбрибуир кабиләләрен аларның үз ханнары булмаганга күрә «кара татар» дип мыскыл итеп йөргәннәр. Үзләре белән солых төзеп, аларның таштан салынган галәмәт биек стеналарын саклый-саклый көн итүче ангыт кабиләсен дә үз итмәгән чиннәр. Ангытларның укый-яза белүче кабилә булуына ташлама ясап кына аларны «ак», әмма, барыбер, үзләре өчен чит-ят икәнне аңлаткан «татар» кушаматы белән атаганнар. Ә инде үзләренә каршы туктаусыз яу йөргән, өстәвенә әле гомер буе Күк Тәңрегә табынып яшәгән магулларга чиннәрнең мөһере элек-электән үк бер булган: «кыргый татарлар», яки кабиләләр санына карап «тугыз татар»—бетте-китте.

«Үшән атка камчы—иң тансык аш», дип белми әйтмиләр шул. Чиннәр аткан кушамат та магуллар сыртында усал камчы булып яңгыраган. Кыят, нирун, тайҗут, чатҗират...—һәммә кабиләләр бердәм уянганнар, күмәк дәүләт төзергә зур омтылыш туган. Мәгәр магуллар инде хан да сайлап куйгач, вәкарь, борнай, масаючан чиннәр үз казаннарын чит-ят куллар китергән утлы күмер белән җылытмакчы булган. Алар тотканнар да, кара татарларны магулларга каршы котырта башлаганнар. Хәер, ырулар арасында магул-татар дошманлыгы турында төрле хәбәр йөри. Кайсысы гына тәгаен, хак икәнен ачыклау да кыен. Бер ишләре ул дошманлашуга исеме дә билгесез камны сәбәп итә. Имеш, моннан егерме-егерме биш еллар элгәре Кабул ханның Тәкый атлы энесе яман авырый башлаган да, магуллар шул хастаны дәваласын өчен кара татарларның баш камын чакырып китергәннәр. Татар камы Тәкый хастаны күп итеп өшкергән, әллә ничә төрле үлән сулары да эчергән. Инде тегесенең хәле яхшыргандай булган. Әмма кам китүгә үк, Кабул ханның энесе яман итеп тартышкан да, мәңгелеккә тынган. «Татар камы хастаны юрамал гына дәвалап йөргән икән, ә чынында бозган»,—дип нәтиҗә ясаганнар. Ачулары купкан магуллар шуннан соң, җыелышып, кара татарлар янына барганнар да, теге камны бөтен кабиләсе каршында кыйнап үтергәннәр. Кам кадәр камны үтерүгә кара татар ыруы да түзеп калмаган.Төрбән, коңгырат, җыен кабиләләре бергә укмашкан да, инде магуллар өстенә зур яу белән килгән...

Магул кабиләләренең кайберләре тагын да хәтәррәк хатирәләр саклый.Чин дәүләте тәхетен берзаманны магул-татар катыш җүрҗән

кабиләсенең бәкләре әләктереп алган, анысы хак. Менә шулар, имеш, кара татарларны котыртып магулларга каршы җибәргәннәр. Яу барышында магуллар җиңелгән, йөзәрләгән ир-ат әсирлеккә төшкән. Җөрҗәнле хакимнәр аларның һәммәсен дә әле зинданда тәннәренә утлы күмер басып җәфалый-җәфалый, әле баш өсләренә кайнап торган су коя-коя газаплап үтергәннәр. Шуннан соң әлеге мәкер өчен үч алырга дип, инде магуллар кара татар кабиләсе өстенә юнәлгәннәр...

Магул кабиләләре арасында йөргән андый хатирәләр бик күп, ә асылы уртак: имеш, беренче булып яу гөрзиен кара татар ыруы күтәргән,шуннан бирле ике халык арасында үзара кан кою башланган. Әледән-әле кабынып торган ул туктаусыз яу әле Ясүгәй сабый чакта—бабасы Кабул хан заманында да бара иде. Кабул бабасыннан соң, уртак хан булып, ак киез өстенә аның улы Котул да инде күптән менде. Ә үзара яу йөрү һәм дошманлык һич кенә дә сүнми...

Котул, Котул... Ясүгәйгә ага тиешле ул. Әтисе Бәртән баһадирның абыйсы. Ясүгәйгә калса, ак дөя йонынннан сугып ясалган дәү һәм изге киез өстенә магуллар аның әтисен күтәрергә тиеш иде. Ясүгәй әле яшь кенә егет булса да, ул чакта ук тәгаен чамалап өлгерде. Бәртән баһадир үз абыйсы Котулга караганда бер карыш озынчарак буйлы, аяк-кул, җилкәләр дөя сыны шикелле мәһабәт һәм эре, йөзе горур. Ул сычкан койрыгы сыман бөтәрләнеп килгән тар кашлары астыннан сөзеп төбәлгәндә аның бораулы, утлы карашы дәү-дәү ирләрне дә бер карышка чүктергәндәй итә. Юкә кайрысы кебек саргаеп чыккан тимер куллары кылыч орышында да, ук очырту бәйгесендә дә үзенә тиңнәрне белми. Ләкин, менә, хан сайлауга калгач, ыру батырлары, бәкләр никтер карсак буйлы, симез корсаклы Котулны яклап чыкты. Бәртән баһадирны кырыс холкы, каты кулы өчен якын күрмәдеме алар, әллә Ясүгәй анасының кара татар ыруындагы конгыратлардан алып кайтылган сылу, әмма килмешәк булуы ошап бетмәдеме?—төгәлен Мәңгелек Күк Тәңре үзе генә белә. Мәгәр тәкъдир Ясүгәй һәм аның энеләре өчен кырыс булып чыкты. Үзе исән чакта бабалары Кабул гел өлкән угылын гына якын күреп яшәде, ахырда инде ыру бәкләре дә шуны якладылар. Нәтиҗәдә шул эт яламас Котул хан да булып алды. Ә ул инде, үз чиратында, иң олы тугайларны, иң сусыл җәйләүләрне, билгеле ки, үз уллары Алтын, Кучар, Сачә бәкләргә өләшеп чыкты. Ясүгәй белән аның энеләре Дәритай, Тайчу, Канунга Онон буендагы иң ерак үзәнлекләр—«утыз татар» кабиләсе белән янәшәлек әләкте. Ясүгәй баһадир хәзер телиме-теләмиме, ләкин һәрбер танда кара татарларның көтелмәгән һөҗүменнән шөлләп көн итүгә дучар...

Дөрес анысы, Бәртән баһадир үз урынына ыру башлыгы булып менгән өлкән улын көч-куәтсез итеп калдырмады. Кайсыдыр бер елда җәйләү-утлаулар өчен Бәртәннекеләр белән Котулныкылар арасында ызгыш-талаш купкач, яшь кенә булуына карамастан, Ясүгәй үзе дә, аның чал әтисе дә үзләрен шактый түзем һәм зирәк дала хуҗалары итеп таныта белде. Шул хәл күршеләрдә ышаныч һәм дәрт уятты, ахры. Магул ыруының нирун, тайҗут кабиләләре дә, Котул хан улларын калдырып, әүвәл Бәртән, аннары Ясүгәй каршына килеп баш иделәр. Әнә шулай, озак еллар дәвамында барган алыш нәтиҗәсендә Ясүгәй кул астына унбиш меңләп тирмә тупланды. Хәвеф-мазар туса, Ясүгәй бер тәүлек эчендә дошманына каршы егерме меңлек гаскәр куя ала. Ә Бәртән баһадир бит, вафаты алдыннан, аңа һаман яңа җирләр яуларга, яңа ыруларны буйсындырырга васыять иткән иде. Ни үкенеч, тик Ясүгәйнең генә соңгы ничә ел буена бер төрле дә җиңүгә ирешә алганы юк. Һич югы шушы мәркәтләрнең борынына чиертеп, аларның аккош канатлы Айлы бикәләрен урлый алсаң икән, ичмаса!..

Чаганнар арасыннан тояк тавышлары ишетелде, үзәнлектә ияр менгән Бучек пәйда булды. Ул Ясүгәйнең Уттоягын да тезгененнән тартып килә иде. Баһадир аңа житез генә сикереп атланды. Үзара бер

сүз дә алышып тормыйча жайдаклар Соры-Айгыр үзәне буйлап Камәр—Табан ягына юыртып киттеләр.

## 2

Ясүгәй белән Бүчек куып житкәндә туй кәрваны Тозлы күл буена төн кунарга туктаган иде. Мәркетләр саклык турында бөтенләй онытканнар. Яр буенча сузылган арбалары каравылсыз тора. Тышауланган атлар сусыл сарут белән тулы инкүлек эчендә утлап йөри. Ә яшьләр күлдән ярты дилбегә буе арада сай гына чокыр казып зур казан асканнар да, һәммәсе дә учак тирәли олы түгәрәк ясап утырганнар. «Бүчек Онон буендагы башка аучыларны таба алмаган, шунысы кызганыч»,—дип Ясүгәй ачынып уйланды.—«Аларны да ияртеп килгән булсам, аһ, күнел ачтырыр идем сон үзегезгә!»

Мәркетләрнен дөньяга һичбер гаме калмаган иде. Менә, алар арасыннан жинсез кайры тунга төренеп утырганы кулына кубыз алды, кичке рәхәт тынлыкны сискәндереп, инкүлек өстендә кылга суккан авазлар янгырады. Күп тә үтмәде, кубыз көенә калын тавышлы ир-ат моны кушылды.

Йалвун анын көзи,
йалкин анын өзи,
толун айын йүзи,
йарды мәнин йүрәк[1].

Кайры тунлы оста тиз-тиз генә кубыз кылларына чиертеп алды, дәртле дә, еламсык та аваз байтак зенләп торды. «Кайры тун» янә бармакларын кубызга тидерүгә инкүлек буйлап инде көмеш кынгырау чылтырагандагы шикелле сихри тавыш иясе жыр сузды:

Айдум анар сәвүк,
Бизни таба нә әлүк,
кәчтин язы кәрик,
кырлар әзиз бәзик?[2]

Ясүгәй үзе яшеренеп торган артыш ботакларын кабаланып этәрде дә, түгәрәктә утырган мәркетләргә текәлде. Анын сизгер күнеле ялгышмады: түгәрәктән беркадәр алга чыгып һәм бер-берсенен кулларыннан тотышып жырлаучылар Чилу бәй белән Айлы бикә иде. Баһадир ачынудан янакларын шыгырдатып кысты, колакларын томалап артыш төбенә иелде. Кин, каты уч төпләре генә аны коткара алмый, инде Чилу бәй башлаган жыр юллары анын колакларын сытып керә иде:

Айды сәнин узу
әмдәк тәлим ызу
йумшар катыг узу
көнлүм сана йүгрүк[3].

Кубыз зенгелдәве, жыр алмашу учак янында озак дәвам итте. Күк йөзенә тулган ай калыкты, Киек Каз Юлы, Казык, Чүмеч йолдызлары кабынды. Борын астыннан гына тиз-тиз пышылдый-пышылдый Ясүгәй Тәнрегә табына башлады...

—Котбый, Үгәй! Сез бүген атларны саклыйсыз,—дип күл буеннан янгырап ишетелгән тавыш Ясүгәйне жиһанга кайтарды. Баһадир артыш

[1]Тылсым анын күзе,
уйнак анын үзе,
тулган айдыр йөзе,
яралады жанны.

[2]Әйттем анар: «Сөеклем,
кин үзәннәрне кичеп,
биек тауларны кичеп,
килә алдын безгә ничек?»

[3]Әйтте: «Газап чигеп
сина килгән чакта,
күнлем ашкынганга
каты юл да йомшак».

*(Жырлар Мәхмүт Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» әсәреннән алынды).*

ботакларын аралады: әмерләрне, әлбәттә, һаман да шул Чилу бәй бирә иде. Учак янында ирләр генә торып калган, кызлар таралышкан.

Мәркет батырының яңа әмере ишетелде:

—Бүртә, Ләббан, Мәсхәт! Олаулар янында торгак булырга бүген сезнең чират. Калганнар, таралыгыз! «Чүмеч» сүнүгә, юлга.

Егетләр бер-берсенә терәп диярлек тезелгән арбалар астына кереп сузылдылар. Учак янында дүрт кенә шәүлә басып калды. Аларның өчесе каравылга билгеләнгән мәркетләр, дүртенчесе Чилу бәй иде. Батырлары учактагы кисәүләрне кузгаткалап бер тын утырды да, озак түзә алмады, оеган аякларын яза-яза тугралы арбага таба юнәлде. Сакчыларның берсе учак янына чүгәләп калды. Икесе олауларның баш-башына барып урнаштылар. Ләкин тулган ай яктысында баганадай басып тору шикләндерде бугай, икесе дә ян-яктагы чаган кәүсәләренә барып сыенды.

Ай нәкъ баш түбәсенә менеп житкәч, һава жиләсләнде. Тәнендә жинелчә калтырану тоеп Ясүгәй чаган төбенә бөгәрләнеп утырды, тирәюньгә колак салды. Күл буе сихерләнгән шикелле тынып калган. Сирәк-мирәк кенә иңкүлектәге атлар пошкырып куя. Ерактан адашкан ләкләк тавышы ишетелгәли. Сүнәр-сүнмәс янган учактагы кисәүләр чыжлавы да талгын чишмә агуын хәтерләтә. Бу тынлыкка бирелеп Ясүгәй үзенең йокыга талганын да сизми калды.

Ул корыган үлән сабаклары кыштырдаган тавышка айнып китте. Кулы инде билендәге хәнжәр сабына яткан иде. Үләннәр арасыннан соры кәпәчле баш калыккач кына Ясүгәй тынычланды. Бүчек икән. Ул әүвәл имән бармагын иреннәренә терәгән иде, соңрак Ясүгәйгә сулга таба ымлап юл күрсәтте, үзе олауларның икенче башына таба шуышып китте. Ясүгәй шуннан соң гына игътибар итте: төнге караңгылык инде беркадәр тарала башлаган, күл буена шактый куе томан яткан икән.

Ун-унбиш адым ара шуышуга ук Ясүгәй төнге сакчыларның берсенә барып төртелә язды. Мәркет егете вазифасын тәмам оныткан һәм баш астына кулын салган хәлдә гырлый-гырлый йоклап ята иде. Ясүгәй аның әле ныклап сакал да чыкмаган йөзенә бер тын гына карап торды да, икенче мизгелдә инде хәнжәрен аның муенына батырды. Аннары ул сикереп урыныннан купты, аяклары үзләреннән-үзе аны тугралы арбага таба алып бара башлады. Ләкин шул чагында ул капылт кына учак янында утырып калган мәркетне исенә төшерде. Кабаланып кулына аткы алды, жәя йөзенә ук көйләде.

«Учак сакчысы», чыннан да, һаман урынында утыра һәм иң гажәбе ул йокламый иде. Ясүгәй аны шәйләүгә шундук сарут арасына сенде, әмма хәйлә-мазар эзләп баш ватмады. Тәнрегә шөкер, ауда гына түгел, яуда да Ясүгәйнең угы ялгышуны белми иде. Бу юлы да очырган ук бичара мәркетнең нәкъ бугазына барып кадалды. «Ут сакчысы» ыңгырашырга да өлгермичә янга авып төште.

Ясүгәй янә житез күтәрелде, аяк очларына басып кына тугралы арба янына йөгереп килде. Болай да өсте һәм ян-яклары капланган арбаның алдына да, артына да ак киездән чыбылдык корганнар, бу «күчмә тирмә»нең ишек ягын чамалавы да авыр иде. Ясүгәй шылт иткән тавыш та чыгармыйча арбаның башына сикереп менде. Хәнжәр йөзе белән киез чыбылдыкны урталай телеп төшерде. Ул чыбылдыкның бер канатын күтәрә башлады һәм кинәт катып калды.

Киң арбаның төбенә дә йомшак ак киез жәелгән. Шул киез өстенә икесе дә анадан тума чишенгән Айлы бикә белән Чилу бәй сузылган. Яшь кәләш бөтенләй эсселәгән, ахры. Ул аккош канатыдай ак кулларын гына түгел, алсу аякларын да як-якка ташлап, туарылып йоклый. Сулыш алганда аның тыгыз, мул күкрәкләре тагын да кабаргандай була, жиләс көндәге күл өсте шикелле дулкынланып куя.

Шулчак артта авыр мышнаган тавыш ишетелде, арба жиңелчә генә селкенгәләп куйды. Ясүгәй үз янына Бүчек менеп басканын да, аның кыбырсынып чыбылдык эченә текәлүен дә тоя, әмма үзендә кыл

кыймылдатырлык та көч таба алмый иде. Алар яшь кәләш тәненә шактый озак вакыт төбәлеп тын тордылар. Кисәк килеп туган хәвефне икесенең берсе дә сизенмичә калды.

Ат сакларга билгеләнгән мәркетләрнең берсе ниндидер йомышы төшеп олаулар янына кайткан һәм учак янындагы иптәшенең гәүдәсенә килеп төртелгән иде, ахры. Нәкъ шул тарафтан куркынып кычкырган тавыш ишетелде һәм Ясүгәй белән Бүчек икесе дә шундук жиргә сикерделәр.

—У-у-вах, у-у-вах, бәла!

Моны һаман да шул мәркет кычкыра, ә Ясүгәйнең ауга чыккан саен диярлек үлән яки камыш кыштырдаган тавышка карап та ук очырганы һәм шулай итеп җәйран, төлкеләрне генә түгел, әрлән-йомраннарны да атып алганы бар иде. Хәзер дә баһадирның кулы ялгышмады бугай, учак ягында гырылдаган аваз гына ишетелеп алды. Ләкин инде мәркет сөрән салган тавышны башкалар да ишеткән, яндагы бер арба астыннан ике егет чыгып килә иде. Аларның берсе Бүчек аткан уктан шундук ауды. Әмма икенчесе әле Ясүгәй җәясенә ук элеп очырганчы башка юлдашларына сөрән салып өлгерде. Кинәт барлык арбалар да бердәм шыгырдады. Хәзер инде җиңүгә өметләнү мөмкин түгел иде.

Ләкин Ясүгәй моны уйламады. Ул үзен-үзе белештермичә туры арба өстенә сикереп менде. Кулындагы хәнҗәр белән киез чыбылдыкны янә бер урыннан телеп төшерде. Ашыгып киез эченә чумды һәм бер мизгелгә генә аптырап калды.

Мәркет бөге урыныннан сикереп торган, тик өстенә әле берни кияргә дә өлгермәгән. Кылыч, җәя таккан, кулына хәнҗәр тоткан Ясүгәйнең кыяфәте үк аның өнен алды бугай. Чилу бәй капылт кына арбаның икенче очына ыргылды да, андагы чыбылдык астына сикереп шундук юкка чыкты.

Айлы бикә киез өстенә торып утырган, күкрәгенә зәңгәр күлмәген кыскан, үзе куркудан дер-дер килә иде. Ясүгәй аны кулыннан эләктереп алды, үз артыннан сөйрәп тышка атлады. Иңкүлектә яман орыш бара, кулына кылыч тоткан Бүчекне ике мәркет бөркәвечле арбалар буена кысрыклаган иде. Үзенең орышка катыша алмасын аңлап, Ясүгәй мәркетләрнең берсенә хәнҗәр томырды. Хәнҗәр мәркетнең күкрәк сөягенә барып төртелде, күрәсең, орышчы егылмады. Шулай да аның инде кылыч селтәнерлек куәте калмаган иде. Хәнҗәр йөзенә ике кулы белән ябышкан көенчә ул артыш куаклары эченә кереп юкка чыкты. Ул арада Бүчек ялгыз мәркетнең күкрәген урталай телеп төшерде.

Кыятлылар өчен һәр мизгел кадерле, аларга мәркетләр яныннан мөмкин кадәр тизрәк качып котылырга кирәк иде. Ясүгәй җиргә сикереп төште, күлмәген тоткан көенчә анадан тума килеш басып торган Айлы бикәне күкрәгенә алды һәм Уттояк яшерелгән чокырга таба зур-зур сикереп йөгерә башлады.

—Бүчек, Бүчек!—дип кычкырды ул гыжылдап.

—Мин монда, мин калмыйм,—дип җавап бирде тегесе.

Бер кулына җәя, икенчесенә кылыч тоткан Бүчек аларны каплап барырга тырышты.

Ул арада Чилу бәй дә аңга килеп өлгергән иде инде. Иңкүлектә аның әмерләре яңгырап ишетелде:

—Усай, Синтәк! Атларны тизрәк куып китерегез! Калганнарыгыз, караклар артыннан. Айлы бикәне урлатсагыз, һәммәгезне суям!

Урланган кәләшне күкрәгенә кыскан көенчә Ясүгәй әллә ни кызу йөгерә алмый иде. Әледән-әле ачыргаланып кычкыруына, тырмашуына да карамады, ул Айлы бикәне иңбашына салды. Яшь кәләш аның аркасын төя, тешли, ләкин мондый хәлдә йөгерү күпкә җиңелләште.

Мәркетләр чокыр янына килеп җиткәнче Ясүгәй Уттояк өстенә менеп өлгерде, Айлы бикәне ияр аша ташлап алдына салды. Ул аткысына ук корып азапланганда мәркетләр чокыр читенә килеп тезелеште. Үзенә

төбәлгән уннан артык укны күргә үк гомерендә беренче мәртәбә Ясүгәйнең тәне чымырдап куйды. Мәркетләр тәтә кылын ычкындырса, уклар һичшиксез Ясүгәйне теткәләячәк иде. Әмма нәкъ шул мизгелдә чокыр өстендә Чилу бәйнең пошаманлы авазы яңгырады:

—Берүк ата күрмәгез, Айлыга тидерәсез!

Үзенә-үзе хөкем чыгаруын Чилу бәй аңламады. Ясүгәй ярсып Уттоякның касыгына типте. Еллар буена йөреп, хуҗасының ымына да өйрәтелгән чаптар кисәк ыргылып урыныннан кузгалды. Мәркетләр янә җәя күтәргәндә Уттояк инде әрәмәлек артына кереп качкан иде.

### 3

Мәркетләр шактый ерак ара куа килделәр, ләкин Соры-Айгыр үзәнендә кыятлыларның эзен югалттылар. Алатау янындагы шарлама янына житкәч кенә, Ясүгәйнең күңеле тынычланды. Кичә тезләнеп су эчкән шома ташлар каршында ул әүвәл үзе Уттояк өстеннән сикереп төште, аннары ярымһушсыз хәлдәге бикәне күкрәгенә күтәреп алды. Ясүгәй аны сак кына жиргә шудырган иде, Айлы бикә оеган аякларына баса алмады, кояшта кызган шома ташлар өстенә сыгылып төште. Ясүгәй аны янә күтәрмәкче булып Айлы бикәнең иннәренә ябышты. Ләкин һич тә көтмәгәндә кырнак кәләш баһадирның беләгенә тешләрен батырды. Ясүгәй кулларын капылт тартып алды да, ышкынырга мәжбүр булды. Айлы бикә зәңгәр күлмәге белән күкрәкләрен томалап бөгәрләнде, әмма озын керфекләр астыннан төбәлгән карашы кыргый, усал иде.

—Курыкма, мин сиңа кагылмыйм,—дип эндәште Ясүгәй. Кызның керфекләре дә селкенмәде. Ясүгәй янә телгә килде.

—Син, мөгаен, нык кына алҗыгансыңдыр. Менә, су. Әзрәк юынып ал. Аннары...

Ясүгәй кызның күлмәгенә ымлады. Айлы бикә шул мизгелдә генә айнып китте бугай, күлмәген жәеп аның бер чите белән бот тирәләрен дә каплагандай итте. Ясүгәй басынкы, тыныч тавыш белән сөйләнүен белде.

—Без кайтасы ара шактый ерак. Әйдә, юын, чибәркәй. Мин сиңа карамыйм.

Ясүгәй башкаларыннан байтак калкып торган олы бер таш өстенә барып утырды. Инендәге жәяне, билендәге кылычын салып ташлады. Өстендәге күн камзулыннан да бушангач, аңа жиләс, рәхәт булып китте. Сиздермәскә тырышып, ул Онон өстенә борылды. Тоткын кызны күрде дә, башын чайкап куйды.

Айлы бикә өстенә күлмәген киеп алган һәм су эченә чүгәләп утырган көенә юына иде. Менә, ул бервакыт гәүдәсен турайтты, аякларын күтәреп баса-баса шарламага таба атлап китте. Тәмам юешләнгән күлмәге тәненә сылашып яткан һәм кырнак кызның бөтен матурлыгын күрсәтеп тора иде. Төз һәм озын ботлар, ике учка сыеп бетәрлек неп-нечкә бил, камыш сабагыдай зифа гәүдә, атлаган саен жанланып уйнаклаучы тыгыз, мул күкрәкләр. «Йә, Тәнре, бу кадәр чибәр колларың да булыр икән!»—дип уйлап куйды Ясүгәй һәм күкрәгендә кабынган ярсу хистән котылырга омтылып, йөзен читкә борды.

Бу минутта Айлы бикә шарламаның читенә үк килеп баскан һәм беркадәр алга иелә төшеп, астагы чоңгылны күзәтә иде. Менә ул ачулы кыяфәт белән кыятлыларга таба күз ташлады. Атларның йөгәннәрен тотып карамалар ышыгында торган Бүчекнең куркынып кычкырган авазы Онон буендагы тынлыкны ярып узды:

—Ясүгәй-ә-әй!

Таш өстеннән капылт сикереп торган баһадирның сискәнүле карашы әүвәл Онон буендагы таллыклар, камышлыкларны айкап узды. Бүчек инде йөгәннәрне ташлап, Ясүгәйгә таба йөгерә башлаган иде. Баһадир

да Ононга таба борылды һәм кисәк катып калды. Шарлама читендә торган Айлы бикә нәкъ шулвакыт, керпе сыман бөгәрләнеп, чоңгыл өстенә томырылды һәм шундук юкка чыкты. Ясүгәй болан шикелле сикергәләп елга өстенә ыргылды. Берничә мизгелдән инде ул да, ук сыман томырылып, чоңгыл эченә кереп чумган иде.

Ясүгәй су астында күзләрен ачып тирә-якны айкап чыкты, бер төрле шәүлә дә шәйләмәде. Ул тагын да тирәнгәрәк чумды, ярсый-ярсый куллары белән чоңгыл төбендәге ташларны, комлыкларны капшый башлады. Тыны тәмам беткәч кенә, ул чоңгыл өстенә калыкты, ашыгып сулыш алды һәм янә чумарга әзерләнде. Ләкин аны кояш нурларында ялтырап уйнаклаган гәрәбәдәй саргылт чәчләр туктатты. Айлы бикә, күрәсең, инде күптән су өстенә калыккан. Ул чоңгыл өстенә ургылып аккан су ташкынының астында, зур гына таш артына яшеренеп тора. Үзе әллә куркудан, әллә өшенүдән дер-дер килә иде.

Ясүгәй йөзеп килеп кулыннан эләктергәч, яшь кыз карышмады. Ашыкмыйча гына яр читенә чыктылар. Ясүгәй кабат аны күкрәгенә күтәрде, шарлама өстенә менеп атлар янына җиткәнче кулларыннан төшермәде. Уттояк каршына китереп бастыргач кына ул әрнүле дә, каһкаһәле дә тоелган тавыш белән берничә сүз әйтте.

—Кая, кем янына качмакчы булдың? Җебегән Чилу янынамы? Сиңа кәләшен ташлап кача торган куркак җан кадерлеме?

Ясүгәй төртмәле сүзләре үзенең кырнак хәленә төшүе, кача алмавы өчен болай да өзгәләнгән кызның соңгы түземлеген сындырды. Чабылган сарут сабагы шикелле бөгелеп төште дә, ап-ак куллары белән җирне төя-төя Айлы бикә әрнеп еларга тотынды. Кызны очкылык тота башлагач кына, баһадир аны кулларыннан тартып күтәрде. Бүчек тоткан күн камзулын алып, Айлы бикәнең инбашына салды. Әледән-әле кабынып сулкылдаган кызны күзәтү авыр иде бугай, үзе дә туймастан Ясүгәй аңа ягымлы эндәште.

—Ә мин сине беркемгә дә бирмәячәкмен, җаный. Мин тач бүре шикелле. Тешемә эләккән калҗаны мәңге ычкындырмыйм. Сине дә җибәрмим...—Ясүгәй нәрсәгәдер килеп төртелгән сыман бер тын туктап торды, әмма теленә килгән сүзен барыбер ярып салды.—...һәм үзем дә качмыйм.

Айлы бикә әрнүле, үпкәле карашын аңа текәде. Ниһаять, беренче мәртәбә телгә килде.

—Ә өеңдә мине кемең итеп тотарсың соң? Кәнизәгең итепме, әллә җариянме?

Ясүгәйнең өстенә кайнар су койдылар диярсең, ул шундук куырылып калды, кызарып чыкты. Карашын яшерергә теләп әле Бүчеккә, әле Уттоякка төбәлде. Ахырда түзмәде, гыжлап җавап бирде.

—Миңа нишләргәдер, әле үзем дә белмим. Мәгәр сине кара кырнак итеп тотасым юк.

—Җариян итмәкчесең инде, алай булгач.

Ясүгәй ярсып җиргә типте.

—Белмим дидем бит, бел-мим!

Уттоякка менеп юл чыккач та, Айлы бикәнең йөзе яктырмады. Ул озак вакыт буе онытылып бара да, йокыдан уянгандай әледән-әле ниндидер сүзләр пышылдап ала иде. Чыдамады, Ясүгәй сорыйсы итте.

—Син үзегезнең Аллагызга эндәшәсеңме соң, ниләр пышылдыйсың?

Айлы бикәнең җавабы усал кысылган иреннәре арасыннан сытылып чыкты.

—Ходай Тәгаләгә ялварам мин. Ул тизрәк ишетсен дә, минем тоткынлыкка эләгүем турында Тимерҗан бәк колагына ирештерсен иде.

Ясүгәй эсселе-суыклы булып китте. Кара татар ыруындагы иң данлыклы һәм гайрәтле әлеге баһадирны Ясүгәй ишетеп тә, малай чакта хәтта күреп тә белә иде. Йөгереп барган дөяне бер сугуда егарлык Алыптай гәүдәле бу батыр әле дә булса Ясүгәйнең күз алдында тора.

һәр инenә дәү ирләр утырырлык киң җилкәле, бала башы кадәр йодрыклы адәм иде ул. Юкка гына аны татарлар «Кыя батыр» дип йөртмиләр. Җитмәсә, ул әле «утыз татар» кабиләсе өстеннән бәк булып та тора.

Ясугәй үзенең эчендәге утны сиздермәде.

—Син кайсы кабиләдән буласың соң?

—Конгыраттан.

—Кабилә башыгызның аты нинди?

Айлы бикәнең инбашлары Ясугәйнең күкрәгенә терәлеп бара иде, алар җиңелчә калтыранып куйды.

—Сәмыйк бәк.

—Димәк, син шул Сәмыйк бәк кызы буласың да инде.

Айлы бикә гаҗәпләнеп баһадирга текәлде, күзләре зур булып ачылды. Ясугәй мыек астыннан гына елмайды да, яшь кәләшкә үзенең карарын өзеп әйтте:

—Кабилә бәгенең кызын урлаган өчен баштан сыйпамаслар, анысын гына чамалыйм. Мәгәр «утыз татар» гына түгел, чаган татарлары[1] белән төрбәнлеләр, конгыратлар, мәркетләр җыелып килсә дә, сине бирәсем юк. Колагыңа киртлә.

## 4

Онон буенда калган Балдак Дала үзәнлегенә кайткач, кыятлылар Ясугәйне сәер каршылады. Иң элек баһадир тирмәсенә өлкән энесе Дәритай котырынып керде. Кәпрәймәкче дә, туганнарының исләрен китәрмәкче дә булып Ясугәй Айлы бикәне чыбылдык артына яшермичә, тирмәнең ак ягында тота иде. Йөзен түбән игән хәлдә чәчен үреп утырган кырнак кыз ягына Дәритай, хәтта әйләнеп тә карамады. Елан-мазар үтә күрмәсен дип ишек төбенә ат кылыннан үреп салынган юан бауны атлап керүгә үк Дәритай төкерек чәчә-чәчә жикеренергә тотынды.

—Ошбу чәчби сиңа нигә кирәк булды? Мәркетләр илә татарлар бергә укмашып килеп барча ыруларны суеп чыксын, дисеңмени? Үзеңнең әткәй тарафыннан баһадир итеп калдырылган булуыңны нигә онытасың?

Ясугәй үзен кулга алып, тыныч калырга тырышты.

—Кара татар кәләшләрне әсир итеп алу магул батыры өчен кайчаннан бирле хурлык санала соң?

Дәритайның куе кашлары борын өстенә җыерылып килде, ул тагын да ярсып кычкырды:

—Хурлык саналмый, баһадир, мәгәр бәла тудыра. Син ошбу чәчбине гадел орышта түгел, бәлки урлап алгансың. Моның өчен Тимерҗан бәк синең белеңне сындырачак. Хәзер Кабул хан заманасы түгел. Магул кабиләләре төрлесе-төрле якка таралышып бетте. Ә татарлар бердәм. Аларның бер җыен кабиләсендә генә дә утызлап күрем бар. Хак булса, кара татарлардагы җәмгы тирмәләрнең саны җитмеш меңгә чаклы җитә икән. Ә синең кул астында унбиш-егерме мең генә ир. Котул ханның сине яклап калуы икеле. Әле яуда без кырыла калсак, сөенеп кенә торыр.

—Ярар соң, кирәк икән, Котул ханнан башка, ялгыз орышырбыз. Мәгәр вакытыннан алда үлмә әле син.

Ясугәйнең ваемсыз җавабы өметен тәмам өзде, күрәсең. Дәритай кулын селтәде дә чыгып китте. Аннан соң беркадәр вакыт узгач тирмәгә атылып кергән энесе Тайчунның тәкъдиме Ясугәйне бөтенләй аптыратты.

—Синең хатының бар, җарияләрең дә әллә ничәү. Ошбу кырнагыңны миңа бирче, батыр?

[1]Чаган татарлары—ангыт кабиләсенең монгол телендәге атамасы. Кытайларча әйтсәк, «ак татарлар».

Кинәт агарып киткән йөзе белән Айлы бикә баһадирга таба борылды. Ясүгәй моны күрде.

—Синең дә жариян илә кәнизәкләрең ике тирмә тулы. Мондый сары чәчби сиңа нәгә кәрәк?

—Мин өйләнәм аңа.

Ясүгәйнең тәненә утлы күмер тигән кебек булды. Тайчуга унсигез яшь тулып килә, ул әлегә ялгыз. Аны башлы-күзле итү, баһадир буларак, Ясүгәй өстендә тора. Житмәсә, бабалар йоласы буенча Тайчуның теләсә кайсы кырнак кызга өйләнергә хокукы бар.

Ясүгәй кайнар карашын Айлы бикәгә төбәде һәм көтелмәгән карарын әйтеп салды.

—Мин аны үзем өчен дип орышып алдым, Тайчу. Ул ошбу тирмәдән чыгып китмәячәк. Мин аны үземә хатынлыкка алам.

Калтыранып утырган Айлы бикә урыныннан кисәк сикереп торды. Ясүгәйнең әле генә мондый карарга килүен Тайчу да аңлап өлгерде. Аның йөзенә куләгә ятты, карашы кырысланды.

—Син миңа үзем сайлаган кырнакка өйләнергә юри ирек бирмисең, атайлар йоласын бозасың,—дип кычкырды ул ярсып.—Мин синең янында кала алмыйм. Бүген үк тайжутлар кабиләсенә китәм. Кирәгем чыгып, чакырырга жыенсаң, мине көтмә. Моннан ары тайжутларның да сиңа буйсынасы юк!

Инде Ясүгәй тирмә киезенә тибеп жикерергә мәжбүр булды.

—Бер түбән чиру илә өстенә килсәм, буйсынмый чараң калмас!

—Булдыра алсаң, ул түбәнне Тимержан бәккә каршы тупла. Кабилә башлыгының кызын кырнак итеп тоткан өчен аның сине гафу кыласы юк. Мине таба алачагына да нык шикләнәм. Мин тайжутларны алып, Онон буеннан китәм. Кайсы якка, кайсы батыр кул астына—анысын күз күрер.

Кырт борылды да, көмеш йөгертелгән кылыч кынын ишек катында торган чиләк-табакларга бәрә-бәрә Тайчу чыгып китте. Ясүгәй тирмә идәненә ябылган барс тиресе өстенә чүгәләде. Тоныкланып калган карашын Айлы бикәгә төбәде. Кабер тынлыгы урнашкан тирмә эчендә бер сүз дә алышмыйча озак утырдылар. Айлы бикәнең түземлеге бетте, күрәсең, йөзен жиң очы белән каплады да, чыбылдык артына кереп югалды. Аягындагы күноекларын салып бераздан Ясүгәй дә кыз янына узды. Айлы бикә тешләде, тырнашты, баһадирны үзенә якын да китермәде. Тырналган эзләрнең берсеннән муенына кан саркып чыгуын үзе дә тойды, Ясүгәй шуны капылт сыпырды да, кызыл төскә баткан уч төбен Айлы бикәнең күз алдына сузды.

—Ошбу канны оныта күрмә, кызыкай, шуның илә ант эчәм.—Ясүгәй уч төбен ялап алды.—Үзең ихтыяр итмичә торып, моннан ары мин сиңа кул сузмыйм. Мәгәр беләм: син яныма үзең киләчәксең. Шуңа чаклы сиңа кырнак урыны!

Баһадир бик тәкәббер кыяфәттә чыгып китте. Әмма түзә алмады, икенче таңда ук гаепле йөз белән килеп керде. Шул кичтә Ясүгәй аның каршына сусар тиресеннән тегелгән тун кертеп салды, ак энже бөртекләреннән тезелгән сәйләнне муенына такты. Тик Айлы бикә барыбер күңел капкаларын ачып елмаймады. Көн артыннан көн үтә башлады. Ясүгәй бер генә иртә һәм кичне дә калдырмыйча кереп Айлы бикә янында утыра торган булды. Тоткын кыз үзенең халәтенә ияләшә башлаган иде, күрәсең, бер таңда баһадир керми калгач, кич белән ул аны елмаеп каршылады. Ясүгәйнең күңеле алданды. Кайнар мәхәббәткә өмет итеп ул кызның муенына иреннәрен тидерде. Ләкин Айлы бикә тагын шундук керпе шикелле бөгәрләнеп ятты, усал тырнап алды.

Ә беркөнне баһадир кара көеп йөри башлады. Аның авызыннан бер сүз дә чыкмый иде. Айлы бикә кырнак хатыннар сөйләшүен ишетеп кенә белде. Тайжут кабиләсе юкка чыккан, теге көнне Тайчу юкка гына янамаган икән. Дөрес булса, тайжутлар магул белән татар катнаш найман

кабиләсе яшәгән Шәрәборын тауларына, Кукы-Ката үзәнлегенә таба киткәннәр, ди. Берәр атна узгач Ясүгәй, алар артыннан биш мең кешелек чиру юллап кына, качакларны кабат Балдак Дала үзәнлегенә кайтара алды. Ләкин тайҗутларда ниндидер яшерен дошманлык хисе яшәп калды бугай, шуннан соң Ясүгәй баһадир оештырган бәйге-орышларда алар бөтенләй катнашмый башладылар...

Айлы бикәнең кырнак хәленә төшүенә ике ай тулганда кыятлыларга тагын да хәтәррәк хәбәр килеп төште. Далай, Буир күлләре буеннан кубып Онон елгасына таба кара татар чирүе килә, сәрдәрләре Тимерҗан бәк икән. Сәбәбен ачыклап маташу артык мәшәкать иде. Ясүгәй баһадир шул көнне үк нирун, тайҗут кабиләләрен чакырып чапкыннар юллады. Иң беренче булып Балдак Далага нируннар башлыгы Ярми килеп җитте. Ул үз кабиләсенең барча ирләрен күтәреп кенә калмаган, ярдәмгә әле магул-татар катнаш гирәй ыруы сугышчыларын да дәшкән икән. Бер үзе дүрт меңнән артык җайдакны җыеп килгән Ярми бәкне Ясүгәй, әлбәттә, кочаклап каршылады.

Кул астында ун меңнән артык җайдак туплануга Ясүгәй баһадир Алатауга таба кузгалды. Ике дәһшәтле көч Соры-Айгыр үзәнендә очрашты. Ясүгәй үз җайдакларының күбесен, тозак чирүе итеп чытырманлык артына яшереп куйган иде. Татарлар аңа орыш осталыгын күрсәтергә ирек бирмәделәр. Магулларга җитәргә ике ук очарлык ара калуга ук, тыгыз сафлар эченнән, айгырын уйнаклатып, алга Тимерҗан бәк чыкты.

—Ата-баба йоласы буенча орышны батырлар башлаячак.—Бәкнең усал, калын тавышы Алатау кыяларына бәрелеп магулларга дәһшәт бөркеде.—Үзенә кырнак илә җарияләрне дә чын ирләрчә итеп таба белми торган угъры батырыгызны чыгарыгыз. Мин ул куркак тәкәне үзем менә шушында, бар чирүе каршында тотып печәм.

Бәкнең сүзләренә татарларның мәсхәрәле көлүе яңгырап кушылды. Ясүгәйнең тәкате корыды, ул Уттоякның касыгына типте. Чаптар сискәнүдән әүвәл арткы аякларына күтәрелеп кешнәде, аннары ук шикелле сузылып алга томырылды.

Тимерҗан бәк кулына озын, саллы сөңге тоткан иде. Ясүгәй дә сөңгесен алга сузды, гәүдәсен үгез тиреләреннән сумала белән катырып салган җинел калкан артына яшерде.

Батырлар арасы мизгел саен кими башлады. Ясүгәй инде Тимерҗан бәкнең бәллүләгән саен җилдә җилфердәгән озын, чал мыекларын да, кысылган керфекләре арасыннан төбәлгән ярсулы карашын да аермачык итеп күрә иде. Маңганга-мангай килергә исәпләп Ясүгәй Уттоякның йөгәнен усал тартты—чаптар тынламады. Бер-берсеннән нәкъ сөңге озынлыгындагы ара калдырып батырлар узып киттеләр. Шулай да бер мизгелдә Тимерҗан бәкнең сөңге очы Ясүгәйнең калканын бәреп узды һәм шул җинел сугу да магул баһадирын ияреннән алып ташлый язды. «Гайрәтле дә соң син, Кыя батыр»,—дип уйлап алды Ясүгәй һәм ике-өч дилбегә озынлыгы ара узуга атын кире борды.

Батырлар янә бер-берсенең каршына ашыктылар. Ясүгәй түгәрәк калканын күкрәгенә кысты. Атлар бу юлы читкә тайпылмады. Менә Тимерҗан бәкнең йөзе якынайды. Ясүгәй аның җыерчыклар баскан яңакларын да шәйләде, мәсхәрә белән тулы карашын да күрде. Аһ, нигә ул татар бәге йөзеннән күз алмады икән?! Нәкъ шул мизгелдә бәкнең юан саплы озын сөңгесе Ясүгәйнең калканын ярып узды. Тимер көбәне сытып, күкрәгенә кадалган очлы сөңге магул баһадирын ияреннән әйләндереп атты. Ясүгәй күз алдында җиһан сүнде...

Үзәнлектәге тынлыкны сискәндереп татарларның тантаналы тавышы яңгырады. Тимерҗан бәк тә сөңгесен болгый-болгый тантана итә иде. Ул бераздан гына дошманына таба күз ташлады. Ясүгәй бер аягы белән өзәңгегә эләгеп калган һәм Уттояк аның гәүдәсен магул чирүе ягына тартып бара иде. Тимерҗан бәк Ясүгәйне инде мәеткә санап урыннан

кузгалмый да торды. Әмма ул ялгышты. Магул баһадиры анын жуйган һәм яраланган гына иде.

... Өч көннән сон, ниһаять, Ясүгәй күзләрен ачты һәм үзенен Балдак Далалагы тирмә эчендә ятуын анлады. Анын күкрәге чәнчеп-чәнчеп яна, күз алдында да яшелле-кызыллы утлар уйный иде. Шулай да ул үз янына тезләнгән Айлы бикәнен шәүләсен бик тиз шәйләп алды, анын тыелып кына үксегән тавышын да аермачык ишетте. Ясүгәй кулын әкрен генә кыймылдатып кызнын тезләренә кагылды, кибеп ябышкан иреннәре аша ике-өч сүз генә сытып чыгара алды.

—Әйт-тем бит, әйт-тем. Менә, үзен килден.

Айлы бикә анын тавышын ишетеп әүвәл гаҗәпләнде, аннары тагын да ярсыбрак елый-елый Сүгәйнен башын кочып алды, баһадирнын күзләрен, янагын, иреннәрен шашып-шашып үбәргә тотынды. Ясүгәйгә рәхәт, күкрәгендәге авырту да онытылган иде.

Айлы бикә тиздән тынычланды. Ул Ясүгәйгә карап кин елмайды, аннары оялудан йөзен түбән иде. Ясүгәй анын кулын үзенен учына кысып, кызнын ал йөзеннән карашын аера алмыйча ятты. Ләкин иннәренә баскан ил кайгысы үзенекен итте, бераздан ул шөбһәләнеп сорарга мәҗбүр булды.

—Орыш ничек беткән, сөйлә мина.

Айлы бикә карашын читкә яшерде.

—Бер як та җинә алмаган. Мәгәр Тимержан бәк юрамал гына чигенгән атлы булган да, тозак чирүе илә өч йөзгә якын тайҗутлыларны әсирлеккә алган.—Айлы бикә тын дәшми торгач, өстәде.—Дәритай энен илә Ярми бәк тә яраланып кайтты.

Ясүгәй тешләрен яман шыгырдатты, бик озак дәшми ятты. Ахырда түзмәде, сорап куйды:

—Син Тимержан баһадирнын монда килүен көткән иденме? Дөресен әйт.

—Мин яу булуын бөтенләй дә теләмәгән идем. Чилу бәйнен инде күптән мина кирәге калмады. Шулай булгач, магул илә татарларнын үзара орышуыннан бер як та отмый. Җитмәсә, кырнак бер кыз өчен.

—Син кырнагым түгел!

—Ә кемен сон?

—Беренче көнне үк әйткән идем. Мин сине үземә хатынлыкка алам.

Айлы бикә янә Ясүгәйнен йөзенә иелде. Бу төнне алар тәүге тапкыр бергә үткәрделәр...

Ясүгәй ике атна дигәндә аягына басты. Шул көнне үк туй итә башладылар. Магул ыруында орыштан яраланып кайтучылар байтак, өстәвенә Дәритай белән Ярми бәкнен дә хәлләре әле һаман яхшырмаган иде. Ясүгәй еракдагы кабиләләргә чапкыннар җибәрә алмады. Шуна күрә көрәштә дә, ат чабышында да нигездә нирунлылар белән кыятлылар гына катнашты.

Туй ыгы-зыгысы узгач, Ясүгәй тынычланган кебек булды, үзалдына елмаеп йөри башлады. Әмма берәр айдан Дәритай да савыкты һәм Ясүгәй белән алар арасында яман талаш купты. Дәритай кара татарлардан үч алырга чакыра, баһадирдан кабат чирү туплавын таләп итә иде. Ясүгәй теше-тырнагы белән каршы торгач, Дәритай нирунлылар янына качып китте. Анда инде Ярми бәк тә аягына күтәрелгән икән. Икәүләп алар янә яртылаш кардәш тиеш гирәй ыруынын олутбәге Түтән янына ярдәм сорап барганнар. Түтән бәк аларга ике мен чамасы нәүкәр биреп җибәргән. Иленә кайткач, Ярми бәк тагын өч мен тирәсе нирунлыларны ияргә күтәргән.

Әлеге хәбәрләр килеп ирешкәндә Ясүгәй инде берни кыла алмый, нирунлылар белән гирәйлеләр Далай күленә карап юлга чыккан иде. Кыш кереп килү сәбәпле бернинди саклык чарасы да күрмәгәннәр. Ярми бәк белән Дәритай чирүе Аргын елгасы буйлап кара татарларнын

төрбән кабиләсен талап узган. Бер ай буе шунда котырынганнан соң, магуллар әллә никадәрле ганимәт туплап һәм тоткыннар җыеп кайту ягына таба борылганнар. Тимерҗан бәк ашыгыч рәвештә чиру туплап, угъры магулларны куа чыккан, ләкин кар-буранлы юлда аларның эзен югалткан. Магуллар шулай бернинди зыян да күрмичә кайтып җиткән.

Ясүгәй баһадир ике-өч ай буена әнә шундый үкенечле һәм шөбһәле хәбәрләр көтеп яшәде, ябыкты, суырылды. Магуллар тантанасының тик вакытлы гына булуын, яз җитүгә кара татарлар белән яңа орыш күтәргә кирәклеген ул алдан ук белеп тора иде.

Тәңренең мәрхәмәте, әле ярый аның күңелен юатырга Айлы бикәсе бар. Ул ягымлы сүзләрен дә, кайнар кочагын да кызганмый. Өстәвенә соңгы бер ай эчендә шактый түгәрәкләнә башлады, Ясүгәйгә бер угыл табарга вәгъдә итә.

## 5

...Хәвеф һәм сөенеч күтә-күтә кыш та үтеп китте. Яз көне, алдан беренче булып, кара хәбәр килде:

—Керулен елгасы буйлап Балдак Далага таба кара болыт булып татар чирүе килә. Тимерҗан бәкнең нирун илә гирәйлеләрне кырып бетермичә торып кире борылырга исәбе юк икән.

Айлы бикәне Чилу бәй кулыннан урлаганга тугыз ай тулып килә, ул инде тулгак тотудан җәфалана иде.

—Нигә инде һаман кан коясыз? Минем туганнарым илә, зинһар, орышсыз-кансыз итеп килешә күр?—дип һәм Ясүгәйгә кылычын кыныннан чыгармаска ялварып, Айлы бикә нык өзгәләнде, ярсып үкседе.

Әмма баһадир кешенең башка чарасы юк, аңа үз кул астындагы кабиләләр иминлеген сакларга кирәк. Кыяттагы, нирун, тайҗут кабиләләрендәге барча ирләр ияргә менде. Сигез меңгә якын җайдак белән аларга гирәй бәге Түтән дә килеп кушылды. Сәрдәр итеп Ясүгәй баһадирны сайладылар. Аның кул астындагы җайдак саны ике төмәнгә тулды. Әмма магул кабиләләренең берсе дә яуга атлыгып тормый, нирун белән гирәйлеләр исә үзләренең кыш башындагы походларыннан бик канәгать, аларга да хәзер корбан бирү урынсыз шикелле тоела иде.

Тимерҗан бәкне Ясүгәй үз чирүен Каратау буена тезеп каршылады. Татарлар сан ягыннан азрак, әмма аларда көбә, очлым һәм кораллар күпкә шәбрәк иде.

Чирүдән аерылып, Ясүгәй алга чыгып басты. Мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып оран салды.

—Юкка кан коюдан бер як та отмый. Корбан урынына кәләш алышып яшәсә, кара татар да, магул да отар гына иде. Шул мәсләктән алышны батырларның орышыннан башлыйк. Җиңелгән батыр ягы кынынннан кылычын чыгармыйча кире борылмасмы? Минем сиңа әҗәтем бар сыман, әйдә, чык, Тимерҗан бәк.

Алмачуар төстәге биек айгыр иләмсез пәһлеванны чирүләр уртасына алып чыкты. Чигә һәм сакалындагы төкләр чалара башласа да, Тимерҗан бәкнең нарат кабыгы сыман яргаланган дәү куллары уйнаклап кына тора иде әле. Бүген ул озын сөңгесен читкә ташлады, тимер үзәнлеккә томырды, кулын кылыч сабына салды. Ике баһадир бер-берсенә текәлеп хәрәкәтсез калдылар.

Ниһаять, аргамаклар алга ыргылды һәм җайдакларны бер-берсенә каршы алып китте. Аралар якынайды. Тимерҗан бәк авыр гөрзиен иңбашына алды, ияреннән беркадәр күтәрелә төште. Менә батырларның күз карашлары очрашты, Ясүгәйнең тыныч йөзен күреп, Тимерҗан бәк ирен читләре белән генә мәсхәрәле төстә елмайгандай итте. Тимерҗан бәккә калса, менә ул тагын ике дилбегә озынлыгы араны узачак һәм гөрзие белән сугып магул батырының башын, һичшиксез, көбәсе эченә

чумдырачак иде. Әмма ул соңгы мизгелдә генә Ясүгәйнен кулларында бернинди дә корал булмавын, магул батырының нибары ат кылыннан үрелгән озын, нечкә бауны гына жилфердәтеп килүен күреп алды. Бәкнең тәне эсселе-суыклы булып китте, авыр гөрзие инбашыннан төште. Икенче мизгелдә инде кыл элмәк татар баһадирының инбашларын чорнап өлгерде. Бер дилбегә буе ара узуга Тимержан бәк иярennән суырылып төште. Уттояк пәһлеван гәүдәсен эреле-ваклы ташлар аунаган үзәнлек буенча сөйри башлады.

Тыгыз саф булып тезелгән магул чирүе өстендә тантаналы жиңү авазы купты, үзәнлек гүләде. Татарлар «аһ» иттеләр, йөзләренә курку, шөбһә чыкты. Магул батыры Ясүгәй Тимержан бәкне әсир итеп алса, татарлар өчен бу, һичшиксез, мәңге юылмаслык кара хурлык иде.

Әмма шул минутта һичкем көтмәгән коточкыч бәла туды. Тимержан бәкнең гәүдәсе эреле-ваклы түмгәкләргә бәрелә-сугыла сөйрәлә, ә Ясүгәй баһадир аның ягына әйләнеп тә карамыйча гына бара иде. Менә Уттояк үз каршына очраган зур-зур ике ташны сикереп узды. Озын кыл бау ташлар арасына шуышып төште. Тимержан бәкнең алыптай гәүдәсе зур ташларга килеп төртелде. Уттоякның чабып баруы тик бер мизгелгә генә тукталгандай булды. Нәкъ шул чакта кыл элмәк Тимержан бәкнең тимер көбә кигән инбашыннан ычкынды һәм муенын чорнап алды. Икенче мизгелдә инде татар баһадирының кылычтай киселеп чыккан башы кылганнар арасына тәгәрәп китте...

Үзәнлек әүвәл «аһ» дигән кызганыч аваз чыгарып инрәде, аннары ике як чирү дә тораташтай калды. Уттоякның кинәт кенә алга ыргылуыннан сискәнгән Ясүгәй дә артына борылды, тетрәнеп китте, йөзе агарынды. Уттоякны ул шундук кирегә борды, эре ташлар янына житәрәк иярennән сикереп төште. Йөгереп барды да, Тимержан бәкнең башын кулларына алды. Әле аның йөзенә, әле татар чирүенә таба текәлеп, нишләргә дә белми газапланды. Аннан гына ул кисек башны Тимержан бәкнең гәүдәсе өстенә илтеп куйды, үзе, эре ташлар янына чүгәләп, хәрәкәтсез калды.

Бераздан соң татар чирүеннән дүрт-биш жайдак аерылып чыкты һәм ташлар янына юыртып килә башлады. Ясүгәйнең йөзендә кыл да селкенмәде, чөнки аның өчен иң коточкыч бәла инде узган иде.

Татарлар бәкләре янына килеп тезләнделәр, арадан кайсыдыр ыңгырашып куйды. Бик озак вакыт буена алар да дәшмәде, үзәнлек өстендә дә һаман кабер тынлыгы гына хөкем сөрде.

Иң беренче булып, бәк гәүдәсе яныннан саргылт чәчле, зәңгәр күзле ир-ат күтәрелде. Аның йөзендә ниндидер таныш чалымнар тоюдан Ясүгәй әсәренде. «Минем Айлы бикәмнең әтисе Сәмыйк бәк түгелме соң бу?»—дигән уй зиһенен яндырып узды. Әмма аңа озаклап күзәтергә вакыт бирмәделәр. Аякка баскан татарлар арасыннан Тимержан бәк шикелле үк пәһлеван гәүдәлесе телгә килде.

—Без китәбез, батыр, орыш булмаячак.

Ясүгәй эндәшмәде. Татарлар Тимержан бәкнең гәүдәсен жирдән күтәрделәр. Шулчак карсак буйлы, сирәк тешле ир-ат өстәп куйды:

—Мәгәр татарлар ошбу хурлык өчен сине гафу кылмаячак, Ясүгәй. Шуны оныта күрмә!

Ясүгәй үз-үзен белештермичә әүвәл кылычына ябышты, аннан гына акылына килде. Берничә минуттан соң татарлар үзәнлектән чыгып югалды. Ясүгәй дә үз чирүенә кире борылырга әмер бирде. Орыш булмый калды, бу һичшиксез олы жиңү иде. Магуллар гөрләштеләр, нидер сөйләнделәр. Тик Ясүгәй генә кара көеп, үзалдына йомылып бара бирде.

Жәйләүләренә житәргә бер фәрсах чамасы ара калганда Балда-Дала ягыннан жан-фәрман чабып килгән ялгыз жайдак күренде. Килә-килешкә үк барча Онон ярын яңгыратып сөрән салды:

—Ясүгәй баһадир! Айлы бикә сәңә угыл тапты! Сәнең угылың бар!

Чигәләренә кинәт кан йөгерүдән Ясүгәйнең күз аллары караңгыланып китте. Туктаусыз рәвештә үзалдына «ниһаять, ниһаять», дип

кабатлады. Янда гына кемдер пышылдады:

—Галәбә килгән көнне угылың да туу бәк кыйммәтле фал инде ул, батыр. Магул сөлаләсенә нәкъ ошбу угылыңның дан вә шөһрәт китерүе ихтимал.

Инде дә түзә алмыйча, Ясүгәй баһадир Уттоякны алга куалады. Бераздан колакларында җил сызгыра башлады, җаны исә бер генә уй җылытты:

—Минем угылым бар! Минем угылым бар!..

Балдак-Далада Уттояктан сикереп төшүгә үк ул тирмә эченә чумды. Айлы бикә чыбылдык артында ята, сабый бала аның кочагында иде. Килеп тезләнде дә, Ясүгәй әүвәл Айлы бикәнең күкрәгенә борынын төртте, аннары сабыйны кулларына алды. Сабыйның йөзе, муены шәфәкъ төсле кызыл, тәне кайнар иде. Ясүгәй аның борынын, күкрәген, кулларын онытылып үбә башлады. Сабыйның уң кулын кысып йомарлаган көе тотуын күргәч, иплән кенә аның бармакларын ачты һәм сискәнеп китте. Сабыйның уч төбендә эрбет чикләвеге зурлыгында булып укмашкан... кан төене җәйрәп ята иде.

Чыбылдык эчендә бер читтә кендекче карчык пышылдап телгә килде, әмма аның сүзләре Ясүгәйнең колакларын ярып ишетелде:

—Атасына бер дә охшамаган... Усал, кансыз батыр микәнни соң монысы, йә, Күк Тәнрем?!.

Тышта инде баһадирлары артыннан кайтып житкән йөзәрләгән җайдакларның тояк тавышлары яңгырады. Сабыен тоткан көе Ясүгәй тирмә эченнән чыкты, аны кул очына алып югарыга күтәрде һәм тантаналы тавыш белән сугышчыларына мөрәҗәгать итте.

—Җиһанга менә минем дә угылым туды. Ул шөһрәтле Байшонкар сунарчы, Томавыл мәргән, Кабул хан вә Бәртән баһадир сөлаләсен дәвам итәчәк. Аның әтисе дә бүген орышта кара татарларның иң гайрәтле баһадиры Тимерҗан бәкне җинде. Ошбу тинсез галәбә хөрмәтенә мин угылыма үзем җиңгән дошман атын куям. Моннан ары ул җиһанда Тимерҗан бәк атын йөртәчәк. Безнеңчә—Тимучин.

—Ти-му-чин, Ти-му-чин!—дип сөрән сала-сала магуллар яңа туган батырны сәламләде. Шул көнне үк Балдак Далада сабый Тимучинга багышланган туй башланды.

Тарих дәрьясында бу һиҗри белән биш йөз дә илле, милади белән мең бер йөз дә илле бишенче елның агышы иде. Магуллар кавемендә генә исәп гап-гади: әлеге хәл дуңгыз елында булды, дип билгеләнде.

## Бишенче бәйләм

### 1

Андрей кенәз Бөек Болгар илен юкка гына сагынып искә ала, андагы хәят инде байтак айлар буе һич тә сокланырлык хәлдә түгел иде. Аның әле сәерлеге дә шунда: Болгарда тау чишмәсе сыман гөрләп кенә барган ил тормышы нәкъ Андрей кенәз киткән елда капылт җимерелде.

Шактый соңарып һәм инде шуңа үкенгәндәй, карлы-бозлы яңгырлары белән котырынып килгән нәкъ шул көздә Бөек Болгар җиренә берьюлы ике тарафтан дошман ябырылды. Муром, Суздаль, Ростов кенәзләкләреннән җыелып килеп, рус угрыларының әле Ука тамагындагы Калачыкны, әле үз эченә чирмеш, ар, эрҗә, мукшыларны алган Мәртүбә вилаятен талап китүләренә болгарлар инде күптән күнеккәннәр һәм тышкы чикләрне саклау өчен ялланган казакларны да, гадәттә, Ука, Сура елгалары тирәсенә туплап тота торганнар иде. Әмма ул көзне руслар үзләре «ушкуй» дип мыскыл итә торган юлбасарлар бөтенләй дә

көтелмәгән яктан—Чулман елгасы буенча—Корым-Чаллы, Тәмте вилаятьләренә үтеп керде. Колын кальгасына кадәрге жирләрне олау белән үтеп, соныннан Чипса елгасы буенча каекларда төшкән яна юлбасарлар Галич, Ярослав калаларыннан жыелган угрылар булып чыкты. Боларның көч-куәте бөтенләй дә мәгълүм түгел иде. Шәмгун хан аларга каршы, курсыбаен биреп һәм беркадәр гаскәр туплап, Ибраһим энекәшен юлларга мәжбүр булды. Әмир Ибраһим Чулман яры буйлап көнбатышка таба кузгалуга атна-ун көн дә вакыт узмагандыр, ак күбеккә баткан чапкын пайтәхеткә яна хәбәр китереп ирештерде:

—Олуг ханиям, бәла! Жаек дәрьясы аша мәмләкәткә карлукъ илә каныклылар чирүе һөҗүм кылды. Сәрдәрләре Сәгыйт хан кулыннан качып котылган кабих Манук икән.

Манук дигәннәре моннан утыз ел элгәре әтисе Әюп ханны, аның белән бергә унлап туганын болгарлар агулап үтергән чакта яугирләр кулыннан тик бер ялгызы качып котыла алган кыпчак бәге иде. Шул бер исем һәммәсен дә анлатканга күрә, Шәмгун хан бәйнә-бәйнә сорашып та тормады. Манук—болгар чирүләренен көч-куәтен инде кат-кат татып киткән яубашы, аның әпен-төпен генә әзерләнгән, юк-бар гаскәр белән үч алырга килүе бөтенләй дә мөмкин түгел иде. Яна чапкын килгәч, ул фараз кылулар тиз расланды. Манук бәк, чыннан да, Болгар жиренә егерме меннән артык жайдак белән кергән булып чыкты.

Вилаятьләрнен һәм түбә башы булып саналган эрерәк калаларның барчасына чапкын юллап, унбиш-егерме мең кешелек гаскәр туплаганчы ике атна чамасы вакыт үтеп китте. Ул арада инде яна хәбәр килде:

—Манук чирүе Сакмар суын кичкән!

Шәмгун хан кайнанасының энә очы кебек төртмәле карашыннан шүрләгән яшь килен житезлеге белән кабалана башлады, каушап калды. Зур яулар кузгалган чакта аның һичбер вакытта да тәхет ышыгында калганы юк иде. Бу юлы да чирү башына төп сәрдәр булып үзе басачагын белдерде. Шулай да соныннан, барыбер, гаскәрен ике төмән итеп төгәл бүлде. Бер төмән башы итеп Сувар каласының бәге Бәрәжне тәгаенләп куйды. Икенче төмәнне үзенен улы Колын кулына бирде. Сөзгәк тәкә сыман яуга атлыгып торган ярсу Хәмбәл, әлбәттә, инде, әтисенен кул астында иде. Пайтәхетне, аның да әле аеруча тәхетен саклау өчен Биләр каласында нибары бер мең кешелек алай белән Әрбәт кенә торып калды.

Сакмар елгасына төбәп юнәлделәр. Кар катыш яңгырлы көзге юллар тиз барырга ирек бирмәде. Көндезләрен дә ыстан булып туктап атларны ашатырга, азатларны учак, казан янында ял иттерергә туры килде. Багучы итеп бер күчеш алга озатылган иравыл алае гына йокы күрми иде. Садак елгасына житкәндә багучылар китергән хәбәрләр болгарлар арасында таркаулык кына өстәде.

—Манук үз чирүен урталайга бүлде. Бәгъзе кыйсем Тук суы буенча Әтил эргәсенә таба бара. Икенчесе Дим буйлатып шималь тарафына юл алды.

Шәмгун хан бу юлы да бик нык каушап калды. Шул каушавы белән хаталанды да.

—Карьялардагы гөнаһсыз инсаннарны баскыннардан талаттырып булмый. Безгә дә олуг чирүне икеләйгә бүлергә туры килер. Кабих баскыннарга янә кушылырга имкян бирү муафыйк гамәл түгелдер.

Шәмгун хан бу карарын үз янына мeнбашларны жыйгач игълан иткән иде. Әлбәттә инде, хан сүзенә каршы килердәй батыр табылмады. Ә күчмә киез чатырдан менбашлар чыгып киткәч, Шәмгун хан үз карарын фәкать Колын углына гына жеген-жеккә тезеп анлаткандай итте.

—Фараз кылуымча, угры Манук Дим буйлатып мәмләкәт үзәгенә һөҗүм итмәк булыр. Астыртын морады—мәнем яуда йөрүдән фәтва кылып, пайтәхетне яулап алудыр. Шуна күрә мәнем үземә пайтәхеткә якын арада хәрәкәт кылу хәвефсезрәк булыр. Мәгълүм гамәл: ханиягә үз тәхетеннән ерак китми йөрү—муафыйграк адым. Мин хәл иттем. Үзем

илә төмәнбашы Бәрәжне ияртәм дә, мин угры Манукка пайтәхет юлын биклим. Ә син, угылым, үз төмәнең илә Әтил буена ашык. Баскыннар Болгар калаларына зәүрәт китермәсен.

Әмир Колынның зиһенен әрем сыман әче бер уй капылт яндырып узды. «Юкка гына мәмләкәт вә халаек кайгысын үз итмәк булып монафыйкланасың, әткәй. Үтәли күреп торам бит: синең өчен ин-иң хәйран вә сәгадәт[1]—Биләр тәхете шул...»

Икенче таңда сабах намазын укып дога кылганнан соң ук, болгар чирүе ияр өстенә менде. Ике төмән дә, капма-каршы тезелеп, сөңгеләрен чөеп хушлаштылар. Шәмгун хан иярендә утырган килеш кенә әмир Колынны кочагына алды.

—Галәбәләр насыйп әйләсен сиңа угылым.

—Үзеңне саклый күр, ханиям.

Ирләр башкача бер сүз дә алышмады. Аргамаклар алга ыргылып берникадәр ара узганнан соң да, бер-берсенә караш ташлаучы җайдак табылмады. Яу юлында артка әйләнеп карау бик яман фал иде. Берсе—хан, икенчесе әмир тәхетен яулаган ата белән ул турында бу таңда алар мәңгелеккә хушлаштылар дип һичкем уйламады.

Ләкин тәкъдир болгарлар белән, сугым малын чалган чакта догабисмилланың ни икәнен дә белми торган явыз кассап[2] сыман, аяусыз эш йөртте. Шәмгун хан да, әмир Колын да яу кырында нәкъ бер үк көндә баш салдылар. Шәмгун хан нык ялгышкан, Дим елгасы буйлап күтәрелгән карлуклар чирүе сафында Манук бәк юк, ул үз җанына якын Кыпчак Даласы аша Иделгә таба хәрәкәт итә иде. Әмма карлуклар да мәкер-хәйләгә оста булып чыкты. Бөгелмә-тау буенда шулар корган тозак чирүе тарафыннан тулгамага эләгеп, Шәмгун хан күз ачып йомганчы хассә-алаенең[3] нәкъ яртысын югалтты. Инде ханга тотык булып төшү хәвефе дә яный башлаган иде. Шулвакытта ике меңбаш белән бергә, карлуклар божрасын ярып, тулгама эченә Бәрәҗ бәк бәреп керде. Хассәалай газиләренә дәрт өстәлде, тантана авазлары үзәнлекне ярды. Ләкин кайсыдыр бер мизгелдә, билгесез дошман очырган сөяк канатлы ук Шәмгун ханның муенын яман тырнап узды. Моңа әлләни игътибар да итмичә, хан әле һаман дәү кылычы белән уңлы-суллы килеп орышуын гына белә иде. Тик берзаманны аның хәле бетә башлады. Газиләр аны яу кырыннан читкә алып чыкты. Ят күзләрдән читтә корылган киез чатыр эченә салгач, хан озак сәгатьләргә түзә алмады. Дошман очырган ук агуланган иде, моны инде яраннарының һәммәсе дә аңлап өлгерде. Ә Шәмгун хан киезләр өстендә боргаланып берникадәр вакыт тартышты да, офыкта шәфәкъ яктысы уйнаганда мәңгелеккә тынды. Баш сәрдәр булып калган Бәрәҗ бәкнең ысылдап дәшкән әмере усал янгырады:

—Карлукларны тар-мар итми торып, хан вафаты турында игълан ясамау фарыз. Теленә нәхуҗа хатынҗәмәйләрне гафу кылмыйм. Андыйларны шәхсән үзем кылычтан уздырачакмын!

Шәмгун хан җеназасы яткан киез тирмәне көчле сак астына куеп чирү каршына чыккач, Бәрәҗ бәкнең яңа әмере яңгырап ишетелде:

—Дошман кулыннан тартып алынган ганимәтләрнең һәммәсе дә азатларның шәхсән малы булып саналачак. Хания илә сәрдәрләр үзләренә бер кыйсем дә ганимәт таләп итми. Асла шикләнмичә яуга ташланыгыз.

Бәрәҗ бәк ни сөйләвен нык чамалый иде. Болгарлар, чыннан да, карлуклар өстенә ярсу карчыгага охшап ыргылдылар...

Әмир Колын өчен дә соңгы сәгать көтмәгәндә генә килеп җитте. Манук бәк чирүен болгарлар Тук елгасы ярында ук куып тотты. Колын инде төмәнен уңга-сулга җәеп, каныклыларны елга суына таба кысрыкламакчы да иде. Манук үз гаскәренә ныклы ыстан корырлык җай калмавын

---

[1]Хәйран вә сәгадәт—яшәү һәм бәхет чыганагы.

[2]Кассап—ит чабучы.

[3]Хассә алай—шәхси гвардия, дружина.

чамалады бугай, сөнгесен югарыга чөеп, ул таш дивар шикелле тыгызланып баскан жайдаклары каршына атылып чыкты.

—Мән монафыйк болгарлар тарафыннан инде әллә ничә кат мәсхәрә кичергән бәкмен. Яуда кизәк кылу[1]—минем хокукымда. Шул мәсләктән чыгып, мән сезнең чирү башыгызны орышка чакырам. Куян йөрәкле әрвах түгел икән, минем каршыма чыксын.

Манук бик тә сирәк кулланыла торган дала канунын барча азатларга ишетелерлек итеп, кычкырып игъланлады. Әйе, Манук—әтисе Әюп ханны болгарлар агулап үтергән чакта исән-имин качып котылган бердәнбер бәк, хәзер инде кан үче таләп итсә дә, хәтта, шунысы да аның хокукында иде. Орышка чыга калса әмир Колынның үзе башлап кылыч та күтәрә алмаячагын чамалаганга күрә болгарларның һәммәсе дә коточкыч шөбһәгә чумды. Үзәнлек өстен тынлык сарып алды, хәтта атларның йөгән селкетүе дә яңгырап ишетелде.

Шулчак, иң беренче булып, урыныннан Хәмбәл кузгалды. Әлбәттә, аның кем булуын Манук та чамалады. Тәнендә хан каны аккан бәк буларак Хәмбәлнең дә Манукка каршы орышка чыгарга хокукы бар иде. Ләкин Хәмбәлне әмир Колынның кырыс тавышы жиргә кадаклап куйган сыман итте.

—Ата кешенең үз баласын әүвәл башлап кылыч астына куярга хокукы юк, угылым. Син артка чик. Кизәк кылу Манук хозурында булса да, орышка чыгу минем өлешемә тигән көмешләр.

Колын чаптыры чирүләр арсындагы киң мәйданга чыкты. Сәрдәрләр карчыгалар сыман бер-берсенә каршы ыргылды. Чирүләр өстендә тәннәрне өшетә торган боздай тынлык туды. Манук бәк сөнгесен еракка сузып алга ята төшкән, ә әмир Колын фәкать түгәрәк күн калкан артына ышыкланып кына оча иде.

Орыш язмышын гоманлау артык гамәл иде, ул тиз хәл ителде. Манук килә-килешкә үк Колынны иярennән бәреп төшерде, икенче мизгелдә инде, чаптарын кырт борып, аякларына күтәрелә башлаган әмирне сөнге очына алды. Муенын сөнге үтәли ерып чыккан Колын гәүдәсе жирдә аунап калды, ә Манук ике кулын күккә чөя-чөя тантана итә башлады.

—Тугры, Ибәк, Әюп хан!

Жинүче бәк, шул рәвешчә кычкыра-кычкыра, инде күптән вафат булган кыпчак ханнарының рухын чакыра, үз тантанасына аларның да шаһит булуын тели иде. Ләкин ни гажәп: кыпчак бәген теге дөньядан кайтырга «тиеш» булган ханнар рухы түгел, хәтта каныклылар да дәртләндереп кычкырмыйлар иде.

Ә ул арада инде ачык мәйданга унбиш кадаклы гөрзиен иңбашына салган Хәмбәл атылып чыкты. Тимер чөйләре чекрәеп торган гөрзие генә түгел, бәлки кара көйгән, нуры качкан, шөкатьсез кыяфәте белән дә куркыныч иде ул.

—Ошбу тарафка борыл, яу нәкәсе![2]—дип, Хәмбәл иләмсез тавышы белән оран салды.—Нахак ысул илә атам жанын кыйдың, мәгәр бик куанма. Тамырыннан өзелгән кылган сымак мәмләкәтеннән куылган бәк булсаң да, атам өчен мән синнән үч алам. Мән синең Газраилең бүген. Кизәк кылу хокукын узды инде. Гадел орышка чык, тукал[3] сөлтек[4]!

—Бәгъземез сөлтектер, анысын яу күрсәтер. Мәгәр мәмләкәттән куылу бер бәктән дә ерак йөрми бит ул. Аң бул, селәгәй!

Манук үз-үзенә куәт өстәргә тырышып кычкырса да, тавышы тоңык чыкты. Ә Хәмбәл, учак тирәли йөгергәләп йөргән әрвах яки алыш

---

[1]Кизәк кылу—орышта беренче булып сугу чираты.
[2]Яу нәкәсе—кешелексезлек, дошман.
[3]Тукал—мүкләк.
[4]Сөлтек—карачкы.

алдыннан тояклары белән җир чокыган гаярь үгез сыман үзен-үзе кыздыра, ярсыта башлады.

—Тукал! Сөлтек! Мәмләкәтеннән мәхрүм калган әрвах! Шуңа күрә печелгән айгыр, нәселсез алаша бит син!

Беренче булып Манук үз чаптарының касыгына типте. Хәмбәл исә, имән кәүсәседәй таза кулы белән унбиш кадаклы гөрзиен югарыга чөйде дә, дошманына каршы ыргылды. Ара күз ачып йомганчы кими башлады, чирүләр өстенә янә тынлык иңде. Һәммәсе дә котсыз кыяфәте белән өрәккә охшап килгән Хәмбәл пәһлеванга текәлделәр. Хәмбәлнең шул котсыз кыяфәте кыпчак бәгенең тәмам өнен алды. Җайдаклар берберсе янына җитәргә бер тотам ара калгач, Манук үз атын капылт читкә борды. Хәмбәлнең югары күтәргән тимер чөйле гөрзие буш һаваны гына ярып узды.

—Җебегән! Тукал! Куркак!—дип, Хәмбәл коточкыч ярсу белән үкерде һәм айгырын шундук кирегә таба борды.

Өне качкан Манук та бу мизгелдә мәйдан уртасында катып тора, ләкин аның инде болгар батыры белән кабат йөзгә-йөз килергә куәте юк иде. Хәмбәлнең янә үзенә таба томырылуын күргәч, кыпчак бәге каныклылар ягына элдертә башлады. Әмма тәкъдиреннән качып котыла алмады ул. Ике ук очышы ара узуга ук Хәмбәл аны дөянекедәй эре сөякле аргамагы белән куып җитте. Янә бер мизгелдән соң тимер чөйле гөрзи Манук очлымы өстенә барып төште. Ике як чирүдә дә һәммәсе «аһ» итте. Мануктың чаптары да чаба, гәүдәсе дә аумый, төз утыра, ләкин кыпчак бәгенең башы булырга тиеш урында... ап-ак умыртка сөяге генә тырпаеп тора иде.

## 2

Шәмгун хан вафатыннан соң ике тәүлек узгач, күзгә төртсәң күренмәслек караңгы төн уртасында, Биләр капкасы каршында күбек белән катнаш ләмгә баткан чапкын пәйда булды.

—Мәмләкәткә олы кайгы иңде. Күперне төшерегез. Мин—хан чапкыны,—дип, ул имән каланчалар өстендә торган toткавылларга оран салды.

Тавышы өзек-өзек булып һәм гыжылдап чыкса да, toткавыллар аның хуҗасын бик тиз танып алды. Болгар иленең һәм Биләр каласының баш сәете Давытның җигән[1] энекәше, изге итеп искә алынучы Якуб Ногман оныгы, ә үзе шагыйрь буларак танылган Сөләйман әл-Сувари иде ул. Гәрчә үзе күбесенчә Сувар каласында яшәсә дә, шагыйрь Сөләйман Биләр, Болгарга да бик еш килеп йөри, чичәннәрнең бәйге-мәҗлесләрендә гел катнаша, шуңа күрә аны һәркем таный һәм үз итә иде...

—Ханнан чапкын килде,—дип шыгавыллар кереп эндәшүгә, Әрбәт йокысыннан куркып уянды. Әмир үз өстенә җылы җилән киеп өлгергәнче, бүлмәгә инде Сөйләйман килеп керде.

—Кара хәбәр китердем. Ир бул, олан.

Шагыйрьнең шушы сүзләре үк Әрбәтнең җанын-тәнен кызган энә кебек үтәли яндырып узды. Әмма ул аксаклап булса да шагыйрьнең каршына килде, Сөләйманның күзләренә туры текәлеп бакты.

—Бәла казык башыннан түгел, безнең баштан йөри. Сөйлә, борадәр.

—Шәмгун атаң вафат. Алдан хәзерләнгән агулы уктан үлде. Кем угы булгандыр ул—тәгаенләү мөмкин гамәл түгел.

Әрбәт иярennән сугып төшерелгән яралы җайдак сыман, авыр итеп ыңгырашып куйды. Сөләйман аның күзләренә керердәй булып текәлде. Юк, әмир кыяфәтендә-йөзендә ясалмалык һич чагылмый иде. Шагыйрь үкенечле, хәвефле тавыш белән сүзен дәвам итте:

[1]Җигән—туганнан туган, ягъни, бертуганның баласы.

—Шәмгун ханга ясин чыгучы булмады. Җеназасын да үткәрә алмыймыз. Хан мәете Бәрәҗ бәк кулында.

Әрбәтнең күзләре зур булып ачылды, бөтен тәне җилләге пәрәвез ятьмәсе шикелле кинәт калтырый башлады. Шагыйрь чамалады: әмирне ярсу, нәфрәт уты шашкын учак булып эчтән талый иде.

—Бәрәҗ бәк хан вафаты хакында азатларга җиткерүне тыйды. Синең илә Колын-Хисам бораdәрең эргәсенә чапкын юллаучыларга да үлем хәвефе яный. «Чапкын озаткан һәр соранны[1] шәхсән үзем кылычтан уздырачакмын».—Бәрәҗ бәкнең менбашларга җиткергән әмере әнә шундый.

Әрбәтнең тәне, яңаклары әле һаман җепшек кар астыннан бәреп чыккан язгы чишмә кебек тартыша, калтырана иде. Ул нибары бер сүз генә сытып чыгара алды.

—Ә син?

—Минем гомер бизмәннәргә салгысыз байлык түгел. Ул хакта сүз кузгатып торуы да артык.

Сөләйман көчле янгырдан соң утырып калган җиһан сыман беркадәр тын торды. Аннары әмир йөзенә текәлеп, тагын да хәвефләнә төшкән тавышы белән дәште:

—Мәмләкәт иясез калды. Ул буралкы[2] хәлендә. Менә бәла кайда. Ә буралкы муенына тәүге булып кем бугалак сала, аның сыртына да шул ук инсан сикереп атлана бит. Бәрәҗ бәк ошбу шайтан коткысына бирелмәс дип, кем әйтә ала?

Әрбәтнең йөзенә ярсу төс өстәлде, аяк калтыравы ешайды.

—Ни-и-ничек Б-б-бәрәҗ? Ко-ко-колын бо-бораdәрем вәли гаһед булырга тиешле бит,—дип, тотлыга-тотлыга, ләкин барыбер чиксез ачу белән эндәште ул.

—И-и-эх, Әрбәт оланкаем,—дип Сөләйман-шагыйрь башын чайкады да, үз итеп, әмирнең иңбашына кулын салды.—Ханнар сөлаләсе сәер кавем шул ул, берүк гаеп итмә. Теләсә кайсы инсан тәненә чыбык очы тиклем генә хания каны эләкте исә, андый бәндә иртәгә үк үзен хаклы вәли гаһед дип фараз кыла башлый. Ә Бәрәҗ бәк моннан утыз-кырык сәнә элгәре Болгар хакиме булып торган Сәгыйть хан оныгының углы. Ибраһим бәк, Колын-Хисам, Хәмбәл илә синең сымак ук Бәрәҗнең дә мәмләкәт тәхетен үзенә дәгъваларга хокукы бар. Бүген Болгар мәмләкәте өстендә кургаш болыт сыман өелеп торган бәла-казаның асылы шушы инде.

Болгар иленә янаган бәланең күләм-куәтен Әрбәт тә тулысынча күз алдына китереп өлгерде. Яңакларындагы калтырану юкка чыкты, карашында ачу-нәфрәт авыр сагыш белән алышынды.

—Хан тәхетен максат итеп куйса, Бәрәҗ өчен бүгенге көн гайре кулай очрак. Ибраһим бәк тә, Колын бораdәрем дә ерак төбәкләрдә яу кылып йөри. Ә Бәрәҗ бәк Бөгелмә-тау эргәсендә, борын төбендә генә. Кулы астында бер төмән чирүе дә бар. Ният итсә, Биләргә юл ачык. Минем азатлы алай белән генә мин тәхетне саклап кала алмамдыр.

Сөләйман-шагыйрь әмир Әрбәтне тынычландырмакчы булды.

—Байчура бәк Ибраһим илә Колын-Хисам әмирләр эргәсенә дә елдам чапкын куды. Ходай тәкъдирендәгене фараз кылуы читен. Шулай да, бәлки, йә Ибраһим бәк, йә Колын-Хисам пайтәхеткә алданрак кайтып өлгерер. Мәгәр бәлки генә шул, бәлки генә...

—Әшгар[3] остасы! Ә син нигә һәммә фикереңне дә әйтеп бетермисең?—дип, Әрбәт капылт ярсып җикерде. Ачулы күзләре кисәк кабынган утлы күмерне хәтерләтте.—Ибраһим бәкнең дә, әмир Колынның да пайтәхеткә кайтып өлгерүен теләмисең бит син, теләмисең! Аларны

---

[1]Соран—төсен үзгәртүче җәнлек, хамелеон.
[2]Буралкы—өйрәтелмәгән, бер тапкыр да иярләнмәгән ат.
[3]Әшгарь—шигырь.

тәхеткә утыртмас өчен түгел. Син шул тәхет аркасында болгар халкының үзара бугазга-бугаз килгәнен, тоташ кан коюын теләмисен.

Сөләйман бер сүз белән дә җавап кайтармады. Таш ватып арыган кеше кыяфәтендә Әрбәт йомшак келәм өстенә барып утырды, куллары сынган каз канатлары шикелле асылынып төште.

—Нә аяныч,—дип телгә килде Әрбәт, тик бераздан гына. Тавышы сүлпән һәм гаять моңсу иде.—Тәхет хакына дип болгар халкының үзара суешуын мин дә теләмим шул. Юк, теләмим!

### 3

Тагын өч көннән соң, Биләрне Бәрәҗ бәкнең төмәне камап алды. Кала күперләре күтәрелгән, азатлар белән бергә һөнәре-субашлар да дивар өстенә менеп баскан иде. Бәрәҗ дистәләгән яу кичереп, тормышта байтак тәҗрибә туплаган бәк иде, дивар артындагы ур өстенә менеп калага күз ташлауга, һәммәсен ачыклады. Дивар белән ур арасындагы ерымнарга су җибәрелмәгән. Кала эчендә төтен әсәре күренми, димәк, казаннар астына ут ягып су һәм сагыз кайнатучылар да юк. Дивар өстенә тезелгән ирләрнең дә бик азы гына көбә күлмәк белән тимер очлымнардан. Көлке, гаҗәп: диварга менгән һәм бүрек-бишмәттән торган ирләр арасында сөңге урынына очын учакта яндырып каралткан таяк кына тотып басканнары да байтак.

Бәрәҗ бәкнең шиге калмады: биләрлеләр кан коярга исәпләми иде. Шуны тагын бер кат сынарга ниятләгән сыман, Сувар бәге юрга атын ур өстендә уйнаклатып торды. Оста мәргән өчен һичбер кыенлык юк, дошман итсә, ул бәкне инде күптән сәрпи ук[1] очына утырта ала иде. Ләкин дивар өстендә җәя күтәрүче азат күренмәде.

Бәрәҗ үз янына наибен дәшеп алды. Аның тавышына хакимнәр мәкаме өстәлеп өлгергән иде инде.

—Калага кер, фәрманымны җиткер. Ниндәен генә монафыйклык уйлап тапмасыннар, асла кабул кылмыйм. Шартым мәгълүм. Чонтык Әрбәт капуларны ачсын, үзе пайтәхетне калдырып китсен. Мән Сәгыйть хан токымы. Ә Сәгыйть хан Әрбәт әмирнең атасы Шәмгунга ага булган хаким. Шәригать буенча, тәхет миңа тиеш.

Ияр өстендә утырса да, наиб бик тырышып башын түбән иде. Наиб йөгәнен тарткалый башлагач кына, Бәрәҗ йомшаграк аһәң белән өстәде.

—Әмир Әрбәт буйсынчаклык кылса, асла онытмамын. Хания мәрхәмәтен күрмичә да калмас. Мәгәр инде...—Бәрәҗ тавышында янә корыч чыңы чагылды.—... Хилаф гамәл кыла, минем юлыма киртә куя икән, ярлыкау көтмәсен. Чүгәр-чигенер әмәлем юктыр. Мәркәзне җимереп юкка чыгару да, тоткавылларын кылычтан үткәрү дә мине туктатмас. Мәгәр инсаннарның каны коела икән, барча гөнаһасы Әрбәт өстенә ягылыр. Ул чонтыкны шул хакта кисәтергә дә онытма.

Бик озак көткәннән соң гына, күпер төшерелде һәм киң капка ачылды. Ләкин каладан салмак кына чыгып килүче кеше Әрбәт тә, Бәрәҗ бәк наибе дә түгел, ә илнең баш сәете Давыт карт иде. Ил өстенә килгән хәвеф, әйтерсең лә, аның иңнәренә авыр йөк булып яткан. Сәетнең гәүдәсе җиргә сеңгән шикелле чүгеп, кечерәеп калган. Йөзе сабыйларын җуйган мескен ананыкы сыман борчулы һәм боек, карашыннан сагыш бөркелеп тора.

Бәрәҗ ияреннән төште, кулларын чапан итәгенә сыпыргалап куйды. Исәбе мөхтәрәм сәет белән ихлас күрешү иде. Әмма Давыт аңа килеп җиткәнче үк туктап калды, ике кулын күкргенә кушырып, баш игәндәй итте.

---

[1]Сәрпи ук—тигез колаклы, еракка оча торган ук.

—Әссәләмүгаләйкүм, дияр идем, мәгәр Мөхәммәт пәйгамбәрнең ошбу изге теләген ниятендә кер вә харам гамәл булмаган инсаннарга гына багышлыйлар. Ә син үзенне жиһанга яраткан ананнан да газизрәк булырга тиешле мәмләкәтең өстенә шайман[1] илә килден. Аның инсаннарына—Аллаһы Тәгалә колларына үч вә кан илә яныйсың.

Давыт кайчандыр Сувар каласында сәет булып торган дин башлыгы иде. Әле шул чакта ук Давыт туры сүзле һәм тәкәббер булды, шуңа күрә Бәрәҗ бәк белән икесе үзара тынышу белмәделәр. Шәмгун хан Давытны Биләргә баш сәет итеп чакыргач, Сувар бәге колын салган бия сыман җиңел сулап калды, Ходай Тәгаләгә шөкерана кылып яшәде. Ә хәзер язмышның уйнавы яки сынавы түгел, дип әйтеп кара инде. Менә бит «Тәкъдир» дигәннәре Бәрәҗ бәкне шул сәет белән янә очраштырды. Аның әле иң аянычы да шул: Бәрәҗ бәк мәмләкәтнең баш сәетен санга сукмыйча һич булдыра алмый һәм хәзер тешен кысып булса да түзәргә мәҗбүр иде.

—Мән бәгъзе инсанга да үч вә яу илә янамыйм, мөхтәрәм сәет хәзрәт,—дип, Бәрәҗ мөмкин кадәр тыныч күренергә тырышып җавап бирде.—Мән фәкать үземә тиеш булган тәхеткә дәгъвамны гына белдерәм. Сәгыйть хан сөласенең бәгъзе вәкиле буларак, мәнем ана дәхелем бар, дип саныйм. Син дә моны инкарь итмисеңдер?

—Юк, инкарь итмим, бәк. Мәгәр даулашып алган зиннәтнең бәрәкәте булмый бит аның, син шуны да онытма.

Сәет кулына тотып килгән сөян таягына таяныбрак басты. Аның нияте Бәрәҗне үгетләп, анык килешүгә ирешүдә иде.

—Син, менә, үз мәнфәгатьләреңне генә алга сөрәсең, бәк. Хан тәхетен фаразлап күзләрен сукырайган. Шул ук вакытта олуг ул тәхеткә Ибраһим бәк тә, Колын илә Әрбәт әмирләр дә алагаем тулы хокуклы бит. Ә син нишләп алар мәнфәгатен күз чалымына да китереп карамыйсың?

Бәрәҗ бәк тешләрен шыгырдатып, усал ысылдады.

—Мән үз дәхелемне инде игълан кылдым. Янә бер тапкыр кабатлыйм. Мән Сәгыйть хан сөләләсенең өлкән вәкиле. Тәхет мина тиеш!

Сәет каш астыннан сөзеп текәлде.

—Хуп, шулай да булсын, ди. Ә нигә соң алайса төмән илә килдең?

—Чонтык Әрбәтнең пайтәхетне үз ихтыяры илә ташлап китәсенә шикләнгәнгә күрә. Кылыч исә гайре тискәре билне дә урталайга өзә.

—Ә Биләр халкы ул әмирне инде хан итеп игълан кылган булса?

—Кире чигенәсем юк. Андый мәлдә миңа тәхетне көч илә яулау юлы гына кала.

—Хәзер инде уйла, бәк,—диде дә, сәет Давыт беркадәр тын торды.—Хуп, син тәхеткә даулашып минден дә, ди. Ә мәмләкәтнең ерак почмакларында үз чирүләре илә шул мәмләкәт мәнфәгате бәрабәренә үк яу кылып йөргән Ибраһим бәк берлә әмир Колын да бар. Иртәгә пайтәхет эргәсенә үз төмәннәре илә алар кайтып җитәр. Әгәр алар да иртәгә тач синең шикелле үк адым кылса? Алар да хан тәхетен инде синнән көч илә дәгъвалый башласа? Андый хәвефле мәлдә син нишләрсең?

Бәрәҗ сүзендә нык торды.

—Сусаган ат инешкә борынын төрткәч, кире чигенү белмәс. Мән шундый аттыр, сәет.

Давыт инде дә түзә алмыйча, күңелендәге уен ачып салды.

—Әллә Ибраһим илә Колын-Хисам кайтып җиткәнче түзәсеңме соң, бәк? Ул чагында, бәлкем, йә үзегез килешә алыр идегез, йә барча вилаять бәкләре, вә тарханнар, вә сәетләр, пайтәхеткә тупланып, берегезне сайлап куяр иде. Шулай гаделрәк булыр, башкаларда дәгъва калмас иде, әллә көтәсеңме?

—Көтмим, сәет. Юкка изаланма.

—Гөнаһсыз инсаннарның каны агачак бит. Нигә Аллаһы Тәгаләнең

[1]Шайман—сугыш кораллары яки киемнәре

колларын кызганмыйсың?

Бәрәҗ бәк инде күптән койрыгын кысла eләктергән төлке сыман кыбырсый башлаган иде. Сәетнең соңгы сүзләрен ишеткәч, ул йөзе белән читкә борылып басты.

—Хәер...—Давытның тавышы гаять тонык чыкты, сизелеп тора, сәетнең рухы инде сынган иде.—Чебен безләгәннән филләр өркәме дә, чебен кырылганга алар кайгырамы? Йә, Ходаем! Изге болгар халкын нигә мондый канлы мәхшәр җибәреп җәзалыйсың? Гөнаһымыз нидә?

Бәрәҗ бәк кулына камчы алды. Инде шикләнерлек урын юк, ул калага һөҗүм ясарга хәзерләнә иде.

—Яуга әмер бирмә,—дип эндәште аңа сәет, элеккечә үк, мәгарәдәге талгын чишмә чылтыравын хәтерләткән тонык тавыш белән.—Биләрдә сиңа каршылык кылучы булмаячак. Янап әйтүем түгел, мәгәр искәртү бик фарыздыр. Дау илә килгән хан өчен ошбу мәмләкәттә сөенүче инсан булмаячак. Андый мәмләкәт илә хакимлек кылу да ай-һай, читен булыр сиңа.

Шул кичтә үк яраннары, аумакай субашлары һәм ялагай сәүдәгәрләр Бәрәҗ бәкне хан тәхетенә күтәрде. Мәмләкәт туграсындагы канатлы ак барс канатлы аждаһа сурәте белән алышынды. Тагын шунысы гаҗәп: яңа хаким пәйда булган тәүге көндә үк Биләр каласының ярлы-ябагае аңа «ат мөгезе кебек уяу колаклы хан» дигән кушамат-бәһа биреп тә өлгергән иде инде.

## 4

Болгар илендәге аяныч һәм коточкыч мәхшәр пайтәхеткә Хәмбәл кайтып кергәч башланды. Әгәр сизгеррәк булса һәм зирәгрәк эш йөртсә, әлеге болганчык көннәрдә Хәмбәлнең, хәтта, хан тәхетенә күтәрелергә дә өмете бар иде. Чөнки Болгарлар ана, берьяктан, туган әтисен югалткан өчен ихлас күңелдән теләктәш булса, икенчедән, каныклыларның бер төмән чирүен пыран-заран китергән, ә үз гаскәрен тулысынча диярлек саклап кала белгән, ил өстенә тыныч тормыш, иминлек китерүе өчен нык соклана иде. Өстәвенә, Хәмбәлнең орышта Манукны юк итүе, шундый шәхси үрнәге белән үк болгарларны җиңүле яуга рухландыра алуы турындагы хәбәрләр Бәрәҗ бәк ягына ауган төмән алайларына да кайтып ирештe һәм әлеге чирүдәге байтак азатлар да батыр сәрдәр, гадел хан хакында хыяллана башлады. Мондый кулай тарафның һәркайсы да Хәмбәл тегерменәнә инеш булып коела һәм теләсә, әгәр бик теләсә, аңа хан тәхетенә юлны ача ала иде. Һич югы, ул бер төмән гаскәре белән пайтәхет диварлары буена кайтып тик кенә торса да, аның язмыш бизмәнен үз ягына аударырдай өмете бар иде.

Ни үкенеч, яугир егет мондый, ашъяулык өстенә тезеп куелган затлы сый шикелле ымсындыргыч, уңай якларның берсен дә шәйли, файдалана белмәде. Орышларда үзен—курку белмәс пәһлеван, яу кырында зирәк сәрдәр итеп танытса да, сәясәттә, мәгыйшәттә Хәмбәл имчәк баласы сыман сукыр булып чыкты. Аның каравы, мәкер белән тәхеткә үрмәләгән Бәрәҗ үзен тиңсез сәрдәр итеп тойган яшь әмирнең данга, яуга омтылучан гадәтеннән оста файдаланды.

Әле Хәмбәл юлда чагында ук аны Бәрәҗ юллаган ялагайлар белән үгетчеләр урап алды. Биләр каласында булып узган хәлләрне алар, әлбәттә, үзләре өчен отышлы балга-майга төреп бәян итә белде:

—Сиңа гамуҗә[1] агаң тиеш булган чонтык Әрбәт тәхеттән үзе баш тарткан. Хәрәзем, Үргәнечләрдә гыйлем эстәп акыл шәрифләре кыегайган бугай. Давыт карт урынына Биләрдә олуг сәет булырга ниятли, үзенә шуннан гайре дәрәҗә фарыз түгел, дип әйткән, ди. Бәрәҗ бәк хан

[1] Гамуҗә—әтисе белән бетуган.

булырга әүвәл дәгъва итмәгән. Пайтәхетнең биләре, имамнары аның эргәсенә килеп үтенгәч кенә ризалашкан. Бер төмән карлукъ чирүе Биләрнең борын төбенә килеп житкән чакта Бәрәж бәк нишләсен? Ул— Сәгыйть хан сөләләсендәге ин күренекле бәк, шулай икән, мәрхүм Шәмгун ханны алыштырырга хәләл хокуклы бит...

Хәмбәл Бәрәж бәкнең хан тәхетендә пәйда булуына әлләни аптырамады. Бәрәж ач калырга теләмәгән, үзенә тиешле калжаны эләктергән эт йә бүре кебек уяу булган икән, аны тагын нидә гаеплисен? Хан сарае тирәсендә тәхет өчен көрәш гомер-гомергә бүреләр өерендәге бәйгеызгышны хәтерләтә бит ул. Андый бәйгедә читне таларга дип теш ыржайтып йөргән, һәрчак уяу, өстәвенә әле үтә кансыз булган көрәшчеләр генә жиңеп чыга ала.

Хәмбәл барыннан да бигрәк Әрбәт агасына карата жен ачулы иде. Ничек шулай бик жинел генә итеп тәхетне һәм Биләрне ташлап китә алган соң ул? Нигә шәһәрне бикләмәгән дә, ник яуга кермәгән? Ахыр чиктә, тәхет өчен яуда ул нигә диеп башын салмаган? Әллә, әллә... карт-карт агайларнын «адәм баласы күбрәк белгән саен тиленәнә», дигән сүзләрендә хаклык бармы? Әрбәт тә бит Хәрәзем, Үргәнечләргә барып укып йөрде. Әллә ничә әжнәби[1] телләрен белә, Коръәнне дә су урынына эчә. Ләкин аннан кемгә, ни файда соң? Жаһил[2] калып көн күр, әмма дошман сиңа каршы корал күтәрә икән, аның кулын сугып сындырырлык кына куәт-вәкарьлеккә ия бул инде син. Бүрегә каршы бүре булмасаң— яшәвен дә артык. Ә Әрбәт, валлаһи, мүкләк, жебегән ул!..

Хәмбәл юл буе Әрбәтне шулай сүгеп кайтты, һәммәсенә аны гаепләде. Юанырлык, дәртләнерлек кәефе юк иде. Ул да түгел, Кернәк каласына житкәндә Тәмте вилаятенең бәге Инсан, дүрт меңгә якын жайдагын үзе белән алып, Таш-билбау тарафына аерылып китте. Инде Биләргә кайтып житәргә кул сузымы гына ара калгач, Актай елгасын кичеп чыккан чакта, пайтәхеттәге һөнәрчеләр идарәсе башлыгы Әбүбәкер Әхмәт углы белән Саксин каласының тарханы Әтәк чирлегә сабыштылар. Алар өчен яр буенда жинел тирмә кордырырга һәм аларны яраннары белән бергә шунда калдырырга туры килде.

Ә жиңүче гаскәр Биләр каласына якынаеп килгәндә Бәрәж инде, шәхси алаен гына үзе белән алып, Хәмбәлне дивар тышына ук чыгып каршылады. «Дошманнан саклану өчен иң отышлы ысул—үзен һөҗүм итү», дигән мәңгелек канун Бәрәж тарафыннан әнә шулай, бик оста рәвештә, тормышка ашырылды. Яна хан тарафыннан әрсезлек кенә түгел, гажәеп тәвәккәллек тә иде бу адым. Айкапуга илтә торган олы юл өстендә кулына Коръән күтәргән Бәрәжне, кайсы затлы чапан, кайсы зиннәтле тун тотып тезелгән берничә бәкне, мәчет имамнарын, тарханнарны һәм шанлы сәүдәгәрләрне күргәч, Хәмбәлнең болай да соскыга охшаш дәү ияге йон бияләй сыман салынып ук төште.

Хәмбәл, иң әүвәл, Бәрәжнең аны гап-гади киемнәр белән каршы алуына шаккатты. Хан тажы да, тәвис каурыйлары һәм якут ташлар белән бизәлгән затлы бүреге дә юк иде аның. Яна хан үз өстенә көмеш жепләр белән генә чигелгән алсу чапан кигән. Башында ак чалма. Аякларында болгари кара итекләр. Бил каешында гадәти бер хәнжәр.

Хәмбәл гажәпләнүдән ханның тирә-ягын, кала диварларын айкап чыкты. Бәрәжнең шәхси сакчылары арасында оста мәргәннәр шактый күп күренә, дивар өсте дә томавыллар ешлыгыннан сыгылып тора. Ләкин ни гажәп—алар арасында жәя өстенә ук салган, яуга әзер торган бер ират юк.

Хәмбәл әле һаман ат өстендә килә иде. Күз кырые белән генә үзенең гаскәренә караш ташлап алды. Алар сафында да һичнинди каударлану, хәвеф сизелми. Сәрдәр тарафыннан әмер-кисәтү булмаганга күрә,

---

[1] Әжнәби—чит ил.
[2] Жаһил—надан.

коралларының кайда икәнлеген дә онытып, кияү егетләре сыман пошынмыйча гына якынаялар.

Ике арада нибары утыз-кырык адым гына калгач, Хәмбәл чаптарын туктатты. Ул да, Бәрәҗ дә сөзешкә чыккан тәкәләр шикелле бер-берсенең күзенә текәлделәр. Хәмбәл зиһене аша йөз төрле уй яшен тизлеге белән чагылып узды. Аны биредә нинди язмыш көтә? Әмир Колыннан калган Кашанны Бәрәҗ аңа бирерме, әллә... әллә ул аны зинданга, аның да әле иң көттәсенә—барслар ябылган базына ыргытырмы? Зиндангадыр, дисәң, Бәрәҗ аны менә хәзер дә мәргәннәреннән, кавын шикелле итеп, теткәләтә ала. Ә нигә, нигә аңа каршы ук күтәрүче юк? Бәрәҗ нәрсәгә өметләнә дә, ул ни әзерләгән?

Ахырда Хәмбәл ияреннән капылт сикереп төште һәм йөзенә берниндн хәвефләнү төсмере чыгармыйча Бәрәҗгә каршы атлады. Ни кызганыч, ул үзенең шәхси ихтыяры белән тәбегә кереп баручы күсе хәленә калуын гына аңлый алмый иде. Ә үзе һаман адым саен: «Ас, кис, мәгәр мин синең алдыңда тезләнәчәк түгелмен, угры Бәрәҗ!»—дип, эченнән генә тәкърарлавын белде.

Яңа хан аның тезләнүен һич тә көтми, гомумән, ул бүген нинди дә үпкә-бозылышу чыгудан яман шүрли иде.

—Әссәләмүгаләйкүм, Болгар мәмләкәтенә олуг галәбә вә имин хәят китергән шанлы батыр!—дип, Бәрәҗнең олыгаеп, данлыклап сәламләгән беренче сүзләреннән үк Хәмбәл иңбашларын, сынын турайтты. Бәрәҗ дә, урыныннан кузгалып, өч-дүрт адым алга чыгып басты һәм элеккечә, сәрдәрнең салпы ягына салам кыстыруын дәвам итте.

—Синең шәхси орышта качкын кыпчак пәһлеваны Манукны утын әрдәнәсе урынына чәрдәкләп ташлавың вә, янә дә килеп, баскын каныклыларны Җаек дәрьясына тиклем куа-куа алагаем кырып бетерүең хакында ишетеп без биниһая сөендек. Ошбу шанлы галәбә вә тырышлыгың өчен болгар халкы сине мәңге онытмас. Сиңа ошбу халаекны...—Бәрәҗ тирякта тезелеп торучыларга таба кул изәде.—... киләчәктә дә үзеннән яңа галәбәләрен илә сөендерергә насыйп әйләсә иде.

—Амин! Ярабби, Ходаем!—дип алдан өйрәтеп куйгандай, һәммәсе дә хан сүзен куәтләде.

Бәрәҗ янә бер-ике адым алга атлады һәм Хәмбәлнең күзенә төтен җибәрүен дәвам итте.

—Син яуларда үзеңне маһир вә булдыклы сәрдәр итеп таныттың. Артабан да шул йөкне үз өстеңә алсаң, болгар халкы, мотлакан, сиңа рәхмәтләр генә укыр иде.

«Монысы нинди сүз тагын?»—дигәндәй, Хәмбәл керфекләрен кыса төшеп текәлде. Ә Бәрәҗ берникадәр вакыт буе юри көттереп торганнан соң гына, аның каравы һәркемгә дә ишетелерлек итеп көр, гаярь тавыш белән игълан итте.

—Мин сиңа биш мең газилык курсыбай тупларга вә аның баш сәрдәре булырга тәкъдим кылам, шанлы батыр. Вә, янә дә килеп, мин сиңа олугбәк дәрәҗәсен бирәм. Син, артабан, минем фәрманымнан гайре дә, теләсә кайсы вилаять бәгенә әмер кыла аласың.

Янда гына кемнәрдер теше сызлаган шикелле яман ыңгырашты, кемнәрдер ашыга-кабалана, «Афәрин! Машалла!»—дип, соклангандай, хуплагандай итте. Хәмбәл зиһенендә, әлбәттә, үз кайгысы иде.

«Иелгән башны кылыч кисми»,—дигән әйтемнәрен аңлый алмый идем. Ә, бәлки, гел хактыр ул? Менә бит, башны иеп килгәч, Бәрәҗ мине мәмләкәтнең баш сәрдәре итеп тәгаенләде. Җитмәсә, әле олугбәк тә итте. Ә әгәр дә Бәрәҗ урынына Әрбәт агам хан булып утырса? Миңа андый дәрәҗә эләгер идемени? Хакыйкатьнең күзенә карасаң, Әрбәтнең мине тәхет дәвамчысы итеп калдыруы гайре икеле хәл. Чөнки аның үз угыллары бар. Күпме генә хыяллансам да, мин хан тәхетенә менә алмый идем бит. Шул ук жебегән Әрбәт агаемны да, аның угылларын да урап үтә алмый идем. Бәс, шулай икән, Бәрәҗ эргәсенә башны иеп килеп,

мин отканмын гына була түгелме соң? Бәлки, сәрдәр дәрәҗәсеннән хан тәхетенә юл күпкә якынрактыр?..»

Хәлбәл, башын иеп, алга атлады. Бәрәҗ аны кочагына алды. Хәмбәл, иелеп, аның кулын үпте. Нәкъ шул минутта, мәңге ычкына алмаслык булып, бер-берсенең тозагына эләгүләрен алар аңламады. Әлегә икесе дә үз дәрәҗәләреннән бик канәгать, алар өчен дөнья гел түгәрәк иде.

## 5

Ул кичтә Хәмбәл үзенең кала бәкләре, аерым мөнбашлар белән бергә хан сараена кайтып, буза чөмерә башлауларын гына хәтерләп калды, аннан соң онытылды. Икенче танда кургаш шикелле авырайган керфекләрен ачканда ул үзенең анадан тума чишенгән ике кыз уртасында ятуын шәйләп өлгерде. Бу хәлгә ул әүвәл куркып калды. Как шикелле кибеп, бер-берсенә ябышкан иреннәре аша көч-хәл белән генә сорау бирде:

—Мин кайда? Монда кем китерде?

Җарияләрнең күзләрен ут шикелле зәһәр сирпегәне, сагыз сыман кара чәчлесе Хәмбәлнең йонлач, киң күкрәге өстендә тал бөресе сыман йомшак, нәфис бармакларын уйнаклата-уйнаклата гына җавап кайтарды.

—Кәлисә[1] урамындагы тимерче Әр-Әслап йортында син, батыр. Мәгәр сине ошбу эргәгә берәү дә аркан илә сөйрәп китермәде. Киресенчә, шәрә җарияләрнең биюе илә хозурланмак булып, монда үзең килдең.

Хәмбәл әле кашларын җыерып, әле чигәләрен уып кичәге көнне хәтерләргә тырышып карады. Юк, ул идән ярыгына төшеп югалган көмеш тәңкә сыман инде юкка чыккан, Хәмбәл аны исенә төшерерлек хәлдә түгел иде. Мона ачуы гына килде. «Кәлисә урамы, кәлисә»,—дип аптырап уйланды ул.—«Аһ, шайтан алгыры! Биләрлеләр аны гәп корганда Саклан урамы, дип йөртәләр бит. Нәсаралар хозурына килеп кунак булган бәгъзе диндарларга да ошбу кяферләр сихерле шәраб эчерә, ә аннары, инде куна калгач, аның муенына тәре тага, имеш. Ошбу мәсләктән килеп, урамнарының исеменә тиклем—Саклан... Саклан!..»

Хәмбәл корт чаккан шикелле кабаланып муенын капшап карады. Аллага шөкер, чылбырга охшаш әйбер очрамады. Аның каравы, ул бармаклар хуҗасының тәнендә һичниндн дә кием булмавын тойды. Хәмбәл уңайсызланып китте. Янындагы кызларга күз атты. Берсе гәрәбәдәй сары чәчле, зәңгәр күзле, мул имчәкле иде. Икенчесе тазалык, зур имчәкләр белән шапырырдай түгел, әмма тәне кайнар. «Һе, берсе маржа, ә карасы элгәре үзебезнең өммәттән булган, мәгәр соңрак нәсаралык кылган керәшен җариясе бугай боларның». Кара чәчле, кайнар тәнлесе әле һаман Хәмбәлнең йонлач күкрәген бөгәрләнеп черем иткән песи баласы шикелле йомшак, нәфис куллары белән кытыклап ята иде. Сәрдәр аның нәни кыңгырау зеңләгән сыман назлы тавышын янә бер мәртәбә хәтерендә яңартты. Аннары онытылды... Тимер эш остасы Ярославның өен калдырып чыккан чакта ул бик уңайсызлана, әмма андагы тойгылар, кызганычка каршы, салкын суга кереп тәүге чирканчык алган йөзүче халәтен генә хәтерләтә иде...

Бөек Болгар иленә килгән мәхшәр санаулы көннәр эчендә канат җәйде. Бәрәҗ хан бик җинел генә, Баш сәрдәр олугбәк дәрәҗәләрен биреп, Хәмбәлне кулга иләштерү турында юкка гына хыялланган иде. Батырга Шәмгун хан вафатыннан соң Биләрдә булып узган хәлләрнең асылын аңлатучылар күп табылды. Үз ялгышын тулысынча аңлап өлгергән Хәмбәл учактагы кисәү шикелле кара көеп чыкты. Аның күңеле хәзер инде, умарта оясына ябылган корт күченә охшап, бетмәс үч һәм үкенечтән генә тора иде.

---

[1]Кәлисә—чиркәү.

Бәрәҗ хан белән Хәмбәл арасындагы астыртын тартыш әлләни озак дәвам итмәде. Гвардия-курсыбай сафына үзе белән Сувардан ук туплап килгән азатларны биреп, Бәрәҗ Хәмбәлне курчак сәрдәр хәленә калдырмакчы иде. Әмма Хәмбәл шундук азау тешен күрсәтте. Ул Җаек буеннан җиңү яулап кайткан түмән калдыгын таратмыйча тотты һәм нигездә кашанлылардан торган ике мең яугирне курсыбайга гази итеп куйды. Инде Бәрәҗ хан аны сәрдәрлектән читләштерү белән яный башлагач, Хәмбәл суварлыларның да ике мең азатын курсыбайга алырга риза булды. Ләкин өч-дүрт көн үтүгә үк бер меңбашның гәүдәсен кала читендәге ерымнан табып алдылар. Икенче курсыбайны ташлап үзе качты. Ә суварлылар өлешендәге йөзбашларны алыштыру гына Хәмбәл өчен берни тормый иде. Тартышта шактый нык оттыра башлавын күреп, Бәрәҗ үзе тәгаенләгән биш мең газинең соңгы бер меңенә янә суварлыларны ялламакчы булды. Тик ни гаҗәп: хан кадәр хан тәхетендә утырган Бәрәҗ өчен, аяз көнне уйнаган яшен сыман булып, Биләргә бер мең кешелек кыпчак чирүе килеп керде. Аның каршына Хәмбәл кыпчакларның данлыклы хакиме Шәрәф хан улы Сарычинны да китереп бастыргач, Бәрәҗнең күзләре маңгаена менде. Яңа меңне һәм аның башлыгын сәрдәр чакырган икән, бу, әлбәттә инде, Хәмбәл белән Сарычин бер ыстанда, дигән сүз иде. Бәрәҗгә тешләрен кысып булса да ризалык бирергә туры килде.

Ә Күкрәге тулы үч йөртүче Хәмбәл нәкъ шуны гына көтеп торган кеше кебек эш итә башлады. Ул инде баш һөнәрче Әбүбәкер белән Саксин тарханы Әтәкнең Актай елгасы буенда ни сәбәпле авыруга сабышуын аңлап өлгергән иде. Сарычин килүгә бер ай да вакыт үтмәгәндер, Хәмбәл әмере буенча кыпчаклар Әбүбәкер йортындагы барча байлыкны талап алды, остаһың чуен, бакыр җиһазлар коюга көйләнгән мич һәм казаннарын җимереп бетерде. Ахырда Әбүбәкер оста Болгар каласына, Ибраһим бәк кул астына качып китәргә мәҗбүр булды.

Аннары Хәмбәл күбесенчә суварлылардан торган ике мең газине Саксин каласына юллады. Саксин нигездә кыпчаклардан торган шәһәр булып исәпләнә һәм әгәр газиләргә каланы җимерү-талау фәрманы җиткерелгән булса, бу эшкә Сарычинның дәррәү каршы кубасын Хәмбәл, һичшиксез, бик чамалый иде. Шуңа күрә сәрдәр газиләргә фәкать тархан йортын гына таларга рөхсәт бирде. Әтәккә шул да җитте. Куркак тархан язмышын кат-кат сынап тормас өчен хатыны ягыннан үзенә бабай тиеш булган башкорт Инсан бәк янына чыгып качты. Хәмбәл һичнинди фәрман-рөхсәт көтеп тормады, Сарычинны Саксинга тархан итеп озатты. Соңыннан Бәрәҗнең әлеге карарны фәрман итеп расламыйча чарасы калмады.

Хәмбәлне хәзер тотып тыешлы түгел, ул инде утар җимереп чыккан ярсу үгез рәвешенә кергән иде. Ул Саксинны ташлап качкан Әтәктән генә түгел, заманында үзенә хыянәт иткән Инсан бәктән дә яман үч алырга ният корды. Ул Сарычиннан соң меңбаш булып калган аның энекәше Әтрәкне үзе белән алды. Аларга кашанлылардан һәм суварлылардан берешәр мең гази өстәде. Шулар белән Хәмбәл Чирмешән, Дим елгаларын бик тиз кичеп үтсә дә, башкорт бәге шымчылары тарафыннан үз вакытында кисәтелгән иде, ахры. Нокыш елгасы буенда Инсан курсыбайны биш мең җайдаклы чирү туплап каршы алды. Орыш гадел башланып киткән булса, кем җиңеп чыгар иде икән?—анысын Ходай Тәгалә үзе генә белә. Ләкин Хәмбәл Инсан бәкнең чирүне икегә бүлеп, берсен кияве Әтәккә тапшыруын белгәч, дошман ыстанына шундук үгетчеләр куды.

—Әтәк тархан буйсыну күрсәтеп вә сәҗдә кылып башсәрдәрнең хозурына килсә, олугбәгемез аны Саксин каласына кайтарырга разый.

Шул коры вәгъдә дә җитә калды: үзенә тапшырылган алайлардагы меңбашларны әсирлеккә алып һәм якыннарын ияртеп Әтәк тархан үзенең бабасын ташлап китте. Җитәкчесез калган җайдаклар оядан егылып төшкән кош балалары сыман ни кылырга белмәде. Ә Хәмбәл ул арада Инсан

бәк җитәкләгән чирү өстенә ташланды. Яртылаш кына калган ул чирүне, әлбәттә инде, Хәмбәл котырган үгез мөгезенә эләккән салам өеме сыман итеп бик тиз туздырып атты. Исән калган берничә йөз җайдагы белән Инсан далага качып котылды. Хәмбәл кияүгә чыгарга өлгермәгән гөнаһсыз кыз белән тәүге төн уздырган карт бер ир-ат сыман тантана итәргә ашыкмады, Әтәкне кулга алырга боерды. Хыянәтче тархан үз хәлен тиз аңлады. Ул да далага качты. Сонрак инде бөтенләй кыпчаклар ягына китеп барды. Аумакай һәм җебегән әлеге тархан турында халык телендә «Әтәк-сәтәк» дигән гыйбарә генә яшәп калды...

Хәмбәл котырына һәм тантана итә, әмма Бәрәҗ хан да йоклап ятмый иде. Төпченә һәм бер-бер артлы шаһитларны тотып газаплый торгач, ул Бөгелмә-тау ягыннан Биләргә, аннары Ибраһим бәк һәм Хәмбәл тарафына чапкыннар юллаучы кешенең Байчура булуын ачыклады. Билгеле ки, ханның хыянәт юлына баскан бәкне гафу итәргә исәбе юк иде. Яңа сылтау белән Бәрәҗ Кернәк каласы бәген сарайга чакыртты. Әмма Байчура да төшеп калганнар кавеменнән түгел иде. Бәрәҗ хәйләсенең асылын ул бик тиз аңлап алды, пайтәхет тарафына аяк та атламады.

Ул арада Биләргә Хәмбәл кайтып житте. Саклан урамында янә буза эчеш, фәхеш башланды. Бик озак баш ваткач, Бәрәҗ хатын-кыз дигәндә башын җуя торган сәрдәр куллары белән утлы күмер сосарга мәкер корды. Үз янына чакырып, иң элек, ул Байчураның мең жарияга да алыштыргысыз, оҗмах фәрештәләредәй чибәр Сәмәрә атлы кызы булуы турында авыз суларын корыта-корыта, Хәмбәлнең эченә ут төшерде. Ә аннары инде чабышкы ат халәтенә кергән сәрдәрне яңа хатын алып кайтырга үгетләде. Ләкин Хәмбәлне Кернәккә озаткан чакта үзенә генә отышлы шартлар куярга да онытмады.

—Мәмләкәттә башсәрдәр берәү генә. Аның туен пайтәхеттә бәйрәм кылу фарыз. Ханиянне үпкәләтмим дисәң, Байчураны—пайтәхеткә чакыр. Туегыз ханиянең хозурында үтсен...

Бер-ике атнадан соң ук Хәмбәл Сәмәрәне Биләргә алып кайтты. Эре сөякле, озын буйлы булса да, ул төскә-биткә, чыннан да, чибәр иде. Мөхтәрәм парның туен Ага-Базарда зур ярминкә узачак көнгә көйләделәр. Хан ярминкәдән кергән барча салым-тамгаларны яшьләргә туй бүләге итеп кайтарырга вәгъдә бирде. Сүз дә юк, Хәмбәл аша туйга, әлбәттә инде, Байчура бәк үзе дә чакырылды. Ханның берьюлы ике куян атарга җыенуын һичкем төшенмәде.

Сәрдәрне бик җайлы сындырып була торган бер сәбәп шул: Хәмбәл өчен кандошманга әверелгән Инсан белән Байчура үзара кода бәкләр иде. Байчураның юлга чыгуы хакында хәбәр алынуга ук Бәрәҗ хан менә шул сәбәпне эшкә җикте.

—Байчураның жансакчылары Инсан иңдергән катилләрдән тора,—дип тәүге сүзләре белән үк Хәмбәлнең күңеленә шом салды ул.—Инсан синнән үч алырга ант эчкән, аксакаллар аны хуплаган. Заманында болгарлар кыпчаклы Әюп ханнан үч алган сымак, Инсан бәк юллаган катилләр дә туй барышында синең башыңа җитәргә ният итә икән.

Моннан утыз биш-кырык еллар чамасы элек болгарларнын Әюп ханны туйга чакырып һәм шунда агу эчертеп үтерүләре хакында балачактан бирле ишетеп белә иде ул. Бәрәҗ хан кисәтүеннән соң шул мәкерле хәлне хәтерендә яңартып, Хәмбәл акылын җуйды.

—Кирәк икән, сөлтек Инсанның жасусларын гына түгел, Байчураның үз башын да өзләрәм мин!—дип котырып кычкырды ул.—Монафыйклыкка түзеп торасым юк!

Хәмбәл сүз белән генә янап калмады. Шул сәгатьтә үк кала капкаларын саклаучы соткавылларны курсыбай газиләре алыштырды. Сәрдәрнең аларга җиткергән соңгы әмере дә кансыз яңгырады:

—Байчура жансакчыларына рәхим-шәфкать күрсәткән сөлтекләрне үзем тотып асам!

Беркадәр вакыттан соң сарайга коточкыч хәбәр кайтып ирешә:

—Газиләр Кернәк гөруһын[1] тулгамага алгач, Байчура үзенең жансакчыларын яклап кылычына ябышкан. Курсыбайныкылар бәкне Айкапу эргәсендә кылыч илә чабып үтергәннәр...

Шул кичтә үк каладан Байчура бәкнең кызы Сәмәрә чыгып качты. Аңа кемнең ярдәм итүе бик тиз ачыкланды. Курсыбай сафындагы кыпчаклар меңбашы Әтрәк тә шул ук кичтә юкка чыккан иде. Хәмбәл шушы бер көн эчендә булып узган коточкыч хәлләрдән соң, кайнар таш йоткан кеше сыман, әүвәл телсез калды, өенә кереп бикләнде, жиһанга чыгып күренмәс булды. Әмма бәгырен талаган үкенү ялкынына әлләни күп түзә алмады бугай, Саклан урамындагы тимерче Ярослав йортына күчеп, ул янә буза төтененә күмелде, фәхешлеккә чумды...

Иренең кансызлыгы белән бозыклыгы болай да гел берьялгызы диярлек көн күргән Осланбикәнең дә үзәгенә үтте. Ул беркемнең дә күзенә күренмичә генә каладан чыгып качты, Идел аръягындагы Мәркәвеш авылына килеп, ерак кардәшләренә сыенды. Ерак-еракта, рус жирендә калган апасы Байгөлне һәм абыйларын сагынудан ул һәркөн саен якындагы биек тау башына менеп, туктала алмыйча, савылып-савылып елый торган булды. Аның саргаеп кипкән жансыз гәүдәсен дә биек тау башыннан табып алдылар, гөнаһсыз һәм мескен хатынның рухын рәнжетмик дип, шунда ук жирләделәр. Күрше-тирә авыл хатыннары, Осланбикәне әүлиягә санап, озак еллар буе ялгыз кабер янына килеп йөрде. Ә соңыннан инде гөнаһсыз хатын күмелгән бу биек тау «Югары Ослан» булып халык теленә күчте...

Әлбәттә, моңа кадәр әле дистәләгән еллар үтәсе бар иде. Ә әлегә... әлегә мәкерле Бәрәж хан ишегалды тулы тавык өере арасында кукраеп йөрүче борнай әтәч кебек берьялгызы гына тантана итте. Ләкин анысы да озын-озак көннәргә сузылып китә алмады. Идел буендагы чапкыннар ханга уклау йоткандай катып калырлык хәбәр китерделәр:

—Һөнәрчеләр илә игенчеләр Сәмәрә бикәне, Кернәккә кайтуга ук, әтисе урынына кала бәге итеп сайлап куйган!

Бәрәж, авыр күсәк белән сугып миңгерәтелгән үгез сыман, берничә минут буе хәрәкәтсез торды. Аннары тәрәзә пыялаларын зеңгелдәтерлек чәрелдек тавыш белән кычкырып жибәрде.

—Ничек инде «әтисе урынына?» Үгез күрмичә гаурәте[2] корыган шул сиерны кала бәге итеп куйганнармы? Минем(!) мәмләкәттә хатынкыз бәк! Адәм тәганәсе! Мондый хәбәр чит-ят падишаһларга барып элгәште исә, оят, хурлык! Асам, кисәм, ул Кернәкне вәйран итеп бетерәм!

Бәрәжнең Хәмбәл колагына барып ирештерерлек һәм аның минминлеген уятырлык кадау сүзләре дә әзер иде инде.

—Елдам төстә башсәрдәрне айнытып китерегез. Үзләре итәк ачып торган кяфер жарияләренә жайдак булып атлану асла читен түгел. Утарына килеп кергән әнә теге Кернәк сиерына жайдак була белсен иде ул. Атан[3] ләкабе илә шан аласы килмәсә, шул сиер Сәмәрәне бер иярләп кайтсын...

Бәрәжнең исемен ишетүдән үк саруы кайнаса да, Хәмбәл башын түбән иеп буйсынды. Ул үзе белән ике мең газилек гаскәр алды һәм Кернәккә төбәп юлга чыкты. Иделне кичтеләр, Зөя яры буйлап байтак төштеләр. Шул чагында багучылар хәбәр житкерде:

—Сәмәрә бикә Бәрәж ханның һәммә фәрманын да шундук белеп тора. Курсыбайның каладагылардан үч алуыннан шүрләп, ул Кернәкне үзе ташлап киткән. Хәзер Әтилне кичкән дә, Жигүле-Ат тауларына менеп яшеренгән, ди. Кыпчак бәге Әтрәк тә аның эргәсендә. Ул Сәмәрәнең кулын бик сораган, мәгәр бикә риза булмаган, ди. Бәрәж хан тарафыннан мәсхәрә вә золым күргән барча инсаннарны үз әләме астына

[1]Гөруһ—төркем.
[2]Гаурәт—оят жир.
[3]Атан—печелгән дөя.

чакыра икән. Әтрәк әләме эргәсенә инде өч мең ир тупланган. Ихтилал[1] күтәрергә җыенган шул чирүнең бер өлеше Җигуле-Ат тавыннан түбәндәрәк, Әтил дугасында, бүрәнә кирмән корган. Ул кирмәнне Сәмәрә бикә исеме илә атаганнар да инде.

Әлеге яңалыкларны ишетүгә, Хәмбәл башта, балтасын суга төшергән бичара төсле, пошаманга калды. Әтрәк туплаган чирүне куып тарату аның өчен берни түгел, ләкин кара халыкка каршы кылыч күтәрүнең үзенә дан һәм шөһрәт китермәсен ул нык чамалый иде. Аннары ул Әтрәк Саксин каласына Хәмбәл үзе тархан итеп куйган Сарычинның да энесе бит әле. Хәмбәл Әтрәккә каршы яуга чыкса, аны яклап кыпчакларның күтәрелүе дә мөмкин. Буралкыдай кыргый Сәмәрә бикәдән мүкләк Бәрәҗ үч алырга җыена дип кенә бер үк диндә булган кыпчаклар белән ике араны бозу муафыйк эшмени?..

Хәмбәл озак кына вакыт утырып уйланды да, ахырда биш йөз газилек алайга Кернәкне талап кайтырга әмер бирде. Калган чирү белән үзе кирегә борылды һәм Кашанга юл тотты. Кашан—туган кала, ләкин менә ничә айлар буе анда Хәмбәл һич кенә дә гафу итә алмаячак чонтык Әрбәт туенып ята иде. Ул—атисенең бертуган энекәше, үтә якын кеше. Әмма нәкъ менә аның җебегәнлеге, куркаклыгы аркасында гына Хәмбәл һичшиксез үзенә тиеш булган тәхеттән коры калды. Аның кебек сатлык аганы Хәмбәлнең мәңге-мәңге гафу итәсе юк!..

Хәмбәл курсыбайны әнә шундый тоташ нәфрәт хисләре кичереп куалады. Ләкин ул сонарды. Хәмбәл имән капкаларны җимереп калага кергән чакта Әрбәт Кашаннан киткән иде инде. Йөзеннән кан, күзеннән нур качкан сәрдәр дистәләгән кешене җәзалатты—Әрбәт качкан юлны белүче табылмады.

## Алтынчы бәйләм

### 1

Андрейның күңелендәге уйлар буйга узган хатын имчәкләре шикелле тулып ташкан иде. Алар аны юл буе эзәрлекләде, кенәз Суздальдагы сарайга кайткач та басылмады. Әледән-әле янына Прокопий, Козьма ише яраннары кереп йөрсә дә, Андрей берни ишетми-күрми, әйтерсең лә, ул бу җиһаннан пыяла дивар артына кереп яшеренгән иде. Тәүге көннәрдә ул әтисе тарафыннан, аны кире чакырып, чапкын артыннан чапкын килер, дип көтте. Юрий кенәз тәхет юуны дәвам итә иде, күрәсең, кала капкаларын усал шакучы кеше күренмәде. Ә бер таңда инде Андрей, һичкемне кисәтмичә, аргамагы өстенә сикереп менде һәм йөгәнен елга буена алып чыгучы капка ягына тартты. Токавыллар кенәзнең ялгыз һәм кисәтмичә-эндәшмичә йөри торган сәер гадәтенә күнегеп килә иде, капка эшермәләрен тавыш-тынсыз гына шудырдылар. Андрей Каменка ярына килеп туктады да, тораташтай калды.

Ул коенып, йөзәргә өйрәнеп үскән елга менә шушы инде. Кинлеге ике-өч дилбегә озынлыгы булыр, ә тирәнлеге, каһәр генә төшсен, тирәнлеге... бер тәртәдән артмый. Менә ничек инде зур-зур каекларны яки җилкәнле корабларны кертү мөмкин булсын?

Андрейның колагына шулчак ул Болгарга сәяхәт кылганда, Ага-Базар янында, урыс сәүдәгәре мыскыллап кычкырган сүзләр кабат кайтып яңгырагандай булды:

—«Суздаль бакалар йөзәрлек кенә сулы Каменка буенда утыра бит ул».

—Хак әйткәнсең, илдәш. Кораблар керердәй елга буена утырмаган

[1] Ихтилал—фетнә; азатлык, гаделлек өчен көрәш.

өчен генә дә Суздаль урыс иленең яңа башкаласы була алмый,—дип, үзе дә тоймастан, Андрей ерак-еракта калган сәүдәгәргә кычкырып җавап бирде.—Кулайрак шәһәр эзләмичә чарабыз юк. Башкаласын бер җирдә нигезләп, ярминкә-тантаналарны икенче төштә үткәреп, чит-ят кенәзләрне баетып булмас инде...

Шул көнне үк, ташчыларны һәм балта осталарын үзе белән алып, Андрей кенәз нәкъ илле ел элек бабасы—бөек Мономах нигезләгән Владимир каласына карап юлга чыкты. Аның нинди максат белән юнәлүен әле һаман һичкем аңламый, һөнәрчеләрне кузгатуына ишарәләп кенә «кенәз болгарлылар һөҗүменнән шүрли, шуңа күрә Владимирны ташкирмән хәленә китермәкче бугай», дип гомандыйлар иде. Ә Андрей инде бер-ике атнадан соң ук барча бояр-сәүдәгәрләргә һәр авылдан ат-олаулар, шулар белән бергә ташчыларны, тимерчеләрне, мич чыгару һәм балта осталарын туплап китерергә әмер җиткерде. Фәрманда кисәтелгәнчә, аны үтәмәгән түрәләргә үлем куркынычы яный иде. Шунлыктан җәй ахырында бөтен бер кенәзлек таяк тыгып болгатылган кырмыска оясына охшап калды. Владимир каласы әйләнәсендә таш диварлар белән бер үк вакытта төзелешкә куып китерелгән олаучылар, һөнәрчеләр кунып көн күрүче катлы-катлы чатырлар, җиргә казып ясалган өннәр пәйда булды. Йөзәр, меңәр булып тупланган төзүчеләргә дә, атларга да ризык җитми иде. Көзге яңгырлар кубуга карамастан, Андрей Клязьма елгасы буендагы кин бер иңкүлектә зур ярминкә үткәреләчәге хакында кисәтеп дистәләгән якка чапкыннар куды. Ярминкә ул өмет иткәнчә үк мул булмады, шулай да җиде-сигез рус кенәзлегеннән байтак кына шанлы сәүдәгәрләр ашлык, тимер кораллар, көнкүреш җиһазлары төялгән олаулары белән килеп җитте. Андрей өчен иң сөенечлесе шул: Ука тамагындагы Калачык кальгасыннан—болгарлар, Идел, Чипса елгаларының аръягыннан арлар, мукшылар да Владимир каласына килгән, димәк, яна ярминкә турындагы хәбәр башка халыкларга да таралачак иде.

Бер уйласаң, Владимир каласы әйләнәсендәге таш диварлар, яңа кирмән әкиятләрдә генә була торган тизлек белән күтәрелә, ләкин Андрей шәһәр кыяфәтеннән әле һаман канәгать түгел иде. «Бу кала киләчәктә галиҗәнап мәркәз булачак бит. Мәгәр ерактан ук үзенә тарта, сокландыра торган мәһабәтлек, могҗизадай күренеш җитми ана»,—дип, бер таңда кинәт яктырып уйланды ул. Төшендә Андрей үзенең янә Болгар каласына баруын күргән иде. Ә уянгач шәһри Болгарның Айкапуы күз алдына килде.

—Әйе, әйе, Владимирга да урыс холобын баш иеп керергә мәҗбүр итә, ә күрше кенәзләрнең өнен ала торган зур капкалар кирәк!—дип, Андрей инде кычкырып карар кылды. Шул көнне үк кенәз диварларның ике урынына берсе—алтын, икенчесе көмеш белән йөгертелгән һәм һәркайсы өстенә тәре, чаң куелган гаҗәеп зур капкалар уярга әмер бирде.

Ә Кыш җиткәч, Андрей үзенең гаиләсен дә Владимирга күчереп куйды. Шул көннәрдә үк байтак кенәзләрне шаккатырып, урыс җиренә гайре кыргый хәбәр таралды.

—Суздаль кенәзлегенең үзәге Владимир каласына күчкән. Моннан ары Суздальда Андрей кенәз тәгаенләгән наиб-воевода гына утырачак икән.

Әйе, гәрчә җиһанда әле каласыз-биләмәсез калган өч энекәше, ике улы булса да, Андрей Суздальны һичкемгә бирмәде. Ул Андрей кыздырган тәүге коймак иде һәм, гаҗәпләнәсе юк, төерле һәм ачы да булып чыкты.

—Изяславка сигез яшь тулды. Андый чакта синең Ростислав атлы абыең Бөек Новгород каласына хуҗа булып торган. Аның турында Хозер-Ильяс килеп кайгыртмаган. Аны синең атаң шунда илтеп утырткан. Кыргый кыпчак хатыныннан туган Ростиславка Новгород каласына хуҗа булырга яраган. Ә гыйлемле болгар хатыныннан яралган Изяславка хәерче

Суздаль биләмәсе дә харам байлыкмыни?—дип, иң беренче булып, ярсу әтәч сыман, Байгөл очып кунды.

—Мин урыс калаларын берләштереп, Болгар шикелле үк зур бер дәүләт төземәкче булам. Башка кенәзләр кебек инде мин дә калаларны үз балаларыма яки туганнарыма өләшә башласам, алар янә бер-берсенә каршы кылыч күтәрәчәк, Ходай каргаган бу урыс җирендә суеш-кырылыш мәңге бетмәячәк. Ахыр чиктә, мин Изяславның үз туганнары кулыннан һәлак булуын теләмим, аңла шуны, Байгөл?!

Андрей әнә шул рәвешчә бик тынычлап кына аңлатмакчы булды, хәтта, ялынып та карады. Кызганыч ки, Байгөл тыңламады. Аның үз кырыгы-кырык: Изяслав өчен ул Суздальны дәгъва итүен белде, әле күзгә яңгыр сыман бертуктамый елап, әле кызыл чүпрәк күргән күркә шикелле ярсып куркытмакчы булды. Андрей бирешмәгәч, элекке галәтенчә, Байгөл балалар бүлмәсенә бикләнеп көн күрә башлады. Аны акылга утыртмакчы булып Андрей ике улын да Байгөлнең кочагыннан суырып алды, аларны монастырьдагы руханилар тәрбиясенә бирде. Ирнең дә, хатынның да чигенергә исәбе күренмәде, ике арадагы упкын киңәя генә барды. Ләкин Андрей инде бердәм дәүләт төзү уе белән учак сыман дөрләп кабынган һәм хәзер ана шуннан гайре барлык гамәлләр дә вак мәсьәлә, көчне юкка сарыф итү генә булып тоела иде. «Күңелләге хисләр каен тузы сыман янып бетте инде, ә аннан калган көлне актарудан бер мәгънә юк»,—дип нәтиҗә ясады Андрей. Гәүдәсенә бала-чага бишмәте ярамаган дәү пәһлеван кебек, ул инде башка төрле тормыш белән барыбер дә яши алмас иде. Байгөл белән ара бозылуга да ул кул гына селтәде, күңеле дирбияләрен салган ат шикелле иркенәеп калды...

Владимир каласына күченгәннән бирле Андрейны Вышегород рухание кисәткән сүзләр эзәрлекләп йөрде:

—«Халыкларны көчле дин берләштерә. Денсез дәүләтнең юлы җимерелүгә, җимерелүгә таба бара. Шуңа күрә һәр бөек эшеңне Ходай Тәгалә исеме белән башла...»

Андрей Вышегородтан алып кайткан Изге Мария иконасын Владимир чиркәвенә илтеп куйды. Үткәндә-сүткәндә дә чиркәү эченә кереп, гел-гел шуңа гына табына торган булды. Бер-ике дини бәйрәмне зурлап үткәреп карады. Әмма бик тиз тоеп алды: урыс кенәзлекләрен мондый юллар белән генә һич тә шаккатырып булмаячак иде. Андрей бик озак баш ватты, мәгәр чарасын да тапты. Тик бу юлы да ул үз максатын, йомырка салмас борын кыткылый башлаган юнсез тавык сыман, алдан белдермәде. Яз башында аның фәрманын алып тирә-якка яңа чапкыннар таралды.

—Елгалардан бозлар китүгә үк һәрбер авыл Клязьма буендагы Акчокырдан Владимир каласы янына иң каты һәм иң затлы ташларны икешәр карыш озынлыгында кисеп китерергә тиеш. Кем дигәндә утыз олау китермәгән авылны «кызыл әтәч» куну куркынычы көтә.

Мондый янау урыс авылы өчен шыр-хәерче өстенә килгән бозлы яңгыр кебек әлләни зур хәвеф булмаса да, бермәлне олаулар Владимир каласына таба тоташ ташкын сыман агыла башлады. Андрей аларның һәммәсен каладан янә унбиш-егерме чакрым ераккарак, Клязьма елгасы буйлап сузылган кына тактасыдай гаҗәеп тигез үзәнлеккә куды. Ә анда инде күптән нигез, идән асты базлары өчен чокырлар әзерләнгән һәм йөзәрләгән ташчы көтеп тора иде. Вышегород рухание бүләк иткән затлы иконаны баш өстенә күтәреп, Андрей шул чагында халык уртасына чыгып басты.

—Халыкларны көчле дин берләштерә,—дип, үз сүзләрен әйткән шикелле, горур башлады ул.—Урыс милләте өчен изге кояш—Иисус Христос булыр. Шул бердәнбер кояш астына туплана да белик, аның тугры коллары да булыйк. Соңгы елларда без Иисусыбызны оныттык, диннең кадере китте. Шуңа күрә урыс җирендә кырылыш, яу тукталмый. Алга таба һәрбер адымыбызны Иисус-кояш исеме белән башлаганда

гына без ул очсыз-кырыйсыз кан коюларны, мөгаен, туктатырбыз. Менә ни максаттан мин шушы киң далада, зур кораблар керердәй тирән сулы Клязьма янәшәсендә, фәкать чиркәүләрдән генә торачак зур бер кальга төзетмәкче булдым. Мин әлеге кальганың исемен дә «Ходай Тәгаләне сөючеләр», дип куям. Бо-го-лю-бов!

Аннары Андрей кенәз һәрбер олаучыны затлы шәраб белән сыйлады. Икенче таңда ук ташчылар, төзүчеләр эшкә керešте. Бер ай дигәндә далада озын, калын дивар һәм шуның эчендә дистәләгән бина үсеп чыкты. Андрей икона күтәреп сөйләсә дә, халыкны алдады. Ул чиркәүләрдән тыш биредә үзе һәм сакчылары өчен дә зур сарайлар төзетә, ә соңыннан бу бистә, аның исәбенчә, һичбер дошман яулый алмаслык ташкирмәнгә әверелергә тиеш иде. Әйе, Андрей халыкның күзенә төтен җибәрә белде, ләкин үзе моңа төкереп тә бирмәде. Чөнки аңа инде бер ай элек үк «Боголюб» дигән абруйлы намь тагылган һәм Андрей турындагы бу яңа дан бөтен урыс кенәзлекләре буенча таралган да иде.

Андрейның өметләре үзе көткәннән дә уңышлырак булып акланды. Шул елда ук Владимир янына күрше кенәзләр талавыннан, яу йөрүдән качып киткән йөзәрләгән, меңәрләгән крестьяннар килә башлады. Ул да түгел, Ростов белән Муром кенәзләре дә Андрейның алдына килеп тезләнде. Алар да инде күрше урыс кенәзләре белән кан коешудан, качкан крестьяннарны эзәрлекләүдән туйган һәм Андрейдан үз канаты астына алуын үтенә иде. Владимир кенәзенең шарты гаять кыска булды:

—Сезнең һәркайсыгыз фәкать миңа гына буйсынып яшәячәк. Икегезнең берегез баш калкыта икән, ул тыңлаусыз башны шундук кыеп төшерәм яки андый кенәз урынына воевода куям. Сез калаларны үз балаларыгызга мирас итү хокукыннан да мәхрүм ителәсез.

Андрей әрем сыман ачы хакыйкатьне турыдан-туры ярып сөйләмәде генә. Чынлыкта исә, Ростов белән Муром хакимнәре кенәзлектән наибвоевода дәрәҗәсенә төшерелә иде. Әмма тегеләр Андрей куйган шартларга күнмичә булдыра алмадылар. Чөнки алар Мономах оныгы да, Юрий Долгорукий уллары да түгел һәм иртәме-соңмы, барыбер, кенәзлекләреннән колак кагасы бичаралар иде. Теләсә кайсы азгын кенәз һөҗүменнән соң башсыз калуга караганда алар көчәеп килүче һәм данга тиенгән Андрейга баш иеп яшәүне үзләренә кулай санадылар. Ә күңел күзе сукыр булмаган күршеләре Владимир кенәзенең көннән-көн көрәя баручы үгез хәленә килүен һәм аның башкалар көтмәгән бер минутта үз аранын җимереп читкә ыргыласын нык чамалап өлгергән иде инде.

## 2

—Таш дивар артына качкан йолкыш монах сыман япа-ялгыз көе яшәү җитәр инде сиңа. Күзең төшәрдәй бер сылуны тап та, әйдә, өйләндерәм.

Андрей кенәз бер иртәдә әйткән шул сүзләр Козьма өчен корт чаккандай булды. Авыр йөк астында калган бер бичара сыман ул кызарып чыкты, күзләрен озын керфекләре каплап алды, теле көрмәкләнде.

—Ә... ә... ә... м-м-мин с-с-сиңа н-н-нинди х-х-хилаф эш эшләдем соң, ке-ке-кенәз?—дип көч-хәл белән генә сытып чыгарды ул.—Синең өчен кирәкмәс кешегә әйләндемме әллә?

Андрей кычкырып көлде.

—Өйләнү дигәндә уттан курыккан кебек бәлтерәп төшкән мондый бәндәне тәүге тапкыр күрәм... Минем янга килүенә дә алты-җиде ел үтте түгелме соң инде? Сиңа күптән хатын назын, ата бәхетен кичерергә вакыт. Синең ир-ат горурлыгың корымагандыр бит, мәлгунь? Әллә... әллә берәр бояр кызына күз аттың да, шуны миңа әйтергә кыймый йөрисеңме? Курыкма, әйт кенә син. Бояр кызы икән, бояр кызы. Барыбер, өйләндерәм...

Козьма тәнен кызган тимер белән өткән сыман, тагын да куырылды,

бер генә дә җавап кайтармады. Ул үзен яман угрылыкта тотылган һәм качар юлы бикләнгән бер бичара карак халәтендә тойды, аның дәшмәве дә котылгысыз җәза көтүгә охшап кына калды.

Бөтен бәла шунда—Козьма байтак айлар буе кенәз хатыны Байгөлгә гашыйк һәм кайчандыр, җан атып, Андрей ягына күчкән пәһлеван хәзер үзен инде тулысынча чарасыз бер әсир шикелле итеп тоя иде. Кайчан туды бу хәл, ничек шулай булды?—ул кадәресен, мөгаен, Козьма үзе анык кына аңлаталмас иде.

Гәрчә Байгөл аның өчен олуг хуҗабикә булып саналса да, Козьма аны әүвәл, туган сеңлеседәй итеп, якын күреп йөрде. Байгөл чынында да аннан ике яшькә кечерәк, ә ялгызлыгы, ятимлеге өчен Козьма аны кызгана да иде. Байгөлнең кияүгә чыгу тарихын да төгәл белеп алгач, Козьма инде тәмам бетеренде. «Аның әтисен үтергән кансыз җәлладның улы белән яшәүгә Байгөл-Василиса ничек түзә? Ике арада яткан кипмәс канны атлап, онытылып сөю мөмкинмени? Җәллад улы белән бергә яшәү, шул катилнең онытларын табу Байгөл-Василиса өчен газап кына бит».

Хуҗабикәнең бик еш кына үз бүлмәсенә бикләнеп үкси-үкси өзгәләнүләренә дә шаһит була башлагач, пәһлеван күңелендәге кызгану һәм әрнү хисләре куера гына барды. Бу гөнаһсыз кешене нигә газаплыйсың, Ходаем? Катил, кансыз Юрий кенәзеңне син ни өчен тантана иттерәсен дә, ата-ана, ир назыннан мәхрүм ителгән ялгыз Байгөл-Василиса ни сәбәпле синең өчен дә үги бер бала соң? Нигә, нигә бу дөньяны шушы кадәр миһербансыз, гаделсез иттереп яраттың син?»—дип, Козьма инде, аптырагач, Ходай Тәгаләгә дә тел тидерергә батырчылык кылды.

Тоташ кызгану хисләренең мәхәббәткә әвереләсенә күп калмаган иде. Әмма аның баш югалтып гашыйк булуы Андрей кенәз Болгар сәяхәтеннән кайткан чакта туды.

Ука тамагындагы Калачыкны үтеп, рус җиренә аяк басуга ук, Андрей кенәз Табанлы-күл буендагы яшел тугайлыкта ялга тукталырга әмер бирде. Җилкәләреннән авыр йөк—болгарларның көтелмәгән һөҗүменнән курку хисе төшкәнгә күрә һәр сәяхәтче балаларын үстереп читкә тараткан, аларны башлы-күзле иткән бәхетле ана сыман тынычланып, иркенәеп калды. Күл буена җинел чатырлар кордылар, балык тоткач, казан астылар. Тын, җылы кич иде, җырлар суза-суза рәхәтләнеп күңел ачтылар. Тәмам төн уртасы житкәч кенә, сәяхәтчеләр чатырларга таралышты. Вазифалар күптән билгеләнгән иде: Прокопий—Андрей кенәз, ә Козьма исә Байгөл чатыры янында сакка калды.

Хуҗабикә бу төндә әледән-әле ике нәни улын үбә-үбә бик тыелып елады. Күрәсең, әле генә аерылышкан туган җирен дә, шунда калган сеңлесе Осланбикәне дә сагына, юксына иде ул. Аның елау авазлары бик озак вакыт үткәч кенә тынды. Ә күзләрне иркәли-иркәли сызылып таң ата башлаганда ул чатырдан чыкты. Бер кенәз чатырына, бер Козьмага карап байтак басып торды. Козьма һичнинди уяулык әсәре сиздермәде, ыстан да тын иде. Шуннан соң Байгөл күл буена юнәлде, песиле тал куаклары артына житкәч, су өстенә текәлеп, янә уйга калды. Менә бермәлне ул инендәге камзулын салып атты, кин изүле күлмәген аяк астына шудырып төшерде. Аннары чатырлар ягына борылып карады да, өстендәге соңгы эчке киемнәрен дә салды. Козьма хуҗабикә эзеннән шуышып килеп, инде күптән тал куаклары төбендә ята иде. Ул Байгөлгә текәлде дә катты.

Офык артында әле генә керфекләрен ачкан шук кояшның ал нурлары яшь хатынның озын, таза ботларында кайтарылып уйный. Ә очына ике чия куңган тыгыз, мул күкрәкләр Байгөл сулыш алган саен җанлангандай була. Ымсындырып торган шул чияләр җылы кояш нурыннан тулырлар да, менә-менә өзелеп төшәр төсле. Әллә Байгөл дә нәкъ шундый ук хисләр кичерде инде. Көтмәгәндә кулларын күтәрде дә, кызгылт чияләрне бармак очларында уйнаклатып алды. Козьма сызланудан ике күзен дә чытырдатып йомды.

Су чупылдаган тавышлар ишетелгәч кенә, ул күзләрен ачты. Байгөл бил тинелтен су эченә кергән, ике учы белән иплəп кенә күкрәкләрен юа. Менә ул тагын бер мәртәбә чатырлар тарафына караш атты. Козьма аның шул карашын күрде дә, куырылып калды. Нәфрәт тә, үкенү дә, сугымга салынган бичара мал күзендәге кебек көчсезлек тә—барысы бергә жыелган иде анда. Әйтерсең, Байгөлнең жаны каядыр очып киткән дә, монда жанының кабыгы гына калган. Козьма инде урыныннан кубарга әзерләнде. Ә Байгөл кинәт су эченә таба ыргылды да, өзелгән камыш сабагы шикелле кинәт юкка чыкты. Ниндидер хәвеф сизгән Козьма яшеренеп торган урыныннан торып басты, Байгөл чумган төштәге түгәрәк дулкыннар өстенә текәлеп торды. Козьмага инде учак ягып казан эләрлек ара узган кебек булды, су өстендәге дулкын эзләре дә юкка чыкты—Байгөл күренмәде. Хәвефнең асылын аңлап өлгергән Козьма ашыгып күлгә чумды, ике-өч колач салуга Байгөл югалган урынга килеп житте. Аннары киерелеп бер тын алды да, хужабикәсе артыннан төпкә чумды.

Байгөл күл төбендә, камыш сабакларын йомарлап тоткан көе, инде һушсыз хәлдә ята иде. Козьма аны үзенең күкрәгенә сосып алды, су өстенә калыккач, ат кебек пошкыра-пошкыра йөзеп китте. Яр өстенә чыгарып салганда да хужабикә жан әсәре белдермәде. Козьма аны-моны уйлап тормыйча уч төпләре белән хужабикәнең мул имчәкләре өстенә кат-кат басты, кулларын аска-өскә йөртеп хәрәкәтләндерә башлады.

Байгөл бик көттереп кенә керфекләрен ачты. Башта һични аңышмыйча Козьманың йөзенә текәлеп ятты. Хужабикәнең өстендә һичбер кием дә юк һәм Козьма телиме-теләмиме яшь, сылу хатынның һәммә байлыгына текәлеп утырырга мәжбүр иде.

Бераздан жиһанга «э-э-эһ»—дигән авыр бер ыңгырашу таралды һәм Байгөл интегеп кенә, өзгәләнә-үски башлады. Ул бер сүз дә әйтми, акланмый, ялвармый да, әмма усал йодрыклары белән жирне төя-төя, һич туктала алмый газаплана иде. Егетнең дә ана комачауларга исәбе юк иде, ул таллыклар артына кереп чүгәләде дә көтте.

Козьманы чатырлар ягында үлән сабаклары сынган тавыш кына жиһанга кайтарды. Прокопий да аягына баскан һәм күл буена төшеп бара иде. Козьма капылт кына урыныннан кузгалды, аяк очларына басып, Байгөл янына ашыкты. Читтә аунаган камзулны алды да, анадан тума яткан хужабикә өстенә иплəп япты. Шуннан соң, янә сиздермәскә тырышып кына, чатыр буена китте.

Хужабикә күл буенда булган әлеге яман хәл турында һичвакытта искә төшермәде. Бер тапкыр гына ул, үтә жылы итеп, Козьманың беләгеннән кысты, әмма барыбер һични эндәшмәде. Ләкин пәһлеван егет таң алдында Табанлы-күл буенда күргән сын белән инде тулысынча сихерләнгән иде. Үзен-үзе күпме генә тыелырга мәжбүр итмәсен, ул янә, сайрар кош сыман талпынып, Байгөл янына омтыла башлады. Хужабикә йокыга ятар алдыннан чишенгәндә һәр кич саен диярлек ул аркан белән тартып китерелгән сыман шул тирәгә суырылып бара һәм аны качып кына күзәтә торган булды. Ул үзенең пәке йөзеннән йөргәндәге кебек хәвефле халәт кичерүен дә, гөнаһка көннән-көн тирәнрәк суырыла, чума баруын да аңлый, әмма сазлык эченә эләккән бичара шикелле аннан котылу әмәлен генә таба алмый иде.

### 3

Боголюбово бистәсе төзелешендә куна-төнә эшләп яткан чакта Андрейга искитмәле сәер хәбәр китерделәр:

—Кенәзлекнең чигендә, Уканың бу ягында, егермеләп болгар шымчысын тоттык. Ни өчендер алар елга тамагындагы Калачык кирмәненә эләгүдән дер калтырап тора. Мәгәр иң гажәбе—ул шымчыларның берсе үзен сиңа яхшы мәгълүм, Әмир, дип таныштыра.

—Исеме ничек?—дип сорады Андрей, каударланып.

Чапкынның җавабы тагын да тылсымлырак булып яңгырады:

—Без дә кат-кат сорадык, ә ул берни әйтми. «Мин атын да, дәрәҗәсен дә югалткан гап-гади бер качкын. Кенәзегез кабул итми икән, мин кыпчак даласына борылып китәм», дип, тик тәкърарлап тора.

Андрейның инде түзем дилбегәсен тагын да сузарлык чамасы калмады.

—Ә хәзер кайда ул?—дип, ашыгып сорау бирде.

—Монда таба алып киләбез. Күп булса, унбиш чакрым ара калгандыр,—дигән җавабын ишетүгә, Андрей чаптары өстенә сикереп менде. Прокопий һәм Козьма аның артыннан көч-хәл белән генә житештеләр.

Чапкыннарны күреп Клязьма ярында туктап калган төркем эченә ярып керүгә үк, Андрей шаккатты. Киемнәре шактый теткәләнгән, үзе нык йончыган, чәче чаларып килгән һәм һич кенә дә көтелмәгән кунак—әле кайчан гына аны үзенең кайнар учактай дәрте, зиһенлеге, горурлыгы белән сокландырган... чонтык Әрбәт иде. Андрей шундук иярдән сикереп төште, кичәге әмирне кочагына сосып алды. Чит-ятлар каршында һичбер төрле сорау бирмәде ул, ләкин Әрбәтнең кинәт дымланган һәм гаепле, мескен кешедәй гел яшерергә тырышкан күзләрен тиз шәйләп өлгерде. Шуңа күрә һични аңлатмыйча, әмма сынар кулы белән кочаклаган хәлдә ул Әрбәтне төркемнән читкә алып китте. Клязьма буйлап берникадәр баргач, икесе тиң аякларын ярдан салындырып, җиргә утырдылар. Шунда Әрбәт, тәгәрмәче күчәреннән чыгып аптыраткан арба шикелле, туктала-туктала, Болгар илендә булып узган барча аяныч хәлне кенәзгә бәян итте. Ни гаҗәп: Андрей әлеге хәбәрләргә һич сөенми, ул бары тик күңеленә сокландыргыч булып кереп калган Болгардагы бердәмлекнең шулай җинел генә таркала алуына сәерсенә иде.

Әрбәт сөйләүдән туктагач, ирләр, давыл вакытында сынып төшкән агач кәүсәләре кебек, тып-тын утырдылар.

—Үзеңне яклау өчен минем гаскәр туплап баруымнан син баш тарттың. Син мона чыннан да инанасыңмы соң?—дип, Андрей инде ничәнче мәртәбә бер үк сорауны кабатлады.

—Мин әйттем бит инде,—дип, Әрбәт тә һаман бер үк җавапны тәкърарлавын белде.—Кан коярга теләмәгән өчен мин тәхеттән баш тарттым, шул ук сәбәп белән туган илемне дә ташлап киттем. Үз халкымның дошманы булырга һичбер исәбем юк. Шәхси орышта мина каршы торырдай кеше булмаса да, мин гомер буе каннан куркып яшим. Ә аннары... Синең гаскәр туплап Болгарга баруыңның уңышка китерәсенә дә нык шикләнәм. Читләр кага башласа, бер гаилә балалары бик тиз берләшә ул. Болгар—хуҗасы сәнәк кадаган нәсел үгезенә охшап калды. Аның каны агып тезгә чүккән хәлен күрү өчен, ай-һай, әле күп котәргә кирәк.

Тагын тын калдылар. Аны, башлап, янә Андрей бозды.

—Сине күрүгә минем Байгөл дә, Кучкәй бистәсендәге туганнарың да шатланыр, дип уйлыйм. Әйдә, Байгөлне ал да, син Кучкәйгә юнәл. Ял ит, көч тупла, рус җирен бәялә. Аннары күз күрер. Чамалап-тоеп торам, син озак вакыт буе тик ятуга түзә алмассың әле...

Шулай килештеләр дә, Әрбәт Владимир каласы аша Кучкәйгә юл тотты. Андрей үзенең бәясендә һич тә ялгышмаган булып чыкты. Бер айдан соң ук Әрбәт тарафыннан чакыру килеп җитте:

—Кучкәй—яңа кала, ныклы кирмән төзү өчен гаҗәеп шәп урын. Мин тирә-юньдәге урманны кистерә башладым инде. Диварларын төзеп куйганчы, килеп күз сал. Үз каланчаннан торып бәһаләгәч, бәлки, синең кирмән мәйданын үзгәртәсең килер.

Андрей кенәзлектә һәрбер эшне ышанып тапшырырдай ярдәмчесе хасил булуын шундук аңлап алды. Сөенече эченә сыймый иде, ул Кучкәй тарафына канатланып очты. Бистә каршына житкәч, үз күзләренә үзе ышанмыйча торды. Яндагы урман киң итеп егылган, ботакларыннан арындырылган имән белән нарат бүрәнәләр тау-тау булып ята, шулар читендә

үз зур таш өемнәре. Бистәнең бөтен тирә-ягын тирән итеп казылган чокыр урап алган. Йортлар янәшәсендә дә чокыр урыннары.

—Хәтереңдә булса, Болгар каласын өч яктан да тирән сулар саклый. Чулманнан тыш, Болгарның бер ягы буйлап Милән суы ага, икенче яктан каланы корыган инеішне казып хасил иткән култык каплап тора,—дип аңлатты Әрбәт, Андрейны булачак кирмән планы белән таныштыра башлагач.—Монда да нәкъ шул хәл. Әнә теге якта—Явыз-елга, биредә—Мәскәү, ә менә инде без казып тирәнәйтә башлаган яңа ерым моңа кадәр «Үлгән су» булып йөргән. Казый-казый Мәскәү белән Явыз-елгага илтеп тоташтыргач, бу ерымга хәтсез су тулачак, шулай итеп синең әлеге яңа кирмәненне нәкъ өч яктан сулы киртә каплап торачак. Качак әмирне кочып үбүдән Андрей үзен көчкә тыеп калды. Аның йөрәге инде ут шикелле яна, бар хыялы яңа каланы тизрәк күрү иде. Ә Әрбәт канатлана-канатлана, сайрар кош шикелле очына-очына сөйләвен генә белде.

—Үлгән-су ягыннан бу кирмәнне таш диварлар белән ныгыту отышлырак булыр. Ул гына да җитмәс, дивар каршына киң ерым казытырбыз, Болгардагы кебек үрләр күтәрербез. Аяныч хәл, таш дигәннәре генә бу якларда бик күп түгел икән. Явыз-елга белән Мәскәү ягына әлегә бүрәнә диварлар гына утыртырга туры киләчәк.

Бермәл тын торды да, авыз ера-ера, Әрбәт сорау бирде.

—Сезнең бу «Мәскәү» дигән сүзегез нәрсә аңлата ул?

Андрей җилкәсен сикертеп куйды, Әрбәт элеп алды.

—Ә безнеңчә «мәсхә»—сыер, «мәскән»—яшәү урыны, дигән мәгънәләрне белдерә. Кемнәр белә, бәлки, чыннан да, әлеге төбәк рус кенәзлекләренең тернәкләнү, нәсел яңарту урыны булып китәр. Мондый төбәк хәтта рус җиренең яңа башкаласы булырга да, эх, кулай бит.

Әрбәттәге ялкындай илһамлану Андрейга да күчте.

—Алай икән, әйдә, яңа каланың исеме «Мәскәү» булып китсен. Син шуны төзе дә, аның беренче воеводасына әйлән. «Әрбәт-воевода!» Ох, шәп яңгырый бит!

Ирләр, бер-берсенең җилкәләренә шап-шоп суга-суга, озак көлештеләр. Бу минутта алар икесе тиң шактый бәхетле, әмма еллар узгач «Үлгән-су»ның—«Неглинная»га, «Явыз-елга»ның—»Яуза»га үзгәртеләсен дә, Мәскәү кирмәнендә тәүге воевода булган болгар улының шәһәр урамнарында «Арбат» исеме белән сакланып каласын да әлегә һичкем белә алмый иде. Ләкин, барыннан да бигрәк, каланың нигез ташын салган болгарларны, күп дәверләр үткәч, рус халкының гомумән белмә-мешкә сабышуы аеруча аяныч хәл булды. Ни хәл итмәк кирәк? Тарихны фәкать җиңүчеләр кулы белән генә язу—күптән мәгълүм хакыйкать шул инде...

## 4

Янадан Владимирга кайтып кергәнче үк Андрейны Киевтан килгән чапкын куып җитте.

—Олуг кенәз көе вафат булган Изяславның улы Мстислав синең бертуган абыең Мстиславны Бөек Новгород каласыннан куып җибәргән. Черниговтагы Изяслав Давид углы да, Смоленскидагы Ростислав та угры Мстиславны яклыйлар, өчесе бергәләшеп синең әтиеңә каршы яу чыгарга җыеналар икән. Олуг кенәз үз янына дәшә, синнән, ким дигәндә, ун мең кешелек гаскәр таләп итә.

Андрей ачудан үртәлеп, капылт йөзен чытты. Башка кенәзлекләргә чыгып йөрмәсә дә, урыс җирендә дәвам иткән кырылыш, яу турында хәбәрдар иде ул. Әтисе күпме көрәшкәннән һәм кан түккәннән соң, Киев тәхетенә утырды, ләкин урыс кенәзләре арасындагы ызгыш-талашны тыя алмады. Бар мәхшәрне, иң элек, үзен аеруча рәнҗетелгәнгә санаган Мстислав Изяслав углы башлап йөрде. Ул әтисеннән калган тәхеткә Юрий утыру белән дә, үзенә Волынь кенәзлеге эләгү белән дә ризалашырга теләмәде. Ул Польша җиренә үзен дошман булып йөргән Олегның улы Святослав белән

Чернигов кенәзе Изяслав та яклап чыкты. Башка чарасы калмагач Юрий кенәз, Польшага качкан Мстиславка—Луцк, Изяславка—Корчевск, Святославка Мозырь калаларын биреп, һәр өчесенең күнелен күрмәкче булды. Юк шул, яуга-канга күнеккән явыз кенәзләрнең берсе дә туя белмәде. Мстислав тотты да, Волынь өлкәсеннән үзенең агасы Владимирны куып җибәрде. Түземлеген җуйган «Озын Куллы» Юрий, үзенә ярдәмгә угыз, бәрәндиләрне дәшеп, әле Мстиславка, әле Чернигов кенәзе белән Төньяк-Новгород хуҗасына каршы яу йөрергә мәҗбүр булды.

Урыс җирендә барган бу мәхшәрне аларның дошманнары да күреп тора иделәр. Кыпчаклар моннан аеруча оста файдаланды. Юрий кенәз Киевны калдырып китәргә мәҗбүр булган саен кыпчаклар урыс кенәзлекләрен аяусыз талап торды. Урыс кенәзләре белән сугышудан арып беткән Юрий, янә шул ук бәрәндиләрне ияртеп, ике мәртәбә кыпчак даласына да җавап походлары оештырды.

Олуг кенәз буласп Киевта калуына ике елга якын вакыт үтсә дә, әтисе мона кадәр Андрейны үзенә ярдәмгә чакырмаган иде. Улының Вышегородны, димәк, берочтан аны да ташлап китүенә үпкәләгән идеме ул, әллә Суздаль-Владимир җирендә башланган гаҗәеп зур эшләрне хупладымы?—моны Андрей, әлбәттә, анламады. Ләкин менә хәзер, әтисе ярдәмгә чакыргач, өстәвенә, бик каттый рәвештә ун мең кешелек гаскәр таләп иткәч, Андрейнын ачуы гына килде. «Тот капчыгынны!—дип, эченнән генә ярсып сүгенде ул.— Мондый тәртип алга таба тагын дәвам итсә, урыс җирендәге бу коточкыч мәхшәрнең мәнге бетәсе юк. Син бүген гомер кичергән тугыз малаеннын берсенә биләмә яулый дип, үз кул астымда булган ун мең (ун мең!) сугышчыны сазлык сыман төпсез яуга илтеп кертергә мин җүләрме әллә? Бик атлыга икән, ул Новгород өчен Мстислав үзе жаны теләгән кадәр канын койсын. Ике аягымның берсен дә атлыйсым юк!»

Андрей эчендә янган утны Киев янында ана «әсирлеккә төшкәннән» бирле бер көн дә аерылмыйча яшәгән пәһлеван Козьма да тоеп алды бугай.

—Син рөхсәт ит, кенәз, мин Киевка китим,—дип, кыш уртасындагы яңгыр сыман һич тә көтелмәгән сүз катты ул.

Андрей гаҗәпсенеп сорарга мәҗбүр булды.

—Вәт әкәмәт! Ә монысы нигә?

—Нинди сәер хәлдер, мәгәр тарих кабатланып торырга ярата икән бит ул. Син Нестор язмасында үзен укыган зирәк Ярослав язмышы турында хәтерлисенме, кенәз?

Андрей теле төйнәлгән кеше шикелле җавапсыз калды, Козьма дәвам итте.

—Хәтеремдә булса, Новгородка кенәз итеп куелгач, Зирәк Ярослав үзенең әтисенә ясак түләүдән баш тарта. Шуның өстенә, әле үз биләмәсен мөстәкыйль кенәзлек, дип тә белдерә ул. Шушы эшне рус берлеген җимерергә омтылу дип анлап, «Кызыл Кояш» Владимир кенәз үз улына каршы гаскәр туплый башлый. Мин Юрий кенәз дә шул хатаны кабатлар, сиңа каршы күтәрелер, дип куркам...

Андрей которынып аны бүлдерде.

—«Кызыл Кояш» олы гаскәр туплый. Мәгәр Ярославка каршы яуга чыгарга өлгерми. Берестов авылына баргач, җарияләре кочагында, үтә сәер хәлдә җан бирә ул. Ә син нигә шуларын да сөйләп бетермәдең? Минем атам белән дә шундый хәл туар, дип шикләнәсенмени?

Ихлас күнелле Козьма, пәһлеван булса да, кешеләрнең туры карашын күтәрә алмый иде. Андрей кычкырырга тотынгач, ул күзләрен бөтенләй кашлары астына яшереп үк басты.

—Мин күрәзәче түгел, аны беләсең булыр.—Козьманың тавышында да үзен гаепле тою авазы ишетелә иде.—Мәгәр Юрий кенәзнең дошманнары бик күп. Мстислав—бер. Чернигов кенәзе—ике. Шуларга өстәп, тагын синең бабаң каршы яуга чыгып йөргән Олегның бүгенге оныклары. Алары инде санап бетергесез. Әле тагын жил кайсы якка иссә, шул тарафка авыша торган Святослав та бар. Тагын... тагын әле Киевның үзендә дә

Юрий кенәзне сөймәүче боярлар—ерып чыккысыз. Шулар һәммәсе берләшеп олуг кенәзне сиңа каршы котыртмас, дип ышанып буламыни?

Андрей инде тынычланып сорау бирде.

—Ә син, Козьма, Киевка барып, ниләр генә майтара алырсың соң? Онытма, сине анда үзең үк жанын кыйган Остомыслның абыйлары көтеп тора бит.

Козьма кулын гына селтәде.

—Әй, минем гомер—гади чыра ла ул. Янды-бетте, аңа төкерәсе. Ә менә синең, үз җилкәңә алган, таудай эшләрең бар. Шуңа күрә сиңа хәтта Юрий кенәз дә кагылмаска тиеш.

—Син миңа мәдхия укыма, максатыңны сөйлә.

—Мин сиңа әле беренче көнне үк барысын да ачып салган идем. Кабих Остомысл үлемгә этәргән минем «Аккош» апама Киевнын Петрила атлы бояры да гыйшык тотып йөри иде, дип сөйләдем мин, шунысы хәтереңдәме? Менә шул Петрила хәзер Киевның иң беренче боярына әверелгән, Юрий кенәзнең уң кулы булып исәпләнә икән. Мин шуның янына барам. Ышанам, ул әле «Аккош»—Ульянаны оныта алмагандыр. Онытмаска тиеш! Ярдәм итми калмас.

Пәһлеванның соңгы сүзләре, пышылдап эндәшкән кебек, тоныкк кына яңгырап ишетелде. Күрәсең, аны тагын ачы хатирәләр биләп алган иде. Бертуган энекәшедәй тугры Козьма белән Андрей сүзсез генә хушлашырга мәҗбүр булды.

## 5

Козьма, саф чишмә төбенә карагандай, илне алда көткән вакыйгаларның барчасын да үтәли күреп кисәткән булып чыкты. Сабак алучылар гына сирәк табыла, ә галиҗәнап тарихның әйләнеше кайбер чакта коймадагы такталар сыман бер-берсенә гаҗәп охшаш булып та кабатлана икән.

... Козьманың аты ярты юлны үткәнче үк янып ауды. Пәһлеван егет Киевка җиткәндә җиһанда яз да борынланган иде инде. Язгы туфрак яңа гына кияүгә чыгып, буйга үтү турында хыялланган яшь хатын шикелле уҗымнар шытуын көтеп тилмерә. Табигатьнең керләнмәгән, тапланмаган чагы, каштаннар чәчәккә бөреләнеп килә, туфрак дымы, кояш җылысы җир өстеннән рәшә сыман кайтарылып уйный. Табигатьнең бар муллыгы белән хозурлан да, җыр гына суз. Күңелләрнең әнә шулай, язгы инеш сыман, тулып ташкан чагы.

Ә Козьма исә, Ләһ капкасын үтеп калага керүгә үк, аптырашка калды. Шәһәр стеналарының эчке каты урыны-урыны белән җимерелеп төшкән. Аны тергезергә дип бүрәнәләр хәзерләүче дә, ике арага кабат тутыру өчен таш һәм туфрак ташучы да күренми. Кала урамнарында ташландык, ярымҗимерек йортлар күзгә бәрелеп тора. Байтак урамнар чокырланып беткән, аларны әрем, алабута, билчән басып киткән. Хәтта, инде чиркәү кадәр чиркәүләр дә хуҗа кулын оныткан. Күбесенең гөмбәзләре өстенә мүк саргандай тоныкланып калган, стеналары акшарланмаган, ятим төсен алган.

Козьманы янә бер тараф үтә сәерсетте. Чиркәү яннары, мәйданнар хәер сорашып утыручы гарип-горәбә һәм ач әрвах белән тулы. Аның каравы, әледән-әле урамнар буйлап йә бояр, йә кенәз унбишәр-егермешәр җайдаклы сак астында узып китә тора. Кала ниндидер куркыныч дошман явын йә олы мәхшәр көтә диярсең. Шәһәрдә кылыч таккан, ат менгән сугышчылар искиткеч күп.

«Андрей кенәз әйтмешли, «валлаһи, әкәмәт бу»,—дип ачынып уйланды Козьма.—«Үзе башкала, дип атала, ә хуҗасы барлыгы һич күренми. Мәгәр бөтен халкы орышка чыгарга, кан коярга әзер. Әйтерсең лә, кылыч селтәп, читне талап кына илне тотып була. Э-эх, Андрей кенәз белеп кул селтәгән.

Ходай каргышы төшкән бу калага, Ходай каргышы!..»

Шәһәр урамнары буйлап ялтырап йөрергә һич ярамый иде. Козьма элек үзе яшәгән бистәгә бик сакланып кына аяк басты. Ләкин бояр Петрила йортлары урнашкан ихатага якынлашуга ук гаҗәпләнеп туктарга туры килде. Ихата уртасына зур-зур ташлардан яна йорт салынган, ишегалды кылыч, хәнҗәр таккан сугышчылар белән тулы. Очлы башлы имән бүрәнәләрдән ясалган биек дивар белән әйләндереп алынган бу ихата бояр утарыннан бигрәк көчле дошман һөҗүмен каршыларга хәзерләнгән зур хәрби кирмәнне хәтерләтә. «Беренче бояр дәрәҗәсенә ирешкән байлар шулай үзгәрә икән»,— дип нәтиҗә ясаса да, Козьма ялгышкан булып чыкты. Ул юлда туктатып сорашкан беренче карчык ук аның өметен өзде.

—Юк, Петрила хәзер үзәктә, София соборы янында ук яши. Аның утарына якын киләм, димә. Диварлары таш, бөтен яклап сакчы. Ә монысы йә угрыларны, йә бөтенләй гөнаһсыз бәндәләрне тотып газаплый торган зиндан гына хәзер. Бу тирәдә йөрмә. Мондагы җәлладлар күргән бер сөяккә ташланырга торган эт сыманнар, олан.

Рәхмәт әйтә-әйтә аерылды да, Козьма үзәккә ашыкты. Узгынчы карчык һич тә арттырмаган, беренче бояр яшәгән утар янына якын килү мөмкин түгел иде. Хуҗасын үтеп барышлый булса да күрергә өметләнеп, Козьма Собор мәйданының аулаграк почмагына елышып утырды.

Мәйдан ыгы-зыгысын беркадәр күзәтеп утыргач, ул бөтен кала тормышын да уч төбендәгедәй күргән кебек булды. Собор стенасын әйләндереп, картлар һәм гарипләр хәер сорашып утыра. Якындагы авылдан килгән ике олаудан ирләр тозлы кыяр белән ачыган сөт сатып тора. Әле теге, әле бу табан ашыгучы короллы җайдаклар агышы һич туктамый. Әнә, бер хатын хәйран гына исереп алган ирен, усал йодрыклары белән төя-төя, өстерәп бара. Телендә тоташ әшәке сүз.

—Мин сина ул соңгы мендәрне ипигә алыштырырга дип биреп чыгардым бит. Ә син тагын бирән булганчы лыкынгансын, дуңгыз! Мин синен ул шайтан балаларына «кишеренне» ашатыйммы әллә?

Ире аннан да гайрәтлерәк тавыш белән сүгенә.

—Юк, «кишергә» тимә, анысы сина кирәк...

Хәер сорашып утырган гарип-горәбәгә шул да җитә, бар дөньяны куптарып көлешәләр.

Козьмага бу кыямәтне күзәтеп утыру гаять сәер иде. Ул хәтерендә әле Кашан, әле Владимир урамнарын янартты һәм шул хәтирәне Киев тормышы белән чагыштырган саен күнелендәге әрнү-сызлану хисе көчәя генә барды. «И-и, Ходаем! Андрей кенәз белеп әйтә икән. Урыс халкына күмәк бүрек кенә түгел, чыбыркы да җитми. Хәвеф-хәтәр килгән чагында гына берләшә беләсез сез. Ә ул үтте икән, сезнең өчен дингез—тубыктан»...

Шундый авыр уйлар кичерә-кичерә Козьма озак утырды бугай. Мәйданда инде шактый гына кешеләр алышынды, ыгы-зыгысы гына бер дә кимемәде. Бермәлне Козьма Собор стенасы буена килеп баскан сынар куллы әзмәвердәй иргә игътибар итте. Ана текәлебрәк карады да, тәне чымырдап куйды. Әлеге ир йолкынып беткән иске җиләненең бер изүен янга төшергән дә, нибары бер карыш озынлыгында калган кисек беләген аска-өскә таба кыймылдаткан булып, кызгандырып тора. Козьма ихтыярсыз рәвештә гарип ирнең йөзенә күз ташлады һәм янә ачынып уйланырга мәҗбүр булды. «Мөгаен, бичара да сынар кулын шул туймас күзле кенәзләр мәнфәгатен яклап яуда өздергәндер. Ә ана әле утыз яшь тә юк бит. Ничек көн итәр соң ул хәзер? Мондый гарип бүген кемгә кирәк?»

Сынар куллы ир әзмәвердәй озын гәүдәле булса да, гаять ябык иде. Күзләре эчкә баткан, яңаклары суырылган, муены да, әнә, беләк шикелле нечкәреп һәм озынаеп калган. «Ачлык галәмәте бу, ачлык галәмәте»,—дип нәтиҗә ясады Козьма.

Ә гарип ир, чыннан да, инде ничәмә ничә тәүлек буена бер кабым икмәк тә күрми тилмерә, ашказанында бүреләр улый иде. Менә, бермәлне ул мәйданның каршы ягында тозлы кыяр сатучы ирләр янына китте. Әүвәл

унга-сулга карангалап алды да, хужасы күрмәгәндә генә бер мичкәдән учы белән кыярларны эләктереп, янә Собор ягына таба йөгерергә тотынды. Ачлык анын үзәгенә үткән иде, ахры, ул йөгереп барышлый ук кыярларны берәм-берәм авызына озата башлады. Шунадыр, үз өстенә якынаеп килгән хәвефне бөтенләй күрмичә дә калды.

Мәйданга жайдакларнын яңа бер төркеме кереп килә иде. Күзебашы тонган гарип ир дә болан сыман сикергәләп мәйдан уртасына томырылды, хәвефтән качарга да өлгермәде. Менә, алдан килгән ат күкрәге белән аңа китереп бәрде. Кулындагы кыярларын тирә-юньгә чәчеп, әзмәвердәй гәүдә жиргә ауды. Тагын бер-ике адым узса, икенче булып килгән айгыр гарип ирне таптап узачак иде. Нәкъ шул мизгелдә чаптар алдында пәһлевандай Козьма пәйда булды һәм ике кулы белән дә аргамакның йөгәненнән усал эләктереп алды. Аргамак куркудан, алгы аякларына тезләнгән шикелле, шып туктады, ә иярдәге жайдак анын башы аша очып жиргә мәтәлеп төште. Козьма сикереп аякларына күтәрелгән әлеге ирнең... кан дошманы Остомыслның бертуган абыйсы Гаврила икәнлеген генә шәйләп өлгерде. Икенче мизгелдә инде кемдер анын баш түбәсенә күсәк белән орды һәм Козьма, әйтерсең лә, упкын төбенә чумды.

## 6

Козьма салкын һәм ярымкараңгы базда аңына килде. Анын кул-аягы бәйләп ташланган һәм кан савудан бөтен тәне берни тоймас хәлгә килгән иде. Ул сызланудан авыр ыңгырашып куйды, шуны ишетүгә үк янына күн алъяпкыч кигән ике жәллад килеп житте.

—Әһә, айныдыңмы, кабих?—дип сүгенде берсе һәм, озак көттермичә, таштай йодрыгы белән пәһлеванның маңгаена сукты. Козьманың күзләреннән ут көлтәсе чәчрәгәндәй булды. Шул ук вакытта тагын катлы-катлы сүгенү сүзләре колакларын сытып яңгырады.

—Моңа хәтле кайда качып йөрдең? Гаврила боярны үтерергә килгән бүтән иптәшләрең бармы?

Нindидер хәвефле сизенүдән Козьманың тәне тартышып алды. Шул минутта ук, ике ягыннан эләктереп, жәлладлар аны юеш эскәмия өстенә күтәреп утырттылар. Егет шөбһәле карашы белән баз эченә төбәлде һәм сискәнеп куйды... Түшәмдәге тимер ыргакка аякларыннан бәйләп баштүбән асылган яп-ябык гәүдәнең сул кул урынында бер карыш озынлыгындагы беләк калдыгы гына тырпаеп күренә иде...

Козьманың борынына ниндидер көйгән ис бәрелде. Карашы белән ул, ялт итеп, базны айкап чыкты. Стенага эреле-ваклы кыскычлар, камчычыбыркылар эленгән. Яндагы бер өстәлдә утлы күмер көйри. Таш идәндә каеш, чылбыр, чыбык өемнәре. «Һе, тәмуг диганнәре, күрәсең, шушы буладыр инде...» Козьма уйлап бетерергә дә өлгермәде, жәлладларның берсе телгә килде.

—Бу «Күлтәпи» белән кайда таныштыгыз? Ул кайсы кенәз холобы? Аннан гайре юлбасарлар кайда?

Козьма бер-берсенә ябышып каткан иреннәрен ачып, нибары өч-дүрт кенә сүз әйтеп кала алды.

—Мин ул бичараның исемен дә белмим...

Һаваны ярып камчы чыжылдаган тавыш ишетелде һәм тәнен кисәк өтеп алган авырту ачысы Козьманы куырып куярга мәжбүр итте.

—Аты Ефим анын, Еф-фим, Еф-фим!—дип, жәлладларның саргылт сакаллысы Козьманың колагына иелеп үкерде.—Башыңны жүләргә салып азапланма, егет. Жирән Демьяннан сер яшереп калырдай бәндә бу дөньяга тумаган да әле. Борыныңа киртлә.

Козьма үзенең бу зинданнан исән-имин котыла алмаячагын, әлбәттә, инде чамалаган иде. «Һичшиксез, бу жәлладлар—Гавриланың тугры этләре»,—дип ашыгып уйланды ул.—»Акланырдай сәбәп табуы кыен, түзәргә генә

кала. Ә бу этләрнең жиде кат тиремне салдырмыйча туктыйсы юк».

Баш очында Жирән Демьянның иләмсез усал тавышы күк күкрәгән сыман яңгырады.

—Бу «Күлтәпи»дән башка иптәшләрең кайда? Гаврила боярны үтерергә сезне кем жибәрде?

Козьма эндәшмәде. Жирән Демьян каерылып, аның яңагына сукты. Сорауларын янә кабатлады. Козьманың жансыз бүкән сыман утыруын күргәч, түземлеге сынды. Ул пәһлеванны әүвәл таш идән өстенә сугып очырды, аннары, аякларыннан каеш белән бәйләп, түшәмдәге ыргакка күтәрттереп асты. Демьян аның өстендәге күлмәк-жиләннәрне икегә аерып төшерде. Ә кансыз жәлладларның пеләш башлысы кулына утлы күмерләр өстенә кибәргә эленгән чыбыркыны алды. Беренче сугулар гына егет тәнен янар кисәү сыман өтеп алды. Аркасындагы рәхимсез чыжылдаулар саны егермедән арткач, Козьма аңын жуйды...

Аннары аны, йөзенә су сибеп, һушына китерделәр. Жирән Демьян бер үк сораулар белән кабат-кабат аның үзәгенә үтте. Козьма исә телен йоткан кешедәй эндәшмәвен белде. Шуннан соң аны янә элмәккә күтәрделәр. Жәлладлар алышынды. Пәһлеван егетне газаплау өч көн, өч төн буе туктаусыз дәвам итте.

Дүртенче тәүлеккә Козьма саташа башлады. Аның иреннәре чәйналүдән һәм кыйналудан канга оешып каткан, сүзләрен аерып алу, аңлау мөмкин түгел иде. Шулай да, аның янына иелеп, жәлладлар тын калды. «Ва-си-ли-са, Василиса»,—дип, Козьма әүвәл гел бер исем белән генә саташты. Жәлладлар, әлбәттә, аның кем булуын аңлый алмый иде. Ләкин беркадәр өметлерәк сүзләр дә озак көттермәде.

—Син Изяслав белән Мстиславны юкка гына аның кочагыннан тартып алдың, кенәз. Василисаның өмете дә, терәге дә шулар гына бит. Мин тәгаен беләм. Шаһит булганым бар. Табанлы-күл буе... Василиса да ул танда ничек матур иде. Аккош кебек. Аккош...

Козьманың саташуында эзлеклелек булмаса да, жәлладларны «кенәз» дигән сәер сүз сагайтты. Шул минутта ук яшь бер жәллад Гаврила артыннан чыгып йөгерде. Бояр яна-пешә килеп житкәндә Козьма саташудан туктамаган иде.

—Мин сиңа да гашыйк кеше, кенәз. Син рус жире, рус халкы, дип көясең. Колың булсам да, аны чамалыйм бит. Мәгәр атаң гына—Юрий кенәз бер дә сөйми сине. Ул килер дә, синең кирмәннәрне жимереп ташлар. Мин бит шуннан куркам. Ә Петрила безгә ярдәм итәр иде. Ул «Аккош»ны сөя. Аккош, Аккош...

Шушы сүзләрне ишетү дә житте, Гаврила өчен һичбер сер калмады.

—Бу холопны элмәктән төшерегез. Рәте булса, ашарына бирсәгез дә ярый,—дип, жәлладларга әмер төсе белән эндәште ул. Ишектән чыгып барышлый әйткән соңгы сүзләре дә ишетелеп калды.—Дар агачы бу хәсисне сагынып күптән еласа да, бәлки, ул башка бер эт тамагына сөяк булып утырырга ярар.

... Кич белән шушы ярымкараңгы базга килеп кергән Петриланы күреп, Козьма шаклар катты. Кемне-кемне, пайтәхетнең беренче боярына әйләнгән Петриланы кара канга баткан жәза базында каршылау Козьма өчен хыялга да кертә алмас бер могжиза иде. Шушы кешене күреп бер сөйләшү өчен ул йөзәрләгән чакрым араны ачлы-туклы үтте. Ахыр чиктә, шул бер очрашу теләге-омтылышы өчен ул мондагы мәсхәрә-жәзалауларга дучар булды. Хыялдагы күрешүгә генә түгел, инде бит исән калачагына да өмете бөтенләй диярлек сүнеп бара иде. Һәм, менә, хыялдагы бояр, әкияттәге фәрештәгә охшап, аның янына үзе килеп житкән.

Петрила шактый мул корсак, киң сакал үстереп жибәрсә дә, Козьма аны шундук танып алды. Элеккеге якын кешесен агач сәке өстендә яткан көенчә каршыларга уңайсызланып, ул урыныннан тормакчы да булды. Ләкин камчы белән телгәләнеп беткән һәм тоташ канга баткан аркасы ул аз гына селкенүгә үк, пычак белән китереп төрткән сыман, шундук куырып алды.

Авыр ыңгырашып һәм иреннәрен тешләп, Козьма янә такта өстенә егылды.

—Кузгалма, кузгалма,—дип эндәште дә, Петрила арган, уйчан кыяфәт белән аның янына килеп утырды. Козьманың күзләренә, йөзенә бик озак вакыт текәлеп торгач, кына, ирен читләре белән елмайгандай итте.

—Ә без сине күптән югалткан идек бит инде. Бер-ике ел чамасы элек кемдер сине Андрей кенәз янында күргәнлеген әйтте, ана ышанмадык. Инде, менә, күрәм, син исәнсең икән.

Козьманың урт сөякләре шыгырдап куйды. Петрила акланган кеше рәвешендә сөйләшүгә күчте.

—Мин синең турыда әле генә, күп булса бер-ике сәгать элек кенә белдем. Миңа ачуланма. Туп-туры ерткыч Гавриланың кулына эләккәнсең бит. Язмыш көлгән синнән. Мәгәр кайгырма. Мин сине хәзер үк үземнең өемә алып китәм. Каршы килмисеңдер бит?

Петрила әллә нинди кыргый тавыш белән көлеп куйды. Ә бу Козьма өчен сау-сәламәт тешкә килеп эләккән тутык тимер сыман тәэсир итте.

—Ай-һай, моннан чыгарга хәлем житәр микән?—диде ул, карлыккан тавыш белән һәм ашыга-кабалана үз гозеренә күчте.—Ә мина бит синең белән бик тә, бик тә сөйләшергә кирәк иде, бояр.

—Өлгерербез,—дигән булып, Петрила гамьсез кыяфәттә генә кул селтәде, шулай да жим ташлады.—Алай ни хакында сөйләшергә ашкынасың?

—Андрей кенәз турында. Аның эшләре, олы максатлары, Юрий кенәз хакында. Гомумән, сүзләрем күп.

Петриланың күз кабаклары кысыла төште.

—Ә син шуның өчен генә дип монда килденмени?

—Фәкать шуның өчен, бояр, шуның өчен.

Петрила, иңбашларын сикертеп, аңламаган кешегә сабышты.

—Син янгын сүндерергә йөгергән кеше кебек ашыгасың, ә мин аңлый алмыйм.

—Менә-менә, нәкъ шулай, Петрила бояр,—дип Козьма ялкынланган каен тузы сыман кабына башлады.—Нәкъ янгын шикелле хәвеф килеп чыгудан куркам да инде мин. Андрей кенәз гаскәр белән ярдәм итмәгәнгә күрә мин Юрий кенәзнең аңа каршы яуга чыгуыннан куркам. Ул бөтен рус халкын бер түбә астына тупламакчы була. Мәгәр аның әле, колын кебек яки тай кебек, юньләп биле ныгымаган чагы. Сындырмаска иде аның билен, комачауламаска иде. Мин шуна дип килдем.

Петрила тәгәрмәчкә таяк кыстырмакчы булды.

—Мөгаен, Андрей кенәз жибәргәндер әле.

—Юк, үзем килдем мин, бояр, үзем, үзем!—дип ачыргаланып кычкырды да, аркасындагы яраларнын ут шикелле талавына карамастан, Козьма терсәкләренә күтәрелде.

Бераздан ул инде барын да бәйнә-бәйнә анлатуга күчте.

## 7

Козьма атна-ун көннән соң гына аякка басты. Ул инде күптән Петрила йортына күчкән һәм аңа күрсәтелгән кадер-хөрмәт шактый мулдан иде.

Беркөнне Петрила аңа үзләренә кунакка олуг кенәз Юрий киләчәген әйтте.

—Ихатадан ерак чыгып йөрмә, өстенә юньлерәк итеп киен. Сый өстәле артына син дә утырырсың.

Петриланың сүзләре Козьманы шаккатырды.

—Мин бит холоп, бояр. Ничек жөрьәт итим?—дип каршы төшкән иде, Петрила җавапны бик тиз тапты.

—Ә син холоп түгел, бәлки аның өлкән углы, шанлы Андрей кенәздән килгән олуг кунак рәвешендә түргә утырачаксың. Шулай булгач, син үзеңне әлләни кимсетмә.

Олуг кенәз төштән соң ук Петрила бояр сараена килеп житте. Яраннары-сакчылары бик күп түгел, ә үзе инде шактый кызмача иде. Козьма олуг кенәзнең кыяфәтен күздән кичерде дә, кызганып ук куйды. Юрий кенәзнең чәче тоташ чаларып беткән, гәүдәсе бөкрәйгән, карашында нур юк, күз төпләре исә шешенгән, зәңгәрләнеп чыккан капчыклардан тора. «Оһ, айныганың юк, ахрысы, кенәз!»—дип нәтиҗә ясады да, Козьма аның тирәсеннән читтәрәк йөрергә карар кылды.

Тиздән Петрила ихатасына ике-өч зур бояр белән бергә явыз Остомыслның абыйсы кансыз Гаврила да килеп керде. Соңгысын күрүгә үк Козьманың күнелен хәвефле уй уттай яндырып узды: «Моның ише сасы козгыннарны үләксә исен сизеп җыела, диләр. Әллә бүген дә берәр төрле бәла көтеләме?»

Өстәл артында ата-ананы белмәс эчеш кузгалды, пешекчеләр йорты белән бояр сарае арасында кыздырылган күркә, дуңгыз, тозлаган каз куелган тәпси күтәреп хезмәтчеләр йөгерешә башлады. Козьманы өстәл янына чакыручы һаман табылмады. Петрила бояр вәгъдәсенә ышанып алданганы, өстәл артына олуг кенәз янәшәсенә ымсынганы өчен Козьмага, хәтта, оят булып китте. Ул үз күләгәсеннән качарга җыенган кеше сыман ихатаның утын әрдәнәләре өелгән почмагына кереп ышыкланды.

Әмма Петрила бояр аны онытмаган, ул үзенчәрәк план корган икән. Инде кичке караңгылык төшеп күз бәйләнгәч, ихатада Козьманы эзләп йөгерешкән хезмәтчеләр тавышы ишетелде:

—Теге үгез кайда? Гаврила зинданыннан котылган теге егет кайда? Аны бояр дәшә.

Петрила бояр Козьманы сараеның алгы бүлмәсенә чыгып каршылады.

—Сиңа да безнең табынга кушылырга вакыт.—Аның тавышы гаять тыныч чыкты.—Мәгәр кунак кеше буш кул белән йөрми. Илбашы булып утырган карт кенәзнең күнелен дә күрә белү кирәк. Угылы Андрей исеменнән өстәлгә менә шушы кувшин белән бергә әнә теге җиләнне алып керерсен. Җиләнне Юрий кенәзнең иннәренә капла, ә кувшиндагы шәрабны үз кулларың белән аңа агызып бир. Тарсынып эш итмә, карт кенәзнең күзләреннән яшь чыгарлык булсын.

Козьманың сул беләгенә әүвәл алтын, көмеш җепләр белән чигелгән бәрхет җилән китереп салдылар, аннары Петрила бояр үзе аның кулларына тар муенлы нәфис кувшин сузды. Хуҗа залга кереп китүгә бер минут та вакыт узмагандыр, дәү, кин ишекләр кабат ачылды һәм аһәнле, вәкарь мәкамле тавыш сарайны яңгыратып игълан итте:

—Владимир-Суздаль җирләренең хуҗасы Андрей кенәз әтрафыннан олуг илбашына баш иеп килгән илче Козьма батыр!

Кыяфәтенә житди, кырыс төсмер бирергә тырышып Козьма алга атлады. Өстәл артында кунаклар шактый гына, ә хәмер чөмерүдән бурсык сыман кызарып чыккан кенәз, әлбәттә инде, иң хөрмәтле җирдә—түргә куелган киң кәнәфи өстендә җәелеп утыра иде.

Козьма иркен залның нәкъ уртасына ук чыгып басты, иДәнгә кадәр иелеп олуг кенәзне сәламләде.

—Тугры улыгыз Андрей кенәз сезгә чиксез сәлам юллый һәм түбәнчелек белән башын ия,—дип, Козьма калтыранган тавыш белән сүз башлаган иде дә, беләгенә салынган затлы җилән нәфис кувшин өстенә кайтарылып төшкәч, тәмам каушап калды. Ул аны янә беләгенә җайлабрак салмакчы булды, җилән тыңламады, һаман саен кувшин өстенә шуышып төшә торды.

—Кенәз янына бар, җиләнне иненә капла,—дип, янда гына Петрила пышылдады.

Тыңлаусыз җиләннән арыну өчен җай чыгуга сөенеп, Козма өстәлләр артына узды. Әүвәл кувшинны өстәл өстенә куйды, аннары җиләнне үзенең бушап калган кулларына алды. Затлы бүләк күргәч, Юрий кенәз дә урыныннан купты, шешенгән кабаклар астына яшеренгән күзләре дымланып ук чыкты. Козьма җиләнне аның иннәренә китереп япкач, Юрий кенәз дулкынлануын да яшереп маташмады.

—Тынлаусыз, башбирмәс булса да, күңелемне күрде бит. Барыбер олылады,—дип сөйләнде дә, Юрий кенәз кул аркасы белән күз төпләрен тиз-тиз сыпырып куйды.

—Ә нигә дип үзе килми соң ул?—диде кенәз, тик бераздан гына.—Инде ничә кабат чакырдым бит үзен. Янап та карадым. Ә ул һаман килми. Нәрсә, анда күлнең күтен күккә асамы әллә?

Козьма ашыга-кабалана тезеп китте:

—Андрей угылың анда яңа кенәзлек төзи. Иске калаларны ныгыта, яңаларын сала. Чит дәүләтләр, чит кенәзләр белән сәүдә эшен җайлый. Яңа дружиналар туплый, яңа чиркәү һәм соборлар күтәрә. Аның исәбе—бөтен урыс җирләрен бер йодрык шикелле итеп бергә туплау. Аның эше бик күп. Зинһар өчен, син комачаулый күрмә аңа, бөек, олуг кенәз?!

—Яңа кенәзлек төзи!—дип, Юрий кенәз каһкаһә катыш мыскыллап кабатлады.—Атасыннан, туганнарыннан йөз чөерә, имеш. Мәгәр сынар бармак белән генә кое казый алыр микән соң ул? Ай-һай! Андрейның минем каршыга тезләнеп киләсе көннәре алда булмагае!

—Әй, дөнья мәшәкәте турында баш ватуны ташласаң иде, олуг кенәз,—дип, янда торган Петрила Козьманың касыгына төртте.—Бокалга шәраб сал.

Ул шулай дип Козьмага ысылдады да, аннары һәркемгә ишетелерлек тавыш белән карт кенәзгә дәште.

—Әнә, шанлы улың сиңа озын гомер теләп, бер мичкә шәраб җибәргә дә онытмаган, кенәз. Шуннан авыз итик.

Козьма шәраб белән мөлдерәмә тулган бокалны Юрий кенәзгә сузды. Тегесенең йөзенә тагын елмаю бәреп чыкты. Ул арада Петрила, яңгыратып, тостны да әйтеп өлгерде.

—Юрий кенәз исәнлеге өчен. Яшәсен, олуг кенәз!

Шау-гөр килеп ирләр кузгалышты, бәллүр, керәч касәләр зеңгелдәде. Ул да түгел, Юрий кенәз шәраб тулы бокалын иреннәренә китерде, голт-голт иттереп эчә үк башлады. Залда көтелмәгән тынлык урнашты. Байтак ирләрнең күзе Юрий кенәз кулындагы бокалга текәлеп тора иде.

Менә, олуг кенәз соңгы тамчы шәрабны да эчеп бетерде. Ул кул аркасы белән сакал-мыекларын сыпырып алды, кикереп куйды. Ул инде кабат кәнәфиенә утырырга җыенгандай итте, алга иелә төште. Ләкин нәкъ шул мизгелдә аркасына кайнар пычак китереп кададылар диярсең, кенәз кисәк тураеп басты. Аның авызы зур булып ачылган, күзләре киң кабаклар арасыннан акаеп чыккан иде. Нидер кабып йотарга теләгән кеше сыман ул кат-кат авызын ачты. Ямьсез булып тырпайган бармаклары белән әүвәл сакалына, аннан күкрәгенә ябышты. Берникадәр вакыт ул һавадан үзе тотынырдай терәк эзләде дә, сонныннан өстәлләр өстенә гөрселдәп барып төште.

—Кенәзне агуладылар! Кенәз үлде! Хыянәт!—дип, иң беренче булып, Гаврила чәрелдәде. Мәхшәрдәге кебек үкереп, аңа башкалар кушылды.

—Андрей кенәз агуланган шәраб җибәргән!

—Хыянәт! Хыянәт!

Козьма берни аңышмыйча сабый бала сыман сүзсез тора иде. Менә, ул кенәз яраннарының урыннарыннан сикереп торуларын күрде. Арадан берсе, кылычын кыныннан суырып, Козьма пәһлеванга таба якынайды. Артта кемдер: «Аллага шөкер, Давидныкыларга да бәйрәм килде, безне онытмаслар»,—дип зәһәр пышылдады. Козьма тавыш иясен шәйләргә өлгермәде.

—Хыянәт! Хыянәт!—дип ярсып кычкырды да, кемдер авыр күсәк белән аның баш түбәсенә орды. Гаврила зинданындагы җәвалаулардан соң ныклап савыгып та өлгермәгән пәһлеван янә тирән упкын эченә очты.

*Дәвамы киләсе санда.*

# ШИГЪРИЯТ



## Әхсән Баян

### ГОМЕРЛӘРДӘН—МОҢ ҺӘМ СУЗ КАЛА...

○

Кайчан гына әле кергән идем
Дөньяның мин ачып капкасын.
Йөгереп кенә кердем, йөгереп кенә
Уздым гүя гомерем бакчасын.

Икенче як капкасына аның
Кай арада килеп җителгән!
Нәрсә чәчтем,ниләр утырттым дип,
Карап торам бакчам читеннән.

Бакча читендәге имәннәрем
Ят чорларда яфрак ярырлар.
Афәтләрсез яусын анда карлар,
Давылларсыз яусын яңгырлар.

Имәннәрем, җилләр кебек узган
Гомерләрдән моң һәм суз кала:
Уйлыларга, зинһар, җиткерегез
Моңнарымны, сүзсез булса да.

○

Җилләр исте, әллә исмәделәр,
Гөлләр үсте, әллә үсмәде.
Җилләр, еллар, яфрак төсле очырып,
Алып китте иң ак хисләрне.

Яшәлдеме, юкмы? Теләкләрнең
Югалмыйча калды кайсысы?
Керфегеңә кунган сорауларның
Тамды бугай соңгы тамчысы.

Гомер узу белән безнең сөю
Онытылыр диеп борчылма.
Моңнарымда мәхәббәтем минем
Яшәп калыр үземнән соң да.

⭘

Мин бәхетле була алам...
Хыялымда, төшемдә.
Булам Җирнең бар төшендә
Бер үк вакыт эчендә.

Йөзә алам диңгезләрдә,
Дельфиннар белән уйнап.
Кошлар белән оча алам,
Тау тезмәләре буйлап.

Сөйгән ярым, упкыннарга
Күз дә салмыйча гына,
Оча бергә, талпынмыйча
Ят ярлар кочагына.

Җирдә, күктә—аның белән—
Мәңгелек буйлап барам.
Бар галәмнәр ишетерлек
Шатлана, көлә алам.

Ак болытка чалкан ятып,
Узам кыйтгалар аша.
«Әй, безгә төш, кунак бул!»—дип,
Илләр кыла тамаша.

Килә фатиха Ходайдан
Җаным сөйгән эшемдә.
Бар теләккә җавап алам...
Уйларымда, төшемдә.

«Ташла,—diləр,—хыялланма,
Куй, төшләргә ышанма!»
Алардан да аерылсак,
Җанга безнең ни кала?!

## Займище урманында

Кая китте синең аю йөргән
Яланлы һәм куе чакларың!
Мәгърур поши кайда? Эзләсәм дә
Аларны мин инде тапмамын.

Тынлык тапмам, сокланалмам күреп
Кызыл алкаларын кураның.
Син урман да түгел һәм бакча да,
Гүя—төнге шәһәр урамы.

Кара урман булган чакларыңнан
Син карарак ләкин, шомлырак.
«Без әле бар!»—диеп коңгылдаган
Козгыннардан күпләр козгынрак.

Әйе, куркасы юк аюлардан,
Һич куркыныч түгел бүреләр.
Алар кача хәзер куркып бездән,
Элеккедәй явыз түгелләр.

Җанварлыкны, ерткычлыкны алар
Кешеләргә, ахры, бирделәр.
Сукбайлар бар—җан һәм башларына
Урын табалмыйча йөриләр.

Алар инде дус һәм туган түгел,
Очрашырга туры килгәндә.
Ни булды соң, әй урманым сиңа,
Ниләр генә булды, и бәндә?!

## Илгә кайттым

Илгә кайттым. Сабый чакның
Урманнарын урадым.
«Туганнарым, сөйгәннәрем,
Сез кайда?»—дип сорадым.

Мин аларга: «Саумысыз!»—дип,
Кулларым сузалмадым.
Битләремне учка кысып,
Сызландым, түзалмадым.

Өянкеләр әйтте шаулап:
«Чишмәләрең кипмәгән!
Бу дөньяга кемнәр генә
Килмәгән дә китмәгән!»

Малай чагым эзләреннән
Агымсулар буйладым.
Агымсулар буйлаганда,
Яшьсез генә еладым..

o

«Безнең инде җыр җырланган!»—диде
Кордаш дустым, гүя сөенеп...
Азагында без җырлаган җырның
Булды «Яшәү» дигән сүз элек.

Җырланганмы безнең җырларыбыз,
Тукталганмы әллә беразга?
Көйләр бүтән хәзер, тик барыбер
Калды «Яшәү!» дигән сүз анда.

## Җилнең иләс чагы

Җилнең кай якка исәргә
Белмәгән иләс чагы.
Яфракларны кузгатырга
Хәленнән килмәс чагы.

Улаулары, дулаулары
Уена кермәс чагы.
Көн үзәгеннән кояшның
Узасы килмәс чагы.

Чү! Еракта нинди күкрәү
Каралтты көлчә тауны?
... Ял ит, җаным, алда безгә
Тәңре ни бирмәс тагы.

## Хыянәт

Кем татымый калган Иблиснең
Алма төсендәге җимешен?
Син дә күмдең аның бер төшен—
Зәһәрлеге калган өлешен.

Уйдан табут ясап, тирәнгә
Күмдең, кал, дип, узган көннәрдә.
Белмәгәнсең әмма матдәсен—
Аның радиоактив мәгънәсен.

Тамактагы ачы төенне
Әллә йоталмаган идеңме?
Йоткан идең зәһәр җимешне,
Үкенүләр тулы рәнҗешне.

Ә ул калган тыныч, тын җирдә—
Аңның аскы, уйсыз төбендә.
Күтәрелә шуннан тын ялкын...
Хәзер ул соң ничек туктасын?

Вакытында тыя белмәгәч,
Дәһшәткә чик куя белмәгәч,
Агуын ул өрә экерен,
Әкерен генә кыла мәкерен.

Җан-тәнеңне шулай җимерерме,
Агулармы бөтен гомереңне?
Сиздермичә саркып тын җирдән—
Аңның уйдан аргы төбеннән,

Күтәрелә утсыз кыямәт—
Хыянәт.

**o**

Үз теләгем белән тусам әгәр,
Туар идем кош булып.
Тумас идем киңне кысан иткән
Ишлеләргә куш булып.

Әйе, сайлар идем илне-җирне,
Белешеп кавемнәрне.
Ә бу илдә кем санлады безне,
Кем белде кадерләрне?

Туар идем йолдызлардан ары
Хыялдагы үлчәмдә.
Теләр идем шунда, йә шәфкатьле
Бүтән чорга күчәргә.

Киләсеңме дөньяга дип бездән
Сорамадылар рөхсәт.
Рәнҗемәсләр, шаять, киткәндә дә
Рөхсәтсез генә китсәк.

○

Аккошларым, сезгә иярим дип,
Мин кул сузып күккә үрелгәч,
Ташладыгыз миңа алсу каурый...
Ә ул чакта миңа—җиде яшь.

Бөтерелеп күктә, алсу каурый
Күксел төскә керде кай ара.
Алның-күкнең кушылып җемелдәве
Хәтеремдә хәзер яңара.

Йөгереп кенә барып алдым кулга
Сез калдырган сихри каурыйны.
«Ни әйтергә теләдегез?»—диеп,
Шул чагыма борылып карыймын.

Беләм, әйткәнсездер: «Язмышыңны
Каурый белән үзең яз!»—диеп.
Каурыемны вакыт дулкыннары—
Күптән инде—китте агызып.

Язлар саен көтәм кайтырсыз дип,
Көтә белгәч, өмет өзелмәс.
Эзләп йөрим алсу каурыемны...
Миңа тагын гүя җиде яшь.

○

Сау бул инде, Егерменче гасыр,
Коллар өчен тиран булган чор.
«Азатлык!» дип теле ачылса да,
Халыкларга зиндан булган чор.
«Якты киләчәккә» җитә язгач,
Ил барышын артка борган чор.
Сул кул белән төзеп, уңы белән
Төзелгәнне җимерә торган чор.
Ил байлыгын талап туялмагач,
Җир буйлата хәер җыйган чор.
Хуш!

Мәйдан ачык, әйдә, Егерме бер!
Мәйдан ачык, Яңа Меңьеллык!
Җирдә, суда, күктә һәм галәмдә
Эзләрегез калыр уелып.
Эзләрегез, узган юлларыгыз
Булыр изге, якты, данлымы?
Әүвәлгечә булыр икейөзле,
Әүвәлгечә булыр канлымы?

Тырышырсыз бәлки китерергә
Башка алла тагын, башка дин?
Булырсызмы иптәш һәм дус безгә,
Булырсызмы әллә господин?
Шундый булса әгәр «миссиягез»,
Дөньяны сез кызык итегез—
Җиргә төшми, тукталмыйча гына,
Коллар болгап узып китегез.

... Яманлыкка ләкин ышанмыйбыз,
Изгелектә ләкин уебыз нык.
Хак азатлык китер, Егерме бер!
Җимерүләрне оныт, Меңьеллык!

*1998—1999*

# ДРАМАТУРГИЯ



Фәнис
Яруллин

## БЕР КҮРЕШҮ — ҮЗЕ БЕР ГОМЕР

КОМЕДИЯ

**Катнашалар:**

Әхмәт.
Мәрьям — аның хатыны.
Ризван — Әхмәтләрнең дусты.
Халидә — Ризванның хатыны.

### Беренче пәрдә

**Әхмәтләр фатиры. Фатир бераз зәвыксызрак җиһазланган. Гаиләнең бик үк ярлы түгеллеге күренә. Пәрдә ачылганда Мәрьям телевизор карап утыра.**

Мәрьям *(экраннан күзен ала алмыйча).* Аһ, чукынмышлар. Тәки үзләренекен иттеләр. Ну бу чит илләрдә яшәп тә карыйлар инде. Өйләрен генә кара син аларның: баскыч та баскыч. Бүлмә саен телефон. Кеше саен машина. Апельсин суы эчеп кенә яшиләр. Ашарга пешерәсе юк. Ә безнең ирләргә күсәге белән ит тоттыр. Ындыр табагы чаклы таба белән бәлешен пешер. Дуңгыз булганчы аракы чөмерт. Алай да рәхмәт ишетмисең. Әй, нигә сөйләнгән булам соң: бәхетле кеше безнең илдә туамыни ул? Бәхетлеләр әнә тегендә *(экранга ымлап)* — апельсин суы эчеп яши торган илләрдә генә туадыр. Аларның дөньяда бер кайгылары юк. Сөяркәсе белән очрашырга җай тапсалар — түбәләре күккә тия. *(Күрсенеп куя).* Их! Булмады шундый илдә туып!

**Әхмәт кайтып керә. Ул Мәрьямнең соңгы сүзләрен ишетеп кала.**

Әхмәт. Нәрсә, карчык, һаман шул чит ил киноларын карап, женләнеп утырасыңмы?

Мәрьям. Андый тормышны кинолардан да карамагач, тагын кайда күрәсең?

Әхмәт. Әллә үзеңә бер путевка

алып биримме, карчык? Кинолардагы тормышны үз күзләрең белән күрерсең. Кыш көне Канар утрауларына барып, кызынып кайтырсың. Чит илнең загары кыйммәтле вә зиннәтле бит. Бөтен кеше «аһ» итәр.

Мәрьям. Авызыңны ерма. Мин бит әле синнән чит илгә барырга путевка сорамыйм. Ир булсаң тизрәк коттеджыңны салып бетер. Менә шуннан соң чит илгә барырга уйлый башларбыз.

Әхмәт. Бетер, бетер. Янадан ун елдан да озак бармас. Коттедж әзер булыр.

Мәрьям. Нервыга тимә әле ичмасам. Янадан ун елдан коттеджларың миңа пычагыма кирәкме? Аннары инде «тегендә» китәргә генә кала.

Әхмәт. Алай дияргә ашыкма, карчык. Ун елдан соң тутырган тавык кебек, син тагын да матураячаксың. Миңа килгәч, көннән-көн матурланасың бит.

Мәрьям. Әй, сөйләнгән буласың инде.

Әхмәт. Ә нигә, чын бит. Килмәгән жирең юк. Жырдагыча әйтсәк:

> Ак алъяпкычлар бәйләсәң,
> кысып тора билләрең.
> Кашың кара, буең зифа.
> Юк килмәгән жирләрең

*(Бераз пауза)*. Кая, карчык, ашарга бирәр нәрсәң бармы?

Мәрьям. Безнең ирләрнең шул булыр инде. Бөтен кайгылары тамак. Әнә анда культурный ирләр кайтып керү белән хатыннарын кочаклап үбәләр. Чыгып китә башласалар да шул хәл.

Әхмәт. Чыгып киткәндә мин дә сине бер үбәрмен әле.

Мәрьям. Кайчан булыр икән ул?

Әхмәт. Бөтенләйгә чыгып киткәндә.

Мәрьям. Некультурный утын түмәре!

Әхмәт. Утын түмәренең культурныйлары да буламыни?

Мәрьям. Телевизор күбрәк карарга кирәк!

Әхмәт. Телевизор карап утырырга вакытым юк минем. Кая, ашарга китер.

Мәрьям. Апельсин суы китеримме соң?

Әхмәт. Нәрсә, нәрсә? Чит ил киноларын карап, миең сыекландымы әллә? Бирермен мин сиңа апельсин суы. Тустаганың белән башыңа капларммын.

Мәрьям. Һәй, надан. Апельсин суын тустаган белән эчәләрмени? Аны бәллүр стаканнарда вак-вак йотып кына эчәләр.

Әхмәт. Уф, шушы телевизорны балконнан томырмый булмый инде.

Мәрьям. Әйе шул, бу телевизорны күптән томырырга вакыт. Юньле кешеләр 72 сантиметрлы япон телевизорын диванга кырын ятып кына карыйлар. Кабызыр өчен дә, сүндерер өчен дә торып йөрисе юк.

Әхмәт. Уф! Шушы өйгә кайтып керәсе килми, валлаһи. «Юньле кешеләр иномаркаларда йөри, юньле кешеләр япон телевизоры карый, юньле кешеләр хатынын иртә дә, кич тә үбә». Юньле кешеләр... Юньле кешеләр... *(Әрле-бирле йөренә.)* Юньле кешеләр бүген бәйрәм итә.

Мәрьям. Нинди бәйрәм?

Әхмәт. Чуртым белгәнме нинди бәйрәм икәнен. Әмма дә ләкин бәйрәм инде.

Мәрьям. Хәзер һәр атнаның өч көне бәйрәм. Хөкүмәт өйрәнеп житте халыкны юләрләндереп табыш алырга.

Әхмәт. Нинди табыш?

Мәрьям. Соң үзеңнән генә чыгып кара. Бәйрәм саен егылганчы эчәсез. Хөкүмәтнең аракысы сатыла. Шул табыш түгелмени?

Әхмәт. Искә төшерүең әйбәт булды, чыгып керим әле кибеткә.

Мәрьям. Бәлки бүген эчми торган бәйрәмдер?!

Әхмәт. Алай димә, карчык. Син дә эчмәсәң, мин дә эчмәсәм, хөкүмәткә акча каян килер? Пенсионерларга пенсия түләргә, эшсезләргә пособие бирергә, картлар йортларын һәм больницаларны тотарга барсына акча кирәк. Тәк что, карчык, эчүчеләр бик саваплы эш эшли бу дөньяда.

Мәрьям. Әнә машинаңны рәтлә. Кайчаннан бирле гаражда череп ята. Савaплы эш шул булыр.

Әхмәт. Юк, карчык, бүген эшләргә ярамый. Бүген бәйрәм. *(Бераз уйланып торганнан соң.)* Ә беләсеңме, минем башка бер уй килде әле.

Мәрьям. Нинди уй тагын?

Әхмәт. Әйдә ресторанга барабыз. Ашарга пешерәсең дә булмас. Рәхәтләнеп гүләйт итеп, бәйрәм ясап кайтырбыз.

Мәрьям. Әстәгыфирулла! Әллә башыңа чүбек тутырдыларммы? Анда соңгы ыштаныңны салып калдырыргамы?

Әхмәт. Элек бик ярата идең бит рестораннарга йөрергә.

Мәрьям. Кайчан?

Әхмәт. Өйләнешкәнче.

Мәрьям. Ул чакта бит акчаны син түли идең.

Әхмәт. Хәзер дә мин түләрмен.

Мәрьям. Хәзер синең акчан— минем акчам инде ул.

Әхмәт. Алайса театрга яки концертка барыйк.

Мәрьям. Театр, концерт карыйсың килсә, әнә, күршеләргә генә кереп чык. Көн саен бер сугышалар да, аннары татулашып, җырлашып эчәләр.

Әхмәт. Күңелле яшиләр икән.

Мәрьям. Әйе, күңелле. Театрмиатр дип фәлән меңнәрен әрәм итмиләр. Бер көн гәзиттән укыган идем әле. Алла Пугачеваның ире килә дигәннәр, билет бәяләре йөз меңнән дүрт йөз меңгә кадәр, ди.

Әхмәт. Алла Пугачеваның ирен күрергә дүрт йөз мең түлиләр диген. Шәп, шәп. Әллә мин дә берәр афиша язып куйыйм микән?

Мәрьям. Нәрсә дип?

Әхмәт. Мәрьямбикә Котлыярованың ире Әхмәт Котлыяров фәлән-фәлән мәдәният сарайларында тамашалар күрсәтә. Тамашалар карарга рәхим итегез дип.

Мәрьям. И, хәчтерүш. Нинди тамаша? Нәрсә күрсәтмәкче буласың?

Әхмәт. Ә нигә? Минем күрсәтерлек нәрсәләрем юк дисеңме әллә?

Мәрьям. Нәрсәң бар соң синең?

Әхмәт *(күкрәгенә сугып)*. Минем кыяфәтем шәп!

Мәрьям. Әй, әллә берәр җитди сүз сөйлисеңме дисәм, юк белән башны катырасың икән.

Әхмәт. Нишләп юк булсын? Әгәр телевизордагы кызлар кебек сәхнәгә шәпшәрә чыгып бассаммы? Дүрт йөз меңне генә түгел, миллионны түләп керәчәкләр. Минем кемлекне син әле белеп бетермисең. Белсәң көн саен миллион түләр идең.

Мәрьям. Һәр көн ике миллион алып кайтсаң берсен түләрмен.

Әхмәт. Ярар. Күп сүз—чүп сүз ди. Җыен, берәр концертка барып кайтыйк. Үзебезнең татар артистларын күреп, җыр тыңлап кайтыйк.

Мәрьям. Әйттең сүз! Иске ыштан кебек туйдырып бетергән артистларга акча әрәм итәргә башыма тай типмәгән әле.

Әхмәт *(хисләнеп)*. Бүген минем нигәдер күңел җилкенә. Каядыр барасы, күңел ачасы килә. Һич югы бер яртыны салып, диванда бот күтәреп җырлап ятасы килә.

Мәрьям. Ирләрнең теле «ярты» дип ачыладыр инде.

Әхмәт. Бөтенен сорамаганга рәхмәт әйт.

Мәрьям. Бөтенен сорасаң—ансы әллә кайда түгел, ансын табарга була.

Әхмәт *(сәерсенеп Мәрьямгә карый)*. Чит ил кинолары карый-карый бөтенләй исәрләндеме әллә?

Мәрьям. Исәрләнерсең дә. Кочаклау юк, үбү юк.

Әхмәт. Синдә кочаклашу, үбешү кайгысы. Әнә үзең әйтеп торасың бит: машинаны рәтлисе, коттеджны салып бетерәсе бар. Бер кулым белән сине кочаклап, икенче кулым белән машина төзәтә алмыйм бит инде мин.

Мәрьям. Юньле ирләр кулларын кесәгә генә тыгып, эшне кешедән эшләтәләр.

Әхмәт. Юньле хатыннар ирләре кайтуга ашарга пешереп куялар. Бот күтәреп диванда телевизор карап ятмыйлар.

Мәрьям. Чиләгенә күрә капкачы.

Әхмәт. Уф! Туйдым, гарык булдым шушы сүзләрдән. Ичмасам берәрсе кунакка да чакырмый.

**Әхмәт шул сүзләрне әйтеп бетерүгә телефон шалтырый. Әхмәт трубканы ала.**

Әхмәт. Алло, тыңлыйм. Ә-ә, Ризван дус, синмени әле бу? Ни хәлләрегез бар?

**Монда сәхнә икегә бүленгән. Бер ягында Әхмәтләр фатиры, икенче ягында Ризваннарныкы. Телефон белән сөйләшкәндә һәр икесе күренеп, сөйләшкәннәре тамашачыга ишетелеп тора.**

Ризван. Аллага шөкер, әйбәт кенә яшәп ятабаз.

Әхмәт. Халидә нишләп йөри? Бала-чагаларыгыз?

Ризван. Барыбыз да исән-саулар. Мәрьямнең хәлләре ничек?

Әхмәт *(Мәрьямгә карап)*. Мәрьямнең хәлләре шәп. Менә әле бәйрәмгә нәрсә әзерлим икән дип кырыйда бөтерелеп йөри. Шампанский ачыйм микән, әллә коньяк микән ди.

Ризван. Карале, Әхмәт дус, сез анда әллә нәрсәләр әзерләнеп маташмагыз. Безгә килегез, бер рәхәтләнеп гөрләшеп утырырбыз.

Әхмәт. Була ул, Ризван дус. Рәхәтләнеп гөрләшербез. Кунакка дигәндә без әзер, һәрвакыт әзер. *(Мәрьямгә дәшә.)* Карчык, бер мәшәкатьтән котылдың.

Мәрьям. Нинди мәшәкатьтән?

Әхмәт. Аш пешерүдән. Әнә Риз-

ваннар кунакка чакыра. Әйдә, жыен. Бер жилләнеп кайтыйк. *(Дәртләнеп.)*

Без кунакка барабыз, әй хатын!
Утырырбыз жырлашып, әй хатын.
Рәхәт бит ул кешеләрнең сые белән
Утыруы бер-беренне сыйлашып, әй хатын.

Әй кунак, вәй кунак,
Кунакта уйна да көл,
Өйдә генә бул тыйнак.

*(Хатынын бөтереп ала.)* Әйдә әзерлән. Нишләп оеп утырасың?

Мәрьям. Син нәрсә, исәрләндеңме әллә? Кем инде бәйрәмдә кунакка бара?

Әхмәт. Кунакка бәйрәмдә баралар инде ул.

Мәрьям. Бәйрәмдә кунакка буш кул белән барып булмый. Шуны онытма.

Әхмәт. Әлбәттә. Ничек инде жан дусларга буш кул белән барасың. Юлда бер яртыны кыстырырбыз.

Мәрьям. Дөньяда сез генә түгел, хатыннар да бар. Шулай булгач, Халидәгә дә бирәр нәрсә кирәк булачак.

Әхмәт. Кирәк булгач—алырсың. Кучтәначлек, бүләклек кенә рәт бар бит әле.

Мәрьям. Сәгате килеп житкәч кенә бүләген каян табасың аның?

Әхмәт. Сандык төбеннә актарсаң әллә ниләр чыгар әле. Һич тә булмаса үзеннең туган көненә Гөлшатлар бүләк иткән яулыкны алып барырсың. Барыбер ошатмадың. Кара бизәкле диден.

Мәрьям. Алып бармый гына торыйм әле. Ул кытайский ефәктән.

Әхмәт. Соң алайса кибеттән бирәр нәрсә алырбыз. Тортмы, конфетмы?

Мәрьям. Артык акчаң булса алырсың, миндә артык акча юк. Тортларның, конфетларның ничә мең сум торганын беләсенме соң син?

Әхмәт. Белмим. Алып караганым юк.

Мәрьям. Белмисең шул, белсәң әйтмәс идең. Кунакка барасы килгән аның! Ә аларның балалары?! Бусагаларын атлауга «живачка апкилденме» дип йөгерешеп киләчәкләр.

Әхмәт. Килсәләр бирерсең, өч сагызың жәл түгелдер бит.

Мәрьям. Акчаны капчыклап апкайтасың кебек тоеладыр әле сиңа. Ризваннарга барыр өчен юлга гына күпме кирәк. Жәһәннәм тишегендә яшиләр. Икеөч транспорт белән барырга. Трамвай-троллейбусларга хәзер барганда бер бәя булса, кайтканда икенче бәя. Ике кешегә күпмегә төшә? Башың булса чутлап кара. Хәзерге заманда юләрләр генә кунак-кунак йөрешә.

Әхмәт. Байлык—бер айлык. Дуслык—мәңгелек. Саранланма! Әзерләнә башла. Мин дә өс-башларымны алыштырам. Әйдә! (Чыгып китәләр.)

**Сәхнәдә Ризваннар фатиры алгы планга чыга.**

Ризван. Әнкәсе. Әхмәтләрне чакырып әйбәт иттек әле, әйеме?

Халидә. Әйе. Яшь чакларыгызны исегезгә төшерерсез. Сез дуслар гына түгел, авылдашлар да бит. Ә авылдашларның сөйләшеп сүзе бетми.

Ризван. Шулай, Халидәкәй. Авыл гел сагындыра. Юкка гына бер шагыйрь болай дип язмагандыр инде.

Читтә йөргән чакта, сагындырып,
Керер өчен төнлә төшенә,
Зәңгәр таңлы, биек аяз күкле
Туган ягы кирәк кешегә.

Халидә *(аны дәвам итә)*.

Зур уңышлар яулап, заманалар
Матур бәя бирсә эшенә,—
Шатлыкларын ишеттерер өчен
Туган ягы кирәк кешегә.

Ризван. Безнең алай күкрәк кагар уңышлар юк инде югын.

Халидә. Шигырьнең бит болай дигән өлеше дә бар *(дәвам итә)*.

Йөри-йөри күңеле тупасланса,
Тузан кунса яшьлек хисенә,—
Бер сафланып килер өчен тагын
Туган ягы кирәк кешегә.

Ризван.

Яшәр өчен бетмәс көч алырга,
Олысына һәм дә кечегә,—
Мәхәббәтле, ямьле, мәрхәмәтле
Туган ягы кирәк кешегә.

Их, Халидәкәй, гармун тартсам, шигырь укысам күңел жилкенә башлый минем. Менә тагын йөрәк кузгалды инде. *(Гармунын алып, авыл көен уйнап жибәрә.)*

Халидә. Картым, мин бәлешемә күз салып кына керим әле. *(Чыгып китә. Ризван күреккә башын салып уйный. Үзе үк жырлый да.)*

Гармун алдым кулыма,
Чыктым авыл юлына.
Кызлар белән таныштыр дип
Әйттем мин гармунына.
Гармун тартсан жыр чыга.

Үзәк өзгеч моң чыга.
Яшь йөрәкнең мәхәббәттән
Янып ялкыны чыга.

**Халидә кереп аны тыңлап тора.**

Халидә. Шул гармунның таныштырды да инде безне.

Ризван. Әйе, әнкәсе. Бу минем бик бәхетле гармуным. Мин аны әллә нинди баяннарга да алыштырмыйм. Хәтерендәме, әнкәсе, мин яшьләрне дәртле көйгә биетеп ятканда, син килдең дә: «Берәр салмаграк бию көе уйнагыз әле»—дидең. Мин гармунымны салмак көйгә күчердем. Син уртага чыгып биеп киттең. Минем карашым үзеннән-үзе сиңа тартылды. Син ул көнне күл өстендә йөзеп йөргән аккош кебек идең.

Халидә. И-и, син бигрәк инде, атасы. Аккош түгел, шөкәтсез үрдәк бәпкәсе диген.

Ризван. Юк, Халидәкәй. Син нәкъ аккошның үзе идең. Өстеңдәге ап-ак күлмәгең, аккош муены кебек сыгылмалы кулларың! Хәтта кызыл туфлиләрең дә салкын суда кызарган аккош тәпиләре булып күренде миңа.

Халидә. Ак күлмәк белән кияргә ак туфлиләрем булмагач, сукрана-сукрана гына кигән идем мин ул туфлиләрне.

Ризван. Әгәр туфлиең дә ак булса, бәлки ул кадәр игътибар да итмәгән булыр идем. Кайчагында кешене әсәрләндерер өчен ниндидер бер юк кына нәрсә җитә.

Халидә *(шаярып).* Ә-ә, син минем туфлиләремә генә гашыйк булдыңмыни әле?

Ризван *(ул да шаяра).* Әйе, башта аягыңдагы туфлиләреңә гашыйк булдым да аннары гыйшкым өскәрәк менә башлады. Аяктан башка кадәр. Их, Халидәкәй *(кочаклый).* Яратам бит мин сине.

Халидә. Кит инде, балалар күрсә.

Ризван. Күрсеннәр. Әнкәләрен ничек яратуымны күрсәтүдән нигә оялырга?! *(Тагын шигырьгә күчә.)*

Күптән инде әйтешкән юк
«Яратам» дигән сүзне.
Бу сүзнең матурлыгын без
Онытып бетермибезме?
Ә бит әле кайчан гына
Бу татлы сүзнең көче
Бәхеттән елата иде,
Ябыштырта иде кичне.

Халидә. Әйе.

Бу сүзнең канатларында
Күкләргә менә идек.
Еш әйтсәк тә моның бик нык
Кадерен белә идек.

Икесе бергә.

Онытмыйк әле, онытмыйк
Бу матур сүз барлыгын.
Аннан башка дөньяларның
Ярлылыгын, тарлыгын.
Онытмыйк!

Ризван *(хискә бирелеп).* Их, Халидәкәй, һаман беренче күргәндәгедәй яратам үзеңне. Хәер, беренче күргәндәгедәй генә түгел, мең тапкыр артыграк яратам.

Халидә. Кит инде, атасы, оялтасың. *(Балалар бүлмәсенә күз салып.)* Әйтергә оят булса да әйтим: мин дә сине элеккедән ныграк яратам. Балалар өйдә югында альбомга беренче очрашканнан соң син язып биргән шигырьне укыйм. Ул бер догага әйләнде инде минем.

Ризван. Йәле, йәле, нинди шигырь икән ул?

Халидә *(яттан).*

Йөзләреңдә яшьлек яме,
Күзкәйләрең сөрмәле.
Шул күзләргә яшеренгән
Мәхәббәтнең серләре.

Ризван *(дәвам итә).*

Күзләреңдәге серләрне
Гел укыр, армас идем.
Күңелеңдә ниләр барын
Аңламый калмас идем.

**Болар шигырь укыганда музыка яңгырый. Бу танго яки вальс булуы мөмкин. Ризван белән Халидә музыкага әйләнеп шигырьне дәвам итәләр.**

Синең күздән минем күзгә
Күпме нур күчәр иде.
Ике күңел арасында
Чәчәкләр үсәр иде.
Шул чәчәкләр арасыннан
Бер сукмак салыр идек.
Серле мәхәббәт илендә
Мәңгегә калыр идек.

**Соңгы юллар ике тапкыр кабатлана. Шуннан соң музыка туктала.**

Халидә. И-и, атасы. Минем бәлешем көеп ятмый микән. Карыйм әле *(чыгып китә).*

Ризван. Мин дә кунаклар килүгә кайбер нәрсәләрне әзерләп торыйм.

Тән сусавын басар өчен әйрән кирәк,
Җан сусавын басар өчен бәйрәм кирәк.

Әллә кайчан безне дөнья басар иде,
Ярый әле бәйрәмнәр бар сирәк-мирәк.

**Чыгып китә.**

**Игътибар Әхмәтләр фатирына юнәлтелә. Әхмәт белән Мәрьям кызыша-кызыша эчкәргә яктан чыгып киләләр.**

Әхмәт. Мин бит Ризваннарга хәзер барабыз дип әйттем. Ә син йокы бүлмәсенә чумгансың.

Мәрьям. Әйтсәң, хәзер бармыйбыз дип әйтерсең. Әнә телефон тот та шалтырат.

Әхмәт. Юк инде, үзең шалтырат. Кунакка барсаң расхут күп чыга диген. Трамвай-троллейбуска токтан акчаларны үзегез түләсәгез, бала-чагаларыгыз жевачка сорамаса, киткәндә өч көн ашарлык күчтәнәч биреп жибәрсәгез сезгә барабыз дип әйтергә дә онытма.

Мәрьям. Әйтермен дә. Бәйрәм саен кунакка йөрергә акчам кычытып тормый әле.

Әхмәт. Алайса үзем генә барам.

Мәрьям. Алма кебек хатыныңны бәйрәм көнне ялгыз калдырып китәр идеңме әллә? Һы, кара син аны! Үзе генә бара ул!

Әхмәт. Үзем генә барсам, расхуты ким булыр. Шуннан куркасың бит.

Мәрьям. Куркам шул. Коттеджның һаман түбәсе ябылмаган. Машинаны төзәтәсе бар. Гараж подвалына су керә—аны нидер эшләтергә кирәк. Аларның барсы да бит акча сорый. Ә Ризваннарга рәхәт аларга. Иске гармуның күтәрәләр дә теләсә кая чыгып чабалар.

Әхмәт *(көрсенеп)*. Әйе, иске гармунның түбәсен ябасы юк. Аның подвалына су да керми. Дөньяның асты-өскә килсә дә алар кайгырмыйлар. Рәхәт!

Мәрьям. Хәерчегә гомер буе рәхәт. Аның табар әйбере дә, югалтыр әйбере дә юк.

Әхмәт. Их, бар иде бит Ризван гармун тартып, мин жырлап авыл урамын жиде кат ураган чаклар. Ризванга әнисе соңгы сыерын сатып гармун алып бирде. Ә без кулга әз генә акча керсә йортны матурладык, ихатаны ныгыттык. Ризваннар бер такта кисәге тапсалар, капка төбенә эскәмия ясап куйдылар. Безнең кулга такта эләксә, тишек-тошыкны ямарга ярар дип сөенә-сөенә чормага яшердек.

Мәрьям. Әллә шул хәерчеләрдән көнләшәсең инде.

Әхмәт. Белмим. Бәлки көнләшәмдер. Тынычлык юк бездә. Берәр нәрсәбез булмаса, шуны булдырыр өчен ах-ух киләбез. Тапсак югалтмасак ярар иде дип борчылабыз. Гел ыгы-зыгы, гел мәшәкать.

Мәрьям. Дөнья шул мәшәкатьләре белән күңелле дә инде ул. Менә тиздән өебез эшләнеп бетәр, яна машина алып жибәрербез. Кая теләсәк—шунда чабарбыз. Курортына, чуртына. Ә Ризваннарның Казан белән Бөгелмәдән башка шәһәр күргәннәре дә юк бит аларның, хәерчеләрнең.

Әхмәт. Әйе, өебез төзелеп бетәр. Машинаның да яңасын алырбыз. Тик кем өчен тырышабыз соң без. Бала-чагаларыбыз да юк бит.

Мәрьям. Булмаса—булыр. Коттеджның ачкычын апкайткан көнне баланы планлаштыра башлыйбыз.

Әхмәт. Соңрак булмасмы соң?

Мәрьям. Булмас! Безнең әбекәйнең әбисенең әбисе алтмыш алтыда бала тапкан. Тәк что житмештә дә картаймыйм әле мин.

Әхмәт. Синең әбиеңнең әбисенең әбисе алтмыш алтыда бала тапса, минем бабамның бабасының бабасы кырык дүрттә үлеп киткән.

Мәрьям. Алайса йортны ашыктыра төш. Минем хөкүмәт фатирында тол каласым килми.

Әхмәт. Ризваннар хөкүмәт йортында да яши бит әле.

Мәрьям. Ничек яшәсәң булмый ул. Кешенең һәрвакыт «Менә бу минеке» дип әйтерлек әйбере булырга тиеш.

Әхмәт. Ризванның бит гармуны бар.

Мәрьям. Әнисенең сыерын сатып алган гармунны ул минеке дип әйтә алмый.

Әхмәт. Ярар, бу турыда сүз куертмыйк. Син миңа шуны әйт: барабызмы без Ризваннарга, юкмы?

Мәрьям. Юк!

Әхмәт. Соң бит мин аңа барабыз дигән идем.

Мәрьям. Әйтсә соң. Бармаска уйласаң мең сәбәп табып була.

Әхмәт. Нәрсә дияргә икән соң?

Мәрьям. Кинәт кенә хатын чирләп китте диген.

Әхмәт. Алай әйбәт булыр микән соң?

Мәрьям. Кинәт кенә үлеп тә китәләр. Дөнья бит ул.

Әхмәт. Ярый алайса. *(Телефон янына килеп номер жыя.)* Алло, Ризванмы? Әхмәт әле бу.

**Икенче якта Ризван.**

Ризван. Әле сез һаман безгә килергә чыкмадыгызмыни?

Әхмәт. Ни бит әле, парин. Кинәт кенә хатын чирләп китте.

Ризван. Мәрьямме?

Әхмәт. Соң минем бүтән хатын юк бит инде.

Ризван. Бая гына әле үзең әйбәт дигән идең.

Әхмәт. Бәла аяк астында диләр бит. Кунакка буш кул белән барып булмас дип, тиз генә кибеткә йөгергән иде. Кайтты да ауды. Башы әйләнә. Тәне ут яна.

Ризван. Температурасын үлчәдегезме соң?

Әхмәт *(хатынына карый. Хатыны ул сөйләшкәндә телефонга колагын куеп Ризванның сүзләрен ишетеп тора).*

Мәрьям *(пышылдап).* Кырык ике ярым диген.

Әхмәт. Әйе, үлчәдек. Кырык өч ярымнан узып бара.

Ризван. Нинди чир икән соң ул? Андый температураны ишеткән юк иде.

Әхмәт. Үзең беләсең, хатынкызның температурасы чирләмәгәндә дә кырыкка житәргә тора бит аның. Әле менә дару эчерергә дип сулы стакан тоттырган идем, стакандагы су гөбер-гөбер кайнарга тотынды.

Ризван. Алай, алай. Врач чакырттыгызмы соң?

Әхмәт. Чакырттык. Хәзер килеп житәрбез диделәр.

Ризван. Алайса мин Халидәгә әйтим әле. Ул сез килер дип мәш килеп әзерләнеп ята иде анда.

Әхмәт. Бар, бар, әйт. Ә мин Мәрьямнең хәлен белим. Үлеп-нитеп китә күрмәсен. Шушы яшемнән тол калсам, Аллам сакласын.

**Трубканы куя. Маңгаеннан тирен сөртеп ала.**

Әхмәт. Шәп сиптемме борчакны?

Мәрьям. Шәп, шәп. Болай булгач бераз сыйламый булмас үзенне.

Әхмәт. Әллә алып куйган берәр нәрсәң бар идеме?

Мәрьям. Яңа елдан калган шампанскига бераз газлы су өстәп куйган идем. Бәйрәм хөрмәтенә җәлләмәм инде. Шытыруны да шәп шыттырдың.

Әхмәт. Стажировканы синдә уздым бит.

Мәрьям. Бөтен этлегенне миңа гына сылтама. Үзеңдә дә житәрлек ул синең.

Әхмәт. Ярар, ярар. Әйткән—беткән. Бар, теге шампан шулпасын алып кил.

**Мәрьям бер шешә һәм стаканнар китереп өстәлгә куя. Әхмәт шәрабны стаканнарга сала.**

Әхмәт. Тәк, тәк. Бүген нинди бәйрәм әле?

Мәрьям. Мин каян белим. Татарстан бәйрәмеме бу, Россиянекеме, Башкортостанныкымы?

Әхмәт. Ярар. Үгез булмагае чурт булсын, түлке балаларга сөт булсын дигәндәй. Нинди бәйрәм икәнлегениважны. Иң важнысы шул: бүген без синең белән җылы өебездә. Йомшак кәнәфиләрдә кәеф-сафа корып утырабыз. Хәзерге дөньяда шунсы әһәмиятле. Әйдәле, шуның өчен берне күтәреп куйыйк, карчык.

**Ялт кына икесе берьюлы стаканга үреләә. Мәрьям бер йотуга ук авызына ут капкандай, нишләргә белми чәбәләнә. Әхмәт тә «ух» итеп куя.**

Әхмәт. Тора-бара градыс кергән моңа, карчык. Авызларны өтте. (Шешәне тотып карый. Мәрьям аның кулыннан шешәне тартып ала.)

Мәрьям. Кагылма! Ярамый!

Әхмәт. Нәрсә, әллә таракан даруы идеме? Харап иттең бит, җен калтырчасы. Уф, үләм, үләм. Тизрәк скорый чакырт. Бар, нәрсә катып торасың?

Мәрьям. Таракан даруы булса үзе дә әле ул...

Әхмәт. Әллә күсе агуы идеме? Уф үләм. *(Эчен тота.)*

Мәрьям. Ачуымны китермә әле. Күсе агуы, имеш. Аякларымны ышкырга тота торган спиртымны чыгарганмын. Эт бәхете бер сөяк, дуңгыз бәхете—бер тизәк дип дөрес әйтәләр шул.

**Әхмәтнең эченә җан кереп китә.**

Әхмәт. Каяле алайса, тагын бер авыз итеп алыйк.

Мәрьям. Итми генә тор әле *(шешәне өстәлдән ала).* Болай да газлы су шулпасы дип шактый тондырган идем.

Әхмәт. Шулай ычкынгалый торган гадәтең булганга яратам мин сине, карчыгым. Бу дөньяда сирәк-мирәк добровольно ычкынгалап алмасаң, бөтенләй ычкынуың бар. *(Күңеле күтәрелеп җырлап җибәрә.)*

Эчеп җибәр салганын, ди,
Сорама каян алганын, ди,
Эчеп җибәрсәң салганын,
Баса йөрәк янганын, ди.

Мәрьям. Йөрәгеннән янганын басарлык булды шул. Ярты стакан саф спирт җиффәргәч ничек басылмасын!

Әхмәт. Шулай инде, карчык, минем йөрәкнең януы басылды, синеке яна башлады. Дөнья бервакытта да тигез булмый.

Мәрьям. Ачуымны китереп, авызыңны ерып торма әле.

Әхмәт. Нәрсә, биргән спиртыңны кире чыгартырсыңмы әллә?

Мәрьям. Чыгартырмын да.

Әхмәт. Мине самогон аппаратына салып кайнатып алсаң гына инде.

Мәрьям. Теләсәм, ничек итеп алырга икәнен белермен мин.

Әхмәт. Ярый, карчык, бер яхшылык эшләгәнсең икән, үкенеп йөрмә инде. Иң яхшысы магнитофонны кабызып җибәрик тә, яшь чакларны искә төшереп, бер танцевать итеп алыйк. Бәйрәм икән, бәйрәм булсын.

**Әхмәт телевизор астындагы тумбочкадан магнитофон тартып чыгара, аны кабызып җибәрә. Анда вальс яңгырый. Әхмәт вальс көенә бер тыпырдап ала да Мәрьям каршысына килеп баса.**

Әхмәт. Прошу, мадам.

Мәрьям. Шушы биш тиенлек эчсә, ун тиенлек исерер инде.

Әхмәт. Еще раз прошу, мадам. *(Мәрьямнең беленнән эләктереп, вальс көенә бөтерелә башлый.)*

Мәрьям. Башымны әйләндерәсең, тукта.

Әхмәт. Хатын-кызның һәрвакыт башын әйләндереп торырга кирәк аның. Бервакытта да айнымасын ул.

Мәрьям. Без дә исереп бетсәк, сезне кем эзләп алып кайтыр соң? Сез бит колхоз ужымына качарга торган бозаулар кебек, юкка чыгарга гына торасыз.

Әхмәт. Мин бит мәхәббәттән айнытмаска дим, карчыгым. Мәхәббәт белән исертеп торырга кирәк сезне. Көннән-көн яңа порция өстәп.

**Мәрьям башта теләмичәрәк кенә вальска әйләнә башласа да соңыннан дәртләнеберәк китә.**

Әхмәт. Между прочим, карчык, Ризваннарга бармыйча акыллы эшләдек бугай без, ә?

Мәрьям. Синең карчыгыңның кайчан акылсыз эшләгәне бар.

Әхмәт. Баш бар синдә. Һәм... башка җирләр дә. Комплектың тулы, хәтта запчастьләр белән.

Мәрьям. Әй тозсыз! *(Үзе кылан-чыкланып артын сикерткәли. Әхмәт аның артына сугып ала. Шулвакыт телефон шалтырый. Әхмәт телефон янына китә.)*

Әхмәт. Әйе, тыңлыйм. Тыңлыйм дим. Кем? Ризван? Нәрсә, нәрсә? Үзегез киләсез? Бик әйбәт уйлагансыз, молодцы! Бергәләп бәйрәм итәрбез. *(Әхмәтнең сүзләрен ишетеп аның янына хатыны килеп баса.)*

Мәрьям *(ысылдап)*. Нәрсә, әллә безгә килергә җыеналармы?

Әхмәт *(трубканы читкәрәк тотып)*. Әйе, карчык, әйе.

Мәрьям *(пышылдап)*. Юк, юк! Юк диген.

Әхмәт. Нәрсә юк?

Мәрьям. Атаң башы! Куй әле трубканны.

Әхмәт *(телефонга)*. Ни, Ризван, монда хатынга начар булып китте әле. Температурасы тагы да күтәрелде бугай. Мин трубканы куеп, аның янына барып киләм. Бераздан үзем шалтыратырмын, ямә.

**Трубканы куя. Хатынына карый.**

Мәрьям. Аңгыра, тинтәк, башсыз. Килегез дип тора.

Әхмәт. Ә нигә, килсеннәр. Ризван буш кул белән йөрми ул. Бер яртыны кыстырып килер. Бергәләп бәйрәм итәрбез.

Мәрьям. Бер ярты, бер ярты... Сезнең авызыгызга йөз грамм керсә, тамакларыгыз әтәч булып кычкыра. Юмартланасыз. Аның бер яртысын эчсәгез, үзең ике ярты куйдыртмый туктамыйсың син.

Әхмәт. Ә нигә? Мөмкинлек бар чакта яшәп калырга кирәк.

Мәрьям. Мөмкинлегең бар? Пешмәгән бизнесмен! Һәр тиененне мин кысып тотканга гына кешечә яшәгәнеңне онытма. Мин булмасам чалбарыңның сыңар балагын сатып ашаган булыр идең инде.

Әхмәт *(җыр белән)*.

Әл дә син бар әле бәхетемә,
Әл дә син бар әле дөньяда.

Мәрьям. Бар шул. Мин булмасам Ризваннарың килеп, актык сыңык ипиеңә кадәр сыдырып китәрләр иде. Кунакка алар кешенекен күбрәк умырыр өчен йөриләр.

Әхмәт. Син бигрәк инде, карчык.

Мәрьям. Бер дә бигрәк түгел. Ни өчен алар һәр җиргә бер өем балаларын ияртеп йөриләр дисең?

Әхмәт. Безнең балалар булмагач, болар да бала-чага чырае күрсеннәр ди торганнардыр.

Мәрьям. Ха! Әйттерерсең әллә ни!

Кешедә бер атналык итеп ашатыр өчен йөртәләр алар шул дегет чиләкләрен. Алар килеп киткәч, ике көн буе савытлар гына юам мин. Суыткычындагы бөтен тәмтомны эт ялагандай итеп китәләр. Хәерчегә хезмәтче булып йөрергә монда!

Әхмәт. Соң алар бит хәл белергә киләләр, карчыгым. Синең температураң кырык өч ярым дигәч, котлары очкан бичараларның.

Мәрьям. Кырык өч ярым дип әйтергә сиңа кем кушты. Кырык икесе дә бик житкән иде.

Әхмәт. Үләргә яткан кешенең температурасы ничә булганын чуртым белгәнме? Үләргә ятам диден бит. Тавыкныкы кадәр миең юк.

Мәрьям. Алай башлы булгач, Ризваннарынны китертмәү чарасын үзең тап.

Әхмәт. Чокырга батканда үзегез батасыз, ә тартып чыгарырга без кирәк.

Мәрьям. Күп сөйләнмә, йә юлга чыга башларлар.

Әхмәт. Нәрсә генә уйлап табарга соң, каһәрең. Иң кирәк чакта башы да эшләми бит аның.

Мәрьям. Эшләт башынны, эшләт.

Әхмәт. Нәрсә уйлап табарга?

**Икесе дә башларын аска иеп, кулларын артка куеп, бүлмә буйлап йөренә башлыйлар. Берсе бер якка, икенчесе икенче якка бара. Юлда бәрелешеп тә алалар.**

Әхмәт. Нәрсә табарга тиеш идек әле без?

Мәрьям. Атаң башын.

Әхмәт. *(Үзенең нәрсә уйлаганын чын-чынлап оныткан. Ул Мәрьямгә гаҗәпләнеп карый.)* Чынлап та нәрсә эзлибез соң без? Нәрсә югалттык?

Мәрьям. Нәрсә булсын! Зиһенебезне югалттык. Ризваннарны кунакка китермәслек хәйлә уйлап табарга кирәк.

Әхмәт. Ә-ә! Алайса таптым!

Мәрьям. Нәрсә?

Әхмәт. Газ юк димен.

Мәрьям. Молодец! *(Әхмәтнең аркасыннан сөеп куя.)* Газ юк. Газ юк! Шалтырат тизрәк.

**Әхмәт телефон номерын җыя башлый.**

Әхмәт. Алло, Ризванмы бу?

**Ризваннар ягыннан трубканы Халидә ала.**

Халидә. Юк, Халидә. Ризван киенеп маташа иде. Хәзер килеп җитәрбез.

Әхмәт. Ни бит әле, Халидә малай, бездә газ бетте бит. Сез киләсе булгач, Мәрьям бәлеш пешерим дисә...

Халидә. Мәрьямнең хәле рәтләндеме әллә?

Әхмәт *(ялгышлык җибәрүен аңлап)*. Ә-ә. Юк. Кая ул рәтләнү! Тагы да начарланды. *(Әхмәтнең сөйләшкәнен Мәрьям дә тыңлый.)* Бәлешне мин пешермәкче идем. Ә Мәрьямне... Аны скорый белән алып китмәсәләр ярар иде дип торам.

Халидә. Әле һаман врач килмәдемени?

Әхмәт *(ык-мык итебрәк)*. Килде, килде. Калтырап торган бер карт иде. Мәрьямнең нинди хәлдә икәнен күргәч, үзе һушсыз булып егылды, бичара. Санитарлары картның үзен носилкага салып алып чыгып киттеләр.

Халидә. Ай-яй-яй. Тизрәк барып җитәргә кирәк алайса сезгә. Ризванны ашыктырыйм әле.

**Мәрьям, Халидәнең сүзләрен ишеткәч, Әхмәткә нидер пышылдап түшәмдәге лампочкага төртеп күрсәтә. Әхмәт аңламый.**

Әхмәт. Нәрсә?

Мәрьям *(ысылдап)*. Ут бетте.

Әхмәт. Нишләп бетсен. Яна бит.

Мәрьям. И-и аңгыра. Ут бетте диген.

Әхмәт *(көчкә аңлап)*. Ә-ә, ни... Халидә. Бездә ут та беткән икән.

Халидә. Ай-ай, бу ни эш инде. Йә, ярар, кайгырмагыз. Шәм алып килербез.

Мәрьям. Уф! *(Пышылдый.)* Батареяларда җылы да бетте.

Әхмәт. Батареяларда җылы да бетте.

Халидә. Үзебез баргач җылытырбыз. Анда Ризван җылыткыч әйберләр әзерләп маташа иде. Ә бәлешләр пешереп мәшәкатьләнмәгез, үзем пешергәнен кайнар килеш алып килербез.

Әхмәт *(телләрен ялап куя)*. Алай дисеңме?

**Мәрьям Әхмәткә кулы белән төрле ишарәләр ясый. Әхмәт сораулы караш белән аңа карый.**

Мәрьям. Әҗәткә акча сора.

Әхмәт. Нәрсәгә ул? Безнең акча бар бит.

Мәрьям. И ахмак! Әҗәткә акча сорасаң кеше сиңа аяк та басмый.

Әхмәт. Ә-ә-ә! Юкәдә икән чикләвек. *(Трубкага.)* Алло, Халидә.

Халидә. Тыңлыйм.

Әхмәт. Бераз акча кирәгие безгә, парин.

**Мәрьям.** Күбрәк сора, тинтәк. Күбрәк сора.

**Халидә.** Нәрсәгә ул акча?

**Әхмәт** *(бераз ык-мык килгәннән соң).* Ни... Мәрьямгә теге врач бер дару язган иде. Шуны алырга кулда акча юк.

**Халидә.** Күпмерәк?

**Әхмәт.** Хәзер бит, үзең беләсең, дару бәяләре кот очарлык. Бер кап даруны бер миллионга табарга мөмкин диде.

**Халидә.** Теге носилка белән алып киткән врачмы?

**Әхмәт.** Әйе. Һушында чагында әйтеп өлгерде мескен. Безнең янда гына торалар икән. Акча тапсагыз, үземнән кереп алырсыз диде.

**Халидә.** Ай-яй! Бигрәк акыртып талыйлар инде. Ул арада гына аның каләр акчаны каян тапмак кирәк?! Шулай да мин Ризван белән киңәшеп карыйм әле.

*(Трубканы куеп, чыгып китә.)*

**Әхмәт.** Бар, бар. Ныклап киңәшегез. Озаграк уйлашыгыз. *(Көлә. Мәрьямгә карап.)* Болай булгач котылдык, хатын.

**Мәрьям.** Котылдык! Хәзер миңге килмәячәкләр алар.

**Әхмәт.** Котылдык. *(Көйләп.)*

Котылдык, котылдык,
Бер бәладән котылдык.
Әй хатын, вәй хатын,
Син көмеш тә мин алтын.

**Мәрьям.**

Әй картым, вәй картым,
Син бакыр да мин алтын.

**Әхмәт.** Әй хатын!

**Мәрьям.** Вәй картым!

**Икесе бергә.**

Икебез дә без алтын.

*Беренче пәрдә тәмам.*

## Икенче пәрдә

**Шул ук Әхмәтләр фатиры. Пәрдә ачылганда Әхмәт диванда аякларын өскә күтәреп, җырлап ята.**

Атлар җиктем мичәп-мичәп,
Безгә дошман унбишләп;
Булса булсын егерме бишләп,
Йөрик теләсәк нишләп.

**Мәрьям.** Шушы өч тиенлек эчсә—биш тиенлек исерер инде. Тик томалдан авыз күтәреп җырлап ятасын, килешмәгәнне.

**Әхмәт.** Авыз күтәреп түгел, бот күтәреп. *(Җырлый.)*

Әйдә барыйк кибеткә,
Көмеш алыйк йөзеккә;
Ни кыланса да килешә
Безнең кебек егеткә.

**Мәрьям.** Сезнең кебек егетләр иномаркаларда чабалар.

**Әхмәт.** Безнең кебек егетләр бүген бәйрәм итә. Чыгар әле, хатын, теге газлы су шулпасын. Синең исәнлеккә җиффәрик тагын берәр стакан.

**Мәрьям.** Авызыңа бер тамчы керсә, икенчесе кайчан тамар икән дип телеңне сузып торасың инде син.

**Әхмәт.** Мина, кем әйтмешли, кәҗә-се түгел, мәзәге кыйммәт. Аннары синең шундый зирәклегеңне билгеләп үтәргә кирәк бит инде, хатын. Ай-яй! Ни генә уйлап тапмыйсың син. Әҗәткә акча диген, ә? Каян башына килә шундый этлекләр. *(Көлә.)*

**Мәрьям** *(бераз һаваланып).* Син генә үзеңне әллә кемгә санап йөргәч тә. Бездә дә бар ул баш.

**Әхмәт.**

Синдә дә баш житәрлек,
Миндә дә баш житәрлек,
Шул акыллы башлар өчен
Әйдә берне күтәрик.

**Тумбочканы ача башлый.**

**Мәрьям.** Тукта үзем алып бирәм. *(Аннан бер шешә алып өстәлгә куя.)* Мә!

**Әхмәт.** Үзеңне дә әбижәйт итмә инде, китер стакан, карчык. Син дә бит кеше. Почти.

**Мәрьям.** Ә-ә-ә, почтимени әле? *(Шешәне тартып алмакчы була, ләкин Әхмәт бирми. Тарткалашып алалар.)*

**Әхмәт** *(тешләре белән бөкене ача).* Бөкене каты тыккансың, газы чыгып бетмәсен дигәнсеңдер инде. Болай булгач, берәр нәрсә капкаларга да кирәк булыр. Бар әле, карчык, суыткычны карап чык. Килосы 40-50 меңлек колбасаң аунап ятмыймы анда?

**Мәрьям.** Аунаган ди, көтеп тор.

Әхмәт. Көтәм-көтәм, бар инде. *(Хатынын төрткәләп чыгарып җибәрә. Үзе хатыны юктан файдаланып тиз генә бая хатыны алып куйган спирт шешәсен алып, бусы белән алыштыра.)* Кызык итик әле хатынны. *(Мәрьям кулына табак тотып килеп чыга.)*

Мәрьям. Кичә пешергән кабак боткасы бар икән. Мә, аша.

Әхмәт *(табакны тотып карый).* Шуны жылытырга ярамый идеме?

Мәрьям. Болай да бик әйбәт жылытып утырасың әле.

Әхмәт. Бик җәлләсәң, газлы су шулпаңны үзең эч. Мә.

Мәрьям. Ярар инде, ярар. Бигрәк серкәң су күтәрми.

Әхмәт. Без су түгел, бераз кайнаргыгын гына күтәрәбез. *(Шешәдәге эчемлекне бераз салып куя. Авызы янмасын өчен кабак боткасын каба.)* Боткаң кайнар икән бит, хатын.

Мәрьям. Көлмә кешедән, авызың өшегән.

Әхмәт. Көлмим. Шәп бит син, карчык.

Мәрьям. Нишләптер синең күзләрең бик ялтырый башлады әле.

Әхмәт. Озак шешәдә ятып, газлы суыңа градус кергәндер.

Мәрьям *(шешәдәге эчемлекне кабып карый).* Аһ! Тагын шешәне бутаганмын икән. *(Шешәне алып куя.)*

Әхмәт. Бирермен дигән колына, чыгарып куяр юлына. Ризваннарны китертмәгән өчен шайтан саташтырган сине. Йә, ярар, кайгырма, аякларыңны ышкырга бальзам алып бирермен әле мин сиңа.

Мәрьям. И хәчтерүш. Бальзам дигән була.

Әхмәт. Ә нигә? Алырмын. Яраткан хатыным өчен бер нәрсә дә жәл түгел. Әремгә кычыткан кушып кайнатылган бальзам алып бирермен.

Мәрьям. Шул кычыткан суы гына алмасаң, синнән башканы көтеп булмас.

Әхмәт. Хатын-кызга иң файдалы нәрсә кычыткан дип язганнар бер гәзиттә.

Мәрьям. Мин укыган гәзиттә иратлар өчен тилебәрән орлыгын шәп дигәннәр.

Әхмәт. Безнең акыл бик көчле. Тилебәрән орлыгы ашап кына тилертеп булмый безне. Менә әле дә күңелем нидер сизә: мөгаен, Ризваннар килер безгә.

Мәрьям. Килде ди, көтеп тор. Үз кулларь белән миллион тәңкә акча китереп бирсәләр, аларны турыдан-туры юләрләр йортына җибәрергә генә кала.

Әхмәт. Чүтеки килсәләр, нишлисең?

Мәрьям. Ул хәерче гармунын тотып урам чатына чыгып утырса гына инде. Анда да бер-ике сәгатьтә миллионны җыя алмас.

Әхмәт. Гармунын сатар да алып килер.

Мәрьям. Ул алама гармунны дурак алсынмы?

Әхмәт. Алай димә, Ризванда нидер бар анда.

Мәрьям. Яшерелгән алтынмы?

Әхмәт. Без белмәгән, без төшенә алмаган нидер бар анда. Мин аны яшь чакта да аңлап бетерми идем. Аннан әллә нәрсәләр көтәргә була.

Мәрьям. Хәерчедән нәрсә көтәсең. Үзе акча сорап килсә генә инде.

Әхмәт. Акчасы миллион булырмы, ансын әйтә алмыйм, әмма ләкин Ризваннар килә.

Мәрьям. Ә мин әйтәм—юк.

Әхмәт. Әйдә, бәхәсләшәбез.

Мәрьям. Әйдә. Ә нәрсәдән?

Әхмәт. Ярар, мин күп сорамыйм: әгәр Ризваннар килсә, саранлыгыңны онытасың. Бәйрәмнәрдә кучтәнәчләп йә үзебез кунакка барабыз, йәки дусларыбызны чакырабыз. Килештекме?

Мәрьям. Килешербез, ләкин тәгәл миллион алып килсәләр генә.

Әхмәт. Кулларны сугыштык алайса?

Мәрьям. Тукта. Мин үз шартымны әйтмәдем бит әле.

Әхмәт. Әйт.

Мәрьям *(уйланып).* Әгәр килмәсәләр... Ул чагында син мине күтәреп 14 этажга алып менәсең?

Әхмәт. Ансы нинди юләрлек тагын?

Мәрьям. Нинди ме? Чөнки өйләнешкән вакытта син мине күтәреп менмәдең. Хәзер менә бөтен кеше алдында шул хатаңны төзәтергә тиешсең.

Әхмәт *(Мәрьямне әйләнеп чыга).* Ай-яй-яй. Сине хәзер 14 нче катка күтәреп менеп булыр микән?

Мәрьям. Курыкма. Бик мышкылдый башласаң жиде кат менгәч куеп торырга рөхсәт итәрмен.

Әхмәт. Ярый алайса, килештек.

Мәрьям. Килештек.

**Кул сугышалар. Шунда ишектә звонок тавышы ишетелә.**

Әхмәт. Килделәр! Ризваннар килде!

Мәрьям. Килде пычагым. Күршеләрдер әле *(ишекнең күзенә барып карый).* Уф Аллам, шулар!

Әхмәт. Әйттем бит киләләр дип. Инде нишлибез?

Мәрьям. Утны сүндер, утны.

Әхмәт. Нигә?

Мәрьям. Нигә, нигә? Потому что бездә ут юк. Тәрәзәләрне дә ач. *(Әхмәт утларны сүндерә.)*

Әхмәт. Суык керә бит.

Мәрьям. Керсен. Онытгыңмени, безнең өйдә бит җылы юк.

Әхмәт. Ә син юрганга төренеп ят. Ныграк ыңгыраш. Кара аны, ышандырырлык булсын. *(Мәрьямне диванга төртеп аудара. Өстенә катлы-катлы әйберләр яба.)*

**Ишектә тагын звонок яңгырый.**

Мәрьям. Әзрәк ачмый тор, өй суына төшсен. Әй, онытып торам икән: суның астагы винтелен яп. Кранны ачып карасалар, су юк дисеннәр.

**Ишекне дөбердәтәләр.**

Әхмәт. Сөйләшмә. Син бит үлеп ятасың. Алар кергәч без ни сөйләшсәк тә, ыңгырашып, «ыгы-ыгы» дип кенә ят.

Мәрьям. Өйрәтмә, ансын синнән башка да белермен.

Әхмәт. Ачам. *(Ишекне ачарга китә. Анда Ризван белән Халидә. Әллә ниләр күтәргәннәр. Ахылдап килеп керәләр.)*

Ризван. Уф! *(Әйберләрен идәнгә куя.)* Лифтыгыз эшләми икән. Ундүртенче катка җәяү мендек.

Халидә. Караңгы, берни күрмим.

Ризван. Хәзер шәмнәрне яндырам. *(Сумкасыннан берничә шәм алып яндырып өсталгә куя.)* Мәрьямнең хәле ничек соң?

Әхмәт. Үлем белән яшәү арасында. Әй, бичаракай... Сез кунакка чакыруга, күчтәнәчкә дип чыгып йөгергән иде. Калдым хатынсыз.

Ризван. Нинди күчтәнәч инде ул! Без бит бераз күңел ачып утырырга гына дип чакырган идек.

Әхмәт. Безнең Мәрьям кунакка күчтәнәчсез йөриме соң инде? Менә бүген дә бер потлы торт алып кайтып килә икән, каршысына ат чаклы эт чыккан да тортын тартып алып, үзен сугып егып качкан.

Халидә. Абау, Ходаем. Әллә тешләгәнме?

Әхмәт. Тешләвен тешләмәгән. Бер потлы торт коткарган бичаракайны. Шуннан кайтты да ауды.

Халидә. Кая соң әле үзе?

Әхмәт. Әнә диванда. Бер яна, бер өши. Температурасы да, бәлки, төшәр иде, телдән язган бичаракай. Шунсы бик яман.

Халидә. Кая әле, кая? *(Диванга таба китә.)*

Ризван. Сездә каяндыр җил өрә түгелме?

Әхмәт. Мәрьям сулыш ала алмый башлагач, тәрәзәләрне ачкан идем.

Ризван *(аны ачуланып).* Үзең батареяларга җылы килми дисең, үзең тәрәзәләреңне ачкансың, тышта җәй түгел бит, Мәрьямгә салкын тидерсәң.

Әхмәт. Тыштан бераз җылы кермәсме дигән идем инде. Тәмам аңгырайдым.

Ризван. Өегез алай салкын сыман түгел бит. (Батареяларны тотып карый.) О-о, батареяларыгыз ут кебек.

Әхмәт *(гаҗәпләнгән булып).* Җылы биргәннәр микәнни? (Батареяларны тотып караган була.) Биргәннәр икән шул.

Халидә. Бәлки ут та булгандыр. *(Утны кабыза.)*

Әхмәт. Кара инде ут та биргәннәр. Күптән киләсегез калган.

Ризван. Күптән киләсе калган шул. Менә Халидә бераз тоткарлады. Мәрьямгә тавык шулпасы пешереп алып барыйк дип, шуның белән мәшәләнеп әзрәк соңардык. *(Мәрьям янына килә.)* Йә, ничек монда эшләр?

Халидә. Хәлең ничек, ахири? *(Мәрьям ыңгыраша, «Ыгы-ыгы» ди.)*

Әхмәт. Теле юк шул мескенкәйнең, теле юк. Сыер кебек күзгә карап мөгрәп ята.

Халидә. И ахирәт, ахирәт. Күчтәнәч дип шулай кабаланырга ярыймыни? Безнең бит, Аллага шөкер, дусларыбызны кунак итәрлек кенә сыебыз бар. *(Ризванга)* Атасы, сумкаларны бушат әле.

Ризван. Ярый, ярый. *(Ике олы авыр сумка алып керә. Берсеннән ике зур термос алып өсталгә куя.)* Боларның берсендә мәтрүшкәле чәй, икенчесендә тавык шулпасы.

**Термосларны куйганда Мәрьям башын калкытып карый. Әхмәт белән Мәрьямнең хәйләләп кенә матавышын болар аңлап өлгергән инде. Ләкин ышанган кыяфәт белән уенны дәвам иттерәләр. Халидә үзе икенче сумканы бушата башлый.**

Халидә. Бусы юкә балы. Болары ит пәрәмәче. Әле суынып та өлгермәгән.

Ризван. Бусы суыкта да суынмый торган нәрсә (өстәлгә аракы куя).

Халидә. Суынса да куркыныч юк. Менә монда бакчага йөртә торган газ плитәсе. Бәлки үзләренең дә газы килгәндер. Кухняга чыгып карыйм әле. *(Чыгып китә.)*

Әхмәт. Газ килүе дә ихтимал. Сез килеп керүгә ут бирделәр. Батареяларга җылы килде.

Халидә. Газыгыз да килә башлаган. Гөрләп яна.

Әхмәт. Сезнең аяк җиңел булды. Сез килүгә бөтенесе җайга төште. *(Өстәлдәге ризыкларга карап, күзен майландырып, телен ялмап-ялмап ала.)* Бу кадәрле сыйхөрмәтне ни арада әзерләп өлгердегез соң?

Ризван. Балалар булыштылар.

Әхмәт. Алып киләсегез калган үзләрен. Бик яратабыз бит без сезнең балаларны. Бигрәк тә Мәрьям алар өчен үлеп тора. *(Мәрьям иренең бу сүзләреннән ыслап куя.)*

Ризван. Балаларның үзләренең дә сезне бик күрәселәре килгән иде, кечкенәсе «жевачка» апаларга барабыз дип киенә үк башлаган иде. Көчкә калдырдык. Йә, ярый, табын әзерлик, әнкәсе.

Халидә. Кеше үләргә ятканда килешерме соң?

Әхмәт *(ашыгып)*. Килешер, килешер. Дуслар килгәч, бәлки әле Мәрьямнең дә хәле рәтләнеп китәр. Ризван дип, Халидә дип үлеп тора бит ул.

Халидә. Беләбез инде, беләбез Мәрьямнең күңеле киң икәнен.

Әхмәт. Дөрес әйтәсең, Халидә, безнең Мәрьямнең күңеленә машина белән керерлек. Үлгәндә дә Халидә дип, Ризван дип үләр инде мескенкәй. Их, теге эт урлаган торт җәл.

Ризван. Кайгырма, дус. Торт булмаса бездә бәлеш бар. Суынганчы ашыйк әле.

Халидә. Туктагыз. Мәрьямнен хәлен белик. *(Мәрьямнең янына килә. Кулын аның маңгаена куя.)* Маңгае да кайнар түгел.

Әхмәт. Шунсы куркыта шул: кайнарлыгы әле кырык өчкә күтәрелә, әле утыз өчкә төшә.

Ризван. Димәк, эчендә нидер сугыша.

Әхмәт. Дөрес әйтәсең, Ризван дус. Аның эченә тортны урлаган этнең җене кергән бугай. Шул саташтыра аны.

Халидә *(Мәрьямгә дәшә)*. Ахирәт, хәлең ничек? Бераз баллы чәй эчеп карамыйсыңмы?

**Мәрьям ыңгыраша. Аякларын чәбәләндерә. Ыгы-ыгы килә.**

Әхмәт. Интектермик инде аны, Халидә. Үзебез генә табынга утырыша башлыйк.

Ризван. Әйе, ризыкларны суытмыйк.

**Табын әзерлиләр. Аштан, бәлештән тәмле ис тарала. Тәмле ис Мәрьямнең дә борынына керә. Ул борынын сузып иснәп ала. Аны Ризваннар күрә, ләкин күрмәмешкә салышалар. Ризван рюмкаларга аракы сала.**

Ризван. Әйдәгез әле, бәйрәм хөрмәтенә берне күтәрик.

Әхмәт. Әйе. Җырда ничек җырлыйлар әле?

Эчеп җибәр салганын,
Сорама каян алганын.
Эчеп җибәрсән салганын,
Баса йөрәк янганын,—диләрме?

Басылсын әле йөрәк янулары.

**Эчеп куялар. Халидә рюмкага авызын гына тидереп куя. Эчкәннән соң тәмләп ашарга тотыналар. Бәлеш ачыла, өстәлгә бал куела. Тәлинкәләргә тавык шулпасы салына. Халидә бер кулына тавык боты, икенче кулына тавык шулпасы тотып Мәрьям янына килә.**

Халидә. Ахирәт, әллә бер-ике кашык тавык шулпасы кабып куясыңмы? Бәлки, кайнар шулпа бераз хәл кертер.

**Мәрьям күзен ачмый ыңгыраша. Ыгы-ыгы килә. Телен ялмаштырып куя.**

Әхмәт. Интектермә инде бичараны. Ятсын тыныч кына. *(Үзе ашыга-ашыга ашый.)*

Халидә. Ярый инде, алайса. *(Ул да тәмләп ашарга тотына. Болар өстәлдәге ризыкка үрелгән саен Мәрьям башын калкытып, авызын ялмап ала. Торып утырмакчы була. Ә тегеләр юри авызларын чәпелдәтебрәк ашыйлар.)*

Әхмәт. Шәп булды әле, дуслар, сезнең килү. Күңел күтәрелеп китте.

Ризван. Ничек инде җан дустыбызның газиз хатыны үләргә ятканда килмисең?

Әхмәт *(Мәрьямгә карап)*. Үләр инде ул мескен, үләр. Бүгеннән дә калмас.

Халидә. Син бит доктор бер дару язып бирде дигән идең, бәлки, шул коткарыр.

Әхмәт. Ул бит төп-төгәл миллион тәңкә сорый. Андый акчаны каян табасың.

Ризван. Дусларыңа таян. Каяле,

Халидә, чыгар әле миллион тәңкәне. Алып кайтсын әле Әхмәт шул даруны.

**Халидә сумкадан төргәкне алып өстәлгә куя. Әхмәт «аһ» итә. Мәрьям дә башын күтәрә.**

Әхмәт. Миллион тәңкә?! Каян таптыгыз?

Ризван. Бай тапса—котлы булсын, ярлы тапса—каян алдын, диләр. Тагын шушы гармун коткарды инде.

Әхмәт. Ничек?

Ризван. Күптән инде бер күршем гармуныңны миңа сат, күпме сорасаң да бирәм дип йөри иде, тоттым да гармунымны күтәреп шуларга кердем.

Әхмәт. Шул иске гармуныңа миллион бирдеме?

Ризван. Минем гармун бит ул уникаль экземпляр. Ул фабрика конвейрыннан төшкән нәрсә түгел. Аны, үзең беләсең, атаклы гармунчы Мәхмүт абый ясаган.

Әхмәт. Авыл кешесе ясаган нәрсә инде ул!

Ризван. Алай димә, дускай. Саф алтыннар бары тик авылдан гына чыга.

Халидә. Ярар инде, әткәсе, гармун турында туктатып торыйк.

Ризван. Мин бит, әнкәсе, сорагангa гына җавап бирәм. Ә җавабымны әйтеп бетермәдем әле. Әйе, гармунымны күтәреп күршемә кердем дә, мә мин әйтәм, ал гармунымны. Бик якын дустыбыз үләргә ята. Срочно миллион тәңкә кирәк, дидем.

Әхмәт. Шуннан ул миллионын чыгарып салдымы?

Ризван. Әйе. Миллионын чыгарып салды, әмма гармунны алмады. Гармун ул синең җаның ди, ә җанны акчага сатарга ярамый, ди. Вәт шулай, дускай. Дөньяда әйбәт кешеләр дә бар бит. Гармунны монда да алып килдем әле. *(Гармунын алып керә. Бер аккорд биреп ала.)*

Халидә. Кеше үләргә ятканда гармун тартып утырма инде, әткәсе.

Әхмәт *(бераз исерә төшкән).* Тартыйк. Барыбыз да бер үләсе инде.

**Шулвакыт ыгы-ыгы килеп Мәрьям башын күтәрә. Өстәлгә куйган ризыкларга мөлдерәп карый. Аның башын калкытканын барсы да күрә. Иң беренче Халидә аның янына килеп, тезләнә.**

Халидә. Мәрьям, ахирәткәй, хәлең бераз яхшырмыймы?

**Мәрьям аңлашылмый торган бер-ике сүз әйтә. Аның янына ире Әхмәт тә килеп Мәрьямне бераз калкытып куя.**

Әхмәт. Карчык, ә карчык. Үз аңында булсаң, безгә берәр төрле итеп белгерт әле. Хәлең жиңеләймиме? *(Мәрьям ыңгыраша. Аякларын чәбәләндерә.)* Үлем белән тартыша ахры. Бичаракаем.

Мәрьям *(күзен ача. Көч-хәл белән дәшә).* Әхмәт, картым?

Әхмәт. Әү, карчыгым.

Мәрьям. Мин кайда?

Әхмәт. Үзебездә, матурым, үзебездә.

Мәрьям. Ә болар нинди ят кешеләр?

Әхмәт. Болармы? Болар безнең дусларыбыз—Ризван белән Халидә. Болар ят кешеләр түгел. Ныклабрак кара әле, матурым. Әйдәле мендәреңә сөялебрәк утыр. *(Мәрьямнең аркасына мендәр куеп аны диванга утырта.)* Танылыңмы инде?

Мәрьям. Бераз таный башладым сыман, бугай, шикелле...

Халидә. Бу мин—Халидә ахирәтең.

Ризван. Бар, Әхмәт, тизрәк даруга йөгер.

Халидә. Әйе, әйе, дарусыз кайтма. *(Өстәлдәге акчаларны Әхмәткә тоттыра.)*

Әхмәт. Миллион тәңкә! Даруга...

Халидә. Кеше гомере миллион тәңкә генә тормый. Бар, бар.

**Әхмәтнең чыгып китәсе килми. Ул юри ыгы-зыгы килә.**

Ризван *(аны төрткәләп).* Бар инде, бар, юкса соңгаруыбыз мөмкин.

Әхмәт. Ни бит... Мин югында Мәрьям үлеп китсә...

Ризван. Алайса үзем барам. Теге носилка белән алып киткән врачның адресын әйт.

Мәрьям *(мескен тавыш белән).* Туктагыз әле... Уф... *(Йөрәген тотып утырып торган була.)* Әз генә чыгып китми торыгыз. *(Яңа күргәндәй.)* Дусларыбыз килгән икән.

Әхмәт. Әйе, Мәрьям. Ныклап кара: бусы Ризван, бусы—Халидә. Ә менә монысы даруга миллион тәңкә! *(Акчаны алып учында сикертә.)* Йөгеримме даруга?

Мәрьям *(Ризваннар күрмәгәндәрәк ысылдап).* Йөгертермен мин сине! Ангыра!

Әхмәт. Син ул ангыра.

Ризван. Нәрсә, дуслар?

Мәрьям. Әй, менә бу ахмакны сүгәм әле. Теге врачның адресын оныткан.

**Әхмәт тиз арада хатынының шундый хәйлә таба алуына шаккатып карап тора.**

Әхмәт. Ә-ә, әйе. Адресын онытканмын шул шайтан алгыры. Хатын кинәт чирләгәч бөтенләй баш эшләми башлады. *(Башына суга.)* Менә сиңа! Менә сиңа!

Ризван. Алай үзеңне җәзалама инде.

Халидә. Әйе *(Мәрьямгә)*. Әйдә, ахирәт, табынга якынрак кил. Кайнар шулпа кабып җибәрерсең. Бу миллионга үзебез дару алып бирербез. Бер дә кайгырма.

Әхмәт. *(Тавык боты сузып.)* Менә бу ботны кимереп куярсың. Бәлеш ашаганнан соң.

Ризван *(рюмкаларга аракы сала)*. Бәлки, Мәрьям ханым, менә моны да берике йотып куяр әле. Кайбер чиргә моның да файдасы тия.

Халидә. Син нәрсә инде, әткәсе. Рәзе мондый чакта бу шайтан суын эчәргә ярый.

Әхмәт. Ярый, ярый! Шулай бит, карчыгым. Кабып куярсың бит? *(Колагына.)* Эч, эч, бушлай килгән нәрсәне әрәм итмә.

Мәрьям. Әллә кабып карыйм микән?

Бар да: Кап, кап!

Мәрьям. Әй, кабыйм әле. Беткән баш беткән инде. *(Рюмканы күтәреп куя. Барсы да эчәләр. Мәрьям комсызланып ашый.)*

Әхмәт. Әллә, Ризван, гармунынны уйнап җибәрәсеңме? Хатынга да җан керде.

Ризван. Була ул. *(Гармунын уйнап җибәрә. Әхмәт җырлый башлый.)*

Һавада очкан кошларның
Канат очлары алтын.
Барлык алтын-көмешләрдән
Минем дусларым якын.

Кульяулыкларым күп иде,
Дуслар саен тараттым.
Бөтен дуслар арасыннан
Сезне бигрәк яраттым.

Әхмәт. Их, бар иде яшь чаклар. Хәтереңдәме, Ризван, армиядән кайткач, син гармун уйнап, мин җырлап, авылны өч ураган идек.

Ризван. Хәтерләмәгән кая!

Халидә. Авыл, авыл дип саргаеп ятабыз инде шәһәрдә.

Ризван. Шәһәр урамында рәхәтләнеп гармун уйнап йөреп тә булмый бит.

Мәрьям. Нәрсәсе бар шул авылның. Рәтле туфли киеп урамына чыга алмыйсың. Кыш көне билдән керткә, җәйләрен, көзләрен пычракка чумасың.

Ризван. Авылның пычрагы да матур аның. Балаларны укытырга музыка мәктәбе булса, бүгеннән авылга кайтып китәр идек.

Халидә. Әллә соң быел җәй бергәләшеп авылыгызга кайтып киләбезме? *(Мәрьямгә.)* Машинагыз бар.

Мәрьям. Ватык ул, ватык.

Ризван. Нигә машина? Автобус йөреп тора. Балаларны да алып бер җилләнеп килербез. Дус-ишләрне күрербез. Бер күрешү—үзе бер гомер.

Әхмәт. Әйе шул. Имәнлеккә менеп төшәрбез. Ял итәрбез.

Мәрьям. Ә коттедж?

Халидә. Коттедж саласызмыни?

Мәрьям *(ялгыш ычкындырганын аңлап)*. Әй, бер эт оясы корып маташабыз шунда.

Әхмәт. *(Исерә төшкән)*. Сигез бүлмәле...

Мәрьям *(Әхмәткә ысылдап)*. Тишек авыз.

Ризван. И-и, салган-салган, 12-13 бүлмәле итмәгәнсез шунда. Безнеке унике бүлмәле.

Мәрьям *(ышанып)*. Унике?

Халидә *(иренең шаяруын дәвам итә)*. Булгач булгач унике бүлмәле булсын дидек инде. Безнең балалар да бар бит.

Мәрьям. Ә акча?

Халидә. И-и, безнең Ризван гармунын бер тартса миллион төшеп тора бит. Әле узган атнада концертлар белән чыгып күпме эшләп кайтты. *(Ризванга.)* Күпме апкайттың әле, атасы?

Ризван. Онытылган инде. Төгәл чуты истән чыккан.

Әхмәт.

Кайтам инде, кайтам
Туган ягыма.
Кырларыма, тугайларыма.

*(Ризванның иңенә кулын сала.)* Әйдәгез әле, дуслар, дөнья мәшәкатьләрен беразга онытып торыйк. Бая син дөрес әйттең, бер күрешү—үзе бер гомер. Килүегез әйбәт булды әле. Дөньяны барыбер куып тотып булмый аны. Иң яхшысы—яшь чакларны искә төшереп, хыялда гына булса да үзебезне авылда дип хис итик.

**Гармун уйный башлый. Әхмәт җырлый.**

Уйна, дустым, гармунынны,
Син матур уйнатасың.
Уйнатасың, җырлатасың,
Күңелне юатасың.

**Икесе уйнап, жырлап сәхнә әйләнәләр.**

Әхмәт. Әйдәгез, кызлар. Кушылыгыз безгә. Искә төшерик яшь чакларны.

**Әхмәт рюмкаларга шәраб сала. Мәрьямнән кала һәммәсе рюмкаларга үрелә. Мәрьям бераз икеләнеп торганнан соң кинәт бер карарга килә.**

Мәрьям. Әй, чукынып китсен дөньясы. Тотыйм әле мин дә. *(Рюмканы ала.)*

Халидә. Чирле кешегә ярар микән соң?

Мәрьям. Чирле кешегә бәлки ярамас, ә мин чирләмим. *(Бар да аңа гаҗәпләнеп карый.)* Әйе, әйе, чирләмим мин. Чирләгән булсам да менә хәзер тереләдем. *(Рюмканы күтәреп эчә дә идәнгә бәрә. Рюмка челпәрәмә килә.)* Чукынып китсен коттеджы, кадалсын—машинасы. Дөньяны күпме кусак та куып бетереп булмас. Барының кадерен белеп яшик әле.

Әхмәт. Терелде карчыгым, терелде. Эченнән котырган эте чыгып китте. Әнә, әнә күрдегезме? Тәрәзәдән чыгып бара. Янадан керә күрмәсен, тәрәзәләрне ябыйк әле.

Халидә. Катырак яп, Әхмәт, бикләп үк куй.

Ризван. Хәзер гармунга сүз бирик, сайрасын әле.

**Ризван дәртле итеп гармунын тартып җибәрә. Хатыннарның икесен дә Әхмәт култыклап ала. Бергәләп жырлашып сәхнә урыйлар.**

Уйна, дускай, гармуныңны
Без жырлаган көйләргә.
Сез уйнаган, без жырлаган
Калсын сагынып сөйләргә.

Жырлыйк әле, жырлыйк әле,
Жырлап ачыла күңел.
Жырлап ачылмаган күңел
Мәңге ачылачак түгел.

**Жыр белән пәрдә ябыла.**

*Тәмам.*

---

## Киләсе санда укыгыз:

Игътибар иткәнсездер, журнал битләрендә узган елның азагында һәм бу елның беренче санында укучыларга ике яңа рубрика тәкъдим ителде. Аларның берсе—«Милләттәшләребез чит илләрдә» булса, икенчесе, ягъни быел ачылганы—«Яңа исемнәр» дип атала. Февраль аенда кызыксынган укучылар шушы ике яңа сәхифәдә үзләре өчен нинди кызыклы яңалык табарлар соң?

Икенче дөнья сугышы елларында Кытайда туган, үсмерлек һәм яшьлек елларын Төркиядә, ятимлектә уздырган, әмма эчкерсез һәм ярдәмчел милләттәшләребез булышлыгы белән югалып калмаган олы галим, хәзерге көндә Мәрмәрә университеты профессоры дәрәҗәсенә ирешкән **Надир Дәүләт** хакында язучы **Рабит Батулланың** кыска гына, әмма тирән эчтәлекле язмасы күпләрне тетрәндерер. Шушы ук сәхифәдә Төркиядә яшәүче татар галименен **«Шагыйрь Шаһвәли Келәүле иҗаты»** дигән мәкаләсе һәм гомерен мөһаҗирлектә үткәргән шагыйрьнең кайбер әсәрләре дә тәкъдим ителәчәк. Яңа исемнәр рубрикасында исә Чаллыда яшәүче яшь язучы **Айгөл Әхмәтгалиеваның** «Соңгы өмет» хикәясе белән танышырга мөмкин булыр.

Февраль санында **Вахит Имамовның** «Утлы дала» романының дәвамы, «Татар хикәяләре хәзинәсеннән» циклыннан **Фатих Әмирханның** «Милләт тәрәккый иттерү» дигән хикәясе, шагыйрьләрдән **Илдар Юзеев, Зөлфәт** шигырьләре, үткән темага язылган мәкаләләр, рецензияләр һәм башка күп кенә кызыклы язмалар бастырып чыгару күздә тотыла.

*Исегезгә төшерәбез: өлгермәгән кешеләр журналга ел дәвамында теләсә кайсы айдан башлап языла алалар. Ярты елга язылу бәясе нибарысы 36 сум. Журналның индексы 73210.*

# ШИГЪРИЯТ



## Рәдиф Гаташ

### «ҖЫР–ИКЕ МЕҢ ИШЕГЕН ШАКЫГАНДА...»

РОБАГЫЙЛАР

❀

Робагый, син—борынгы сүз бостаны,—
Бул бүгенге язарымның гөлханы?!
...Сөембикә илхан! Нугай кураең
Моңнары бу: бездә аның илһамы...

❀

«Нәкъ Казан арты»ннан—изге тияктән,
Тукай әнкәсе күмелгән төбәктән
Килә һаман бер өн—җырга фатиха,
Тарихи наз булып милли йөрәктән.

❀

Аерма халкым гаменнән, йа Раббым!—
Тугач та бу җанны илгә караттың.
... Мәхәббәт орлыгын салдың син аңа—
Ихлас хис, пакь яшь өчен дип яраттың.

❀

Җыр—Ике Мең ишеген шакыганда,
Багышлавым—ул Сиңа, гадел Ярга:
Язганымны ирештер—яңа йөздә
Исемемне яд итәр гашыйкларга !

❀

... Мин язам. Ә бакчамдагы алмалар
Ымсындыра: үрел, ал—алсу, аллар...
... Көзнең тиңсез яме, өмете булып
Чемнән түгел, җаннан өзелер алар.

❀

Кайгыда җан... Ил кайгысы ул: Нажар...
Китте олут шагыйрь—күңелләргә Яр.
Уфада яшәп, Казан! дип янган дус...
«Татар теле» дип кем язар, кем янар?!

❀

Без якташлар идек, әйе, бер яктан—
Агыйделле һәм Бабичлы тарафтан.
Ике тиңсез остазым... Шигырь-Әнкә,
Туармы Сине шулар күк яраткан?

❀

Аны уйлыйм; уем—шигырь минем дә:
Истәлекләр... Җәйнең матур көнендә
Бакчама бит мине эзләп килде ул:
Шуңадыр—яшь бүген гөлләр күзендә!

❀

Яшь гөлләргә, яшьлеккә—хәятында
Гел сокланды, тукталды җыр атында:
Киләчәген күзаллаган ул—Моңның!
(...Яр, синең исмең дә бар—хатында...)

❀

Китә соңгы асылзат, азаматлар.
Төрки рухны үлгәч тә алар саклар.
... Шундыйлыкка әллә бездәме дәгъва,
Әй, барсыннан разый, тук, канәгатьләр?!

❀

Шагыйрь үлү—йолдыз сүнү, югалу...
Күңелләрдә уелып нуры калу.
... Кабатлана—китеп, кадере «арткач»,
Бер пәйгамбәр иде бит!—дип юану...

❀

2000 гә керәм моңсу... Беләм мин:
«Гүрләр аша алга!»—Гёте сүзләрен;
Алда—Яшәү, Сөю, Җыр; алда—Яшьлек:
Анда һаман сиңа баксын күзләрем!

❀

Әлегә Син янда. Җанда—хыялым
Исән һаман, Хистән нигә оялыйм?
...Киләчәктә бу «Робагыйят» Сине
Исертерме? «Искермәмме»? Уйланыйм...

❀

Әле фани дөньяда мин—фанатик:
Түбәдә йөрим, күкләрдә—лунатик.
Айның тарту көчеме син, биеклек?
Сиңа ник гашыйк җан якын була тик?

❀

Сөйләшик бер шул урында, сердәшем:
«Яр» сүзе күптер җырымда, чордашым?
«Яр»—Хак үзе бар итү, яратудан,
Һәм ул—нәкъ Синең турында, җирдәшем!

❀

...Бер манзара: еракта кораб бара...
Мәрмәр, Эгей? Ярга чыккан кыз бала:
Җир тетрәгән чакта бирегә аны
Ни китергән? Җырмы? Сакла, бер Алла!

❀

Ил-кыйтталар кысандыр шигырьләргә,
Төрки нигез—тамыр сау күңелләргә.
Милли тарих—Моң, Җирсү җилкән булмас
Маңкортка тик... Юлдаш булмас җилләр дә!

❀

...Сәйяр җанның сәламе килеп җиткән;
Ул—китаплар (мине дә!) сорый икән:
Төркиядә—гашыйклар ватанында
Шансыз исемең, Гаташ, яңгырый микән?

❀

Ә бит чакыра безне дә аваз-нида:
Анда—Троя... Ә бәлки, Атлантида!
Нуриханын көткән Фест дисбеседәй,
Әйтә булыр:—Мин монда, Әнкә-дөнья!

❀

Сөрмә ит, Җыр, читтә ватан тузанын!
Илдә үтәрбез Вөҗдан, Тел кушканын:
Әлифбабыз да латинга кайтыр, шәт,
Шул имлада дөнья иңлик, дусларым!

❀

...Яр! Син, кереп, ямьләп чыккан бакчамның
Бар төшендә нур калдырганмы җаның?
Һәр чәчәге сорый:—Кая китте ул—
Ханиясе безнең моңсу бостанның?

❀

Флокслар үскән җирне тирәләп,
Нинди әфсен укыдың, Яр-Күбәләк?—
Арта гөлнең хуш исе... Кисеп җанны,
Юкса, көз килә—таҗларны өзгәләп...

❀

Тик безнеке булган серле кичәләр...
Башкалар шул сергә дәгъва итсәләр?
Бар мизгелләр: Җиргә тик икәү сыйган...
Тартына Хис—хәтта Күкләр белсәләр...

❀

Шүрәле күрдеңме? Син—Тукай ягында...
Кемне уйладың анда—Жыр тарафында?
«Сине түгел!»—дип, җил хәбәр китергәч,
Һушсыз булып яттым гөл арасында.

❀

Бәрәңге дә, күр, даулый илдә хакын:
Каләм тотар яшь кулың казый «алтын»...
Ризык таушы яшьтән таныш шул безгә!—
Шигырь бәясе төшмәс бит, әйт, халкым?

❀

«Чакырып алдым әле чакрым ярымнан...»—
Белдем: аерым яши алмам ярымнан.
Җитмеш булсын, йөз, мең чакрым—чакырам,
Жырда сине аерыр көч юк җанымнан!

❀

«Бу илләрдә гашыйк «чал бала» булды...»—
Шундый язу күзеңә чалындымы?—
Балкып, сүнеп, шулай искәртәдер Күк!
...Әллә бу жыр—янмыйча язылдымы?

❀

Ошыймы язганым—нигә язмыйсың?
Көзге уттан курка мәллә яз хисең?
Инде бар җан дөньям егылды Сиңа
Сәҗдәгә—Кояш, Ай, Җир дә... Аз!—димсең?

❀

Онытма (мең елдан соң да!) сөйгәнем:
Иртә-кич шашып янына килгәнем,
Көнләвем... һәм ир башымнан елавым...
Әмма кыен булды—шуннан көлгәнең!

❀

«Какканны... күрдем» сөюдә мин-ятим,
Ихлас «сыйпап үстерде тик милләтем»...
Яшәү—булмас үпкәсез... Була калса,
Милләтнең тәкәббер кызы, сиңа әйтим?!

❀

Нәкъ кырык ел (!)—мәктәп бетергән идем,
Аннан—Уфа, Казанда дарелфөнүн.
Мәскәүдә дә шәкерт идем. Кем булдым?
Түземле бу дөньяга: гафу кыл!—дим.

❀

Ә Уфамда кумир—Атнабай иде;
Дуслыкта—Ай, шәкертләргә бай иде.
«Иде» дим... Аһ! «Кабатланмас канат-дус
Вафат!» диеп, җан өзәр хәбәр килде.

❀

«Йолдызларга йолдыз атылып», гелән
«Очрашканда,—диеп,—көннәр төн белән»—
Синең җырны Ярга җырлаган идем...
Шул мәл җан кошың очканны кем белгән?!

❀

«Кичә берәү китте бу дөньядан», дип
Язган идең, тормышка гашыйк әдип...
Үзең киттең бүген... Олуг матәмең
Күтәрә алырмы энең—чал Рәдиф?!

❀

Күз алдымда бит шанлы гомер кичте,—
Остазларым бакый дөньяга күчте.
Югалтулардан гел тулы Моң касәм
Бушармы бер? Бу җаным күпме эчте!

❀

Алтмышынчы еллар! Шигъри табында
Без, «биш йолдыз», тостлар чөйгән чагында
Ант эчтек бит—һаман тугры калырга
Гасыр ахырында һәм аргы ягында?!

❀

**Күпме хаким, хәким—безнең дәвердә**
**«Сөрде дәүран»... Күпләр инде кабердә.**
**Күпме канун алмашынды! Иман—сау...**
**Шагыйрьлек тә сакланды күк—хәзергә!**

❀

**Дары иснәгән буын, син исәнме?**
**Оныклар хәзер газ, агу иснәрме?**
**... «Герман көе» елаткан милли җанны**
**Инде Әфган, Чечен моңы кисәрме?**

❀

**Азмы—алмалы хыяллар алдады!**
**Коелдымы?.. Яфрагы да калмады.**
**...Бер гаҗәеп яктылык пәйда булды:**
**Ачык күрәм Мәңгелекне... Алланы!**

❀

**Үзгәрде—дуслар, чынлыклар бу йөздә**
**(Юккамы тирән сызыклар бу йөздә?!).**
**Сабыйдай пакь, Йосыфтай матур яшьлек,**
**Сине танып, бүген дәшәр кем безгә?!**

❀

**Һәм якында—Хисап көнең үткәннән!**
**Еллар—гомер, бәлки, бушка үтмәгән?**
**...Һаман багам: туган җир—Җыр башында**
**Бер чишмә бар... Исәндер ул—кипмәгән?**

❀

**Элек, Хыял, йорт-курамнан чыкмадың,**
**Хәзер инде киңәйде офыкларым:**
**Шөкер, күзаллыйм безгәчә дөньяны—**
**Киләчәген чамалыйм оныкларның!**

❀

**Әйтә төштә—әткәң-әнкәңме:—Рәхмәт,**
**Җаныгыз ихлас—тимәстер сүз-гайбәт.**
**Аңлап та бетмәстер, бәлки, бу гавәм,**
**Шигырьгә без—бәхил: ихласлык—әйбәт!**

❀

**Бу—хат елы булды: язам, язылыр...**
**Көн-төн синең тарафка сүз агылыр...**
**Гасыр ахырыннан хатларым! Югалтма:**
**Яңа йөздә аңлаганнар табылыр!**

❀

Сентябрьме? Көннәр көн дә үзгәрер.
«Яңгыр», «аяз»—җырда да сизеләдер?
Шулай да, җырым—алтын көз җимеше;
Татлы, диярсең, ачыккач син дә бер!

❀

Нәрсә әйтим, дусларың әйбәт алар;
Язганымнан «әзләреңне» тапсалар:
—Нинди бәхетле Син!—диләр,—Каракай...
Аһ, безне дә бер шулай яратсалар!

❀

Исмеңә атап, бу китапны язсам да,
Гомер көзем һәм хисем фашласам да,—
Ике дөнья каршында да йөзең ак,—
Фатихаң бир—яңасын башласам да!

❀

Яр! Сафолар, Софьялар, Мариналар...—
Матур затлар,—барыбер җанга чит алар:
«Безнең ил»дә «Гөлҗамал»лар тибрәткән
Талбишектән төшмәгәннәр бит алар!

❀

Көз, димен дә... якты көн дә аз булмый.
Тик җылы аз... Көз шул хискә—Яз булмый...
Бүген сезгә очырам Моң кошымны:
—Синсез яшәү юк: язылмый... Рас! Булмый!..

❀

Сөеклем, дим, «түлә сөю әҗере»н?—
Йөз сүземә бер җавап бир, кадерлем?
...Кайда соң ул, дулап таләп иткән чак?
Ник басылдым, хәтта юаш хәзер мин?!

❀

*(Тәмамлау)*

Ни генә әйтмә, Гаребтән җан гарык:
Аннан алган калып-өслүбем ярык...
Шуңа гел—Хәйям! дим; кайтам Тукайга...
Кайтам, димәк, үзебезгә: без—Шәрекъ!

*1999, сентябрь—октябрь.*

# ПУБЛИЦИСТИКА



## Барлас Камалов

# ҮТКӘННӘРГӘ БОРЫЛЫП КАРАСАМ...

ХӘТЕР— ХАТИРӘ

*Бу гомергә һәммәсе булды насыйп,*
*Тик булмадык нигездә артык кашык.*
*Китмәсәк тә җиде күкләргә ашып,*
*Бәллүр җирдә калдык без туры басып.*

Мөдәррис Әгъләмов.

Яшем житте житмешкә, йөрәк һаман яшьлектә... Бу—егетләнергә маташып сөйләнү генә, әлбәттә. Картлык үзенекен итә, күбрәк истәлекләр белән яши башлыйсың. Тормыш дигәнең адәм баласын чүки, игәүли, чарлый һәм дөньяда өч ямьсез нәрсә барлыгын төшендерә: аларның берсе—фәкыйрьлек-ярлылык; икенчесе—сырхау-чир; өченчесе—картлык-хәлсезлек.

Беренчесе минем ишеләрне куркытмый, ул—гомерлек юлдаш. Шәхсән үземә килгәндә, Ходайга мең шөкер, артык сырхап та интекмәдем. Өченчесе белән дә килешергә туры килә, Табигать кануннары һәркем өчен аерым язылмаган шул. Моңа холкында үпкә үрчетер хәл юк.

Гомер юлындагы чакрым баганаларын күбрәк артта калдырган саен, кеше үзенең үткәненә җентекләбрәк карый башлый булса кирәк. Гомеремнең азмы-күпме йөк салган арбасы да җитмешенче баганасына җитеп килә: мин 1930 елның 17 гыйнварында Чистай каласында дөньяга килгәнмен.

Шундый тойгы белән яшим: гүя тормышымның буеннан-буена күзгә күренмәс кыллар сузылган. Кайчак язмыш аларга оста музыкантларча кагыла (күркәм көннәр кичерәм); ә кайвакыт шул нечкә-нәфис кылларга кувалда белән оралар (ник туганыма үкенерлек халәттә калам).

Әти-әнием—Хәмит һәм Фатыйма Камаловлар Чистай педагогия техникумын тәмамлаган авыл укытучылары иделәр.

Буа районының Янтуган авылына күченеп килүебез истә (1934 елның августы). Тәтештән ат белән килеп төштек. Каршавыл (Камброд) белән Янтуган арасындагы зират. Арбадан аякларын салындырып утырган әтинең сүзләре хәтергә сеңеп калган: «Зиратлары бигрәк ямьсез икән, монда гына үлеп калырга язмасын!»

Язмыш уеныдыр инде: эти 1936 елнын 1 июлендә Янтуганда вафат булды, ләкин бертуган абыйсы Әхәт белән энесе Фоат аны кайчандыр үзе эшләп киткән авылга—Лаеш районынын Татар Сараланы зиратына җирләделәр. Әхәт абый ул елларда Саралан мәктәбендә директор иде.

Шул рәвешле, әни—тол; без, өч бала, сеңелләрем Ралина (1931), Джемма (1933) һәм мин ятим торып калдык.

Ул елларда да тормыш «пар канатлылар» өчен дә җинел түгел иде, егерме алты яшендә өч бала белән тол калган укытучы гаиләсендә көн саен кояш көлеп тора алмаганлыгы аңлашылса кирәк. Әнинең башы бурычтан чыкмавы бәгырьгә уелып язылган.

Эти үлгән елның көзендә, ягъни 1936 елда, беренче класска укырга кердем. Ул вакытта сигездән укый башлыйлар иде, тик мине өйдә бикләп тотудан ни мәгънә?—дүрт яшемдә укый-яза идем ич инде. Хисапта да яшемә күрә тетенем туры йөргән булса кирәк.

Әни әйтеп торгандыр инде, җидееллык мәктәп директоры Зиннәт Гафият улы Вәлиев исеменә гариза яздым. Латин алфавитының гамәлдә чагы бит. Тырыша торгач, «гариза» урынына «гарижа» килеп чыккан. Көлделәр.

Беренче укытучыбыз Рәхимҗан абый Муллин иде. Ул ак финнәргә каршы да сугышты, Бөек Ватан сугышында һәлак булды.

Янтуганнан без 1942 елда киттек. Сугышның кызган чагы иде. Шул ук районның Исәк авылына күчтек. Әни «Революция» колхозында хисапчы булып эшли башлады. Укытучылык хезмәт хакына яшәр мәл калмаган иде инде. Җиденче классны мин Исәк мәктәбендә тәмамладым.

Җиденче класстан соң, 1943 елның көзендә Буа ветеринария техникумына укырга кердем, ләкин «Октябрь бәйрәме»нә кайтканнан соң кабат бармадым. Күңелем тартмый иде. Әни, йомшак холыклы хатын, әллә ни басымчакланмады. Хәзер болай фикерлим: ярый әле теләр-теләмәс укып китмәгәнмен. Яратмый өйләнергә мәҗбүр ителгән кеше төсле, күңелемә чит булган хезмәттә гомерем буе чиләнер идем. Ә болай, яраткан эшем белән кинәнеп шөгыльләнгәч, үземне сират кичеп, фирдәүстә (иң беренче дәрәҗә оҗмахта) утыргандай хис итәм. Әдәби иҗат—минем өчен сәгадәт талы (бәхет символы!). Ветфельдшер булып китсәм, рас әгәре, сукырларга көзге сатучы булыр идем. Ә бит үзләрен ветеринариядә бик бәхетле санаган кешеләр дә аз түгел. Алар да үз һөнәрләренә гашыйк...

Исәктән Кул-Черкен авылына күчеп килгәч, колхозда эшли башладым (ул елларда—«Искра», хәзер «Ватан» күмәк хуҗалыгы). Такыр басу торнасы—артык кашык булып яшәр хәлем юк иде. Политрук ире фронтта һәлак булган апаның (әниемнең бертуган сеңелесе)—җидееллык мәктәп директоры Хәтимә Курамшинаның үзенең дә өч баласы бар иде бит. Дәү әни дә аның тәрбиясендә.

Колхозда үгез дә, ат та җиктем. Кырга тиресен дә чыгардык, чәчүлек орлыгын да, көлтәсен дә ташыдык, көзен Лашчы разъездына бәрәңге заданиесен дә илтә идек. Кордашлар белән эшләү үзенә күрә бер канәгатьләнү хисе бирә иде шикелле.

Үгез җигеп изаланганнан соң атка күчеп утыргач, үзеңне самолетта очкандай сизәсең икән. Үгез—ике мөгез (МУ-2) ашыгуны белми. Сал син арбаңа теләсәң күпме йөк—тартачак, мәгәр ашыктырма. Исе дә китмәячәк. Кыйнасаң да, кан баскан күзләрен акайтып кына торачак. Урысларның «Упрямый как бык» дигәннәрен мин шул елларда аңладым...

Үгез белән тарткалашкан көннәр истә нык калган, хәтта көндәлегем битләренә дә кергән.

Сугыш чорында мин үгез җиктем,  
Рәнҗи идем кире беткәнгә,  
Бар язмышым кире үгез булды,  
Ирешалмадым күңел кәткәнгә...

1944 елның язы бәгырь майларын сыздырган ачлыгы белән истәлекле. И-их, интектек тә соң ачка! Ярый әле, колхоз партоешмасы секретаре йөген дә сөйрәп баручы, Кул-Черкендә мәктәп директоры Хәтимә апа Курамшина, колхоз идарәсе рәисе Кәлимулла абый Алимов белән сөйләшеп, мине язгы чәчү һәм урак өсте вакытына ачылган ашханәгә мөдир итеп билгеләтте. Бер мәлгә тамак тук булды.

Колхозда эшләгәндә, 1944 елны, мине комсомолга алдылар. Шушы елның ук көзендә исә Буа шәһәрендәге Мулланур Вахитов исемендәге урта мәктәпнең сигезенче классында укый башладым. 1945-1946 уку елында тугызынчы классны тәмамлагач, хәл бөтенләй начарланды. Өс-баш чыгып төште, ризык дигәненә өмет киселде. Терәксез калган колмак сабагыдай булдым.

Хәрби училищега китәргә карар иттем. Тик ул ният тә чынга ашмады. Район хәрби комиссариатында эшләүче Украинский дигән бер офицер алдап йөртте-йөртте дә, тәп башына утыртып калдырды...

Шулай нишләргә белми кангырып йөргән көзге көннәрнең берсендә мине Буада яшәүче атаклы артистка Зөләйха ханым Богданова очратып, хәл-әхвәлләремне сораштырды да минем ул житәкләгән агитбригадада район авылларын әйләнеп чыкканым бар иде инде), аннары, кырт кисеп, эш тәкъдим итте.

—Энем,—диде ул,—Буа колхоз-совхоз театрына актерлар кирәк. Яңа оешып киләләр. «Галиябану»ны сәхнәләштерәләр. Син бит безнең шәп артист. Урнаш шунда эшкә. Алар тиздән гастрольгә китәчәкләр...

«Менәр як—атның сул ягы. Камчылау як—атның уң ягы. Сайла, Барлас, бер якны,—дидем үземә.—Йә театрга урнашасың да көн итәрлек жай табасың, йә сукбайлыкта йөрисең ...» Яшьлек хыялым булган театрга керергә ризалаштым. Зөләйха апа театрның директоры һәм режиссеры Исхак абый Дасаев белән сөйләште һәм мин иртәгәсен үк сәхнә эшчесе (театрда рабочий сцены дигән штат берәмлеге бар) һәм актер булып киттем. Ни хәл итим? Талда кунар урыны юк кош сыман идем ич. Карыным белән кар ярып, борыным белән боз тишәргә риза идем.

Театрда эшли башлау 1946 елның декабрендә булды.

Башкарырга тиешле ролем шул иде: Исмәгыйль Хәлилне аткач, йөгереп килеп житкән ике кешенең берсе—мин. Әйтер сүзем: «Бу ни хәл? Ни булды? Нишләделәр?»

Гастрольгә киттек. Беренче тамашабыз Буа районының Ташкичү авылында декабрьнең егерме сигезендә уйналды. Спектакль тәмамлангач, театрның прима-актрисасы Сылу ханым Садрина (директор Исхак абый Дасаевның хатыны) мактады үземне. «Карале, сәхнәдә чирканмыйсың да икән бит син. Яңа әсәр хәстәрли башлагач, роль бирергә кирәк сиңа, тулы роль. Исхакка әйтермен мин...»

(Бераздан төшендем: бөтенләй сәләтсез булсаң да, Сылу ханым кушкач, Исхак абый роль бирәчәк. Садрина апабыз театрда Әби-Патша иде. Ире аның сүзеннән кусан да чыкмый, чыга да алмый!)

Фатирга карт актер Гали абзый Донской белән төшеп йөрдек. Котыш белән Тотыш сыман. Мин аның йомышчысы идем, ләкин ул, күпне күргән, күпне белә торган карт, миңа да байтакны бирде.

Йомышчылыгым базага—Буага кайткач аңа бик хажәт була торган иде. Ул ялгыз маржада фатирда торды. Хужабикә, саулыкка туймыйча картаеп баручы хатын, Гали абыйга әллә ни хезмәт күрсәтә алмый иде. Ә мин йөгерәм генә. Төп эшем кибеткә йөрү, азык-төлек юнәтү һәм, әлбәттә, аракы алып кайту.

Кәефләнеп алгач, ул Әстерхан театрында узган яшьлеген сагынып сөйләргә ярата иде. Урыс театры корифейларының әсәрләрен бик еш телгә ала, алар тәгълиматын иң садә төстә миңа ирештерергә тели иде. Немирович-Данчеко исемен мин беренче тапкыр аңардан ишеттем. К. С. Станиславскийның «Моя жизнь в искусстве» дигән бик шәп китабы турында да миңа башлап ул сөйләде (бу хезмәтне мин соңыннан, студент елларымда укыдым).

Шулай башланган «актерлык эшчәнлегем» 1946 елның декабреннән алып 1948 елның июленә кадәр дәвам итте. Миңа Гамир Насрыйның «Күңел дәфтәре»ндә—Зәйнетдин картны, Сәет Кальметовның «Безнең кияү» комедиясендә—Шәңгәрәй картны, Риза Ишморатның «Бүләк» пьесасында Хәйдулла абзыйны уйнарга туры килде. Әсәрне сәхнәгә драматург, әле гимнастеркасын да салырга өлгермәгән фронтовик-майор Риза Ишморат үзе куйды. Без аның белән шул елдан бирле танышлар, дуслар булдык. Риза ага Ишморат әсәрен репетицияләгән көннәрнең берсендә болай диде: «Син уйный торган карт образ түгел әле, рольдә уйнау гына. Тора-бара моны ныклап төшенерсең»,—диде. Ул бик хаклы булган.

Танылган драматург һәм режиссер Риза абый туксаннан узып вафат булгач та ул сөйләгән бик күп истәлекләрне гыйбрәтле хатирәләр итеп уемда яңартам.

Гастрольләрдә йөргәндә, спектакльләрдән тыш, колхоз-совхоз театры артистларының концерт программалары да бар иде. Ул концертларда минем өлешем нәфис сүз белән катнашудан гыйбарәт иде. Габдулла Тукайның «Су анасы»н, «Китмибез»ен, Һади Такташның «Мокамай», «Туң трагедиясе»н, Әхмәт Фәйзинең «Әүхәдинең хатыны Майшәкәр белән саубуллашуы»н, Фатих Кәримнең «Өмет йолдызы» поэмасын укый идем.

Театрда мине «Яшь карт» дип йөрталәр иде. Чыннан да, унжиде яшендә картлар

роле белән кинәндерүләре үзе бер мәзәк хәл ләбаса! Егетләр ролен да уйнаганым булды булуын. Әйтик, Сәет Кальметовның «Йолдызлар балкый» әсәре буенча автор үзе үк сәхнәгә куйган спектакльдә фронттан кайткан егетне башкарган идем.

Гомеремдә бер тапкыр миңа «Галиябану»да Хәлил булырга да туры килде. Ничарадан бичара хәл иде бу. Хәлилне уйнаучы актерыбыз—Әхмәт абый Галиәкбәров суык тидереп, нык авырып китте. Спектакльне өзсәк, акча да җыелмый кала, иртәгәсен күрше авылга күчәргә атлар яки үгезләр дә бирмәячәкләр. Директор һәм режиссер Исхак абый Дасаев: «Өзмибез тамашаны. Хәлилне син уйныйсың!»—диде. Сүзләрне яттан беләм, һәр көнне шуларны кабатлыйбыз бит. Яшьлек тә бар, «кыяфәт тә»—Хәлил димәслек түгел. Ә менә җырга килгәндә, юк инде, иптәшкәем, юк. Мәҗлесләрдә кешегә кушылып җырлаган булам да соң, Хәлил түгел инде. Шулай да тәвәккәлләдем, Хәлил киемнәрен кидем, гармунны кулга алдым. Чынында бит Әхмәт абый Галиәкбәров та үзе уйнамый, арттан баянчы-гармунчы Хафиз Сөләйманов уйный (ул тумышы белән Буа районының Аксу авылы егете иде).

Хәлилнең Галиябану тәрәзәсенә килер чагы житте. Кайнар укол кададылар диярсең, пешеп чыктым. Борылып: «Бар куәтенә кычкыртып уйна, Хафиз!»—дим. Аллага тапшырып, җыр башладым:

Билемдәге ал билбавым
Тормый кыстырган җирдә;
Үзе чакыра, үзе кача,
Галиябану, сылуым иркәм,
Чыкмый сызгырган җиргә...

Галиябану—Мәдинә Гатиятуллина тәрәзә янына килеп, җавап җырын суза. Ул яхшы җырлый!..

Тәвәккәл таш ярган, диләрме? Ерып чыктым бит тәки! Труппабыз белән сөенештек, спектакль өзелмәде ич!

Мәдинә Гатиятуллина (ул—Казан кызы, атаклы балетмейстр Мансур Гатиятуллинның сеңелесе) кәефемне тәмам күтәрде. «Чын егет белән дә кара-каршы уйнар көнем бар икән!»—ди. Салпы якка салам кыстыруын чамалыйм, шулай да күңелгә рәхәт!

Иртәгәсен чаналарга декорацияләрне төяп ятабыз, бу авылның мәктәп директоры укытучы хатыны белән мәктәпкә табан узып бара. Хәләле нигәдер турсайган иде бугай, аңа сүз кушарга җыеныптыр инде, миңа күрсәтеп:

—Таныйсыңмы кичәге Хәлилне?—дигән булды. Нишләсен, яшь ханым да ирен чите белән генә елмаеп куйды:

—Таныйм, таныйм, бик яхшы уйнады,—дип тә өстәде.

Шуннан сөйләшеп узып киттеләр. «Яхшы уйнауның ни икәнен бик яхшы беләбез дә бит,—дим эчемнән генә.—Җәннәткә гөнаһлар җибәрми. Җырчы булмагач, ни хәл итим?..»

Ике елга якын гомер эчендә дистәгә якын рольдә чыгыш ясадым. Ярата идем сәхнәне, хәзер дә ихластан яратам. Үзешчәннәргә кушылып уйнарга бүген дә әзермен. Әмма ул елларда укыйсы килү теләгем һәммәсеннән дә көчлерәк иде. Өс-башны беркадәр рәткә-юньгә китергәч, кышлыкка дип унбиш-егерме потлап бодай алып куйгач, унынчы класста укый башладым. 1949 елның җәендә урта мәктәпне тәмамлау турында аттестат алдым. Түбәм күккә тиде, тик... бу әле юлның башы гына иде. Югары белем аласы бик килә, мәгәр ничегрәк итеп яшәргә?

Фанер чемоданыма хәзинәдә барын—запас бер күлмәк, бер трусикны һәм китапларны салып, Казанга юл тоттым. Исәбем вагон түбәсендә бару иде. Юлга бер тиен дә акчам юк. Ходайның рәхмәте дими, ни дисең, тарихтан укытучыбыз Гөлсем Галләмовна Султиева очрады (ул—Янтуганныкы, әтиемнең дә, әниемнең дә укучысы.) «Юлыңа акчаң бармы соң?»—дип сорады. Бик кыенсынсам да турысын әйттем. Ул миңа егерме алты сум акча бирде. Нәкъ билетлык. Бу—мине поездга түгел, олы тормышка озату иде.

Иртәнге бишләр чамасы иде шикелле, Казанга килеп төштем. Барып сыеныр урыным бер генә—Щапов урамындагы тугызынчы йортның икенче фатиры. Анда үзләренең биш баласы белән әти ягыннан кардәш Хәйдәр абый Камалов һәм Гашурә җиңги яши. Абый, туфрагы җиңел булсын, йомшак күңелле кеше иде. Шофер правосын алдырганнан соң тимер юл вокзалындагы посылкалар ташу бүлегендә каравыл торды.

Гашурә җиңги (без аңа «Гашура апа» дип эндәшәбез) гомере буе авыр эштә булды, ниндидер «снаб»та йөк төяде, йөк бушатты. Бик яхшы җөйчә. Миңа, минем сеңелләремә

генә дә күпме кием тегеп кидерде самими, ярдәмчел жан!

Аларны уятып кермәдем. Кояшлы, аяз иртә иде. Йокыларыннан торып, аякланууларын көттем. Үзем көтәм, үзем үртәләм. «Менә урманда—урынсыз, кырда койрыксызлык галәмәте!» Гомерем булып, һөнәр алып, йорт-жирле яисә фатирлы була калсам, елның теләсә кайсы вакытында, тәүлекнең теләсә ниткән сәгатендә туган-тумачаны гына түгел, дус-иш, таныш-белешне генә дә түгел, монарчы күз күрмәгән мосафирны да кертеп кундырырмын, кирәксә, соңгы сынык ипиемне бүлешермен»,—дим үз-үземә. Әтисез дә, әнисез дә булгач, (әни 1944 елның 31 мартында вафат булды), кунар куагын булмау аерата сиздерә бит ул.

Шапырынуга кермәсен, шул антыма тугрылыклы мин.

Гашурә апа мине гадәттәгечә бик ачык каршылады. Кабул итү имтиханнарына килүемне белгәч (документларны шул көнне тапшырдым): «Үзебездә торырсың»,—диде. Әй кин күнелле кеше дә соң! Гадел хезмәт кешеләре арасында, шөкер, андыйлар аз түгел бит әле, түгел!

Сульяк Болак белән Мартын Межлаук (соңгы елларда шулай атала) урамнары кисешкән жирдә Казан дәүләт педагогия институтының төп бинасы урнашкан. Кабул итү комиссиясе дә шунда. Документларны тапшырдым. «Тулай торак кирәкме?»—ди директорның алгы бүлмәсендә утыручы зур гәүдәле, зур борынлы, бөдрә чәчле яһүд агай. Күзлек пыялалары артында зур ачылган күзләр. Кырыс, кискен.

—Кирәксә, әнә теге ишектән директор янына кереп, менә бу ордерга имза сырлатып чык... (Ул елларда ректор фәкать университетта гына булып, башка югары уку йортларының башлыклары директор дип йөртелә иде.)

Керсәм... бар булдыгымны сөенеч басты. Зур кабинетта, «Т» хәрефе ясап сузылган зур өстәлләр түрендә Йосыф Әхмәтжанович Туишев утыра. Ул бит Телеграф тыкрыгындагы махсус урта мәктәпнең директоры иде, ә минем ул мәктәптә сигезенче классны тәмамлагач, ике ай чамасы укып алганым, погоннар тагып йөргәнем дә булды бит. Күз дигәнең йомшаграк булу аркасында кире Буага кайтып киткән идем.

—Уз әйдә, уз. Тулай тораккамы?—Ул ордерны алырга кул сузды һәм мине исенә төшереп өлгерде:

—Махсус мәктәптә укып алган идеңме әле?

—Әйе, абый.

—Бөдрәләреңнән таныдым. Инде безгә, институтка килдеңме? Әйбәт булган. Карале, Камалов, ялгышмасам, син круглый сирота бит, әйеме?

—Әйе, абый. Укытучы балаларыннан, әти-әниләре үлгән булса да, укыган өчен түләтмиләр дигәч, монда килдем.

—Шуның өчен генәме?—Туишев агайның күзләрендә үпкәме, шелтәме очкыны кабынып сүнде.

—Соң укытучы һөнәре мина бик якын инде ул.—Сөйләшә белми торган мәнсез бәндә булуым өчен үземне чәйнәп ташлар хәлгә житкән идем.

Директор ордерга кул куйды һәм стена буендагы урындыкларны күрсәтте. Бу аның «утыр» дигәне иде. Үзе телефоннан шылтыратып, Бирюшев дигән берәүне чакырды. Тиз арада озын буйлы, кара тутлы бер абый килеп керде. Фронтовик булырга тиеш, бер кулы гарибрәк.

—Менә, Рашат, безгә бер тырыш малай килә. Татар теле-әдәбияты бүлегенә. Мин аны дүрт-биш елдан бирле беләм. Спецшколадан. Ул шыр ятим. Хәзер дә менә кесәсендә бер тиене юк, иманым камил. Профкомда сөйләш, акчалата булышыгыз. Хәзер үк. Аннары мин үз фондымнан карармын. Беренче экзаменыңны биргәч тә минем яныма кер, Камалов, ярыймы?

Рашат абый Бирюшев институтның ВЛКСМ комитеты секретаре икән. Тарих факультетын тәмамлап, аспирантурага калган.

Ике йөз сум акча биреп, кул куйдырдылар. Бер кирпеч ипи сатып алып, Гашурә апаларга кайтканда, мин жирдәге жәннәтнең жиденче катында идем. Ник дигәндә, жавап анык: фитрәт көннәре—кризис кичерә идем ләбаса! Инде болай булгач, фәлән-фәсмәтән, катык-сөзмәдән дигәндәйләрне дә авыз итәргә мөмкин булачак!

Институтның беренче тулай торагында, Зур Кызыл урамындагы борынгы монастырьда яшәп, керү имтиханнарын тапшыра башладым.

Беренче имтихан—урыс әдәбиятыннан сочинение. Ике тема—берсе мәктәп программасы буенча өйрәнгәннәрдән, икенчесе—ирекле. Бүгенгедәй хәтердә: «Я знаю—город будет, я знаю—саду цвесть». В. Маяковский.»

Мин ирекле теманы сайладым. Буадагы М. Вахитов исемендәге урта мәктәпнең унынчы классын бергә тәмамлаган сабакташларым Мөһит Мөхәммәтжанов (Исәк авылыннан), Даян Бикмуллин (Чәчкап авылыннан, моннан берничә ел элек вафат булды) янәшәмдә. Мөһит—көчле математик, сочинение аңа авыр бирелә, шунадыр минем янәшәмдә булырга тырыша.

Төп бинаның 67 аудиториясендә барлык факультетларга керүчеләр бергә язабыз. Иң арткы рәткә утырган идек, имтихан алучы Корбан Тимергалиевич Вәлитов, нидәндер шикләнеп, безне иң алгы рәткә күчереп утыртты. Бу аның тарафыннан чебенгә чукмар күтәрү иде инде. Без болай да куркып-имәнеп кенә тора идек. «Һәй, чиркәү мәәзине!»—дип мыгырдандым, тик тыңламый хәлебез юк иде. Ядәчен киергән дә усал карап тора!

Иртәгәсен урыс теле һәм әдәбиятыннан телдән имтихан тотканда сочинениене «хорошо»га язганымны белдем. Ике урында өтерне санга сукмаганмын икән. Әмма Вәлитов агай миннән канәгать икәнлеген яшереп тә тормады. Телдән җавапларыма «отл» куйды.

Географиядән керү имтиханын Сара апа Еникеева алды. Билеттагы сорауларга җилле генә җавап бирдем кебек. Һәрхәлдә, бәйләнмәде, ризасызлык белдереп, чырай сытмады. Соңыннан карталар буйлап куа башлады. География кабинетының стеналары төрле карталар белән тулы. Йөгерә-йөгерә җавап бирәсең. Мәгәр шундый итеп куа, өлгерер хәл юк. Мәктәптә дә шулай тинтерәткән булсалар икән, дим. Кыскасы, бу апа миңа «хор»ны куеп чыгарды. Бик риза-бәхил идем инде. Карталар янында житез булалмадым бит!..

Немец теленнән «хор»ны фәрештә канатын җәюе аркасында гына булуын әйтергә тиешмен. Күпме генә тырышып хәстәрләнгән булсам да, мин имтиханны «яхшы» билгесенә бирә алмаячак идем.

Имтиханга керер алдыннан мине доцент Маһинур апа Фәйзуллина эзләп тапты. «Фатыйма улы икәнсең бит. Әниең чалымнары бар шул. Бөдрәләрең әниеңнеке»,—дип сөйләшеп китте ул, хәл-әхвәл сорашты.

Мин хәлемнең мөшкеллеген туп-туры әйттем. Берәр фәнне «өчле»гә бирсәм, стипендия булмаячак, хәрби училищега китәрмен дип килдем, дидем.

Маһинур апа имтихан алучы Баһаветдинова апа янына кереп чыкты. Минем чаманы аңлаткандыр инде.

Баһаветдинова апага мең рәхмәт! «Хор»ны кызганмады. Шунда әйтте:

—Укый башлагач, тырышыгыз инде!—диде.

Вәгъдә бирдем һәм сүземдә тордым.

Икенче курс азагында холыксызлыкның аръягындагы Морозовага да имтиханны «отлично»га тапшырдым. Шуның белән мин кабул итү имтиханында биргән вәгъдәмне дә үтәдем, ике курс дәвамында бер генә «хор» да алмаган һәм җәмәгать эшләрендә җин сызганып йөргән активист буларак, өченче-дүртенче курсларда иң зур стипендияне—Сталин исемендәгесен алдым. Мәгълүм бер горурлык белән раслый алам: кызыл дипломымның кушымтасында «зачтено» һәм «отлично» дигәннәрдән башка билге юк.

Мине аспирантурага калдырдылар. Кандидатлык минимумының да иң җәфалысы, сырхауга сабыштыра язганы немец теле булды. Монда инде милләте белән немка—Хованько түти—Хак Тәгаләнә дә исе китми торган адәми зат кирәкне бирде. Кабул итү сынавында миңа «канәгатьләнерлек» куйды, укуны тәмамлаганда «яхшы»сын кызганмады.

Янә институтка кергән көннәргә кайтыйм әле.

Беренче имтиханнарны уңышлы тапшыргач, Йосыф абый Туишев янына кердем. Бу юлы кабул итү бүлмәсендәге яһүд агай—Александр Абрамович Фрумин әллә ни тоткарламады (без аны үзе артында Трумэн дип тә атый торган идек).

Йосыф абый директор фондыннан ике йөз сум яздырып бирде. Рәхмәтем чиксез иде. Беренче стипендия көненә—22 сентябрьгә кадәр тамагым тук, күңелем көр булды. Үземне кеше итеп тойдым.

Күп еллар үткәч, Йосыф Әхмәтҗановичны соңгы юлга озатканда, минем, сакаллы сабыйның, кешеләрдән качып елавым да шуларны хәтерләп иде.

Әйе, институтта барлык фәннәрне дә диярлек күңелгә якын алып укыдым. Шулай да бер төкәнү ташына абына язып калдым. Предметы да төшенмәслек тә, укып өлгермәслек тә түгел. Нибары егерме ике лекция. «Мәктәп гигиенасы». Безгә аның буенча лекцияне шәһәрдә бердәнбер белгеч саналган Рашат Суняков дигән зат укыды.

Өлкән курс студентлары кисәткәннәр иде. «Сак бул!—дигәннәр иде алар.—Суняков

абзагыз, ни гажәптер, студент егетләрне өнәми, тоташ «отлично»га укучыларны үз итми».

Чыннан да, шулай булып чыкты.

Парта капкачының калынлыгын әйткәндә ике миллиметрга хаталандым. Шул житә калды.

—Мин сезгә «отлично» куя алмыйм. Икенче билет аласызмы?—ди һәм калын пыялалы күзлеге аша сөзеп карый.

Алдым. Чатнатып жавап бирдем.

—Әгәр өченче билетка да шулай жавап бирсәгез, «отлично»,—ди мөхтәрәм мөгаллимебез.

Өченчесен дә алдым. Бәйләнер урыны калмады. Ин югары билгене куйды. Әмма минем нервылар балалайка кыллары хәленә килеп, зенләп тора иде...

Инде чын күңелдән үз иткән, ярты гасырга якын гомер үткәч тә сагындыра торган укытучыларыбыз турында язып узыйм.

Студент халкы XIX гасыр башы рус әдәбияты тарихы буенча лекцияләр укучы Семен Николаевич Никольскийны бик ярата иде. Гадилеге, кешелеклелеге, тирән белеме өчен. Аңа булган тирән ихтирамны коммунист студентлар ул бәлага тарган бер очракта күрсәттеләр.

Ниндидер әләкче-көлавыз институт дирекциясе һәм парткомына пышылдаган: Никольский үзе укыткан фәннән читтән торып укучы бер студенткадан имтиханны ресторанда эчеп утырганда алган, имеш.

Бәйләнәләр. Абзыйның, чыннан да, капкалау гадәте бар. Ни өчен эчкәли, анысын уйлап та бирмиләр, шуна ябышып пычратмакчылар.

Кая ул! Һәммә факультетлардан студентлар (ул чакта фронтовиклар да бар әле) шундый итеп күтәрелделәр, партком секретаре мондый мәсьәләне жыелышка куюына үкенеп бетә алмагандыр...

Татар теле һәм әдәбияты бүлегендә доцент Якуб Хәлил улы Агишевның абруе бик олы иде. Күпне күргән. Эрудит. Демократ. Партиясез. Курыкмый. Инанганын сөйли. Лекцияләре тирән мәгънәле дә, мавыктыргыч та. Сөйләү остасы. Аның лекцияләрендә йокыга китмисең яисә кызларга хат сырларга утырмыйсың инде. Авызыңны ачып тыңлыйсың, кайчак кәгазьгә теркәп барырга тиешлегенне дә онытып жибәрәсең...

Миңа ул икеләтә якын иде. Остазым буларак та, әтиемнең дусты буларак та. Аларның дуслыгы, фикердәшлеге 1932 елда ук башланган. Бу вакытта әтием Лаеш районының Саралан авылы мәктәбендә директор була. Ә 1930 елда Казан дәүләт педагогия институтында укый башлаган Якуб Хәлил улы Саралан мәктәбенә педагогик практикага килә.

Якуб абый әтидән ун яшькә өлкән булса да, үзара уртак тел тапканнар.

Мин Якуб абыйны педагогия институтының беренче курсында укый башлаган көнне 80 мәктәп бинасында (аның ике этажын пединститут били иде) очраттым.

—Беренче курс студентлары исемлегендә күрдем фамилиянне,—диде ул.— Стипендия алырлык булып кергәнсең икән. Монысы—яхшы... Керү имтиханнары биргәндә нигә килмәдең безгә? Адресны деканаттан алырга иде. Белешмәләр бюросы бар, наконец...

—Борчыйсым килмәде,—дидем.

—Бу кадәр дә әниеңә охшамасаң... Әтиең ут уйната иде!..

Укый башлагач, мин Якуб абыйларның фатирына баргаладым. Хатыны Хәдичә апа да бик ачык каршылый иде. Уллары Рөстәм белән дә дуслашып киттек...

Ул елларда (илленче еллар башында) уку отличникларын һәм жәмәгать эше активистларын бик килешле итеп хуплый беләләр иде. Әйтик, мин өченче курсны тәмамлаган жәйдә, 1952 елда, профком бер төркем уку алдынгыларын илебез башкаласы Мәскәүгә туристлык сәяхәтенә жибәрде. Күбебезнең, шул жөмләдән минем дә, Мәскәүне беренче күрүебез иде. Тау тикле тәэсирләр белән кайттык.

Өченче-дүртенче курсларда исемле стипендия алып уку миңа сеңелем Ралинаны (соңрак кече сеңелем Джемманы да) институтка китерергә, тулай торакка урнаштырырга жай бирде.

Педагогия институтында үткән чор минем өчен бик күп нәрсәләрнең борынлап китүе белән бәйле.

Беренче шигырьләр. Яшьлегендә шигырь язмаган кеше булмыйдыр. Мин иниң беренче шигыремне Буа районында ул чакта «Яңа юл» исеме белән чыккан гәзитә дә бастырдым. Май бәйрәменә багышланган иде шикелле. Тезмә юллар теркәлгән

дәфтәр битенә районга ниндидер казна эше белән килгән Ибраһим абый Гыйльфановтан цензура мөһере дә бастырып алган идем. Мөһерле нөсхәне гәзитә редакторы Нәҗип Гобәйдуллин үзенә алып калган иде (перестраховка өчен!).

Студент булгач, «Яшь сталинчы»да (хәзерге «Татарстан яшьләре») бер-ике шигырем басылды. Монысы шагыйрь Сәхаб Урайский ярдәменә бәйләнгән. Шигырьләр, әлбәттә, Сталинга мәдхия җырлаучы юлларыннан гыйбарәт иде.

Әле дә булса тезмә юллардан бизгәнем юк. Кайчак үз-үземә сорау да куям: прозаик башың белән ни дип чиләнәсең әле рифма-ритм җәһәтеннән? Бу сораугa үзем үк җавап бирергә тиеш бит инде. Эш болайрак тора: миннән шагыйрь чыкмасын институтның беренче курсында укыганда ук аңлаган идем, берничә шигырем матбугат йөзе күргәч. Мәгәр шигырьдән бизмәдем һәм бизмәмен. Шигъри әдәбиятны сатып алып та укыйм, китапханәләрдән алып та. Шигырьсез (чын шигырьсез!) яшәү тутык дөнья белән бер миңа.

Фикерле, асыл бизәкле, хис-тойгыларга да жим бирерлек, уйландырырлык, рухландырырлык шигъри юлларны шагыйрь булып туган зат кына яза ала. Минем тезмә юлларым фәкать үзем өчен генә. Әсәрләремә кереп киткәннәрe дә теге яки бу персонажның күңел чайпалышы нәтиҗәсе. Алар—шагыйрь түгелләр, ләкин теләсә ничек сөйләргә һәм язарга хаклы кешеләр.

Беренче хикәям... Ул да «Яшь сталинчы»да дөнья күрде. «Күңел газабы» дип аталган бу өйрәнчек әсәр дүртенче курста укыганда, 1953 елның 20 февралендә басылды. Аның гәзитә сәхифәсенә кереп китүенә ул елларда үзе дә яшь язучы исәпләнгән Гариф Ахуновның булышлыгы тигәнен әйтү кирәк.

Журналистикага беренче адымымны да яшьләр гәзитәсендә ясадым. Студент чагында ук эшли башлаган иде, күрәсең, соңыннан радиожурналист булып киткән Роберт Гатауллин миңа ял паркларының җәйге сезонны башлап җибәрергә хәзерлеге турында язарга задание бирде. Бүгенгедәй истә, башлап Үзәк паркка юнәлгән идем. Мәкалә чыкты. Шуны юл башы дип саныйм.

Аннан соң йөзләгән мәкаләләр бастырдым. Редакторлар Гали абый Хуҗи, Рашат Гайнанов, Рафак Тимергалин хуплап тордылар. Гали Хуҗи абый белән без нык дуслашып киттек. Мин аны, Риза ага Ишморат, Шәрәф абый Мөдәррис, Зәки абый Нури белән беррәттән, әдәби остазым дип саныйм. Һәммәсенең якты истәлеген гомерем азагынача күңел түремдә изге саклаячакмын.

Үземнән шагыйрь чыкмаячагын аңлагач, тәнкыйтьче булырга ниятләдем. Бу өлкәдә мин Ибраһим абый Нуруллинга соклана идем. Форсаттан файдаланып әйтим, ул—миңа булышучы зат иде. Берничә әсәремне укып, бәяләп, яхшыртуга нык ярдәм итте.

Әдәби рецензияләр, тәнкыйть мәкаләләре язып карадым. Шундыйлардан хәзерге «Совет әдәбияты» журналында (хәзер «Казан утлары» журналы) басылганнарының берничәсен күрсәтим: «Таләпчәнлекне киметмәскә!» *(«Совет әдәбияты», № 11, 1953 ел)*, «Партизан малай» *(«С.Ә.», № 4, 1954)*, «Безнең заман» *(«С.Ә.», № 9, 1955)*, «Тормыш юлында» *(«С.Ә.», N 7, 1956)*, «Ямьле Ык буйлары» *(«С.Ә.», № 5, 1956)*, «Үсү юлында» *(«С.Ә.», № 9, 1956)*, «Мирхәйдәр Фәйзинең иҗат лабораториясеннән. «Галиябану» драмасының язылу тарихы» *(«С.Ә.», N12, 1956)*, «Кыска хикәяләр» *(«С.Ә.», № 11, 1958)* һәм башка бик күпләр.

Әдәби тәнкыйть дөньясына юл башы әнә шундыйрак булды.

Соңгы араларда, картларга хас бер кызыксыну белән, очеркларымны һәм бу жанрга карата язганнарымны барлап чыктым. 1959-1998 елларда алтмыштан артык очерк биргәнмен икән. Күп диярлек түгел, әмма хикмәт санда гынамыни?!

Әйткәнемчә, институтны тәмамлагач, гыйльми совет мине татар әдәбияты буенча аспирантурага тәкъдим итте. Фәнни җитәкчем итеп Җамал Гали кызы Вәҗиеванны билгеләделәр. Кандидатлык минимумын ярыйсы гына тапшырдым, диссертациягә керештем. Темам «Мирхәйдәр Фәйзи драматургиясе» иде.

Диссертация язылды, ике кат кафедрада тикшерелде (кафедра мөдире Абдулла Җамалетдин улы Сайганов иде), 1956 ел көзендә яклауга куелырга тиеш иде.

«Хәерчегә җил каршы,—дигәндәй,—алдан булса—тезе туңа, арттан булса—оны туза.» КПССның XX съезды И. В. Сталинның шәхес культын пыран-заран китерде. Ә минем диссертациям, бик күпләрнеке шикелле, Сталинның әдәбиятка кагылышлы фикерләре, теге яки бу чорга, вакыйгаларга карата әйткәннәреннән цитаталар белән

шыплап тутырылган, гомумән, сталинизм рухында язылган иде. Моны ул чор үзе таләп итә, ә фәнни житәкче, «муен тамырына төеп», шуны даулый иде. Диссертациянең бу варианты узмаячагы кояшлы иртәдәй ачык булып калды. Хакыйкать шуннан гыйбарәт иде. Моңа да карамастан, миңа өлкән укытучылыкны тәкъдим иттеләр. Стационарда да, читтән торып укучылар белән дә эшләргә, татар совет әдәбияты һәм нәфис сүз укытырга тиеш буласы идем. Эш торак мәсьәләсенә килеп терәлде. Институт житәкчесе, хөрмәтлебез Йосыф ага Туишев кырт кисте:

—Тулай торактан бүлмә бирә алмыйм. Комсомол, профсоюз конференцияләрендә ишетеп торасың бит, студентлар бугаздан алалар: «Акчалы укытучылар тулай торакта мәйдан билиләр, студент халкы фатирга түләп ыштансыз кала!»—диләр...

Һәммәсенә кул селтәп, Буа районы гәзитәсе редакциясенә эшкә кайтып киттем. Хатыным, әнисе өендә яшәп, Буадагы Луначарский исемендәге урта мәктәптә һәм Буа ветеринария техникумында укыта иде. 1954 елның 26 апрелендә туган Рөстәм әбисе кулында үсә иде (энесе Рәшит нәкъ биш елдан 1959 елның 25 апрелендә дөньяга килде).

Алгарак узып булса да әйтим: диссертация якланмаса да, тупланган материал, ясалган нәтижәләр, куелган көч бөтенләй үк әрәм булмады. Байтак еллар үткәч, 1987 елда Татарстан китап нәшриятында «Мирхәйдәр Фәйзи» дигән китап бастырып чыгардым.

Буа район гәзитәсе редакциясендә баштарак—тәржемәче, аннары жаваплы секретарь булдым. Редактор урынбасары булып беркадәр эшләгәч, мине Казанга, «Татарстан яшьләре» редакциясенә редактор итеп күчерделәр. Мәскәүгә, ВЛКСМ Үзәк Комитетына әңгәмә-консультациягә, расланугa барып кайттым.

Буа белән жылы гына саубуллашырга туры килде. Райкомның беренче секретаре Георгий Федорович Мамаков саубуллашканда әйтте:

—Җибәрмәскә ни тырышып карадым, булмады. Яшьләр партия өлкә комитетының икенче секретаре Салих Гыйлемханович Батыевка кергәннәр. Ул сине күчерергә вәгъдә биргән... Мин, Барлас, сине райкомга идеология буенча секретарь итеп алмакчы идем,—диде.

Ә минем, турысын әйтим, Казанга бик-бик күчәсем килә иде. Бу кала—әдәби мәркәзебез бит. Бөек Тукай әйткәнчә, «монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур». Мин исә язарга ныклап керешергә карар кылган идем.

Буада эшләгән чагында Татарстан китап нәшриятында беренче жыентыгым—«Гомер иткәндә» дигән тупланмам дөнья күрде. Бу хәл, беренче улым тугандагы кебек үк, олы шатлык китерде.

Жыентыкның кульязмасына эчке рецензияне күренекле әдипләребез, әсәрләрен укып үскән язучылар—Мирсәй ага Әмир белән Ибраһим абый Гази яздылар. Алар, нигездә, уңай фикер әйткәннәр иде. Үзем турында үзем күп сүзләнгәнче, остазларым буларак ихтирам иткән язучылар әйткәннәрнең берничә җөмләсен китерим. Мирсәй абый Әмир болай язган иде:

*«... Иң әһәмиятлесе: Барлас иптәштә «ана сөте белән кергән» язучылык таланты бар... Моның өстенә бу яшь язучының теоретик яктан да хәзерлеге бар икәнлеге күренеп тора. Әдәби әсәрне чынлап та әдәби итә торган художество чараларын, тегe яки бу күренешне жанлы итеп сурәтләү юлларын ул, күп кенә башлап язучыларга хас булганча, интуиция белән генә түгел, ә белеп, аңлап куллана. Бусы инде нур өстенә нур дигән сүз.*

*9.Х.1958.»*

Ибраһим абый Газиның фикере мондый:

*«... Ипт. Камалов, кайбер яшь язучылар кебек, телсез язучы түгел, ул халык телен яхшы белә, халык теленнән оста файдалана, тик кайвакытта ешрак файдалану белән арттырыбрак җибәрә.*

*Икенче күңелгә килә торган нәрсә автордагы юмор, дөресрәге, сатира элементлары. Шуның өстенә ипт. Камаловның тормыш мәсьәләләрен куюда да осталыгы (юк, өлгерлеге, җитезлеге дисәк, дөресрәк булыр) бар. Мондый сыйфатлары булган кешедән вакыты белән яхшы язучы үсәр дип өметләнергә була. Октябрь, 1956».*

Хикәяләр, повестьлар язуымны дәвам иттем. Төп хезмәттән һәм жәмәгать эшләреннән соң вакыт бик аз кала иде югыйсә. Әмма яшь чакта аруны белмисең икән ул. Хәзер үзем дә гажәпләнгәләп алам, ничек өлгергәнмен? Комсомол райкомы бюросы әгъзасы, партия райкомы лекторы (1957 елда 72 лекция укыганмын), татар һәм урыс драма түгәрәкләре житәкчесе (үзем дә уйнап), район радиоузелында татарча тапшыруларны алып баручы редактор-диктор. Кичен эштән кайтканда, райком

каршындагы фатирым янында ат яки машина көтеп торучан.

—Кайсы колхоздан?—дип белешәм дә, хәзер чыгам дип, тамак ялгарга кереп китәм. Аннары—колхозга, лекция укырга! Рәхмәт, халык күп җыела иде. Игътибар белән тыңлыйлар, сораулар байтак була.

Буада эшләгәндә гаять истәлекле бер вакыйга булды. Мин 1957 елда яшьләрнең һәм студентларның VI Бөтендөнья фестиваленә бардым. Районнан дүртәү идек: ВЛКСМ райкомының беренче секретаре Наил Зарипов, Кыят совхозы тракторчысы Виктор Цыганков, «Кызыл йолдыз» колхозы (Карлы авылы) сыер савучысы Гөлфия Мифтахова һәм мин.

Шушы грандиоз вакыйгага катнашу беренче тапкыр ил чикләрен атлап чыгуга тиң иде. Дөнья киңлеген тойгандай булдым.

Казанга күчеп эшли башлагач, җаваплылык күпкә артса да, мәшәкать бераз кимеде. Дөрес, монда да ВЛКСМ өлкә комитеты бюросы әгъзасы, әледән-әле эш куша торалар иде, ләкин районндагыча чабулыйсы түгел иде инде.

Бердәм, тату коллективта эшләдем дип әйтә алам. Нигездә. Ни өчен нигездә дим?

Комсомол Үзәк Комитетыннан расланып кайткач, эшкә керештем. 1959 елның 16 октябрендә «Татарстан яшьләре»н беренче мәртәбә кул куеп чыгардым. Редакция хезмәткәрләренең һәммәсе диярлек берәм-берәм яныма кереп, сөйләшеп, зар түгеп чыктылар. Кечкенә генә коллективта да ике-өч төрле позициядә торучылар барлыгы беленде.

Эшли башлавыма ун көн дигәндә коллективны җыеп алып, киңәшмә уздырдык. Бу чара миңа: «Хөрмәтле каләмдәшләр, минем янда күбегез булып чыкты. Һәркайсыгызны дикъкать белән тыңладым, аңларга тырыштым. Күңелемдә кырык бер сер тартмасы бар. Иләкнекен чиләккә бушатып йөри торган гадәтем юк. Колактан колакка хәбәр ташымыйм. Сер итеп сөйләгәннәрегез миндә калыр. Инде болай килешик: һәр бәхәсле нәрсәне коллектив җыелышында тикшереп хәл кылырбыз. Читтә-чатта гәп куертулар булмасын», —дип әйтү өчен зарур иде.

Шулай булды да.

«Татарстан яшьләре»ндә эшләү миңа тормышны өйрәнү юлында күпне бирде. Яшь язучы буларак, бу чорда шактый бай материал тупладым, гыйбрәтле язмышлы кешеләр белән очраштым, халык тормышының пульсын тоярга өйрәнә төштем. Теләсәм-теләмәсәм дә экономик мәсьәләләр белән кызыксынырга тиеш булдым. Беренче чиратта нефть дөньясына игътибар итәргә кирәк иде.

Район матбугаты журналистларына тәтемәгән зур бер мөмкинлек туды, Татарстанның һәммә районын әйләнеп чыктым. Күп милләтле туган республикам—ап-ачык булып күз алдыма басты.

Казанның үзендәге предприятиеләрнең бик үзенчәлекләренә дә аяк басканым юк иде, аларның байтагы белән таныштым. Органик синтез заводы корылышында бик еш булырга туры килә иде.

Күрше республикаларга, өлкәләргә бару җае да мине куандырды. Чувашия, Башкортстан, Оренбург, Пермь журналистлары белән аралаштым. Ә Мәскәүдә уза торган киңәшмәләрдә элеккеге Союзның һәммә почмакларыннан килгән журналистларның фикерен тыңларга мөмкин була иде.

Яшь хәбәрчеләрнең II Бөтенсоюз съезды хәтергә уелып калган (июль, 1961 ел). Анда «Комсомолец Татарии» гәзитәсеннән—Надежда Андреевна Сальтина, «Татарстан яшьләре»ннән мин бардык.

Каһарман дингезче татар егете Әсгать Җиһаншин белән якыннан танышуыма да журналистлыгым сәбәпче.

Өлкән буын кешеләре яхшы хәтерли, 1960 ел башында кече сержант Әсгать Җиһаншин житәкчелегендәге дүрт солдат, язмыш шаяруы аркасында, моторы сафтан чыккан баржада Тын океанда 49 көнлек дрейф кичерделәр. Азыксыз, сусыз... Аларны американлылар коткарды. Туган илгә кайткач, егетләрне Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләделәр.

Ул вакытта космонавтлар галәмгә күтәрелмәгән иде әле, яшь солдатларның батырлыгы дөньяны шаулатты.

Океан гизәргә мәҗбүр булган егетләрнең (Филипп Поплавский, Анатолий Крючковский, Иван Федотов) башлыгы Әсгать Җиһаншинның Самара өлкәсендәге (ул чакта Куйбышев өлкәсе) Шентала район үзәгенә, әти-әнисе, туганнары янына ялга кайтасын белеп, без, берничә журналист, шул тарафка сәфәр чыктык. Төркемдә шагыйрь Илдар Юзеев, «Комсомолец Татарии» хезмәткәре (ул бик оста фотокор да) Җан

Миндубаев, радиожурналист Карл Фәизов һәм мин идем. Океан батырына дип Муса Җәлилнең өч томлыгын алып бардым. Укыдымы икән, һич әйтә алмыйм, ул көннәрдә герой-шагыйрь томнары олы мәгънәгә ия бүләк иде, минемчә.

Төрле тарафлардан килүчеләр күп булса да, Җиһаншиннар өендә безне, Татарстан матбугаты вәкилләрен, әйбәт каршыладылар. Солдатның этисе Рәхимҗан абый да, әнисе Хәтимә апа да улларының исән кайтуына чиксез шат иделәр. Ник дигәндә, Әсгатьләрне чит илгә качып китмәделәрме икән дип шикләнүчеләр дә табылган булган.

Беркадәр вакыт узгач, мин Әсгать белән Әлмәттә, яшь нефтьчеләр слетында күрештем. Аның белән янә бер очрашуыбыз комсомолның XIV съездында булды (16-20 апрель, 1962 ел). Егет ул вакытта Ломоносов шәһәрендә дингезчеләр мәктәбендә укый һәм Ленинград өлкәсеннән делегат булып сайланган иде. Тәнәфесләрдә гел бергә сөйләшеп йөрдек, ә бер кичне ул без яшәгән «Варшава» кунакханәсенә дә килде... Шул күрешүләрдән каһарман егет хакында күңелемдә якты истәлек уелып калды.

Соңрак яшьләр гәзитәсеннән мине «Социалистик Татарстан»га (хәзерге «Ватаным Татарстан») күчерделәр. Нәкъ менә күчерделәр. Яшьләр гәзитәсеннән китәсем килми иде әле. «Социалистик Татарстан»ның баш редакторы Шәмси Хәбибулла улы Хамматов үзе дә куймый үзенә өндәде, ниһаять, партия өлкә комитетының бүлек мөдире Н. А. Андриянов мине күчәргә мәҗбүр итте. Әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире булып эшли башладым. Баш редакторыбыз Шәмси ага бик әйбәт кеше иде, әмма эшкә җигү дигәндә аяусыз булды, тын алырга да ирек бирмәде. «Мина язучы кирәкми, журналист кирәк» дип кырт кискәне дә булды. Сиздем: монда эшләү озакка китсә, хушыгыз, хикәя һәм повестьлар. Роман язу хыялы да челпәрәмә киләчәк.

«Социалистик Татарстан»да эшләгәндәге командировкаларның иң истәлеклесе космонавт Андриан Николаевның туган авылы—Шоршелыга бару булды бугай.

«Чаян» редакциясенә күчәсе иттем. Анда вакыт иркенрәк. Тик ничек диләр әле? «Ходай бүрегә ризык бирсә, тешен сындырып бирә» диләрме? Сатира-юмор әсәрләре язу минем өлешкә тигән көмеш түгел икән. Бер ел эшләгәч, ул чактагы баш редактор Әхмәт абый Исхак хозурына кердем.

—Булмый миннән монда эшләү, азат итегез,—дип гозерләдем.

Ул килеште.

—Минем үземнең дә конкрет адрес, конкрет фамилия белән фельетон язганым юк. Мәсәлләр—бүтән мәсьәлә,—диде.

Татарстан радиосында эшли башладым. Әүвәле пропаганда редакциясендә булдым, аннары иҗтимагый-сәяси тапшырулар буенча баш редактор иттеләр. Нәкъ бер ел эшләгәч (өстәвенә мин бит әле перевод белән килгән идем), радиотапшырулар һәм телевидение комитеты житәкчесе Фаик Газизович Надыйровтан чираттагы ялга җибәрүен сорадым. Ул, кешеләр житешми, кайсы сырхау, кайсы укуда дип, отпуск бирмәде. Ә минем «Яшь имәннәр» повестын тәгәлләп, Татарстан китап нәшриятына тапшырасым бар иде.

Кат-кат сорап та ял бирмәгәч, ундүрт ай эшләгәннән соң үз белдегем белән китеп бардым. Мәгәр бу миңа кыйммәткә төште. Партҗыелышта мина каты шелтә «ябыштырдылар». «Яшь имәннәр» бер елга соңарып чыкты.

1966 елның маеннан профессиональ язучымын. Дөрес, ара-тирә редакцияләрдә эшләп алам, радиога да язам, чыгышларым да булгалый...

Пенсиягә кадәр һәм хезмәт ялына чыккач тырышулар заяга булмады. Бер-бер артлы «Яшьлеккә сәяхәт», «Күршеләр», «Күңел кыңгыраулары», «Ялыкмаслар», «Урамнар кинәя», «Язгы күкрәү», «Сарсаз кызы Сария», «Колокольчики души», «Канат ярганда», «Канатлы кырмыска», «Йөрәк давыллары», «Ярсөяр әрәмәсе», «Өметең өзелмәсен», «Язмыш сәхифәләре», «Уйлый күңел» китапларым дөнья күрде. Боларга өстәп, берничә очерк китабым чыгуын да әйтергә мөмкин.

Татарстан китап нәшриятында «Көмеш беләзек» дигән тупланмам тузан җыеп ятарга мәҗбүр. «Адашкан адәмнәр» дигән яңа повестемның кульязмасы редакцияләп типографиягә озатырга әзер.

Кызык өчен санап баккан идем, бу юлларга имза куйган көнгә 2 романым («Өметең өзелмәсен», «Җир күчәре»), 23 повестым, 215 хикәям бар икән. Китапларга, спектакльләргә рецензияләрем байтак.

Беренче хикәям басылганга кырык биш елдан артык вакыт узган да киткән. Еллар саны белән китаплар санын чагыштырсаң, һич мактанырлык чама юк. Хәер, хикмәт сыйфатта бит, вакыт сынавын узып, әсәрләрнең укучы күңелендә азмы-күпме яшәвендә.

һич югы бер әсәреңнең үзеңнән соң киләсе буынга калуында.

Әсәрләрнең сыйфаты турында исә үзем авыз ача калсам, бу һичничек акланмаган минсенү булыр иде. Аларга бәя бирү әдәби җәмәгатьчелек һәм укучылар эше. Кырык елдан артык каләм тибрәтеп, бармакка сөял йоктыруның нәтиҗәсен шунда күрәм: сүз кыйммәтенә, әдәби сүз кадеренә төшенеп барам шикелле.

Сүз, туган телдә әйтелгән вә язылган сүз, тылсымга иядер ул. Сүз ана назыннан да ләззәтлерәк була ала. Шуның белән бергә, сүзнең дарыдан, бомбадан да хәвефлерәк булуы мөмкин. Шуңа күрә сүзләр белән үтә сак булу зарур. Сүзләргә карата түзем булу кирәк. Сүз белән үтереп тә, әҗәлдән коткарып та була. Сүз белән хыянәт кылырга да мөмкин.

Изге сүзләрне—Ата-Ана, Ватан, Азатлык, Тугрылык, Намус, Вөҗдан сүзләрен—адым саен тәкрарлап, арзанайтмаган хәерле. Гаскәри часть байрагын чехолда саклаган кебек, олы, мөкатдәс сүзләрне күңел түрендә саклау—иң хәерлесе.

Язучы өчен сүз—бөек могҗиза. Сүздә мәгънә дә, хис тә, моң-көй дә, хәтта төс тә бергә тупланган...

Инде ни дияргә кала?

Мактанып житкермәгәнмен икән ләбаса! Мина 1980 елның апрелендә—Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, ә 1992 елның августында Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре дигән исемнәр бирелде. Санга сугучыларга бик рәхмәт!

Бүгеннәрдә яңа әсәр язам. Килер көннәргә үземчә планнар да бар. Әмма әдәбият типкен хәлендә бит. Ил түрәләренә аның кирәге юк. Мәктәп аларны әдәбиятка ихтирам рухында тәрбияләргә бик тырышкан иде дә, кәнәфи дигән йомшак урындык кемнән туганнарын оныттыра шул. Мәскәү алдында тәлинкә тотудан бушый алмыйлар. Артларына тибеп төшергәч, үтә демократ булып сөйләнүчәннәр алар. Шунысы хак: халык аларга тәхеттә чакта да ышанмады, аннан киткәч, гомумән, чүп кисәге итеп карый...

Без экономик фәхишәлек баткаклыгында, рухи сазлыкта. Дөньяви ориентирларны җуйдык бугай. Тормыш мәгънәсе тойгысын югалттык шикелле. Әдәбият та «каралды». Сталинизмны сүгеп кереп киттек тә, сүкмәгән нәрсәбез аз калып бара бугай инде. Әхлак, намус, мәхәббәт, ышаныч, оят, вөҗдан, аяу-мәрхәмәт дигәннәргә кире кайту зарур.

Халыкның башы түбән иелгән. Халык түзә.

Бер анекдот хәтердә яңара: кайсыдыр заводта баш адәм эшчеләрне сүгә икән, сезне һичнинди чаралар белән куркытып булмый, иртәгә асабыз инде сезне, ди, янәсе. Шул чакта бер эшче кул күтәреп, рөхсәт алып кына сорый: «Аса торган бау казнаныкы буламы, әллә үзебезгә өйдән алып килү тиешме?»—ди, имеш... Илдә суеш, ызгыш бара. Менә без нинди маразмда. Ә бит тыныч заманда яшибез дигән булабыз. Фашистик Германияне, милитаристик Японияне җиңүгә дә ничә ел узды! Ярты гасырдан артык! Җиңүче хәерчеләр икәнебезне онытабызмы? Җиңелгән немец белән җиңелгән япон тормышы безнең кешеләрнең таң алды төшенә дә керми...

Менә иҗат әһеле булып яшә шул вазгыятьтә! Алып-сатарлар соң дәрәҗәдә азынган, дәүләтне талаучылар койрык чәнчеп чапкан шартларда. Илдә чын хуҗа юк, чын хуҗа! Шуңа бик авыр...

Ә йөрәктә, картаюга да бакмастан, тормыш томанлы, буталчык булса да, иҗат дәрте сау әле, шөкер. Вакыйгаларны шәхсән үзең катнашкан төсле итеп, кешеләрне кул биреп күрешердәй тоеп булырлык рәвештә сурәтләп, фикере дигәндә тыгыз, эшләнеше белән тел-теш тидермәслек яңа әсәр язасы иде, дим. Әмма монысы гомер барлыгы-юклыгына бәйле. Бу яшьтә максимум максатлар хакында сөйләү үзе үк сәер тоелыр сыман.

Язмама керешкәндә Мөдәррис Әгъләмне ярдәмгә чакырган идем, инде язмамны тәмамлаганда, Татарстанның халык шагыйре Гамил Афзалга таяныйм:

Ташка уеп язар сүзләрем юк,
Алтын хәреф белән язмагыз.
Сарыклар да исән, бүре дә тук—
Бик простой кеше абзагыз.

*

# ШИГЪРИЯТ

## ОКЕАН АРТЫННАН КИЛГӘН ШИГЫРЬЛӘР

*Нурия Измайлова исеме укучыларыбызга яхшы таныш дип беләбез: җитмешенче еллар ахырында аны нәкъ менә безнең «Казан утлары» ачты; ун еллар дәвамында ул журналыбызда зур-зур һәм кызыклы шигъри бәйләмнәре белән күренеп килде. Аннары «Яратам», «Алтын тарак» исемле шигырь китаплары басылып чыкты, Язучылар берлегенә алынды. Ул елларда шагыйрә Мәскәүдә яшәде: атаклы милләттәшебез, галим Вил Мирзаянов белән гаилә корып, ике бала—уллар үстерде; язуын да онытмады—шигырьләре, хикәяләре көндәлек матбугатта еш күренде, үзе дә Казанга иҗади форумнарга кайтып йөрде. Соңыннан—иренең Россиядә химик сугыш коралы җитештерүне фаш иткән кыю чыгышлары өчен үч алулар башлангач, Мирзаяновлар гаиләсе АКШка күчеп китәргә мәҗбүр ителде. Менә берничә ел инде шагыйрәбез дә Америкада, әйе, үзе сурәтләгәнчә, «ялгызлар иле»ндә... Нигә шулай атый ул атаклы, бай бу илне?—бусын журнал укучыларыбыз шагыйрәнең 50 яше уңае белән тәкъдим ителә торган яңа шигырьләр бәйләме белән танышкач, аңларлар, дибез. Ә без—редакция, каләмдәшләре, дуслары исеменнән океан артыннан безгә шигъри сәламнәр җибәргән Нурия дустыбызны бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, аңа сәламәтлек, иҗат уңышлары, җан тынычлыгы, рухи ныклык телибез!*



**Нурия Измайлова**

### МИН—ЯЛГЫЗЛАР ИЛЕНДӘ

❀

**Әй, куркытып җилләр улый,**
**Өермәләр өерелә.**
**Мин курыкмыйм бернидән дә,—**
**Алчы мине, өермә!**

Бергә керик океанга,
Яңгырлар булып чыгыйк.
Су бассын, сагыш басканчы,
Давылга качып җылыйк!

Күптер качып җылаучылар—
Көн дә давыл тилерә.
Мин генә җитмәгән икән
Бу—давыллар илендә...
Хәер, болар чыга белә
Судан да коры килеш.
Су баса дип кайгырмыйлар,—
Монда—шат булу тиеш!
Зарлыларны яратмыйлар.
Елмаерга—бу илдә.
Мин оныткан елмаюны—
Алчы мине, өермә!
Куптар таш булган җиремнән,
Теләсәң кая ыргыт!
Йә—коткар кеше булудан,
Икәү өермә булыйк!

«Чын кеше» була белмәдем,
Чын йөземне үзгәртеп.—
Кешеләр: елмая белә,
Ялгыз, димәсеннәр дип.
Ялгызларны яратмыйлар.
Яшерелгән ялгызлык
Елмайган тешләр артына,
Зарланырга зар булып...
Мин дә тешне кыскан ла ул,
Җаным күздән түгелә...
Мин генә җитмәгән икән
Бу ялгызлар илендә!

❀

«Ак калфакның каралган чагы»...
Иске җырның яңарган чагы.

Ак калфакның ертылган чагы.
Үткәннәрнең онтылган чагы.

Ак калфакның югалган чагы.
Горур башның хурланган чагы.

Ак калфакның ташланган чагы.
Җаннарымның тапталган чагы.

Ак калфакның салынган чагы.
Йөрәгемнең ярылган чагы.

Ак калфакның энҗесез чагы.
Каргышларның җиңгесез чагы.

Ак калфакның таушалган чагы.
Ходайның да ташлаган чагы.

Ак калфакның урынсыз чагы.
Язмышларның узмышсыз чагы.

Ак калфакның бизәксез чагы...
(Җырларның да кирәксез чагы!)

❀

*Тарагын ташлады—урман булды.*
*Яулыгын ташлады—күл булды.*

Тарак төште, мөмкин иде тотарга.
Тик тотмадым—иелмәдем «юк-бар»га.

Тарак төшкән, урман үскән, котырган.
Мин—нәзек тә сыялмаслык чытырман.

Ни алда юк, ни артта юк яктылык.
Кайчагында яшен генә ялтырый.

Мин йөгерәм өлгерим дип, тотыйм дип!
Бер тубал утка әйләнеп очыйм дип!

Риза утлар дөньясына күчәргә—
Бу караңгылыкны гына кичәргә!

Юк! Яшен дә алмый мине—мин ямьсез!
Чәч кенә үсә урмандай иләмсез.

Тарагым юк, тузган чәчем-башларым!
Мин убырлы карчык була башладым...

Мәрхәмәт кыл! Кодрәтең бир, уф алла!
Тубал хәтле утка калып очарга!

Канатсыз мин—очарга да яраксыз...
Булмый икән бу дөньяда тараксыз...—

Тегесендә—убырга да охшамам,
Тараксыз калганыма да уфтанмам.

## Бердәнбер чара

Йөрәгемнең син—өметсез чире.
Тик Вакыт кына—өмет аңарга.
Тетрәүле рәнҗеш эчләрем тулы!—
Тетрәп торалар җир дә, һава да.

Ай, бер сүзкәең «Исәнме!» дигән!—
Вакыт кодрәтен юк дип белергә,

Үксеп тетрәгән һава дулкынын
Шау музыкага әйләндерергә!

Тик минем тетрәү—синеке түгел.—
Аңлап торасың, дәшмисең шуңа.
Син дә телисең һава җырлавын!
Ах, җитми тора бер тылсым гына!...
Тылсым кылмагач, бу Сөюемне
Нәрсәгә диеп кылдың, Ходаем?!
Ә син җәлләмә, «Исәнме!»—димә.
Исән түгелмен. Ләкин чыдармын.

Исән түгелмен. Син—минем чирем.
Терелтәлмәссең, бик тырышсак та.
Бер-беребез өчен яңадан туу—
Бердәнбер чара безнең очракта.

## Мин сөйсәм...

Мөлдер күзләреңдә диңгез төсе.—
«Хэйзел» була икән сезнеңчә.
Дулкын-дулкын, алкын-салкын-шашкын!
Төштем—баттым!—
«Әһ!» тә димичә!

Йөзә белмим. Диңгез төпләрендә
Әйләнермен алсу энҗегә.
Булалмаммы мин бер бөртек энҗе!—
Керә алгач инде күзеңә!

Ә теләсәң—йөзәм. Өйрәнми дә,
Йөзәлермен синең кочакта.
Бер диңгезне генә кичмәмме мин,
«Хэйзел дулкыннарым» бар чакта!

Ә «Чык!» дисәң, чыгам... «Диңгезеңә
Ут төртимме»? Нишлим иң элек?
Әллә эчеп кенә куйыйм микән,
Күзләреңә генә иелеп?

Бер диңгезне генә эчмимме соң,
Әй, «хэйзел»ем, «Чыкма! Эч!» дисәң!
Мин эчкәннән тик ул ташар гына.—
Корытмыйча сөям мин, сөйсәм!

❀

Чирле мәхәббәтем минем!
Яратуым яралы.
Әрнү тулы ләззәтләре,
Тынычырак газабы.

Әрнүләргә чыдый алмыйм,
Чирен яшергән—үлгән.
Мин—түземсез, үлемсез зат...
Авыртудан тилерәм!

Өч көн җенләнеп ярату!
Бик җиткән бер гомергә.
Акылыма көч бир, Раббым!
Җенләнүме—җүнлегә?!

Ә газапларга—түзәрмен,
Өйрәнгән аларына.
Хуш, мәхәббәт! Тапшыр мине
Терелү газабына.

## 9 январь, Принсетонда беренче кар

Унҗиде кат яфраклардан котылдык инде.
Кап-кара калган агачлар күк булдык инде.

Коелып төште, үксеп очты, кышка калмады!
Кызгануымы язмышның, әллә җәзамы?

Әллә бушлык газабында сынавы микән?
Яфраксыз калган агачлар еламый икән...

Югалтасын югалткан да ялгыз-ялангач,
«Мин бар микән, юк микән?» ди йокы аралаш.

Уян! Куркыр нәрсә беткән, үлем җиңмәгән!
Саргайткан яфрак сагышы, тамыр шиңмәгән.

Елата да, юата да—гадел табигать.—
Һәм яратмый ул бушлыкны, кар сибә җырлап:

«Бергә кара булган идек, бергә ак булыйк!»
Агара кара ботаклар, карларга чумып.

«Алла бирсә», калмас әле кара җире дә!—
Ялгыз башым агарырга өйрәним генә!

Мин төшләрдән кайтып киләм кебек өнемә:
Кар кочаклап, башны салдым язмыш иңенә.

*Яңа исемнәр*

# АК ЮЛ ТЕЛИК



*Сөмбел—Казан кызы. Ул мәктәптә уку еллары татар милли-азатлык хәрәкәтенең күтәрелеш чорына туры килеп, шәһәр шартларында урта белемне туган телендә алган, балачагыннан ук милли-мәдәни мохитта, халкыбызның бай рухи мирасы даирәсендә тәрбияләнгән бәхетле буыннан. Шуңа күрә япь-яшь кенә кызның кеше күңелендәге үтә саф, садә кичерешләрне, туган тел чишмәсенең иң яшерен агымнарын да нечкә тоемлавы, милли үзаңының югары кимәлдә булуы бер дә гаҗәпләндерми. Ул—туган телендә генә, яисә урыс телендә генә сөйләшә-аңлаша алган иске зыялыларга алмашка килүче, татар теле белән бергә инглиз һәм урыс телләрен да камил белүче, әдәбиятыбызны дөнья мәйданына алып чыгу кебек бөек миссия йөкләнгән яңа буыннан. Егерме беренче гасырда мәдәни бәхре җиһанда аның кебек яшьләр канат талпыначак.*

*Аптырап куйдым әле, Сөмбелне—япь-яшь кенә кыз баланы—мин шактыйдан белəм икән. Менә инде алты ел рәттән татарның төрле кыйтгалардан җыелган иң акыллы, сәләтле балалары һәм яшьләре җәйләрен "Сәләт" лагеренда—җәйге аланда үткәрәләр, бергәләп укыйлар, ял итәләр, атаклы галимнәр һәм сәнгать эшлеклеләре белән аралашалар. Миңа да ул лагерьларда 1996 елдан бирле "Татар дөньясы", "Татар теле һәм әдәбияты" курслары буенча дәресләр үткәрү, шул яшьләр белән якыннан аралашу бәхете насыйп булды. Һәм булсын дәресләрдә, булсын кичәләрдә яисә аланда үткәрелгән башка чараларда (ул бик матур итеп җырлый да әле), иң активларның, чая-үткеннәрнең берсе Сөмбел иде дип әйтә алам. Шулай итеп ул башта, "Сәләт"тәгечә итеп әйтсәк, "сәлкеш" (сәләтле кеше) иде, аннан соң инде ике ел рәттән үзе үк бу лагерьларда вожатый, ягъни "әйдәман" булып катнашты.*

*Хәзер Сөмбел Казан дәүләт университетының "Татар теле, әдәбияты һәм инглиз теле" бүлегендә өченче курста укый, бер үк вакытта "Таһир-Зөһрә" гәзитендә корреспондент-мөхбир вазифасын башкара, хикәяләре, әкиятләре, мәкаләләре гәзит-журнал битләрендә даими басылып килә. 1996 елда аның хикәяләрдән һәм әкиятләрдән торган "Безнең-сезнең заманда" исемле беренче җыентыгы "Сәләт" китапханәсе" сериясендә дөнья күргән иде. Әле унберенче класста укыганда ук өлкән әдипләр Сөмбел Гаффарованы Татарстан Язучылар берлегенә әгъзалыкка тәкъдим иткәннәр иде һәм ул үткән елның азагында бертавыштан кабул ителде дә. Кыскасы, яшь каләмдәшебез турында әлегә шуларны әйтү җитеп торыр кебек. Иң мөһиме, ул күп яза, ни әйтергә теләгәнен аңлап, тоеп яза. Булсын табигать күренешләре, булсын җәнлекләр турында—барысының да асылында кеше хисләре, адәм баласының рухи халәте чагылыш таба. Алар ничек килеп чыга торгандыр, анысын инде, хөрмәтле укучы, тәкъдим ителгән шушы өч парчадан үзегез үк тәгаенли алырсыз дип беләм. Ә без Сөмбелгә яңа иҗат уңышлары, бәхет һәм әдәбияттагы кебек үк тормышында да ак юл телик.*

**Флүс ЛАТЫЙФИ.**
*7 ноябрь, 1999 ел.*

# Сөмбел Гаффарова

## Тәкъдирнең изге ялганы

Кышкы салкын Кырлай өйләрен үз кочагына кысты. Һәр йортта бу салкыннан котылыр өчен жылы итеп мичләр яктылар. Сәгъди абзыйларның өендәге мич жылысы бу салкынны, кадерсез кунакны чыгарып жибәргән ише, урамга куып чыгарды. Ә усал жил исә, тәрәзә капкачларын ачулы бәргәли-бәргәли, урам буенча түбән очка төшеп китте.

... Зәңгәр күктә, яшь кызның чулпыларындагы көмеш тәңкәләре кебек эреле-ваклы йолдызлар жемелдәшә. Авыл өйләренә ап-ак шикәр комы булып, әкрен генә кар ява. Аннары әлеге ком-кар зур-зур шикәр кисәкләренә әйләнә шикелле. Бу шикәрне малай кулын сузып кына алар иде сыман...

Кечкенә Габдулла шушы төшне әллә ничәнче мәртәбә күрә инде. Ул менә өченче көн, әле туңып, калтырап, әле уттай янып, иреннәре кара көеп, эчәсе килгәнен дә әйтә алмыйча авырып ята. Әнә хәзер дә аның үз әнисенә бик тә охшаган мөлаем йөзле, ак яулыклы бер апа аңа әтисенең зур касәсенә, өрек жимеше салып, чәй ясап китергән дә ул үз гомерендә беркайчан да ашап карамаган балан бәлеше кисәген сузып тора...

Габдулланың әлеге дәү бәлеш кисәгенә үрелгән хәлсез кулы мич кырыеннан салынып төште. Малай кулы кызу кирпечкә тиюгә сискәнеп уянып китте. Теге мөлаем йөзле апа каядыр юкка чыкты. Ул үзенең мич башында—әтисенең иске тунын бөркәнеп ятуын абайлап алды. Малайның колагына үзе шикелле үк ятим кәжә бәтиенең мич астыннан кызганыч мәэлдәгәне, сәке астындагы яңарак кына туган песи баласының көчсез генә мияулаганы тоныкк кына ишетелде. Габдулла көч-хәл белән күзләрен ачты, кипшенгән иреннәрен ялап алды. Төшендәге балан бәлешен ашарга өлгерми калуы кайгысыннан аның күзләренә кайнар яшь тулды.

—И-и, төш кенә булган ич бу! Шул балан бәлеше кисәген ашап бетергәч уянса ни була иде инде, жә?!

Күз яшен дә сөртергә өлгермәгән Габдулланы кабат авыр караңгылык йотты.

... Урамның аргы башыннан чиккән түбәтәйле, чем-кара читекле, бик ыспай киенгән, китап-дәфтәр тутырылган зур букчасын инбашына аскан үсмер бер малай төшеп килә. Ул әле генә сабакташ шәкертләргә үзе язган шигырен укыган. Аңа хәлфәсе афәрин дигән, ә дус малайлары, жилкәсенә кага-кага: «Яхшы!»—дип мактаганнар. Ул бик шат: аңа ияреп, бар дөнья куанадыр шикелле... Малай әлеге яшүсмердә үзен таныды һәм аңа бу Габдулла бик ошады...

Мич башында каеры тун астында туңып-калтырап яткан авыру малай, хыял-төшендәге Габдуллага ияреп, кипкән иреннәрен көчкә кыймылдатып шул шигырьне кабатлады:

Үпкәненнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә син,
Һәр ишектән сөрде угълыңны мәхәббәт сакчысы.
Бар күнелләрдән жылы, йомшак синең кабрең ташы—
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачысы һәм татлысы!

Авыру Габдулла янына сулы чүмеч тоткан Сәгъди абзый килде. Ул үзен-үзе белештермичә нидер сөйләнеп яткан малайның кайнар башын күтәреп, аның кипшенгән иреннәренә су тидерде. Малай, имән кисмәк тәме сеңгән жылымса суны йотлыгып-йотлыгып эчте. Сәгъди абзый аның өстендәге тунны ипләбрәк япкан шикелле итте дә, авыр сулап, мич аралыгыннан чыгып китте.

... И-и, бигрәк тә татлы, тәмле икән Казанның суы!.. Габдулла—шагыйрь, ул—Казан каласындагы егетләрнең иң чибәре, мәһабәт гәүдәлесе, мәртәбәлесе. Ул инде хәзер Казан дигән шанлы калада яши, имеш. Менә шушы шагыйрь

ерактан якынлашып килгән кыңгыраулар чыңын ишетте: «Әниләр-әтиләр килде!»

Йортының яшелгә буялган челтәрле киң капкалары ачылып китте дә ишегалдына пар ат җигелгән тарантас килеп керде. Габдулла, кочагын җәеп, әти-әниләренә каршы ашыкты. Аның Казандагы һәм Кырлайдагы әти-әниләре шагыйрь улларына кунакка килгәннәр иде. Әниләре, тарантастан төшү белән, төенчекләрен чиштеләр дә, аннан кызыл билле прәннекләр чыгарып, яраткан уллары Габдуллага суздылар. Габдулла, үзенең ике катлы таш өенең парадный ишегеннән аларны аскы каттагы күп тәрәзәле якты бүлмәгә алып керде. Бүлмә идәненә тутый кош сурәте төшерелгән хәтфә палас җәелгән, каршы дивар буендагы пыяла тәрәзәле зур шкафларга хисапсыз китап тезелгән иде. Йомшак кәнәфиләргә утырган, ак ефәк шәлләр япкан матур кызлар, яхшы киемнәр кигән укымышлы егетләр аларны аягүрә басып каршы алдылар. Кечкенә түгәрәк өстәлдәге кәкре муенлы җиз граммафоннан әкрен генә матур бер көй—«Әллүки» агыла. Бүлмә уртасында ак ашъяулык җәелгән озын өстәл тора. Аларны хәтта өстәлдәге эреле-ваклы балан бәлешләре, кызарып пешкән пәрәмәч-өчпочмаклар да елмаешып каршылыйлар сыман иде. Габдулла исә, бу нигъмәтләрнең берсенә дә кагылмыйча, йоп-йомшак, ап-ак күмәчне сап-сары балга манчый-манчый ашап, алтын puталы зур касәдән өрек җимеше салынган һинд чәе эчеп утыра, имеш...

Кинәт малайны Зөһрә әнисенең:

—Карале, Габдулла тагын саташа бугай,—дигән тавышы беразга гына аңына китерде, тик авыруы аны тагын татлы караңгылыкка этеп төшерде.

... Ул авылның, һич онытмыйм, һәр ягы урман иде;
Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде...

Кырлайның беркатлы «Шүрәлеләре» яшәгән урманның алсу сандугач, зәңгәр кыңгырау чәчәкләренә күмелгән иң матур түгәрәк аланында, шул чәчәкләр арасында ике кыз бала белән өч малай куышлы уйныйлар, имеш. Алар барысы да чук кебек киенгән: кызларның аякларында чигүле читекләр, кара чәчләрендә кызыл, яшел төстәге энҗеле калфаклар, ә малайлар исә ап-ак ситсы күлмәктә, яшел, зәңгәр кәзәкиләрдә.

Алан уртасындагы бөдрәләнеп үскән юан каен агачына аркасын терәп, ак күлмәк белән кара бәрхет кәзәки кигән бер ир-ат утыра. Ул үрелеп кенә үз тирәсендәге кып-кызыл каен җиләкләрен уң кулы белән сул учына җыя. Учы җиләк белән тулгач, балаларын үз янына чакырып ала. Балалары, чыпчыклар төркеме сыман чыр-чу килешеп, аның янына җыелышалар. Һәммәсенең кулында рәсемле китап, ә ул китапларны язган кеше Габдулла Тукаев дигән шагыйрь, имеш. Күз ачып йомганчы әтиләре кулындагы җиләкләрне чүпләп бетерергә өлгергән балалар, бер-берсен уздырып, көйләп-көйләп шигырь укыйлар, имеш.

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям жаным, тәнем белән.

Балаларның аталары, җәйге урманның акрын шавыннан, чәчәкләр-нең хуш исеннән, тирә-яктагы чәчәкләргә кунгалап очкан төрле төстәге күбәләкләр, шул күбәләкләрдән дә матуррак булган балаларының күңелле, шат авазларыннан күңеле тулып, күзләрен йомды. Бик, бик бәхетле иде ул бу мизгелдә.

«Карале, бу бәхетле ата—Габдулла үзе икән ич!»

Кинәт бу ямьле манзара юкка чыкты, түгәрәк аланда фәкать ямьсез итеп ябалак кычкырган тавыш кына яңгырап калды. Малай, шул тавыштан куркып, уянып киткәндәй булды.

Алгы якта Зөһрә әнисе, сукрана-сукрана, кулыннан ялгыш төшереп җибәргән чүмеч-кашыкларын җыя иде. Малайның төшендәге хуш исле каен җиләге исен өенендәге көн саен диярлек ашый торган майсыз борай боткасы исе алыштырды. Әнисе, авыр атлап, аның янына керде. Габдулла үзенең кайнар маңгаенда аның кытыршы, салкынча учын тойды. Аның белән гел төксе генә сөйләшә торган әнисенең эштән бушамаган, бирчәеп беткән бармаклары әкрен генә малайның маңгаендагы тир тамчыларын сөртеп алды, житү чәчен сыйпады.

Көтелмәгән бу наздан тетрәнеп киткән авыру малай күзен ачарга да куркып ятты. Бу мизгелдә ана әйтеп-аңлатып бетергесез рәхәт иде. Аның озын кара керфекләре астыннан тәгәрәшеп чыккан кайнар яшь бөртекләре әнисенең рәхимле бармакларын чылатты.

Әнисенең:

—Балакаем, өч көн ашаганың юк, бер-ике генә кашык булса да кап инде,—дигән йомшак тавышына Габдулла күзләрен ачып җибәрде. Зөһрә әнисе аңа сөтле ботка салынган зәңгәр чәчәкле җамаяк сузды. Гаҗәп, малайның хәзер бер җире дә авыртмый. Әнисенең шәфкатьле куллары аның маңгаендагы тир тамчыларын гына түгел, гүя тәнендәге, җанындагы авыруын да сыпырып алган иде.

Бу минутларда үзен өч көн буена үлем белән яшәү арасында тоткан авырудан котылган Габдулланың күзләре шатлык яшьләре, ә кечкенә җәрәхәтле йөрәге бәхет белән тулды. Ул бу минутларда әлеге төшләрендәге мизгелләрнең үз гомерендә беркайчан да булмаячагын белмәве белән дә бәхетле иде.

Тәкъдире авыру малайга бу төшләрендә киләчәктә аның бөек шагыйрь Габдулла Тукай буласын күрсәтте, тик аның язмышына язган чын хакыйкатьне, әллә аны кызганып, әллә булачак Шагыйрь алдында үзенең көчсезлеген аңлап, аннан яшерде.

Бу изге ялган алдында каты авыру җинелде. Нәни Габдулланы язмышы кызганды: зәһәр чир чигенде. Кечкенә Апушның гомер китабына язылган ачы Язмышы киләчәктә:

—Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп кашсыз йөзек—
Без аның бик зур фәхерле, чын бриллиант кашлары!—

диячәк. Һәм, татар милләтенең рухияте таҗында ин эре асылташы булачак, шигърияте белән гасырлар буена үз халкының күнел кылларын тибрәтеп торачак, тарихта мәңгегә егерме җиде яшьлек егет булып калачак үлемсез Шагыйрьне нәни Апуш чагында ук үз халкыннан тартып алырга батырчылык итмәде.

## Сабантуйлы авылым

Җәй. Авыл. Сабантуй.

Мин—шәһәр кызы. Әмма бу өч төшенчә минем күнелемдә гел бергә яши. Мин ел саен ашкынып, дулкынланып авылыма Сабан-туена кайтам. Һәр ел саен бер яналык, бер истәлек ишетеп, хатирәләр тынлап киләм. Авылымның, авылдашларымның үткәнен аңларга, моңна-рын тоярга өйрәнәм. Шуңа күрәдерме, һәр узган Сабантуе, икенчесенә кадәр, үзенең җырларын җырлатып, минем күнелемне җылытып яшәтә дә инде.

Быел да шулай булды. Иртәгә Сабантуе дигән көнне кичтән, көн сүрелгәч, барлык эшләр беткәч, авыл тынгач, өйләрдәге тәрәзәләрдә утлар сүнә башлагач, мин капка төбенә чыгып утырдым. Чөнки бу вакытта авыл үзенә бер төрле серле тормыш белән яши башлый. Капка төпләрендә төркем-төркем булып яшьләр җыелыша, аннан алар, сөйкемле парлар булып, авыл урамы буйлап таралыша һәм урамга серле тынлык инә...

Мин дә капка төбендәге уңайлы эскәмиядә утырам һәм нидер көтәм. Каршыдагы зәңгәр чәчәкле капка төбендәге эскәмиядә урам уртасындагы баганадан төшкән көчле ут яктысында күрше Галимҗан бабай белән югары очта яшәүче Рамазан абыйның малае Искәндәр утыра. Искәндәр гармун уйный. Ул әкрен генә, салмак кына, әмма гаҗәеп матур итеп, бар дөньяны оныттырырлык итеп уйный: җиһанда моң һәм син генә каласың.

Мин, күнелем тулып, күкләргә ашардай булып, моң кочагында тирбәләм. Бу минутларда мин әйтеп бетергесез бер рәхәтлек кичерәм.

Гармун тына. Һәм шул ук мәлдә Галимҗан бабайның Искәндәргә әйткән сүзләрен ишетәм:

—Әйдә, улым, минем көйне, минем җырны сыздыр әле. Синең уйнаганны

ишеткәндә мин яшәреп китәм, синең моңың бар. Синең моның күнеленнән бармакларына да күчә беләә.

Егет, гармун каешларын җилкәсенә җайлабрак куеп, бармакларын гармун телләре буйлап йөгертеп ала.

—Юк, Галимҗан бабай, мин бик шәп уйнамыйм, синең гармуның шулай шәп сыздыра, әллә нинди моңнар чыга үзеннән. Гармунда бармакларым түгел, җаным уйный кебек, кыңгырауларын да мин түгел, йөрәгем чынлата шикелле—әллә нинди көчкә ия синең гармуның.

—Шулайдыр, миңа да шулай тоела иде: гармун җаным, күңелем әйтергә теләгәнне көй итеп сибә иде. Бармаклар гармун телләренә кагылуга көй үзе чыга кебек иде,—диде ул әкрен генә. Аннан, уйланып торгач:

—Туктале, ничә ел инде аңа?—диде.

—Нәрсә турында әйтәсен, бабай?—дип сорады Искәндәр, гармунын тезләренә куеп.

—Дөрес,—диде карт, үзенең уенын җөпләгәндәй,—миңа бу гармунны нәкъ менә шушы көнне—иртәгә Сабантуе буласы көнне, миңа унсигез яшь тулган көнне—әти бүләк иткән иде. Әти минем укытучы кеше иде. Бераз хыялыйрак та иде. Хуҗалыкта аннан да кирәгрәк башка нәрсәләр дә булгандыр. Шулай да, әти миңа, бөтен авыл халкын сокландырып уйнарга, җыр белән яшәргә язсын сиңа дип, гармун бүләк итте. Мин кечкенәдән гармунда уйный идем, минем иске генә булса да гармуным да бар иде. Әмма бу гармунны күргәч мин тынсыз калдым: искиткеч гармун иде ул. Әни гармунга нәни генә көмеш кыңгыраулар такты: алар гармун моңына кушылып чыңладылар.

—Шуннан соң ни булды, Галимҗан бабай?

—Шуннан соңмы? Мин гармунда уйнаган соңгы Сабантуе булды. «Иң оста гармунчыга иң унган кыз» чиккән кульяулык алган соңгы Сабантуе иде ул. Шуннан сугыш башланды. Көрәшче Мәрданша да, күрше авылның сабантуйлар батыры Салих абый да, җырчы Исмәгыйль дә, тракторчы Хәсән дә... барыбыз да сугышка киттек. Күргәнең бардыр: мәктәп бакчасындагы һәйкәлгә 124 исем-фамилия язылган, ә ул елларда безнең авылда барлыгы 140 йорт бар иде. Үзең уйлап-исәпләп кара... Шул сабантуеннан соң минем беркайчан да гармунда уйнаганым булмады. Йөрәгем моңнарын, шатлык-сөенечләремне көйгә әйләндереп сибүдән туктады ул... Соңгы сабантуенда чиккән кульяулыгын алган кыз—Нәфисә минем кайтуымны җиде ел көтте. Мин, сугышның беренче көненнән соңгы көненә кадәр йөреп, аннан соң да әле өч ел хезмәт итеп кайттым. Ә Нәфисә...

Шулчак капка ачылды да, алар янына озын аксыл күлмәк кигән, иңенә ак Оренбур шәл салган бик сөйкемле әби чыкты.

—Галимҗан, кер инде. Егетне клубта кызлар көтәдер. Мин дә сине әллә кайчаннан бирле чәй эчәргә көтәм.

—Хәзер, әби,—диде Искәндәр, аңа урын биреп.—Галимҗан бабай, синең бу гармунда ничә еллар уйнаганың юк. Мә, тот әле. Син бу ягыннан уйнарсың, бу яктан мин тартырмын. Сыздырыйк әле синең көйне! Ишетсен авыл: гармунчы Галимҗан уйный дисеннәр! Башлыйбыз!..

—Туктале, улым, йөрәгем сикерә.—Галимҗан бабай, сак кына итеп, Искәндәр иңенә кидергән гармунның телләренә кагылды, аннан соң бармакларын әкрен генә гармун телләре буйлап йөртеп алды.

Һәм кинәт, төнге авыл урамын моңга күмеп, көй агыла башлады. Көй-моң, көчәйгәннән-көчәя барып, урамга сыймыйча, югарыга күтәрелде, агач яфракларын шаулатты.

Олы юлның тузанында
Калды минем эзләрем...

Галимҗан бабай бераз карлыкканрак, Искәндәр исә яшь, көчле тавыш белән җырлап җибәрделәр. Мин дә, эчемнән генә, җырга кушылдым:

... Кайда икән яшьлегем, дип,
Шул юллардан эзләдем...

Җырлап бетергәч тә, Искәндәр белән бер кулсыз Галимҗан бабай, гармунчы

Галимжан, тагын берничә көй уйнадылар. Башын кынгыр салып, тырышып-тырышып гармунда уйнаган бер кулсыз Галимжан бабайның йөзендә шат елмаю иде бу мизгелләрдә. Галимжан бабай башын кынгырайтып, гармунга куйган, йөзендә ягымлы елмаю балкый, иреннәре исә әкрен генә үзе уйнаган көйне көйли. Мин сокланып та, тетрәнеп тә ана карап утырам. Мин генә түгел, ак шәленең очлары белән авызын каплаган Нәфисә әби дә ана карап тынсыз калган иде. Мин анладым! Галимжан бабай шулай үзенең яшьлегенә—иң бәхетле көннәренә кире кайткан. Чөнки аның иртәгә туган көне, иртәгә сабантуе, иртәгә Нәфисәсенең беренче бүләген—чиккән кульяулык алачак көне, иртәгә авылның иң оста гармунчысы—унсигез яшьлек гармунчы Галимжан көне!

Гармун тынды. Авыл урамын айкаган, күкләргә ашкан моң сүнде.

—Искәндәр улым, минем гармунда уйнарлык оныгым юк, шуна күрә мин бу гармунны сиңа бүләк итәм. Быелгы сабантуенда минем гармунда син уйна, көрәшүче батырларга да, чабышкы атларга да, кыз күзләгән егет-җиләнгә дә, яшь кызларга да синең йөрәгең аша шушы гармунга күчкән моңнар ярдәм итсен, күнелләренә сафлык булып керсен.

—Ай, рәхмәт, Галимжан бабай!—Искәндәр аның алдындагы гармунны кулларына алды, иңенә асты.—Мин тагын килермен әле синең янга, синең көйләрне әле тагын бергәләп уйнарбыз.

Искәндәр урам буйлап уйнап, түбәнгә, клубка төшеп китте. Аның артыннан тагын моң-жыр сузылып калды:

Бабайлар моныннан башка
Туган жир ятим бит ул.
Көйсез-моңсыз үткән көннәр—
Яшәлмәгән көн бит ул.

Капка төбендәге эскәмиядә бер-берсенә сыенышып утырган Галим-жан бабай белән Нәфисә әби әкрен генә нидер сөйләшә иде. Мин, сак кына урынымнан торып, кече капканы шыгырдатмаска тырышып ачып, өйгә кереп киттем.

Күргән-ишеткәннәремне уйлап, йоклап китә алмый ятам. Башымда уйлар, күнелемдә моңнар, йөрәгемдә сабантуе алдыннан гына була торган ниндидер ашкыну, нидер көтү...

Менә иртәнге кояшның беренче нурлары тәрәзәдә өй эченә сибелде. Авыл әтәчләр тавышына күмелде. Туган авылымның—жырлы-моңлы сабантуйлы авылымның—яна сабантуйлы таңы атып килә иде.

## Булмас димә...

*Нәниләргә*

Әнәс исемле песи малаен кунакка дип шәһәргә алып килделәр. Әнәс бер көн кунак булган, ике көн кунак булган—күнелсез мона. Зөһрә апасы иртән иртүк мәктәбенә йөгергән, аның әти-әнисе эшләренә киткәннәр. Шуннан көне буена юк та юк икән болар. Песи малае Әнәс тәрәзә төбендә и моная ди, и эче поша ди моның. Гажәп икән шәһәр дигән жирдә. Зу-ур ишегалдында ни сыер мөгрәми, ни сарыклар бәәлдәми, ни чуар тавыклар кыткылдамый, ни кызыл кикрикле чем-кара әтәч тә кәпрәеп йөрми, ни үсеп килүче каз бәпкәләре дә пипелдәшми. Монда кешеләрдән дә машиналар күбрәк икән. Шулай да әллә нидә бер жиргә сыенып диярлек мәчеләр үткәли дә, агач төбе саен иснәнеп йөргән әллә нинди килбәтсез этләрен иярткән кешеләр генә күренгәли.

Өченче көнне инде Әнәс исемле песи малае түзмәгән: Зөһрә мәктәптән кайтып керүгә үк:

—Апа, урамга чыгып әйләнеп керим әле,—дигән.

—Бар инде, бар,—дигән Зөһрә.—Син авылда ирекә ияләнгән шул. Тик кара аны, адаша күрмә.

—Адашмам!—дигән песи малае Әнәс.—Мин авылда урамнарны бер итеп йөргән малай бит! Сезнең ишегалдыгыз мина мич башы шикелле генә ул.

Песи малае бик әйбәтләп йонын чистарткан, битен юган, мыекларын тараган да, лифтка гына утырып, аска төшкән һәм ишек төбендә әби-бабайлар өчен куелган эскәмиягә менеп утырган. Ул шактый вакыт тын гына тирә-юньне күзәтеп утырган. Ул арада караңгы да төшкән. Менә песи малае Әнәс янына күрше ишек төбеннән бер кара песи килеп җиткән. Килеп тә җиткән, колагын тырпайтып, мыегын кабартып, койрыгын кәкрәйтеп:

—Ты кто такой? Дай миллион. Я—рэкет,—дигән.

—Мин—песи малае Әнәс.

—Чего-то не понимаю. Татарский кот шту-ли?

—Татар песие шул,—дигән песи малае Әнәс.

—А я—русская кошка. Дворовая красавица Мурка.

—Я по-русски не разговариваю,—дигән песи малае Әнәс.

Урыс песие Мурка моңа бик гаҗәпләнеп карап торган-торган да нәрсәләрдер әйтеп караган. Шуннан соң:

—А я по-татарски не понимаю,—дип бик хәтәр тавыш белән сузып елап җибәргән. Ә песи малае Әнәснең моңа исе дә китмәгән. Башта авызын ерып елмайган, аннары рәхәтләнеп көлгән, соңыннан инде «Урам көе»нә җырлап-мырлап та җибәргән:

Безнен урам мәчеләре
Берсеннән-берсе чибәр.
Кала мәчеләре кыланчык,
Күрсән, гайрәтен чигәр-әр...

—Мыр-расиво поешь!—дигән аптырап киткән Мурка.—Научи меня-у-у.

Нишләсен инде песи малае Әнәс. Эскәмиядә колак тырпайтып, мыек кабартып, тырнак кәпрәйтеп кенә утырып булмый бит инде. Сөйләшәм дисәң, татарча да белми икән ич әле бу Муркасы да. Ниндирәк җыр өйрәтергә икән соң моңа дип, бераз уйлап торгач, песи малае Әнәс сузып җибәргән:

Иртән торып, тышка чыксам,
Этләр өрә урамда;
Эт өрүе нипачум ул
Дуслашсалар мыраула-а-ар...

Аңа бик әкрен генә булса да Мурка да кушылгалап алган. Җырлап бетергәч карасалар, боларны ала-кола, ак, кара мәчеләр уратып алган икән. Песи малае аларга күз генә төшереп алган да икенче җырын сузган.

Төнлә торып тышка чыксам,
Мырлаша илле мәче.
Илле мәче җырлаганда
Безне мең эт җинмәячәк!

Җырлап бетергәндә ишетә песи малае Әнәс—әлеге песиләр дә аларга кушылып киткәннәр икән. Татарча җырлыйлар! Карасалар, песи малае Әнәс җырына кушылган илле ике мәченең илле икесе дә татар песиләре булып чыккан! Алар хуҗалары кушканга күрә урыс исемнәре алып, чит телдә мырлашып, җырлашып йөргәннәр икән!

И киткән шуннан соң гәпләшү, җырлашу... Ишегалдына бөтен квартал мәчеләре җыелышкан һәм алар таң атканчыга кадәр Сабан туе үткәргәннәр. Алар бергә булгач, ишек алдына хуҗаларын ияртеп чыккан муенчаклы килбәтсез этләрдән качып үз дәрәҗәләрен дә төшермәгәннәр, сырт тырпайтып ысылдап та азапланмаганнар. Рәхәтләнеп туган телләрендә сөйләшкәннәр-мырлашканнар, җырлашканнар. Ана телең тырнаштырмый да, сугыштырмый да, ә дуслаштыра гына икән ул, әйеме?

Шулай итеп, авылдан килгән песи малае Әнәс үз туган телен, үз мыр-мырларын оныткан, урыслашкан шәһәр песиләрен ана телләрендә мырауларга өйрәтеп киткән, ди. Шуннан бирле квартал песиләре бары тик туган телләрендә генә мыраулаша икән хәзер. Вәт.

*Бүгенге әдәбият*

# КИЛӘЧӘККӘ КАРАП

**«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ РЕДКОЛЛЕГИЯСЕНЕН КИҢӘЙТЕЛГӘН УТЫРЫШЫННАН**

***Узган елның 15 ноябрендә үткәрелгән утырышта баш редактор Р.Фәйзуллин; идарә әгъзалары Х. Әюпов, М. Госманов, А. Гыйләҗев, А.Гыймадиев, Ф. Латыйфи, С. Маннапов, Т. Миңнуллин, Х. Миңнегулов, Б. Солтанбәков; «Казан утлары»ның актив авторлары М. Әгъләмов, М.Әмирханов, Ф. Галимуллин, Г. Гыйльманов, Р. Кәрами, И. Надиров, Г.Рәхим, Ф. Урманче, М. Хуҗин; редакция хезмәткәрләре М. Вәли, Н.Гамбәр, Р. Гаташ, Ш. Маннапов, М. Шабаев; газета һәм журналлар, «Татарстан» теле-радиокомпаниясеннән вәкилләр катнашты.***

*Көн тәртибендә журналның быел басылган саннарына күзәтү генә каралса да, бу көнне татар әдәбияты турында зур һәм җитди сөйләшү булды. Утырышны кереш сүз белән «Казан утлары»ның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин ачты. Жанрлар буенча докладларны Флүс Латыйфи (проза), Гәрәй Рәхим (шигърият), Марс Шабаев (публицистика), Галимҗан Гыйльманов (әдәби тәнкыйть) ясады. Аннары килгән кунакларга сүз бирелде.*

Укучыларыбызга редколлегия утырышы беркетмәсеннән кыскача сөземтә тәкъдим итәбез.

## Равил Фәйзуллин:



Бүген сезнең кулыгызда «Казан утлары»ның быелгы 10 нчы, ә гомумән алганда 924 нче саны. 1000 санын күрергә дә ерак калмый... Шөкер, әлегә журналыбыз график буенча вакытында чыгып килә, укучылар кулына барып ирешә. Кайбер басмалар шикелле, ике айныкын яки кварталныкын берләштереп куш саннар чыгарган юк. Авторларга каләмхак түләү дә соңгы елда җайга салынып бара... Хөкүмәтнең, шул исәптән үз министрлыгыбызның, кайгыртучанлыгын һәрдаим тоеп эшлибез.

«Казан утлары»н бүгенге татар әдәби хәрәкәтенең төп штабы, үзенә күрә бер «диспетчерлык» үзәге дип саналырга хаклыдыр дип уйлыйбыз. Чөнки татар язучыларының, фикер ияләренең иң яхшы дигән яңа әсәрләре, галимнәрнең хезмәтләре, гадәттә, безгә килә. 1999 елда журналыбызда 257 авторның эреле-ваклы әсәре, язмасы дөнья күргән. Шуларның кимендә яртысы—бүгенге әдәби хәрәкәттә актив катнашучы авторлар. 1999 елда 5 роман бастырдык. Хәтердә, кайчандыр «проза жанрында быел бер роман туды» яисә «ике съезд арасында өч роман язылды» дип сөйләнгән чаклар бар иде. Быел дөнья күргәннәре—арадан сайлап алып басылган романнар бит. Шуларга өстәп—20 гә якын повесть һәм хикәяләр, 2 пьеса, 2 поэма, һәр санда даими басылып килә торган публицистика һәм тәнкыйть мәкаләләре, тарихи хезмәтләр, әдәбият-сәнгать яңалыклары...

Бүгенге әдәбиятта кызыклы, гыйбрәтле хәлләр бара. Эчтәлек-фикер ягыннан да, сыйфатый-камиллек ягыннан да күп унай мисаллар китерергә мөмкин булса да, борчыган нәрсәләр дә житәрлек. Шуларнын, мөгаен, иң авыры—әдәби процесста хаосның хөкем сөрүе. Нәшриятлар күп, акча-дәрманы булган кешеләр дә юк түгел. Китап исеме астында бик күп антиәдәбият чыга. Махсус әзерлеге булмаган гади укучыга талантны графоманнан, яхшы әсәрне яманнан аеру кыенлашты. Бу очракта ориентир-маяклар күрсәтергә тиеш әдәби тәнкыйтебез бик зәгыйфь. «Казан утлары» бу мәсьәләдә үзенә күрә бер юлкүрсәткеч булырга тиеш. Шуны анлап, алга таба әдәби тәнкыйть үсешенә аерым игътибар бирмәкчебез. Алдагы саннарда «әдәби тәнкыйтьне ничек «терелтергә»? дигән баш астында чыккан язмадан күренгәнчә, күп кенә әдипләрне дә бик борчый бу хәл.

Тираж мәсьәләсе. Һәммәбезне дә бик уйландыра торган мәсьәлә. Бүгенге көнгә тиражыбыз—8229 данә. Заманына күрә ярый да сыман. Әмма татарның төп журналы өчен азрак. Тиражларның кимүенә сәбәпләр күп: гади халыкның матди хәле начар булу, газета-журналларның күбәюе (татар телендә укучы халык ишәйми, алар моннан егерме-утыз ел электәге кебек 5-6 басма алдырмыйлар, язылсалар 1-2 газетка йә журналга язылалар), урындагы җаваплы кешеләрнең мәсьәләне анлап җиткермәүләре, пошмаулары, иманнары булмавы һ. б... Әлбәттә, үзебезнең редакция хезмәткәрләре ягыннан да пропагандалау эшен заманча эффектлы итеп оештырып бетерә алмыйбыз әле. Миңа калса, алдагы елларда «Казан утлары»нын тиражы минимум 10-15 мең булырга тиеш.

Кульязмалар 1999 елда бүтән еллардагыга караганда күбрәк керде. Язучыларның абсолют күпчелеге бездә басылырга тели. Менә журналның стабиль чыгуы, унга-сулга тайпылмыйча төпле мәсләге булуы, һәм ниһаять, азмы-күпме булган каләмхакны вакытында түләп бару да сәбәп булса кирәк. Иң мөһиме—сайлап алып бастырырга мөмкинлек бар. Күләм күп булса да, яхшы проза әсәре—сирәк кунак. Сәбәпләре дә бар: М. Мәһди, Х. Сәрьян, М. Хәсәнов, Ш. Хөсәеновләр (олуг драматург булу белән рәттән ул менә дигән прозаик та иде) китеп бардылар. Танылган әдипләр—халык язучылары Ә. Еники, А. Гыйләҗев, Г. Ахуновлар өлкәнәйделәр... Мәйдан уртасында 40-50 яшьлекләрдән Ә. Гаффар, М. Галиев, Р. Сибат, Ф. Әмәк, Н. Гыйматдинова, Ф. Яхин, З. Хәкимнәр калып бара. 30-35 яшьлекләрдән авыз тутырып әйтердәй чын талант иярләре аз. 60-70 еллардагы татар мәктәпләре бетерелүгә хөкем ителгән чорның нәтиҗәләрен татыйбыз хәзер... Бүтән жанрлардагы хәлләр турында махсус әзерләнеп килгән иптәшләребез тәфсилләбрәк сөйләр.

Без, вазгыять, сәяси-мал заманы яңара дип, кинәт кенә кардиналь үзгәрә алмыйбыз. Хәтта, теләсәк тә. Базар мөнәсәбәтләре чорына ярашып ук бетә алмыйбыз. Редакция хезмәткәрләре генә түгел, язучыларыбыз да, хәтта, әйтер идем, җәмгыятебез дә. Әйтик, без журналыбызда реклама-игъланнар басмыйбыз. Кемдер әйтер, биш-алты мең генә булса да, керемегез булыр иде, дияр. Әйе, бәлки, безгә дә акча кирәктер... Әмма журнал тышлыкларында без язучыларыбыз портретларын, олуг сәнгать осталарынын, әйтик рәссамнарның, яңа зур хезмәтләрен бастырабыз. Алай эшләү—халык мәнфәгатенә күбрәк туры килә дип исәплибез.

Бу җыелышыбызда Редколлегиянең яңа әгъзаларын да расларбыз дип ышанам. Моңарчы эшләп килгән әгъзаларның кайберләре дөнья куйды (Н. Нәҗми), кайберләре үз теләкләре белән бу вазифадан азат итүне сорадылар. Редколлегия составына тәкъдим ителә торган иптәшләр түбәндәгеләр: Зилә Вәлиева—Татарстан матбугат, телевидение, радиотапшырулар һәм гаммави коммуникацияләр министры; Фоат Галимуллин—Татарстан Язучылар берлеге рәисе; Гәрәй Рәхим—Татарстан Дәүләт Советы аппараты референты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

Хөрмәтле каләмдәшләр! Сезнең кулыгызда 2000 елга төзелгән план-проект. Анда безнең эшчәнлегебез юнәлешләре күрсәтелгән, редакция портфелендә булган әсәрләр исемлеге бирелгән. Танышып, үз фикерләрегезне әйтерсез дип ышанам. Ә хәзер бүгенге әдәбиятыбыз, аерым алганда, быел «Казан утлары»нда басылган әсәрләр турында ихлас сөйләшергә чакырам.

## Флүс Латыйфи:



Соңгы елларда журналда басылып чыккан әсәрләрдә нәрсә күзәтелә? Гомумән, бүгенге прозада нинди тенденция өстенлек итә, нинди процесслар бара? Минем шул хактагы фикерләремне сезнең белән уртаклашасым килә. Яшерен-батырын түгел, әле моннан дүрт-биш ел элек кенә проза әсәрләре бик сыек иде. Журнал битләрендә, гәрчә алар Язучылар берлеге әгъзасы булып исәпләнсәләр дә, ярымүзешчән авторлар өстенлек итте, бар мәйданны алар басып алган иде. Һәм без беренче эш иттереп, акрынлап булса да таләпчәнлек планкасын күтәрә барабыз. Болай эшләр өчен безгә нәрсә мөмкинлек бирә соң?

Беренчедән, соңгы ике-өч елда чәчмә әсәрләр бик күп керә башлады. 1998-1999 елларда исә рекордлы дәрәҗәгә житте. Һәм, табигый ки, бу үзеннән-үзе аларга карата таләпчәнлекне дә бермә-бер арттырырга мөмкинлек тудырды. Кистереп әйтә алам, редакция тарафыннан борылган биш-алты роман бар, повестьлар бихисап, хикәяләрне әйтеп тә тормыйм. Әйткәнемчә, аларның авторлары Язучылар Берлеге әгъзалары. Мондый сәясәт бәлки, кемдәдер үпкә дә уята торгандыр, кемнәрдер, редакциягә ачу тотып та китә торгандыр... Ләкин нишлисең, әсәрләре редакциянең, зәвыклы укучының таләпләренә җавап биреп бетерерлек түгел иде.

Соңгы еллардагы иҗтимагый тотрыксызлык сәбәпме ана, белмим, әмма проза язучылар сирәгәйгән, бу жанрда, чыннан да, таләпчәнлек бик нык кимегән иде бит. Ни өчен? Уйланып карыйк әле. Еш кына без китап чыгаруны бик авыр дип зарланырга яратабыз. Шунысы бар, пычак ике яклы дигән кебек, ул кемгәдер бик авырайды, ләкин шул ук вакытта кемгәдер бик жиңеләйде дә бит. Яхшы беләбез, әдәбият тирәсендә язучы булырга, язучы дигән бөек исемне алырга үтә дә тырышып йөргән бер даирә шома егетләр, графоманнар даирәсе димме, бар. Ул акчалы дуслар таба, тегеләй итә, болай итә, әмма китабын бастырып чыгара. Китап чыга. Ул китап йөри, тарала. Авторы аны бик актив рәвештә, хәтта бушлай диярлек тарата, таныла һәм язучы булып йөри башлый. Кесәсе калын кешегә китап чыгару хәзер кыен түгел. Акчан булса, теләсә нинди тузга язмаган нәрсәләрне бастырып чыгарырга әзер ярымүзешчән нәшриятлары да, типографияләре дә житәрлек. Ләкин гомере буе әсәр язган, чын әдәбият сагындагы Татарстан китап нәшриятына тугры калган һәм бары тик каләмхак әҗеренә яшәп килгән язучы моны эшли алмый. Шулай итеп, китап базарын камил булмаган, чын әдәбияттан шактый ерак торган зәвыксыз китаплар басып алды. Дөрес, андый китапларның да үз укучысы, үз даирәсе бардыр, ләкин чын мәгънәсендә югары сәнгатьле, чын, камил әсәрләр бары тик "Казан утлары"нда гына басыла ала. Ни өчен "Казан утлары"нда? Чөнки монда әсәрне акча түләп бастырып булмый. Акча түләп тә, башкача итеп тә... Шунлыктан, мин бүген чын татар әдәбияты, чын татар романы, иң матур шигырьләр, чын мәгънәсендә әдәби тәнкыйть һәм публицистика кайда ул, дип сорасалар, курыкмыйча әйтә алам, алар бары тик "Казан утлары" журналы битләрендә генә. Бу башка басмаларга күләгә төшерергә теләгәннән түгел, ә бәлки журналдагы хәлне, әдәби сәясәтне белгәнгә күрә ассызыклап әйтелгән сүзләр. "Казан утлары"нда басылу өчен әсәрнең чын мәгънәсендә югары кимәлдә эшләнеше, теленең сафлыгы, чисталыгы, зәвыклы әсәр булуы, чын әдәби осталык шарт. Темасы әйбәт бит, авторы яхшы кеше бит дип кенә журналда әсәр чыгарып булмый.

1999 елда журнал битләрендә биш роман, тугыз повесть, ун хикәя һәм "Татар хикәяләре хәзинәсеннән" дигән циклдан тагын өч хикәя басылып чыкты.

Бу рубрика ни өчен һәм кемгә кирәк? Иң элек ул үрнәк өчен. Нинди

хикәяләребез бар? Гасыр дәвамында язучыларыбыз нинди темалар күтәргән. Иң яхшы хикәя дигәнебез нинди булган? Алтын хәзинәбезне нәрсәләр тәшкил итә? Классикларыбызның иң яхшы әсәрләре генә сайлап басыла. Әмирхан Еникинең "Шаяру", Габделхәй Сабитовның "Өч күнел", Кәрим Тинчуринның "Дачада" дигән хикәяләрен бастырып чыгардык. Бүгенге көндә дә һәм тел ягыннан, һәм сюжет ягыннан өлге-үрнәк булырлык хикәяләр алар. Әсәр житмәгәнлектән басмыйбыз без аларны. Әйткәнемчә, әсәрләр житәрлек. Бу укучыларга, үсеп килүче яңа буынга күрсәтер өчен махсус эшләнә. Чөнки ул китаплар инде тузган, яңалары исә басылмый. Ә "Казан утлары"нда басылып чыккач алар яңа сулыш алалар, чын хикәя шушындый була икән дигән бик матур тәэсир калдыралар.

Инде роман жанры турында. Монда исә бик кызыклы бер тенденция күзәтелә. Бер яктан, әле һаман да су кебек озын, унтугызынчы гасыр азакларындагыча яисә илленче еллардагыча, күпсүзлелектән жәфа чигүче романнар язу дәвам итү белән бергә, тыгыз концентрацияле, катлаулы сюжетлы, аз сүзле, әмма сурәтләү ягыннан киң колачлы яңа тип романнар күренә башлады. Һәм бу аңлашыла да. Чөнки заман үзгәрде, кешеләр үзгәрде. Югары тизлек, компьютерлар заманы килде, дөньяны информация ташкыны басып китте. Кешенең бишәр йөз, алтышар йөз битлек, хәтта меңәр битлек романнар укып утырырга вакыты да, түземе дә һәм теләге дә юк. Шушы хәл безнең әдәбиятта да үзен нык сиздерә башлады. 1999 елда чыккан романнарның иң озын дигәне дә ун табактан артмый. Ә инде кыскалык ягыннан рекордны, миңа калса, Айдар Хәлим куйды. Аның "Татар вакыты" романы журнал битләрендә нибарысы утыз сигез бит алып тора. Машинка битләре белән исәпләгәндә, өч табакка, нибарысы 75 биткә, Октябрь инкыйлабыннан соң татар тормышында булган, милләтнең жанына, икътисадына, яшәү рәвешенә суга торган бөтен әверелешләр сыйган. Ул шулхәтле тыгыз язылган ки, әле уйлап та куям, бу теманы нинди дә булса күп сүзле язучы алган булса, бәлки ул рәхәтләнеп жиде йөз биткә дә тарта алган булыр иде. Дөрес, автор аның жанрын кыска роман дип билгеләгән. Әдәбият теориясе кануннары буенча тикшерсәң, әсәр бәлки роман да түгелдер. Анысы бәхәс тә кузгатырга мөмкин. Ләкин сурәтләнгән вакыйгалар романлык. Әсәрдә кереп кенә чыккан геройлар бар. Һәм шул геройларның кылган гамәлендә бөтен кеше язмышына житәрлек вакыйгалар, шагыйранә символик сурәтләр.

1999 елда шаян сүз остасы дип танылган Камил Кәримов роман авторы буларак бөтенләй яңа яктан ачылды—аяз көнне күк күкрәгән шикелле "Ком сәгате" дигән романын бирде. Кызыклы параллель. А. Хәлимнең романы "Татар вакыты" дип атала, Камилнеке дә шуңа аваздаш—"Ком сәгате". Вакыт үтә, ул бармак арасыннан агып чыккан ком кебек... Безгә бирелгән гомер вакыты үтә бара, үтә бара... Бер генә ком бөртеген дә кире кайтарып булмый. Без ничек коелабыз соң әле? Бездән жир йөзендә нинди эзләр кала? Камил язган, сурәтләгән темасын, вакыйгаларны белеп һәм яратып яза. Аның белән бергә роман геройларына гашыйк булып каласың. Алар белән бергә кайгырасың, сөенәсең, борчыласың... Алар тормышы белән яши башлыйсың. Бу романнарны мин әдәбиятыбызда соңгы еллардагы вакыйга дип саныйм.

Зәки Зәйнуллинның романы да матур тәэсир калдырды. Ул нәрсәсе белән кызыклы? Бәлки, язылыш ягыннан аның чатаклыклары да бардыр. Тел ягыннан да шомартылып житмәгән урыннар күзгә ташлана. Чөнки роман тиз арада эшләнгән, суытып өлгермәгән көйгә редакциягә килеп керде, бераз эшкәртелсә дә житешмәгән жирләре калган булуы ихтимал. Бу табигый хәл. Әсәрнең кыйммәте шунда, З. Зәйнуллин Башкортстандагы вәзгыятькә әдәби әсәр белән бәя бирә белде. Хәзер Көнбатыш Башкортстан дип аталган жирләрдә борынгы болгар калаларының булганлыгы, борынгы бабаларыбыз яшәгән жирләр икәнлеген раслап, бу жирләрдә татарның килмешәк түгеллеген, туган жире, үз жире икәнлеген ассызыклап куйды. Бу безнең татар жире, без Башкортстанда килмешәк түгел, монда башкорт теленең уйлап чыгарылган нииндидер көнбатыш диалектында сөйләшүчеләр түгел, ә борын-борыннан татарлар яши дигән фикер ул. Һәм ул фикер тарихи чыганаклар белән исбатлана. Әсәрнең табигый рәвештә Мирсәет Солтангалиев язмышына килеп тоташуы да табигый. Ул әсәрне бүгенге көн белән дә, ерак тарих белән дә бәйләп куйды. Зәки абый тыныч кына, тик кенә утыра торган кеше түгел. Ул аны әле тагын да камилләштерер, китап итеп чыкканга кадәр роман тагын да шомара төшәр дип беләм.

Марат Әмирханов шулай ук беренче романы белән катнашты. Аның моңа кадәр

басылган "Гөлнәзирә" повестен журнал укучылар яратып кабул иткән иде. Яңа әсәрдә дә хатын-кыз язмышы, аның авырлыклары да, матурлыклары да, фаҗигасе дә. Заманча язылган әсәр. Шулай да, "Гөлнәзирә" эшләнеш ягыннан матуррак, үтемлерәк иде. Җыйнаграк иде.

Инде докладчы икәнмен, тагын бер романны әйтмичә кала алмыйм. Аңа нииндидер бәя бирергә җыенмыйм. Шунысын гына искәртәсем килә, (бирелә өченче затта сөйләргә мәҗбүрмен) Флүс Латыйфиның "Ишелеп төшкән бәхет"е—роман-эксперимент. Ул, безнең традицион татар романнарында булмаганча, дөньяны эре штрихлар белән колачларга тырышып карау. Татар кайда бәхетле? Татарстанда бәхетлеме ул? Чит илләргә күчеп киткән, качып китәргә мәҗбүр ителгән татарлар бәхетлеме? Беренче карашка мәхәббәт һәм Ватанга тугрылык хакындагы сыман тоелучы роман тукымасына урыс дәүләтенең татарга карата гасырлар буе дәвам иткән мәкерле сәясәте яшерелгән. Ничек тә булса татарның тамырын корыту, аның генофондын юкка чыгару сәясәте ул. Укыган кешеләр аңа үз бәяләрен бирер дип беләм.

Һәр әсәргә тукталырга вакыт җитмәсә дә, повестьлар хакында аерым фикер әйтәсе килә. Алар тугыз. Яңа авторлар байтак. Шуларның берсе—Каим Шәйхетдинов. "Кышлар узар..." Хәрби кеше язмалары. Каләме бар. Бу уңайдан кызыклы бер закончалык күзәтелә. Запаска, отставкага чыккан хәрбиләр каләмгә тотына. Һәм бу бер дә гаҗәпләндерми. Чөнки ул чорларда татар егетләре өчен офицер булу бер дәрәҗә саналган, акыллы, сәләтле егетләребез гомерләрен гаскәрилеккә багышлаган. "Казан утлары" өчен Әмирҗан Моталлапов исеме дә яңа булды. Повесть белән катнашты. Бөтенләй яңа автор—Нурулла Гариф. "Мәмеш Бирде" дигән тарихи кыйссасында ул үткән заманнарны мавыктыргыч итеп әдәби кимәлдә күз алдына китереп бастыра алды. Һәммәсендә рациональ орлык бар. Бүген башка язучылар тарафыннан әлегәчә әйтелмәгән, күтәрелмәгән яңа катламнар ачыла. Алар шуның белән кызыклы. Ә инде повестьлар арасында иң уңышлысы дип мәрхүм Әнәс Галиевнең "Чигенгәндә" дигән әсәрен аерып куясым килә. Кызыл армия чигенеп бара Украина якларыннан. Бер төркем егетләрне алып, бик мөһим задание биреп ерак тылга озаталар. Болар чолганышта кала-кала, иптәшләрен югалта-югалта кайтып егылалар Грузиягә—хәрби округның үзәк шәһәренә. Нәрсә алып кайтканнар болар? Дәүләтнең ин яшерен серләрен саклап кайтабыз дип, газиз башларын мең бәла астына куеп кайткан егетләр ни төяп кайткан соң? Болар акча, асыл маллар икән. Армия сәргаскәрләре хатыннарына, гаиләләренә зур байлык кайта. Тегендә немецлар килгәнче банклар ачык, хранилищелар ачык... Барысы да эвакуацияләнә алмаган. Әсәрдә бүгенге урыс армиясенең дә хәле ачык күзаллана.

Әсәрләрне кыскача санап чыгу гына да "Казан утлары" журналының бүгенге тормышка актив позициядә торуын күрсәтә.

Хикәяләр бик күп булды. Хикәя дигәч, кайчандыр ишеткән бик мәгънәле сүзләр искә төште әле. Әдәбиятка керү чагыштырмача җиңел, ә менә анда гамәлдә булу шактый авыр эш. Әдәбиятта калу исә бөтенләй мөмкин булмаган, аерым фидакарьләргә генә тәтегән бәхет ул. Алар инде классиклар. Бер китабы, бер әсәре белән кергән кешеләр кала алмый әдәбиятта. Ә безгә хикәя күтәреп күбесенчә шундый кешеләр килә дисәм, ялгышмамдыр. Шулай итеп, әдәбиятта, Язучылар берлегендә балласт барлыкка килә. Хәтта үзегез эшләп бетерегез инде, язып бир инде дигән тәкъдим белән килүчеләр дә бар. Ләкин кешегә ничек язып бирмәк кирәк. Андый заманалар үтте бит.

Прозада тагын нинди тенденция бара? Иң күзгә ташланганы, бу өлкәгә дә хатын-кызлар килә башлады. Бөтенләй белмәгән, күрмәгән җирләрдән, авыл җирләреннән, районнардан—Чаллы, Сарман, Мөслим, Актаныш якларыннан килә әдәби әсәрләр. Матур, җырлап торган чишмә кебек татар теле белән язылган әйберләр. Чак кына кул тигереп, вакыйгаларны, ситуацияне үзгәртеп җибәрәсең, менә дигән әсәр килә дә чыга инде. Хәзер редакция папкасында Казан кызы Сөмбел Гаффарованың бик әйбәт хикәяләре ята. Айгөл Әхмәтгалиева дигән кыз беркемгә дә билгеле түгел. Хикәяләре Чаллыдан килеп төште. Җырлап укыла, теле бай, халыкчан. Теленнән җылылык бөркелеп тора, андый телне тотып, сөеп карыйсы килә башлый. Мөслимнән Ләлә Сөләйманова дигән авторның нәни генә әйбәт повесте ята.

Өстәп шуны әйтәсем килә, элегрәк Арча якларыннан әдәбиятка яңа алмаш килә торган иде. Хәзер менә шундый үзәк Татарстанның көнчыгышына күченә бара. Әкренләп ул процесс көчәя, төп көчләр шуннан килә. Иң матур, халыкчан телле язучылар бүгенге көндә шул яклардан. Мисалга Факил Сафинны алыйк. Соңгы елларда гына роман һәм повесте чыкты. Теле гаҗәп бай! Казанга килеп күренгәне дә юк, Мөслимдә яшәп язып ята Фоат Садри. Аласың әсәрләрен, укырга рәхәт. Җырлап торган йомшак, ягымлы, матур тел.

Тагын бер үзенчәлек, яшьрәк буын телсез иде, телсез язучылар күренә иде. Хәзер исә яңа яшьләрнең әдәби теле яхшыра башлады. Хәтерегездәдер, әле моннан бер ун ел элек кенә митингларга чыгып кычкыра идек: дәһшәтле бер сан бар иде. Татар балаларының бары тик җиде проценты гына ана телендә укый иде. Телне кисү, үтерү бара иде. Хәзер исә Татарстан мәгариф министрлыгыннан алынган яңа мәгълүматлар күрсәткәнчә, республикадагы татар яшьләренең 47 проценты чын татар мәктәбендә урта белемне туган телдә ала. Аз әле, әмма үсеш бар. Юк-юк дисәң дә, хәзер һәр өлкә үзәгендә татар мәктәпләре эшли. Күптән түгел Ижауда "Казан утлары" көннәре уздырып кайткан идек. Удмуртия башкаласында удмурт мәктәбе юк, ә классик татар гимназиясе ачканнар. Пединститутларында татар филологиясе бүлеге, педучилищеда татар бүлеге эшләп тора. Инде беренче чыгарылышлары булган. Әкренләп булса да кадрлар әзерләнә. Менә шушындый куанычлы үзгәрешләр фонында яшьләрнең әдәбиятка омтылуы аеруча сөенечле хәл бит.

Чыгышымның башында ук мин әсәрләргә таләпчәнлек дәрәҗәсе нык күтәрелде дигән идем. Әйе, ул шулай. Әмма, шуның белән бергә, редакциягә проза әсәрләре килү дә нык артты. Бүгенге көндә редакция папкасында инде өйрәнелгән һәм өйрәнелү стадиясендәге сигез роман, ун повесть бар, хикәяләр исә бихисап. Бу инде үзе генә дә безнең потенциаль мөмкинлекләребез, потенциаль энергиябез сүнмәгән, сүрелмәгән дигәнне анлата. Проза торгынлыктан чыгып килә, ул күтәрелештә дип әйтергә тулы нигез бар дип әйтәсем килә.

## Гәрәй Рәхим:



Журналның быелгы ун санында басылып чыккан поэзия әсәрләре белән таныштым, аларны бер мин генә түгел, инде һәрберебез дә укыган, шул сәбәпле, һәр әсәргә аерым-аерым тукталуны кирәк санамыйм. Бүгенге поэзия һәм «Казан утлары»ның бер-берсе белән нинди мөнәсәбәттә булулары хакында кайбер фикерләрем белән генә уртаклашасым килә. Бүгенге татар поэзиясенең торышы, үсү юллары, үзгәрешләре һәм аның иң зур уңышларын тәгәл күрсәтү, аның йөзен тәгаен генә билгеләү миссиясе «Казан утлары»нда дип саныйм. Биредә басылган әсәрләрдән чыгып кына без татар поэзиясенең бүгенге әдәбиятта тоткан урынын билгели алабыз.

Әйдәгез, журналда басылган әсәрләргә иң элек тематик яктан якын килеп карыйк. Бу яктан алганда, бөтен шагыйрьдә дә уртак бер күренеш күзәтелә. Нинди уртаклык соң бу? Бу—без электән аһ-зар килеп әйтә алмыйча интеккән, шигырь юллары арасына яшерә-яшерә генә халыкка житкерә алган, бәгыребезнең түреннән чыккан иң төп тема—татар халкының рухи тормышын, аның дөньядагы һәм күрше-күлән арасында тоткан урынын һәм татар менталитетына гына хас үзенчәлекләрен билгеләү темасы. Бу күренешне мин бик табигый дип саныйм, чөнки ул бүгенге көндә иң актуаль тема булып исәпләнә. Рәсәйдә басылып чыккан тарих китаплары, Рәсәйнең матбугат чаралары

әле һаман да безнең тарихыбызны дөрес анлатмый, киресен сөйләргә тырыша. Шушы шартларда бу теманы күтәреп чыгуны мин татар шагыйрьләренең унышы дип уйлыйм.

Журналда басылган шигырьләрдә тагын бер уртаклык сизелә—90 еллар башында милли хәрәкәтебез, милли фикеребез урамнарга, митингларга бәреп чыккан хәтәр бер заманда, без—шагыйрьләр—бераз гына югалып калдык шикелле. Партия идеологиясе бетте, яңа идеология күренми... Шушы көчеш чорында бигрәк тә поэзиянең лирик формалары, шигърияттнең иң нечкә жанрлары ничектер тукталып калды. Ләкин менә соңгы вакытларда шигърият артык сәясәтне алып ташлап, янадан үз эзенә, поэтик сүз әйтүгә, поэтик сәнгатьнең күп мөмкинлекләренә нигезләнгән әсәрләр иҗат итүгә юнәлде. Шушы яссылыктан карaганда, журналда быел басылган шигырьләргә күз салсак, начар дип әйтерлек шигырь юк. Уртакул шигырьләр бар, ләкин алар азчылыкны тәшкил итә. Иң күбе—әйбәт шигырьләр.

Әле генә Равил Фәйзуллин әйткән фикер белән килешәм—дөрестән дә, гади укучыга яхшы әсәрне начардан аеру кыенлашты. Миңа калса, бу яктан да журнал гади укучыга ориентир булып тора.

Поэма жанры буенча бер-ике сүз әйтеп китәм. Әлеге жанр соңгы вакытта зур үзгәрешләр кичерде. Беренчедән, поэмалар сан ягыннан бик нык кимеде, икенчедән, күләм ягыннан бик нык кыскарды. Быел менә нибары ике поэма басылган. Берсе—Ренат Харисныкы, икенчесе—Рөстәм Мингалимнын шигъри новелла кебек әсәре. Кыска булсалар да, аларда шигъри көч шактый күп.

Бу саннарда басылган шагыйрьләрдән мин Гамил Афзал, Зөлфәт, Радиф Гаташ, Наис Гамбәр һәм Шамил Маннаповның шигырьләрен әйбәт дип әйтер идем. Шулай ук яшьләр арасында берничә шагыйрь һәм шагыйрәләребезне аерып әйтергә мөмкин—аларда инде бернинди өйрәнчеклек юк, өлгергән әсәрләр иҗат иткәннәр.

Инде тәкъдимнәргә килгәндә. Беренчедән, әдәби юмор кимеде. Эпиграммалар, шаржлар, багышлаулар элегрәк журналда еш басыла һәм алар шактый кызык була торган иде. Бәлки инде хәзер аның авторлары да юктыр. Яшь шагыйрьләр, менә игътибар итсеннәр иде.

Икенчедән, журналда иҗат портретлары, аерым язучының иҗаты һәм биографиясе турында кызыклы мәгълүматлар белән язылган чын әдәби очерклар юк. Мин, мәсәлән, сан саен бер язучы турында укырга теләр идем. Язучыдан башка әдәбият юк, язучы әсәреннән башка журнал юк. Бәлки, журналның дүртенче тышлыгында рәсеме чыгучы язучы турында шул номерда ук мәкалә урнаштырыргадыр?

## Галимҗан Гыйльманов:



Бүгенге тормыш шактый катлаулы, дөньяда зур үзгәрешләр бара. «Казан утлары» журналын шушы чорда әдәби процессны тотып торучы журнал дип саныйм һәм киләчәктә дә аның шулай булачагына ышанам.

Әдәби тәнкыйть—әдәби иҗатның бәя, анализ белән бәйле өлкәсе. Шуңа күрә агымдагы әдәби хәрәкәтнең барышы, асылы, үсеш перспективасы турыдан-туры шушы жанрның егәрлегеннән тора. Чынлап та, бүген бу жанрның хәле ничек соң? Агымдагы елда «Казан утлары» журналында дөнья күргән тәнкыйть мәкаләләре берничә борчулы фикергә урын калдыралар.

Мәгълүм ки, соңгы вакытта әдәби тәнкыйтьнең яңа чалымнары барлыкка килде. Әйтик, публицистик

аһәң бик көчәйде. Бу турыдан-туры тәнкыйтьчеләрнең заман сулышын тоеп яшәүләре, гражданлык позицияләре активлашуы белән бәйләнгән. Академик фән, әдәбият гыйлеме дә нык үтеп керә башлады тәнкыйтькә. Сөенергә генә кирәк, югыйсә. Әмма беренче очракта да, икенче очракта да публицизм һәм академизм белән мавыгуларны күрми калу мөмкин түгел. Мәсәлән, 1999 елда «Әдәби тәнкыйть» рубрикасында басылып чыккан кайбер мәкаләләр (Ф.Хатипов, Ф. Урманче, Г. Мөхәммәтвәлиева һ.б.) әдәби тәнкыйть язмалары булудан бигрәк, әдәбият белеме буенча тикшеренүләрне хәтерләтәләр.

Икенче бер чик: шул ук рубрикада Лена Шагыйрьҗанның «Сүз»гә багышланган лирик язмасы, эссесе китерелгән («К.У.» № 3). Аның әдәби тәнкыйть белән бернинди уртаклыгы да юк.

Укучыны ялгыш юзанга кертеп җибәрергә мөмкин сәяси публицизмга бер мисал. Беренче санда Радик Фәизовның тәнкыйди язмасы (анкетага җаваплар) урнаштырылган. Автор монда туксанынчы еллар сәяси тормышын «егерменче еллар инкыйлабы» белән чагыштыра һәм егерменче еллар инкыйлабы (?) халык кузгалышы нәтиҗәсендә,ә туксанынчы еллар инкыйлабы (?) «асылда югарыдан, өстән ясалды, анда халык, хезмәт ияләре бөтенләй катнашмады», дигән фикер үткәрә. Татар язучылары бу хәрәкәттә, ягъни мәсәлән, «аны башкаруда урын тотмадылар» дип тә җибәрә хәтта хөрмәтле язучыбыз. Мондый бәхәсле язмалар әдәби тәнкыйтькә генә түгел, журнал абруена да шактый зыян китерә, минемчә.

Тагын бер борчыган нәрсә: журналда басылган мәкаләләрдә әдәби тәнкыйть жанрының яшәү-яшәмәве, гомумән, шик астына алына. Алтынчы санда басылган мәкаләсендә Ф. Урманче болай дип яза: «Безнең көннәрдә әдәбият фәненнән, чын шигърияттән ерак торган социалистик реализм кануннарының барысы да чәлпәрәмә килде, берсе дә калмады. Бәлки, шуна күрәдер, әдәби тәнкыйть тә шактый сүрелеп, гомумән бетүгә йөз тотты». Шунда ук автор Х. Госман, Г. Халит, И. Нуруллин, Г. Кашшаф, Н. Юзиев кебек корифейларның исемнәрен телгә алып: «Чын әдәбият белемен дә, әдәби тәнкыйтьне дә үзләре белән алып киттеләр» дигән үтә дә бәхәсле фикер әйтә. Бәхәсле, чөнки тәнкыйть жанрының үсешен соцреализм белән, бигрәк тә аерым исемнәр белән генә бәйләү дөрес булмас иде. Бүгенге көндә Ф. Галимуллин, Т. Галиуллин, Р. Рахмани, Г. Сверигин, Н. Хисамов кебек «фәннән килгән» тәнкыйтьчеләр дә, М. Вәли, Р. Мостафин кебек «публицистик рухлы» тәнкыйтьчеләр дә бердәй актив иҗат итеп киләләр. Аларның барысы да—шул ук Х. Госманның, И. Нуруллинның яисә Н. Юзиевнын шәкертләре, дәвамчылары.

Ф. Урманченың әлеге мәкаләсендә тәнкыйтьче, бигрәк тә халык иҗаты белән язма әдәбият бәйләнешләре хакында язучы өчен «дистәләгән еллар буе халык иҗатын өйрәнү» шарты куела. Минемчә, тәнкыйтьче булу өчен, унар еллар архив-фондларда утырып, диссертацияләр язу мәҗбүри түгел, аңарда ин элек Ходай тарафыннан бирелгән тоем булырга тиеш. Тәнкыйтьче бәяне анализлап кына түгел, күнеле, хыялы аша да үткәреп бирергә тиеш.

Шул ук җавапны Р. Сверигиннын: «Бүгенге төп кыенлык сепаратор булмауда—ягъни әдәби тәнкыйть дигән нәрсәнең үз функцияләрен, вазифаларын башкарудан бөтенләй читләшүендә»,—дигән сүзләренә карата да бирәсем килә. Бар әдәби тәнкыйть, бар. Читләшми дә ул, заманга яраклы рәвештә бераз үзгәрә генә. Заманга өлгерә алмый икән инде—анысы икенче мәсьәлә.

Киңәшем шул: үзенең чын тәнкыйть рухын, тәнкыйть мәктәбен саклап калган «Казан утлары» киләчәктә «тәнкыйтьнең бетүе» хакындагы язмаларга азрак игътибар бирсен иде.

Әдәби тәнкыйть өлкәсендә журналның иң зур уңышы—90 еллар әдәбияты хакында анкетага җаваплар. Әлеге җавапларда әдәби тәнкыйть жанрының бөтен чалымнары да ачык чагылган. Алар арасында анализга нигезләнгән язмалар да (Л. Шагыйрьҗан, Р. Гаташ, Н. Гамбәр һ.б.) шактый.

Сорауларга җаваплар соңгы 10—15 елда ирешелгән әдәби казанышларны, уңай сыйфатларны, шулай ук чор әдәбиятының кимчелекләрен, һәм ниһаять, алдагы гасырга аяк атлаганда язучының тоткан урынын ачыкларга тиеш иде.

Максатка ирешелгән дип саныйм. Төп фикер бер үк исемнәр тирәсендә бөтерелә. Соңгы 10—15 елда иң күренекле әсәрләрне Мәхмүт Хәсәнов, Әмирхан Еники, Фоат Садриев, Тәлгать Галиуллин, Ринат Мөхәммәдиев, Ибраһим Салахов, Аяз Гыйләҗев, Флүс Латыйфи, Миргазыян Юныс, Зөлфәт Хәким, Марсель Галиев, Факил Әмәк, Рафаэль Сибат, Айдар Хәлим, Зәки Зәйнуллин биргән. Шигърияттә—Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм, Харрас Әюп, Газинур Морат һәм әлбәттә, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рәшит Әхмәтҗан, Рәшит Әхмәт, Лена Шагыйрьҗан һ. б. Драматургиядә ике исем: Туфан Миңнуллин һәм Зөлфәт Хәким.

Соңгы елларның әдәби казанышы, гадәттә, заман геройлары белән, хәтердә калырлык төп образлар белән бәйләнгән була. М. Хәсәновның Иргалие күп телгә алына, шулай ук Р. Мөхәммәдиев белән Т. Галиуллиннарның бүгенге көн кешесенең типик вәкилен күрсәтеп бирә алулары искәртелә.

Бүгенге көндә әдәби тәнкыйть игътибар итәр мәсьәләләр күп: милли рух проблемасы һәм әдәби процесс, әдәбият һәм социология, әдәбият һәм бүгенге әхлак, әдәбият һәм базар психологиясе... Әдәбиятның төрле дәрәҗәләрдә (образ, сүз, мәгънә) пычрануы, әхлакый тотнаксызлык, акча белән буталу...

Жанр формаларында да активлык кирәк. Үткен, дәлилле һәм гадел мәкаләләр житешми, әдәби портретлар азайды. Дөрес, тәнкыйди эсселар «сүзбаш»лары, аналитик тәнкыйть формалары һаман актив килеш кала, әмма әдәби тәнкыйтьнең җаны булган рецензия жанрына заман сулышы өрәсе бар әле.

## Марс Шабай:



1999 ел публицистикасын журналның баш мөхәррире Равил Фәйзуллинның «Гасыр йомгагын төенләгәндә» исемле зур мәкаләсе ачып җибәрде. Әдип үзенең бу хезмәтендә халкыбызның тулы бер гасырдагы язмышы турында уйлана, киләчәге хакында борчылып фараз кыла. Дәлилләве, фәлсәфи анализлавы һәм ниһаять стиль-язылышы белән мин бу язманы журналда басылган публицистик әсәрләр арасында иң яхшыларның берсе дип исәплим.

Беренче ике санда М. Зариповның «Генерал булу рәхәтме?» исемле мәкаләсе басылды. Автор анда Татарстан нефтьчеләре тормышын, «Татнефть» берләшмәсенең үткәнендә һәм бүгенгесендә нинди кыенлыклары булуы хакында бик тәфсилләп яза.

Соңгы елларда без әңгәмә жанрын публицистик характерда алып барырга тырышабыз. Бу бик тә отышлы күренеш. Узган ел Туфан Миңнуллин, Шәүкәт Биктимеров һәм Марсель Сәлимҗановның татар театры язмышы хакындагы фикерләрен әңгәмә рәвешендә биргән идек. Халык бик яратып кабул итте. Чөнки ул көн кадагына суга, бүгенге вәзгыятьтә чишелеш көтеп яткан бөтен проблемаларны үз эченә ала торган кайнар публицистик тел белән язылган мәкалә иде. Быел исә журналның икенче санында шагыйрь Гәрәй Рәхимнең Лондонда яшәүче күренекле татар шагыйре, публицист, җәмәгать эшлеклесе Равил Бохарай белән әңгәмәсе басылып чыкты. Равил Бохарай дөньяга мәгълүм Би-Би-Си радиосында эшли, Англиядә танылып килүче журналист булу белән бергә ул татар шагыйрьләренең әсәрләрен инглиз һәм башка чит телләргә тәржемә итү, аларны бастырып чыгару буенча да шактый күп эш башкара. Әлеге әңгәмә шулай ук күпләрдә уңай фикер калдырды.

Публицистика жанры буенча безнең даими авторыбыз—Мәскәүдә яшәп иҗат итүче Әгъдәс Борһанов. Мәскәү гуманитар Дәүләт университеты профессоры. Ул ел саен безгә ике-өч мәкалә китерә. Русча яза, тәржемә итәргә туры килә. Теле бик авыр, бик фәнни. Аны тәржемә итә-итә, безнең укучыга үтә күренмәле булсын дип тырыша-тырыша җан тирләрне чыгарырга туры килә.

Әгъдәс Борһановның журналның унынчы санында дөнья күргән «Россия жәмгыятенең кризис чыганагы» исемле мәкаләсе авыр, четерекле, ләкин бик мәгънәле. Автор әлеге мәкаләсендә Рәсәй халкының ни өчен эшлексез, башсыз, эчкече булуын аңлатырга омтыла. Урыс империясенең башка милләтләр байлыгын талап формалашуын һәм киләчәктә болай барса урысларның милләт буларак көчсезләнү ихтималы барлыгы хакында искәртә.

Алтынчы санда Тәүфыйк Әйдинең «Үз жырыбыз үзәктә» исемле публицистик әсәре басылды. Бу—автор Казакъстаннан кайткач язылган мәкалә. Тәүфыйк Әйди кая гына барса да, татар диаспорасы, урындагы татарлар турында яза, кайберләрен чеметеп тә, милләтпәрвәр булганнарын мактап та ала. Ел саен аның шундый рухтагы бер-ике әсәре безнең журналда басыла.

Кайнар публицистик тел белән язылган тагын ике мәкалә игътибарга лаек. Болар—Миркасыйм Госмановның «Каһирә очрашулары» һәм Миргазыян Юнысның «Альбатрос язмышы». Икесендә дә бүгенге көн сулышы, кайнар каләм, тирән проблемалар сизелә.

Соңгы санда Әгъзам Фәйзрахмановның «Гасыр бусагасын атлаганда» исемле мәкаләсе чыгып килә. Ул шулай ук Дәүләт думасы, дәүләтчелек, бүгенге вәзгыять турында бик җентекләп яза.

Бүгенге жыелудан файдаланып, редколлегия әгъзаларына әйтәсе килгән сүзем шул—барыгызның да күңел төбендә публицистик орлык ята, теләгәндә яза аласыз. Һәркемгә дә елга бер генә мәкалә белән булса да катнашу фарыз эш, дип саныйм. Публицистиканы язучы авторларны табу җиңел эш түгел. Чөнки аның эрудициясе, белеме булырга тиеш, күңелен борчып торган, әйтәсе килгән сүзе булырга тиеш. Минә ике-өч ел буе инде шулай мине кымтырыклап килгән берничә тема бар. Мәсәлән, мещанлык. Мещанлык—битарафлыкның иң уңдырышлы туфрагы.

Тагын бер тема—без милли-мәдәни мохтәрият, дип авыз суын корытабыз, ләкин гади халыкның күбесе моның ни икәнлеге аңламый, үзләренең хокукларын белеп бетерми. Киләчәктә журнал битләрендә минә шулар турындагы язмаларны да күрсәк иде.

## Хатип Миңнегулов:



Бүгенге сөйләшү журнал хакында гына түгел, ә гомумән, татар әдәбияты хакында, аның бүгенгесе һәм киләчәге хакында бара. Игътибар итеп утырам—узган ел үткән редколлегиядә әйтелгән тәкъдимнәрнең күбесе искә алынган, журнал бер урында гына тормый, гел иҗади эзләнүдә. Эчтәлек, сәнгати дәрәҗәсе ягыннан да күтәрелә бара. Аннан соң бүгенге сөйләшүдә мина ошаган нәрсә—бер-беребезгә хөрмәт белән карау. Бер-беребезне тәнкыйтьләгәндә дә сак, матур итеп тәнкыйтьләү.

Инде журнал турында. Проза өлкәсендә матур фикерләр булды. Мин үземнең күңелемә хуш килгән Нур Әхмәдиевнең «Амбирак яки кара каен кайгысы» турында әйтеп китәсем килә. Аны мин бик яратып укыдым. Әйбәт, матур тел белән язылган, әхлакый яктан чиста повесть.

Шигърияттә яшьләргә, башка төбәктә яшәп иҗат итүчеләргә киң урын бирелүне матур күренеш дип исәплим.

Аннан соң тагын бер фикер—дөнья күләмендәге классик әсәрләрне татар укучыларына күбрәк җиткерергә кирәк. Ги де Мопассанның «Бер асрауның кыйссасы» менә үрнәк булып тора. С. Ибраһимова тәржемәсендә ул нәкъ туган телдә язылган әсәр кебек яңгырады. Мондый сәхифәләр—һәм тәржемә мәктәбе, һәм яшьләр өчен классик әдәбият мәктәбе булыр иде.


## Булат Солтанбәков:



Тиздән яңа гасырга аяк басабыз, аннан инде өченче меңьеллыкка да күп калмый. Йомгак ясыйсы, фикер ияләре алдында тупланган рухи байлыкны гомумиләштерү буенча хәл итәсе мәсьәләләр биниһая күп. Киләсе елларда тарихка, тарихи материалларга игътибарны көчәйтергә кирәк. Бу үткән гасырга борылып карау, андагы уңышларны һәм ялгышларны тагын бер кат күздән кичерү булыр иде. Бер генә журнал да тарихны «Казан утлары» хәтле сеңдерә алмый. Биредә беренче чиратта язучы кулы, язучы фикере, язучы акылы, димәк, сезнең ярдәм сорала.

Дөньяда татарның абруе үсә бара. Татар зыялылары, татарның күренекле вәкилләре XX гасырда дөньякүләм аренага чыкты. Бу да әдәби әсәрләрдә чагылыш табарга тиеш дип исәплим. Ә ана кадәр бу темалар татар философлары һәм галимнәре хезмәтләрендә җитди анализланыр дип беләм.

## Фоат Галимуллин:



«Казан утлары» безнең әдәбиятыбыз мохитендә иң җитди, иң югары кимәлдәге, планканы иң югары куючы журнал. Быелгы Язучылар корылтаенда башка мәсьәләләр белән мавыгып, иҗат турында сөйләшү бөтенләй аз булды, күңелләрдә бушлык калды. Менә шул бушлыкны бүген «Казан утлары» журналы тутырды. Чөнки биредә әдәбиятның төп көчләре, әдәбиятка төп юнәлеш бирүчеләр, абруйлы шәхесләр тупланган. Аларның сүзе гомуми әдәбиятыбызны билгеләүдә бик дөрес ориентир, дип уйлыйм мин. Без 2000 елның февраль аенда «Әдәби ел йомгаклары»н уздырачакбыз, һәм менә корылтай белән әлеге «Әдәби ел йомгаклары» арасында «Казан утлары» журналы турында бүгенге сөйләшү билгеле бер этапны тәшкил итә. Чөнки бу сөйләшү тулаем әдәбиятыбызның халәтен, хәлен билгеләү дигән сүз.

Үзенең чыгышында Равил Фәйзуллин: «Хәтта Язучылар берлеге әгъзасы булып исәпләнүче кайбер иптәшләрнең да әсәрләрен кире борырга мәҗбүр булабыз»,—диде. Бу—уйланырга мәҗбүр итә торган факт. Аннан соң, Флүс Латыйфи да шундый фикер әйтте: «Әдәбиятка килеп керү җиңел, әмма әдәбиятта калу шактый авыр»,—диде ул. Дөрестән дә, әдәбиятта калу, анда үз кеше булу, берничә дистә ел буена җиң сызганып иҗат итү искиткеч авыр эш. Иң аянычлысы шул—рәхәтләнеп иҗат итә алырдай кайбер иптәшләр әле һаман үткән багаж белән йөриләр, баштанаяк иҗатка чумасы урында кайбер бүтән мәсьәләләрне хәл итү белән мавыгалар. Бүгенге, яисә киләчәк иҗат планнары турында сүз чыккач, алар берни дә әйтә алмыйлар. Бу, чынлап та, әдәбиятта калуның шактый авыр бер эш икәнлеге хакында сөйли.

Яшерен-батырын түгел, Язучылар берлегенә кабул итүдә таләпчәнлек соңгы елларда кими төште. Шуна да без әдәбиятыбызның әйдәп баручысы булган «Казан утлары»ның баш мөхәррире Равил Фәйзуллинның кабул итү коллегиясенә җитәкчелек итүен үтендек һәм әдәбиятыбыздагы шушы гомуми халнең торышы турында ихлас борчылган каләм әһеле буларак, ул менә ризалыгын бирде.

## Мәгъсум Хуҗин:



Мина журналның 10 нчы сандагы шигырьләр ошады. Киләчәктә дә журнал шундый әйбәт әсәрләр белән ачылсын иде. Гәрәй Рәхимнең фикерләре белән килешәм—дөрестән дә иҗат портретларын ешрак бирергә кирәк. Бу—бердән, яшь буынны әдәби осталыкка өйрәтү өчен файдалы булса, икенчедән, үзебез өчен бер тарих, истәлек булыр иде.

Инде үземне борчыган бер нәрсә хакында әйтеп китәм. Мәҗит Гафуриның 1914 елда язылган «Хан кызы Алтынчәч» исемле хикәясе бар. 1915 елда Нәҗип Думави «Болгар кызы Тойгы туташ» дигән хикәя яза. Фатих Әмирханның «Халык кызлары» исемле хикәяләре бар. Менә алар барысы да бер әкияти форма тапканнар. Күрәсең, моның сәбәпләре дә булгандыр, бәлки бөтен нәрсәне дә турыдан-туры әйтергә ярамагандыр. Әмма шушы әкиятләрнең барысында да безнең халыкның үткәне, барлыгы һәм киләчәге, әкияти формада булса да, әдәби калыпка салынган. Дөрес, соңгы вакытта хикәяләрдә тарих чагыла башлады, әмма бу өлкәдә «Казан утлары»ның өлеше сизелмәде. Моны нигездә «Идел» журналы алып барды. Минемчә, хикәя жанрында тарихның шулай олы итеп чагылуы ул әлбәттә безнең горурлыгыбыз булырга тиеш. Киләчәктә, «Казан утлары» журналы тарихка мөрәҗәгать иткән вакытта, шушыларны истә тотса әйбәт булыр иде.

## Туфан Миңнуллин:



Ин элек сүзне журнал таратудагы кыенлыклардан башлыйм әле. Гариф абый әйтмешли, мин рәис булып эшләгән вакытта, язучыларның һәркайсыннан «Казан утлары»наязылганлык турында квитанция сорамакчы идек. Иманым камил—язучыларның 50 % ы бүгенге көндә «Казан утлары»н алмый. Хәтта өлкән яшьтәгеләрнең дә күпчелегенең мөмкинчелеге бар бит, югыйсә.

Аннары, әлеге мәсьәләне Дәүләт күләмендә куярга кирәктер—һәр китапханә, һәр мәктәп алдырырга тиеш журнальны! Элек бит һәр коммунистка «Правда»ны яздырттыралар иде. Ә нигә «Казан утлары»на язылуны һәр татар теле укытучысына мәҗбүри итеп куймаска! Икмәге бит ул аның, ризыгы. Математика укытучысыннан таләп итмибез бит без аны.

Киеренке, шау-шулы заманда яшибез. Шушы чор әдәбиятка кереп калырга тиеш. Әле беркөнне уйланып ятам: тарих яңадан эшләнә бит, җәмәгать! Казыналар, эзләнәләр, тикшеренәләр. Шул өлкәдә эшлүчеләргә рәхмәтем зур. Ләкин безнең әдәбиятта чор фаҗигасы, тарих фаҗигасе барыбер эшләнеп бетмәгән әле. Һәр чор фәнгә кереп калу белән берррәттән, әдәбиятка да кереп калсын иде. Шул очракта гына ул халык аңына тиешенчә барып җитәчәк.

Журналда шигъриятне тиешле югарылыкта дип исәплим. Ә инде прозага килгәндә, кызганычка каршы, шигърият белән чагыштырырлык әйбәт проза әлегә күренми. Ниндидер конкурс рәвешендә оештырыпмы, гонорарын икеләтә арттыру хисабынамы, кыскасы, безнең чорны чагылдырган әйбәт проза әсәрләрен киләчәктә журнал битләрендә күрәсе иде.

## Аяз Гыйләҗев:



Флүс Латыйфи белән килешәм—берничә ел элек прозаның нык түбән төшүе күзәтелде. Мин инде хафалана башладым. Кая бу прозаиклар, нишли бу татар прозасы, дип. Соңгы елларда әйбәт әсәрләр күренә башлады. Әйтик, Марат Әмирхановның «Гөлнәзирә»се. Ул чын татар тормышы турында. Татар телен, татар язмышын белеп татар характерын тудыра алган. Камил Кәримовның романы да унышлы гына чыккан, темасы кызыклы, үзенчәлекле.

Бүгенге прозаикларның төп гаебе дип мин әдип булырга җыенган кешеләрнең татар телен белмәүләрен саныйм. Алар бәлки инде хәзер Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗевләрнең телен аңлап та бетерми торганнардыр.

Тагын бер үземне борчыган нәрсә хакында. Күптән түгел Ибраһим Салаховның архивы Казанга кайтты дип язып чыктылар. Ул кайда, аның белән кызыксынган кеше бармы? Гомумән, әдипләрнең архивы белән кем шөгыльләнә? Архив бит һәрвакыт хәрәкәттә, эштә булырга тиеш. Менә мин бик белергә теләр идем: Нәкый Исәнбәтнең архивы кайда? Хәсән Туфанның архивы кайда? Алар белән кем эшли? Тарих ул архив ияләренең урыннарын билгеләргә, аларның зарурлыгын ачыкларга тиештер бит?

## Миркасыйм Госманов:



Чыннан да, монда безне борчыган, безгә кирәкле мәсьәләләр турында сүз бара. Тагын бер нәрсәгә басым ясар идем. Соңгы елларда күп кенә яңа журналлар барлыкка килде, күбесе үзгәрде: кайберләре бик матураеп китте, кайберләре сүлпәнләнде, дигәндәй... «Казан утлары» исә дәрәҗәсен тиешле югарылыкта саклап кала алды. Ни өчен мин моңа басым ясыйм? «Шура» журналы битләрендә бәхәс бара. Сорау куела: атадан калган мирасны өч бала өч төрле хәл кылган. Беренчесе ярлыдан баеган, икенчесе байлыкны туздырган, өченчесе саклап калган. Бу өч улның кайсысы югары бәя алырга тиеш? Фикер алыша-алыша шундый нәтиҗәгә киләләр: юкны бар иткән дә түгел, барны юк иткән дә түгел, ә бәлки барны саклап калганы хөрмәткә лаек. Әгәр дә һәр буын үзенең кулында булганны югалта икән, яисә ватып-җимереп ташлый икән, ул инде башка буынга, башка культурага ияләнә алмый. Һәм җәмгыятьләрнең үсешендә без күреп-сынап киләбез—яңаны төзегән җәмгыятьләр түгел, булган байлыкны саклап, шуны хәстәрләп үстергән җәмгыятьләр отты, алар алдан бара. «Казан утлары» да, үзенең стилен, алымын саклап калуы белән башкаларга үрнәк булып тора.

Кайбер журналларны актарганда борчыласың, кайберләрен караганда, «кара, болар акчаны ничек оста эшли беләләр!» дип елмаясың, ә менә «Казан утлары»н мин тыныч күңел белән актарам.

Публицистика мәсьәләсенә берникадәр игътибар итәсе килә. Никадәр генә инкарь итәргә тырышсагыз да, минем белән килешми булдыра алмассыз—публицистиканы мин беренче чиратка куям—заман аныкы бит! Көрәш заманы! Шуны истә тотып, журналның публицистика өлешен җанландырасы иде. Бу өлкәдә безнең проблемалар җитәрлек. Татар өчен беренче проблема—авыл, авыл тормышы проблемасы дип әйтер идем мин! Үзем шәһәрдә туып-үскән булсам да, экспедицияләргә, командировкаларга йөрергә, бүгенге татар авылларында еш

булырга туры килә. Шунда чаң сугарлык күренешләргә тап буласың. Бүгенге авыл упкынга тәгәрәп бара. Татар халкының төп резервы булган авыл эчкечелеккә бирелде һәм картлыкка гына калды. Күп авыллар үлемгә, бетүгә йөз тота. Авылларны кичекмәстән җанландырырга кирәк. Бу өлкәдә кайбер мәсьәләләрне актуальләштерәсе иде.

Архив хакында Аяз Гыйләҗевка кушылам. Халыкта архивка карата хөрмәт тәрбияләү мөһим. Кызганычка каршы, безнең халык—архивын туздыру белән мактанган халык. Аннары, «Казан утлары»ның үз архивы да баерак булсын, хроникада әдәби-мәдәни тормыш киңрәк яктыртылсын иде.

## Илбарис Надиров:



Чит ил татарлары белән аралашып яшәгәнгә, мин аларның безнең илдә бара торган сәяси һәм мәдәни тормышка мөнәсәбәтләрен азмы-күпме күзаллыйм. Аларның бер өлеше бездә басыла торган журналларны, газетларны даими укып бара. Мәсәлән, Финляндиядә алты, Төркиядә ике гаилә «Казан утлары»н алдыра. Журналның соңгы, 10 санында Төркәр Соукканның «Швециядән татар тавышлары» дигән мәкаләсе басылды. Төркәр—Швеция полиция академиясе доценты, гаҗәеп белемле, мәгълүматлы кеше. Әнә шундый шәхесләрнең иҗатын, язмаларын даими урнаштырып барырга кирәк. Чөнки чит төбәкләрдә безнең күренекле шәхесләребез бар. Ул очракта журнал чит илләргә дә күбрәк күләмдә чыгар иде.

## Мөдәррис Вәлиев:



Журнал таратудагы кыенлыклар хакында сүз булды, иң авырткан җиребез шулдыр. Аларга өстәп әйтәсе килгән фикерем: журналга нииндидер бер функциональ ихтыяҗ тудыра белергә кирәк. Ягъни, шушы журналны алмасаң, нәрсәнедер югалтасың икән, бүгенге әдәби хәрәкәттәге иң мөһим моментны белми каласың икән. Кайбер газета-журналлар үзләренә реклама биргән вакытта «дәресләр, укытучылар, укучылар өчен кызыклы һәм кирәкле материал бездә басыла» дип язалар. «Казан утлары»нда да менә шушы функциональ якны көчәйтеп булмый микән? Әйтик, нииндидер махсус бер рубрика кертеп, мәгълүмати якны көчәйтеп. Укытучылар бүген методик ярдәмгә бик тә ихтыяҗ кичерәләр бит.

## Равил Фәйзуллин:

Байтак кызыклы фикерләр ишеттек, һәркем күңелдәгесен әйтеп сөйләште. Һәркайсыгызга рәхмәт. Һәрберебез өчен бик тә җаваплы, әле без төгәл күз алдына китермәгән гасырлар алышынган бу елларда, иҗатларыбызда ярдәмләшеп, бергә-бергә фикердәш булып, алга таба да шулай киңәш-табыш итеп яшик!

*Журнал өчен* А. ГЫЙМАДИЕВ *әзерләде.*

*Тарих*



**Зәрия Хәбипова**

# «ИДЕГӘЙ» ҮТКӘН ЮЛ

## Дастанның «сөргеннән» кайтуы

«ИДЕГӘЙ» дастанынын халкыбызга «тоткыннан» кайту юлы татарнын үз язмышына тиң катлаулы һәм фаҗигале. Әйе, дастанның юкка чыгудан котылу тарихы чор сулышын сиздереп торучы төгәл бер барометрны хәтерләтә.

«Идегәй»не беренче тапкыр XIX гасыр уртасында төрки дөньяны өйрәнүче урыс галиме В. В. Радлов язып алган. Дастан галимне күптән җимерелеп юкка чыккан дөньяны колачлы һәм тирәнтен сурәтләве белән кызыксындырганмы, әллә ул аны тарихи чыганакларга өстәмә буларак теркәп калдырганмы, бу сорауларга хәзер төгәл җавап табу кыен—әмма бу хәл-күренеш «Идегәй»нең әле язылмаган һәм аның юкка чыгудан котылу тарихын өйрәнү өчен гаять әһәмиятле.

Икенче тапкыр дастан 1919 елда Көнбатыш Себернең Тар өязе Яланкүл авылында Ситдыйк Зәйнетдиновтан язып алынган. Бу эшне галим һәм журналист, 1937 ел корбаны Нигъмәт Хәким башкарган. Дастан ул вакытта да, кызганычка каршы, әдәби хәрәкәткә керә алмыйча калган. Әмма аның татар әдәби-тарихи җирлегенә эләгүе—үзе үк шактый зур эш. Бу инде ым, киная рәвешендә генә булса да татарның яшәү өмете туды дигән сүз. Нигъмәт Хәкимнең эшен таныган галимебез Нәкый Исәнбәт дәвам иткән. Исәнбәт зур авырлык белән булса да 1940 елда дастанны «Совет әдәбияты» журналының 11, 12 саннарында бастырып чыгаруга ирешкән. Ул «Идегәй»не заманга яраклаштырыбрак драма әсәре итеп тә эшкәрткән һәм дастан шул рәвештә 1941 елның июнендә Мәскәүдә Татарстанның әдәбият һәм сәнгать атналыгы көннәрендә күрсәтелергә тиеш булган. Сугыш башлану сәбәпле, бу ният тормышка ашырылмыйча кала. Сугыш комачавы гына тоткарлап торган очракта, тынычлык көннәре килгәч дастан белән кызыксынучылар, һичшиксез, табылыр иде, тик 1944 елда дастанны җәмәгатьчелек күзеннән югалту турында ВКБ(б) ның махсус карары чыга һәм «Идегәй»не шундый итеп яшерәләр һәм тыялар ки, хәтта аны фәнни институтларда, уку йортларында искә алу да җинаять санала башлый. Партия «Идегәй»не байлар-феодаллар дастаны, шуна күрә хезмәт ияләренә зарарлы әсәр дип таба. Дастан совет чорында мәҗбүри өйрәнелгән, әле шушы көнгә кадәр безне милләт буларак юкка чыгарыр өчен кулланылып килгән тарихтагы кара ялганны—

---

ХӘБИПОВА Зәрия Габдулла кызы *(1949) — 1972 елда Казан дәүләт университетының механика-математика факультетын тәмамлый. Бүгенге көндә «Татнефть» системасында инженер-программист булып эшли. Татар фәлсәфәсе һәм тел язмышы белән кызыксына. Журналыбызда урын алган бу мәкалә фәлсәфи эзләнүләрнең этрафлы чагылышы. Әлмәттә яши.*

«татар халкының артта калган, надан, кыргый халык» булуын тулысынча инкяр итү белән генә чикләнеп калмый, әлбәттә. «Идегәй»дә татарның омтылышы, холыкфигыле, гореф-гадәтләре, идеалы, дәүләт тоту тәртибе, гомумән, безнең халыкка гына хас тулы милли галәме (космосы) сурәтләнеп калган.

1985 елдан Русия дәүләтенең империячел сәясәтендә чатнаулар барлыкка килү, милләтләрнең уяна башлавы «Идегәй»не яңадан татар дөньясына кайтырга мөмкинлек бирде. Дастан 1988 елда башта «Казан утлары» журналында, аннан соң аерым китап булып басылып чыкты. Шушы әсәр буенча Г. Камал театры зур спектакль (драматург Юныс Сафиуллин эшкәртүендә) куелды. Шул рәвешле, дастан әдәбият сөючеләр арасында, гомумән, татар зыялыларында күпмедер кызыксыну тудырып, тарихыбызның халык иҗатында гына сакланып калган тулы канлы героик чорын күзалларга, колониаль изүгә кадәр татарның психологиясен, рухи дөньясын тоярга, ерак бабаларыбызның кылган гамәлләре белән горурланырга мөмкинлекләр туды.

Аңлашыла ки, «Идегәй»нең әдәби хәрәкәттә элегрәк үзенең тиешле урынын ала алмавы, татар әдәбияты, тарихы, фәлсәфәсе, тел гыйлеме, милли рухиятнең үсешендә ясалма тоткарлык тудырып, бушлык барлыкка китергән иде. Чагыштыру өчен урысларның «Слово о полку Игореве» исемле дастанын гына алып карыйк. «Идегәй»дән күпкә кечкенә әлеге әсәргә багышланган фәнни эшләрне бергә теркәсәң, дистәләгән калын томнар барлыкка килер иде. Әлеге дастанның һәр персонажы гына түгел, андагы һәр сүз, һәр ижек, хәтта әйтелмәгән сүзләргә кадәр берәмтекләп өйрәнелгән. «Слово»ның геройларын тарихи прототиплар белән җентекләп чагыштырып чыкканнар. Әсәрне күп тапкырлар бүгенге урыс теленә, чит ил телләренә, элекке СССРда яшәүче халыкларның телләренә тәрҗемә иткәннәр. Дастан эчтәлегенә таянып «Князь Игорь» операсы язылган. Рәссамнар күп тапкырлар басылып чыккан дастан китапларын бизәү белән генә канәгатьләнмичә, махсус альбомнар, зур полотнолы әсәрләр иҗат иткәннәр. «Слово о полку Игореве» мәктәптә өйрәнелә, гуманитар, сәнгать югары уку йортларының программаларына керә. Шулай итеп, урысларның үз ерак тарихларына тоташуы барлыкка килә. Милләткә исән калу өчен берләшү кирәклеге турындагы үй тарих һәм сәнгать теле белән һәр урыс кешесенең күңеленә салына.

Әйе, милләтләрне формалаштыручы әсәрләр күп түгел. Грекларны Гомерның «Илиада»сыннан, исландларны сагаларыннан, германлыларны «Небелунглар» җырыннан, инглизләрне Шекспир драмаларыннан, һиндларны «Рамаяна» һәм «Махабхарата»дан, гарәпләрне «1001 кичә»дән, Коръәннән башка күз алдына китерү мөмкин булмаган кебек, татар дөньясын да «Идегәй» дастаныннан башка яшәргә рухи җегәре, өметле киләчәге, мөстәкыйльлеккә ирешү мөмкинлеге булган дөнья итеп күз алдына китереп булмый. Шушы фикерне дәлилләү өчен «Идегәй» дастанын дикъкать белән шәрехләп чыгарга кирәк.

Дөньяда бүген яңа карашка, яңа фәлсәфәгә ихтыяҗ зур. Әмма дөньяны яңача күзаллау буш урында үзеннән-үзе барлыкка килә алмый. Боларның барысы да үткәндәгеләрнең рухи мирасын ныклап үзләштергәндә, һәр буын калдырган байлыкны бөртекләп җыйганда, саклаганда һәм өйрәнгәндә генә безнең күңелләребезгә иңәргә мөмкин.

Шушы фикердән чыгып караганда да, «Идегәй» дастаны тирәнтен өйрәнелергә тиешле милләткүләм бөек әсәр. Язылган чоры төгәл билгеле булмаса да, татарның дәүләтчелеген әле тәмам югалтмаганлыгы, татар теленең Кытайдан Әдрән ярларына кадәр тылмачсыз да аңлашылганлыгы әсәрдә бик ачык сизелеп тора. Дастанның күп байлыклары бүген дә үзенең өйрәнүчесен көтеп ята бирә.

## Тарихка кыскача сәяхәт

«ИДЕГӘЙ» дастаны тарихи җирлеккә таянып, шаулап узган вакыйгаларның кайтаваз тавышын ишетеп, геройларының көчен-данын тоеп язылган әсәр. Аның эчтәлегендә Алтын Урданың таркалу чоры, шушы таркалуы әдәби һәм фәлсәфи биеклектән торып сурәтләнгән. Әсәрнең каһарманнары—Туктамыш хан, Аксак Тимер, Идегәй морза, Кадыйрбирде, Норадын һәм башкалар—Алтын Урда тарихында билгеле шәхесләр. Тарихи чыганаклар Идегәйне Туктамышның гаскәр башлыгы, сугышчан юлбашчысы итеп күрсәтә. Ул Туктамыш һәм Аксак Тимер бәрелешләреннән оста файдаланып, Туктамышны 1398 елда тәхеттән куа һәм егерме ел дәүләт дилбегәсен үз кулында тота. Чыңгыз нәселеннән булмаганлыктан, үзе тәхеткә утыра алмый, «курчак»

ханнар аша идарә итә. Бу шәхесне дәүләтне таркатудан туктатырга алынган соңгы кодрәтле көч дип атарга да була һәм 1419 елда, 63 яшендә, үзенең кан дошманы Туктамышның улы Кадыйрбирде кулы белән үтерелә.

Дастанда Котлыкыя нәселе белән Туктамыш нәселе арасында барган кан үче котылгысыз мистик тәгаллек белән кабатланган итеп сурәтләнә. Идегәйнең әтисен Туктамыш хан үтертә, Туктамышның үзен—Идегәйнең малае, Идегәйне исә—Туктамыш малае. Кан үче—дәүләтне җимерүче сәбәпләрең берсе буларак, фаҗигале хәрәкәттә сурәтләнә. Бу көч хәтта гаять каты куллы, хакимият серләрен белгән тәҗрибәле шәхесләргә дә буйсынырга теләми шикелле тоела.

Буыннан буын чабылса,
Ул чагында ни калыр?
Йорт урынында яу калыр,
Яу чапканда ни калыр?
Ялгыз башы кангырап,
Куйдай булып мангырап,
Чүл далада тинтерәп,
Дуадактай хан калыр.

Идегәй—кешеләргә көчле тәэсир итә белгән, күренекле, хәтергә тирән сеңеп кала торган шәхес булган. Аны адәм баласында сирәк очрый торган серле көчкә дә ия, дип санаганнар. Үзе исән вакытта ук Идегәйнең көченә бәйле төрле мәзәк хәлләр, сәер риваятьләр халык арасында таралган булган. Дастан авторына алар билгеле булган, дип, исәпләргә кирәк, чөнки дастанда Идегәйнең тәэсир көчен күрсәтүче вакыйгалар оста файдаланыла. Яу кырында дошманың кыяфәт тәэсире белән бергә ега алу, Аксак Тимер утыртып киткән курчак ханны чукмар итеп тотып сарайдан аның яраннарын куу кебек морзаның мифик көчен күрсәткән юлларны елмаймыйча укып булмый. Әмма әсәргә мондый күренешләрне кертү әдәби алым—фольклор гиперболасы икәнен дә истән чыгарырга ярамый. Идегәйгә бәйләнешле гыйбрәтле вакыйгалар, татар күңелен җылытып, көч өстәп торучы мәзәкләр, серле риваятьләр үзе үлгәч тә халыкта озак сакланган.

Туктамыш хан белән орышта Идегәй болай ди:

Бер селтәде—бере ауды,
Бере ауганга уны ауды.
Ун ауганның җиле бар,
Уны белән йөзе ауды.
Йөзе ауганга мене ауды.

...Үлән ярган бүредәй,
Адәм егып юл ярып,
Килә бирде Идегәй.
Салкын казан, суык су,—
Аны җитеп аударып,
Чыңгыздан калган кара ту—
Аны җитеп аударып,
Ат астында калдырып,
Тоякка салып сындырып,
Юлда барын таптатып,
Сөрә бирде Идегәй.

Чынбарлыктагы Идегәйнең колачлы шәхес икәнлеген төрлечә кабул иткәннәр һәм бәяләгәннәр. Риза Фәхретдин аны Алтын Урданы таркатуда гаепли. Кайбер тикшерүчеләр аның шәхеслек масштабын кечерәйтеп, татар тарихына керткән өлешен киметеп, Идегәйне мангыт ыруы җирлегендә генә күрсәтергә тырышалар. Ничек кенә булмасын, Идегәй морза тарихта, замандашлары күңелендә җуелмас тирән эз калдырган. Вак-төяк вакыйгалар гына дастанга нигез-зәмин була алмыйлар. Без ясалма, примитив, ялган геройлар җирлегендә тәрбияләнгән адәми затлар буларак, күп вакыйгаларга бүгенге кеше күзе белән карыйбыз. Без—ышанмыйбыз. Чөнки кичә батыр дип игълан ителгән кеше, хакимият кулы белән генә күтәрелгән дә, хакимият алышынгач хурлауга, таптауга ук дучар булып чыга. Бабайлар сүзе—ялганның гомере бер көнлек икәнлеген тагын бер кат исбатлый. Ә гасырлар буена халык күңелендә саклануы дастан каһарманнары халык ихлас яраткан, үзе өлге—үрнәк итеп алган һәм тарихта

сизелерлек эз калдыра алучылардан гына туа ала. «Идегәй»не укыганда кабат шуны истә тотарга кирәк: ул заман кешеләрен бүгенге үлчәм белән үлчәү, бүгенге күзаллау белән күрү шактый зур ялгышлыкларга, ялган бәяләргә, хәтта капма-каршы нәтиҗәләргә китерәчәк. Шундый зур, көчле дәүләтне җыйган олпат ир-егетләр гомерләрен ат сыртында үткәрергә, туктаусыз дөнья гизәргә, хәлиткеч вакыйгаларның үзәгендә кайнап мәйдан тотарга, туган җирләреннән еракта, көч сынашуда, сугыш кырында үлеп калырга да мәҗбүр булганнар. Дөньяны алар шулай кабул иткәннәр. Җир—алар өчен әле ачылып бетмәгән могҗизалы чиксезлек, ирлекне сынау-сыналу һәм саклау кыры булган. Хыял һәм омтылышлары, үз көчләренә ышанулары шулкадәр гайрәтле булган—алар үзләрен үлемсез, тарихи вакыйгаларны үзгәртергә, аларны башка юнәлешкә борырга сәләтле дип хис итеп яшәгәннәр. Дастандагы тормыш-яшәеш хәрәкәтен, аның кыйбласын һәм максатын бүгенге көнкүреш хәрәкәте, кыйбласы, максаты белән һич кенә дә чагыштырырлык түгел. Хәрәкәт һәр шәхеснең үзендә һәм ул ташкын кебек ургылып тора. Бу максатлы тынгысызлык үзенә ат ярсулыгын да кушкан. Дастанның һәр юлында без шуны тоеп торабыз.

Галәм гизүчеләрнең исеме дә—ир-ат—тирән мәгънәле, күнелдә төрле чагыштырулар калкыта торган сүз. Канатлы омтылыш, ярсулы көч, таянырга терәк янгырый бу сүздә. Гаиләне, илне, милләтне саклаучы кешене генә шулай атап була. Татар ирләре холкындагы әле тулысынча сүнеп бетмәгән илаһи ярсулык, максатчан ашкынучанлык, мөгаен, шул заманнар җиленең тәэсиредер.

## Тел һәм сүз сере

«ИДЕГӘЙ»нең үзенчәлекле әсәр булуы беренче юллардан ук үзен сиздерә. Дастан кыска гына кереш сүз белән Туктамыш ханның ауда йөргәнен тасвирлаудан башланып китә. Туктамышның кем икәнлеге, холкы, идарә итү ысулы, сарайдагы, илдәге тәртипләр һәм алдагы хикәяләүгә бәйле сюжет төеннәре барысы да шунда төйнәлә. Сурәтләр җете, сөйләм чагыштыруларга, тел парчаларына ифрат бай. Гади кыскалык түгел бу—кыска шигъри җөмләләр янгыравыклы, йөгерек, җегәрен югалтмаган көчле, тыгыз тел белән язылган. Дастан хәтердән сөйләнә торган әсәр булганлыктан, сүзләрнең тәэсире, хәтердә калу мөмкинлеге, сурәт тудыру көче гасырлар буенча тупланып килгән акыннар тәҗрибәсеннән чыгып файдаланылган. Дастан сүзе безне азагына кадәр сихерләп, үзенең җилкенүле, мәкерле һәм омтылышлы тәэсир агымыннан җибәрми тота.

Әйе, татар теленең гайрәтле чагы сурәтләнеп калган дастанда. Телнең киләчәге, мөмкинлекләре чиксез гасырларга сузылыр һәм халыкка чиксез озак хезмәт итәр, дип ышанып сурәтләнгән. Телне шулай кадерләп, нечкәлеген тоеп иҗат итү—ул чор кешеләренең бу байлыкка булган мөнәсәбәтләре бөтенләй башка, хәзергедән күпкә самими, җитди, тирән фәлсәфи сугарылышта булуы белән аерылып тора.

Дәвамлы үсеш күзлегеннән караганда телнең барлыкка килүе, үсүе кешене хайваннар дөньясыннан аерып чыгарган хәлиткеч көч булып аңлашыла. Тел гаҗәеп серле, шушы көнгә кадәр өйрәнелеп бетмәгән мирас. Ул сөйләүче белән яши һәм үзен саклап, үстереп, камилләштереп буыннан-буынга тапшыручылары беткәч сүрелә һәм язма чыганакларда гына калып сүнә. Алай да ул тулысынча югалмый, ә үзе кайчандыр аралашкан халыклар теленә сыенып, сүз ясашларына кереп сизелерлек эзен калдыра. Җир кешеләре—тулаем телгә корылган цивилизация кешеләре. Кешегә хас гамәл кылу—тел, сүз аша калыплашып канга сеңгән. Дөньяны киңрәк, тулырак күрү, киңрәк аңлау, шуны дөрес тасвирлау, уй барлыкка китерү һәм уртак уй ярдәмендә оешу, хәтер туплау, шуны саклау, киләчәк буыннарга тапшыру, тарихның төп чыганагы һәм хәрәкәте булып та сүзләр казаны—тел тора. Төрле чорларда аерым телләр, бигрәк тә яулап алу юлына баскан халыкларның телләре, өстенлек итәргә дәгъва белдереп, башка телләрне кысрыклаган, аларга тәэсирле йогынты ясарга омтылган. Ничек кенә булмасын, телләр төрлелеге, аларның үзенчәлеге исән һәм һәр тел дөньяга үзенә генә хас күрү, фикерләү, исәп туплау, фәлсәфә кору мөмкинлекләрен биреп тора.

Евразиянең иксез-чиксез кинлекләрендә дәүләт төзегән күчмә һәм утрак төркиләр тормышында тел аеруча зур роль уйнаган. Ул мәгълүмат туплау, аны саклау һәм тапшыруның тикшерелгән һәм ышанычлы бер коралы булган. Китап, хат рәвешендә сүзне яшәтү мөмкинлекләре—алар да файдаланылган, әлбәттә. Әмма ул чорда сөйләүче

(тулгаучы) тарафыннан житкерелгән сүз тәэсирлерәк тә, көчлерәк тә икәнлеген белгәннәр. Чөнки һәр кеше сүз әйтү белән генә чикләнмичә, ана үзенең хисләрен, шәхеслеген, өмет-багланышларын, сүз иясенең мөнәсәбәтен сыйдырырга тырыша. Дастан безгә шушы турыда сөйли.

Ирнен ирдән нисе артык?—
Бер сөйләгән сүзе артык.

Бүгенге көндә сүз рәвешендәге мәгълүматның кирәксез дәрәҗәдә күп булуы, сүзнең хакыйкатьне ачудан битәр, аны яшерү, күз буяу, сәясәт, басым ясау, алдау, ялган юлга җибәрү өчен ешрак кулланылуы сүзнең җегәрен алган, аның чын асылын томыкландырган. «Идегәй»нең телен бүгенге көндә кулланылган тел белән чагыштырганда, бүгенге тел байлыгыбызның чиктән тыш таушалуы, чүпләнүе, төссезләнеп бетүе күзгә ташлана. Кол хәлендәге кешене «хезмәт алдынгысы» дип атау, мескенлеккә төшкән илне «сәяси тотрыклылык һәм дуслык» иле дип игълан итү, халыкны талауны «халык турында кайгырту» дип шапырыну, милләт исемен атап әйтергә курку, «татар» урынына «татарстанлы» сүзен куллану кебек кыланышлар кешене сүздән биздерәләр, ана булган инанулы ышанычны бермә-бер киметәләр. Мондый дөньяда яшәү безне сүзгә битараф булырга өйрәтә. Хисләрне, фикерләрне яшерергә куша. Кешеләр арасында сөйләшеп аралашуны, оешкан бергәлекне юкка чыгара. Шул ук вакытта, безнең күңел ихластан әйтелгән хак сүзне эчке сиземләү дулкыннары аша тотып ала. Дастан чорында яшәгән кешеләр моны бездән тирәнрәк аңлаганнар. Чыннан да, сүзнең тәэсире сөйләүченең күңел халәтенә, күрә белү, ышандыру, инандыру осталыгына, шәхеслек дәрәҗәсенә бәйле.

Табигый үсеш нәтиҗәсендә кешедә сүзне үзләштерү, аның мөмкинлекләрен тою, аңлау, көндәлектә файдалану, ягъни сүзгә таба эчке бер авышу барлыкка килгән. Кеше сүз аша дөньяны күрү белән генә чикләнеп калмый. Ул һәр очракта сүзне күңелендә кат-кат яңгыратып, вакыйгаларны күңелендә кабат кичереп, үзе өчен сүзнең унай яки тискәре тәэсирен көчәйтә яисә киметә ала. Сүз кешене күпмедер дәрәҗәдә буйсындыра, аның күзәнәкләренә үк кереп оялый, кешене үз дулкынынннан җибәрмичә тота. Күңелгә килеп тигән сүздән арыну, чирдән арыну кебек үк катлаулы, авыр һәм күп вакыт шактый газаплы. Һәр очракта ишеткән сүзнең, әйтелү тәэсиренә карап, күңелдә гомерлек җуелмас эзе кала. Телдә калыпланган «җылы сүз», «яман сүз», «сүз ишеттерү», «битен ертып бәреп әйтү», «кеше сүзе кеше үтерә», «сүз ишетү чирдән яман» һәм башка телгә кагылышлы гыйбәрәләр буыннан-буынга тапшырылып, бик борынгыдан халкыбызның телгә-сүзгә биргән бәясе, сүзнең көчен искәртүче аңлатмалы тамгалар булып сакланып киләләр.

Дастанда сүз аерым төрләргә бүленгән. Һәр төр, һәр катлам сүзнең куллану һәм тәэсир мөмкинлеге ачык күрсәтелгән. Әсәрдә сүз-тел дөньясы гадәти (гади) сүз, теләк (доганы кертеп), ант, каргыш, юрау, күпер-хәтер, тоташу-күрү (ерү) рәвешендә тасвирланалар. Һәр очракта сүзне кулланучы (әйтүче, тулгаучы) башта юнәлеш сайларга, аннан соң аерым халәткә керергә, шул халәттә әйтелгән сүзләрдән ваз кичмәскә, әйткән сүзенә тугрылыклы булырга, аның тәэсире, нәтиҗәсе өчен тайпылгысыз җавап тотарга тиеш икәнлеге ачык аңлашыла.

Аксак Тимер хатын укыган Туктамыш хан манзарасында сүзнең күңелгә ничек үтеп керүе һәм тәэсире бөтен нечкәлеге белән сурәтләнгән. Сүз тәэсире дастанда бер яктан салкын боз һәм икенче яктан утта кызган тимер белән чагыштырып бирелгән:

Эченә суык боз төште—
Туң тимердәй күк булды;
Эченә кызу ут төште—
Сум тимердәй кызарды.
Кызарган соң ут булды,
Аннан да үтеп ак булды.

Тимер иң югары эрү ноктасында ак булса, кеше сүз тәэсиреннән ак булганда аның күңеле, киресенчә, соңгы чиккә җитеп каткан, туңган хәлгә кергән була. Шундый халәттәге Туктамыш, киләчәктә нинди катлаулы вакыйгалар туасын уена да кертмичә, Идегәйнең әтисе Котлыкыяны үлем җәзасына хөкем итеп ташлый. Котлыкыя би һәм өлкән пир Җантимер заманында үзара ант эчешкән олпат ирләр булалар. Антны соңгы сулышка кадәр саклау безнең ерак бабаларыбызда тайпылгысыз бер шарт булган. Нәкъ шушы тугрылык мәсҗәүлеләр белән мөнәсәбәткә кергән очракларда

урыс файдасына эшләп килгән. Мәскәүлеләр антны вәзгыятьнең хәлиткеч мизгелендә үзләрен саклап калу өчен бирә торган булганнар һәм җае чыгу белән антларын бозып торганнар. Бу сыйфат Рәсәйдә хәзер мәскәүлеләр өчен генә түгел, дәрәҗәгә омтылган, хакимияткә үрмәләгән һәр адәми зат өчен кагыйдәгә әйләнде.

Җантимер антташын соңгы чиккә кадәр батырларча яклый: Котлыкыя сүзләрендә хаклык барын, бу җәзаның язмышны бозачагын әйтеп ханны кисәтә:

Туктамыштай олы хан
Аның телен алмады,
Сүзенә колак салмады.

Ант хан боерыгыннан өстен—ул күкләр карамагындагы илаһи халәт саналган. Безнең бабаларыбыз моңа тулысынча инанганнар. Шуңа Җантимер үз баласын үлемгә биреп, Котлыкыяның нәселен саклап калуга барып җитә. Бу адым аның соңгы чиккә кадәр антына тугрылыклы калуын күрсәтә. «Тәңре хөкеме бу иде»—газиз баласыннан да өстен—дастан туган чорда антның катгыйлыгы шул дәрәҗәдә бәяләнгән.

Тәңре! Менә кемгә мөрәҗәгать итә торган булган Алтын Урда кешесе үзенең бөтен ялварулары белән. Табигать белән тыгыз бәйләнгән, дөресрәге, табигать көчләренә таянудан барлыкка килгән дин буларак, тәңречелек кешенең кызыксынуын, үзен табигать белән бәйли, аннан көч ала белүен тыймаган. Киресенчә, бу дин кешенең хәрәкәт, сиземләү, уй-хыял нәтиҗәсендә тапкан катлаулы күзаллауларын үзенеке иткән. Шуңа күрә тәңречелеккә күрәзәлек итү, еру, тылсым кебек көчле тәэсиргә нигезләнгән, исламны кабул иткәч тыелган алымнар да, ант, теләк, юрау, каргыш, каһәр кебек сүз аша тапшырыла торган алымнар да тулысынча сыя алган. Дастанда һәр алымның куллану күренеше бирелгән. Алда без аларның кайберләрен кыскача тикшереп китәрбез.

Ихластан, җан ачысы белән яки көчү халәтендә (үлгәндә) әйтелгән сүзләр, кайдадыр күкләрдә сакланып, сүз аткан кешенең язмышына тәэсир итәсенә чын күңелдән ышанып гамәл кылалар дастан геройлары. Каргыш—җан ачысының иң тетрәндергеч биек, иң кайнар ноктасы. Кешенең һәр кылган гамәле башта аның үзенең тойгыларын кузгата. Чөнки гамәл кылу өчен кеше уй, фикер, күңел, тән хәрәкәтләре ясарга мәҗбүр була. Шуңа да каргыш һәр очракта ике җәпле һәм ике яклы. Каргаган кеше шушы халәтнең шаукымын үзендә дә калдыра һәм ул аның киләчәк язмышына тәэсир итә. Дастан авторы моны аңлый. Шуңа күрә ул үлем хәлендәге Кара Тиен Йосынчыдан түбәндәге сүзләрне әйттерә:

Каргышым аткыючтан очкыдыр,
Кара таптан үтәдер.
Сине каргап нитием?
Каргамый ак китием.

Куып тотылган Туктамыш хан үзенең дошманы Норадынны болай дип каргый:

Казак чыгып жиреннән,
Садагы төшми биленнән,
Минемдәен аптырап,
Куркуыннан калтырап
Баш куярга җир тапмый,
Куылып йөрсен иленнән!

Үз заманы өчен каргыш, аның тәэсире, аннан котылу юллары нык, җентекләп өйрәнелгән булган. Авыл кешеләре бүгенге көндә дә каргышның тәэсиренә ышаналар. Кешенең тормышында килеп чыккан бәхетсезлекләрне каргыш белән дә бәйләү авыл җирендә әле һаман табигый санала. «Каргап үлде ул аны», «Шул кешенең каргышы гына башына җитте»,—кебек сүзләрне авылда еш ишетергә була. Дастан чорында каргышлары иң тәэсирле кешеләр булып ятим балалар саналган. Ни өчен? Чөнки алар иң кимсетелгән, газапны иң мул кичерүчеләр. Аларның күңелләре даими әрнүле, тирән хәсрәттә. Ятим, гарип-горәбә күңеленә газап өстәү—алар күңеленнән үзенә көчәйгән кайтаваз газап дулкыннары килүгә сәбәп була. Безнең шулай уйларга хакыбыз бар төсле. Дастанда хәтта Туктамыш хан да ятим Норадынның каргышыннан куркып, аны үтертми, ә мескен атка атландырып чүлдә үлемгә чыгарып җибәрү белән чикләнә.

Ул заманнарда каргышны кайтару мөмкин дип саналган. Аның өчен үзеннән гаепсезлегенә көчле инану хисе белән, түбәндәге сүзләрне әйтергә кирәк булган:

Андый, андый каргышны
Монда бастым, бакырттым!
Жиде тауны яңраттым,
Каргышың кара башына.

Сүзнең яшәү агымына шундый тәэсирле йогынтысын тану борынгы бабаларыбыз культурасының әһәмиятле һәм аерылгысыз бер өлеше булып торган.

Зур дәүләтләрнең барлыкка килүенә ниндидер серле, без аңлап житкермәгән көчләр йогынты ясаган, шул көчләр юл күрсәткән сыман тоела. Чыннан да, ничек туган ул гайрәт-жегәрлек шундый иксез-чиксез далалар киңлеген үзләштерергә, халыкны, гаскәрне оештырырга? Кемнән, кайдан өйрәнгәннәр алар табигатьнең чиктән тыш кырыс шартларына каршы тора алу мөмкинлекләренә? Төрле юнәлешләрдә хәрәкәт итеп ничек адашмаганнар? Юлда, яуда йөргәндә ничек таралып, югалып, юкка чыгып бетмәгәннәр? Бу сораулар бүгенге көн чынбарлыгыннан гына гади һәм беркатлы яңгырый. Әгәр тарихка күз салсак, ачылмаган жирләрне өйрәнүчеләрнең яки хәрәкәт итүче гаскәрнең күбесе (тикшерүчеләр 60—90 % дип исәплиләр) чыккан юлдан кире әйләнеп кайтмаган. Жир, дингез-океаннар үз серләрен жинел генә ачмаганнар. Мисал итеп, 1859 елда Австралияне көньяктан төньякка кисеп үткән экспедиция язмышын күрсәтергә була. Атлар, дөяләр, азык-төлек житәрлек булуга карамастан, Роберт Бурк һәм Уильям Уилс житәкләгән экспедиция тулысынча юлда һәлак була. Тәжрибәсезлек, бер-беренә яраклаша белмәүдән туган үзара ызгыш, начар һава шартлары юлга чыккан кешеләрне күп очракта үлемгә дучар итә.

Евразия континентын дер селкетеп торган дәүләт төзегән борынгы бабаларыбызның көчен курку белмәс ир, жегәрлекле ат, тайпылмас тугры Сүз бердәмлегe укмаштырып, аларның хәрәкәтенә ташу яруыдай ярсулык биргән дисәк, тарихи чынбарлыкка хилафлык китермәбез шикелле. Аңлашыладыр ки, шушы өч көч бергәлегендә сүз—үзара бәйләүче, аңлашу тудыручы, юл күрсәтүче, канат чыгаручы көч булып торган.

Дастан геройлары сүзне гамәлгә юнәлеш бирер өчен генә сөйлиләр һәм аларда сүз белән гамәл арасы шулкадәр кыска, тыгыз ара—сүз әйтелү белән гамәл кылына башлый кебек. Тормышта бу рәвештә хәрәкәт оста өйрәтелгән гаскәрдә генә күзәтелә. Шулай да гаскәр дигәч, бүгенге көн чынбарлыгына яраклаштырып, куркытуга көйләнгән сукырларча (дедовщина) буйсыну турында сүз бара дип уйласак, без ялгышырбыз. Дастан заманында үзара мөнәсәбәт, бүгенге сүз белән әйткәндә, демократик, дәресрәге, хәрби демократик ысулда алып барылган. Туктамышның һәр батырын аерып атаган урыннары шуны дәлилли:

Бу жыенның эчендә
Кемнәр бар да, кемнәр юк,
Аптыраган көнемдә
Тулгамага кешем юк!—

дип зарлана ул. Чөнки хаким жәмгыять пирамидасында иң югарыдагы зур дәрәжә һәм шуңа күрә хан үзе тугры, хак сүзгә башкалардан күпкә мохтажрак. Сүз гамәлгә юл ачып, хәрәкәт итәргә мөмкинлек бирә. Сүз юнәлешне билгели һәм ялгышуны, хатага юлыкканны ачыклап күрсәтә. Чыңгыз заманыннан яшәп килгән бу тәртип хаким өчен идарә итү рәвеше һәм аның кулланма өлгесе дә булып торган. «Идегәй»не укыганда шул аңлашыла—хакимнең ышанычы, аның көче якыннарының көченә, аларның мөстәкыйль күрә, үзенчәлекле аңлый белү сәләтенә һәм шул сәләтләрнең идарә итүченеке белән берләшүенә таяна. Чыңгызның үзе тирәсенә көчле тәэсирле, үзенчәлекле күрә, аңлый белүче кешеләрне туплап идарә итүе тарихи чыганакларда да сакланып калган.

Сүзгә булган мөнәсәбәтнең дастан чорында бүгенгедән ни дәрәжәдә аерылып торганын тагын берничә мисалда карап узыйк. Туктамышның лачын караучысы Котлыкыя хан каршында басып тора. Туктамышның күнеле тун тимердәй катканын сизә ул, ханның нәфрәтен дә ачык тоя, үзен жинаятьтә, сатылуда гаепләнгәнлеген дә ишетә. Ул инде коты алынып, хаким каршында дер калтырап торырга тиеш кебек. Ә ул үзен тыныч тота. Сүзләрен курыкмыйча, аяк терәп, ярып әйтә. Мескенләнеп түбәнсенүдән, кол булудан горур үлемне өстен күреп:

Чабучы булсаң, баш—минә!
Түгүче булса, кан—минә!—

дип жавабын тәмамлый Котлыкыя.

Бу Котлыкыянның дуамаллыгы яки үлемнән курыкмавы белән генә дә чикләнми, ә төркиләрнең яшәү, идарә итү тәртибенә килеп тоташа. Борынгы төркиләр культурасы тормыш-көнкүреш өчен төрле мөмкинлекләрне тулы файдалану, сәяхәт ысулларының камиллеге, хәрби осталык өстенә, әйтелгән сүзгә катгый, хәтта кырыс мөнәсәбәт, сүз ярдәмендә шәхескә куйган таләпләре, уй һәм сүз белән тәэсир итү осталыклары белән дә аерылып торган. Урлашу һәм ялган сөйләү иң каты җәзага—үлемгә китерә торган гамәлләрдән саналган. Менә нәрсә көч-гайрәт, гыйбрәт биргән аларга.

Дөрмән улы Урман би
Туксан бала эчендә
Каракчылык кылган би:
Балалар менгән таяк ат
Аны урлап тотылды.

Таяк атны урлаган өчен Идегәй Урман бинең башын кистерә һәм Туктамыш бу хөкемнең хак икәнен танырга мәҗбүр була.

Мәңгелектән хәбәр-белешмә алучы Субра ерау сүзенең хаклыгын башын куеп дәлилли.

Ир кешенең иң беренче, хәлиткеч (асыл) сыйфаты ялганламау икәнен белдереп:

Юкны димәс ирдермен!—

дип, Идегәй ант итә.

Шушы өзекләрдән күренгәнчә, ил төзүче ирләрнең сүзләре катгый рәвештә ялганга юл куймыйча, хакыйкатькә таянып эш итүгә, шушы юл белән көч-куәтне, бердәмлекне сакларга һәм арттырырга ярдәм иткән. Урлашу, ялган, риялы сүз—байлык тупларга җиңел юл кебек тоелса да, соңгы чиктә яшәеш сазлыгына илткәнен, илне—дәүләтне юкка чыгарганын кат-кат искәртә «Идегәй» дастаны. Бу яктан аның эчтәлеге бүгенге көн өчен ифрат актуаль һәм гыйбрәтле.

Дастанны иҗат итүчеләр фикеренчә, уйлаганны, күргәнне әйтүгә сүз табу—илаһи бер халәт. Күңелдә сүз барлыкка килү һәм сүз белән чынбарлык арасындагы элемтәне үзара чагыштырып карауны һәр кеше үзе хәл итүе—җәмгыятьтәге бәйләнешләрнең камил һәм ышанычлы булуының билгесе. Уйны сүз аша белдерү, үз сүзеңне ишеттерү, сөйләшү-урталашу—безнең культурада махсус юкка чыгарылган. Без уй белән сүзнең аралары өзелгән, сүз белән гамәл үзара тәнгәлсезлеккә дучар булган җимерек сәясәт дөньясында яшибез. Әйтәсе сүзен дә әйтә алмаган мескен халыкның тормыш диңгезенең иң төбендә, ләм астында ятып калуы берничек тә гаҗәп түгел. Ничә еллар безне сүз әйтү хокукыннан мәхрүм итеп, авызга йодрык тыгып, куркытып, күз буярга мәҗбүр итеп, өнсез яшәттеләр. Уй-фикерле кеше булудан ваз кичтереп, телсез, куркак, күндәм эш аты, саз үләне, кабырчык булып тәпәлдек без. Шуна күрә язмышыбыз фаҗигале—ләм кипкәннән соң тузан булып юкка чыгачакбыз. Кешелек дөньясының күпмедер өлешендә сүзнең чын бәясе югалу, аның алдау, көчләү, сәяси пропаганда, риялы реклама чарасына әйләнүе, тормышның имгәнүен, кешенең мондый җәмгыятьтә алданып, киләчәксез, куанычсыз яшәгәнен белдертә.

Сүзне аерым төрләргә бүлеп куллану сүзгә дәрәҗә бирү түгел, ә дөньяны тирәнрәк аңлау-аңлатуга бәйле. Бу алым үтә нечкә, нәтиҗәле сиземләүгә корылган һәм күзаллауны тулырак гамәлгә ашырырга ярдәм итә. Шушы уңайдан без үзебез яшәгән дөнья өчен сүз нәрсә соң ул дигән сорауны куярга һәм шул сорауга җавап эзләп карарга тиештербез. Сүз ул шул ук тавыш, яктылык, радио дулкыннары шикелле дулкын, кешенең башка адәми затлар белән элемтәгә кергәндә барлыкка килә торган авазлар һәм биокыр бәйләнеше. Ләкин сүз гади дулкын гына түгел. Ул адәм баласының күз белән һәм күңел белән күрүен, рухи халәтен берләштереп үзенә сыйдыра алган һәм шуны саклап йөртүче җанлы бер дулкын да. Сүз ул—кыр. Сүз гади кыр гына түгел, ул үзара бәйләү һәм берләштерү көченә ия булган тылсымлы кыр. Яки киресенчә—таркату, сукырайту, хәтта үтерү көченә ия усал биокыр—дулкын. «Идегәй» дастанында бүгенге көндә катлаулы физик, галәм кануннары нигезендә генә исбат итеп булган күренешләр искиткеч самими, төгәл тоемлау һәм тирә-якны үзара бәйләнешле күрә, күзәтә, аңлый белү нәтиҗәсендә моннан ничә йөз ел элек ерак бабаларыбызга мәгълүм булган. Мәгълүм булган гына түгел, шушы беренче карауда катлаулы тоелган алымнар көндәлек тормышта кулланылып торган.

## Уй һәм кыр

БЕЗ—ТАТАРЛАРНЫҢ бербөтен халык булып оешуында Алтын Урданың өлеше хәлиткеч зур. Урдада югары камиллеккә ирешкән татар теле киң тарала. Халык күңелендә туган җирне үз итү хисе, бергәлекне тою һәм тану тойгысы барлыкка килә. Туган илнең никадәр кадерле, якын икәнен Идегәйнең кайту күренешенә багышланган юлларда ачык күрәбез. Үз ягының яфрагы да калкадай, агачының ботагы да көмеш алкадай күренә аңа. Идегәйнең илгә кайтканда әйткән җилкенүле сүзләре йөрәкне телгәләп ала:

Адәм гарибе шул булыр—
Кайтып илен тапмаса.

Әгәр дә Алтын Урда дәүләт буларак тагын йөз, ике йөз ел яшәгән булса, халкыбызның нинди дәрәҗәгә җитеп үсә, ныгый, тарала алуын күз алдына китерү дә кыен. Дастанда сурәтләнгән дөньяны күзаллау табигать серләренә гаҗәеп тирән үтеп керү мөмкинлекләрен саклый. Шул мөмкинлекләрнең фән һәм фәлсәфә юнәлешендә үсеп җитеп саклана алмавы безнең киләчәк язмышыбыз өчен зур фаҗига булган.

Сүз—Алтын Урда цивилизациясенең иң мөһим, иң хәлиткеч бер элементы. Сүзнең көчен, тәэсирен аңлау, аны куллануны аерым тәртиптә алып бару, сүз сөйләүне илаһи халәткә тиңләү—безнең каныбызга сеңеп калган. Сүзгә ышану, сүзне тота белү татар кешесе табигатенең үтә нечкә һәм үзенчәлекле бер сыйфаты. Шушы сыйфатыбызга таянып, безне сүз ярдәмендә шактый җиңел ышандырырга, алдарга була. Татар кешесе үзен ялган, ялтыравыклы сүздән коткара белми. Бу өлкәдә ул сабыйга тиң. Без бит үткәннән яралган, хәтергә, теләккә бәйле сүзгә мөкиббән, кыр тәэсиренә үтә сизгер, ашкынуга бирелүчән, яратудан таралып төшә торган үтә дә серле затлар.

Кашларына карасам,—
Каләмнән пәйда булгандай;
Күзләренә карасам,—
Күгеннән пәйда булгандай;
Каршыннан торып карасам,—
Каһәрдән пәйда булгандай;
Буйларына карасам,—
Нурдан пәйда булгандай!

Бу юлларда Идегәйгә тәэсир иткән көчләр һәм аларның Идегәй кыяфәтендә гәүдәләнеше саналган. Әлеге күзаллауда борынгырак мифлар да чагылыш таба, мәсәлән, нурдан пәйда булу. Әмма алар мифик элемент буларак түгел, ә кешегә тәэсир итә алучы чынбарлык рәвешендә сурәтләнгәннәр. Дастан туган чор сиземләү көче аша табигатьне тирәнтен аңлау, шул серләрне кешенең мөмкинлекләрен киңәйтү өчен ныклап файдалана башлауга күчү чоры булган, күрәсең. Биокыр белән тәэсир итү (Идегәйнең Норадынны бәреп егу күренеше), кешенең хәтер кырыннан мәгълүмат ала белү (Субра ерауның Идегәйнең кем икәнлеген ачуы), кырны көчәйтү ысуллары (Норадын тәрбиясе), уй белән кешегә тәэсир итү, уйны кузгата һәм туктата белү, хәтер, мәгълүмат, вакыт һәм мәңгелекне бүгенгегә караганда ачыграк аңлау—болар барсы да Алтын Урда цивилизациясенең тирә-як дөньяны тасвирлауда үзенчәлекле караш барлыкка китергәнлеге һәм шул карашларга таянып үзенчәлекле булып үскәнлеге турында сөйли. Уй һәм акыл—Галәмнеке ди дастан. Кеше Галәмнең уртак уена тоташып кына гамәл кыла ала һәм аның үз уе Галәмдә даими теркәлеп кала.

Уй тәэсире... Кыр тәэсире...

Дастан үзе сүз аша тапшырылган куәк уй рәвешендә безгә килеп ирешкән. Укыган чакта аның һәр юлы кыр көче белән синең акылыңа, уеңа тәэсир итеп тора. Аксак Тимернең ачуы, Идегәйнең ярсып мәҗлестән чыгып китүе, Кара Тиен Йосынчыны күргәч кинәт шүрләп калуы, пир Галәтдингә үпкәсе, сугышта табигый куркусызлыгы, илгә кайтуы, Норадынны яратуы, Туктамышның качып бару күренешләре—тылсымлы тәэсир көче белән күңелне тирән тетрәндереп, күңелгә сеңеп кала торган юллар. Аларны кат-кат укыйсың һәм сүзнең көченә, уйның бөеклегенә тагын бер кат инанасың. Ихлас сүз беркайчан да югалмый икән ул. Аның тәэсирен вакыт та җуя алмый икән. Безне бетерүгә, тарихтан чыгарып ыргытуга көйләнгән чынбарлыкта «Идегәй»нең исән калып безгә килеп ирешүе—шушы гипотезаны исбатлаучы бер дәлил түгелмени?

Дастанда Евразия киңлекләренең төрле төбәк сөйләмнәре хоры яңгырый. Татар иленең чиксез киңлеген шул яңгыраш тапкан диалектлар, шивәләр үзенчәлекләре аша даими тоеп торасың. Анда хәтта минем туган авылым сөйләме дә катнашкан. Дастан иҗатчысы безнең Исергәпчә «жик күреп», «тенкә кортып», «яскынып», «кыдырып» дип сөйли. Норадын әнисенә безнеңчә «инәки» дип эндәшә. Сүзләр урыныурыны белән каяндыр еррактан ишетелгән кебек тоела. Әйе, ерактан, безнең балачагыбыздан. Мин хәтерлим, безнең әби-бабайлар шулайрак сөйләшә иде. Кайбер сүзләр аңлашылып та бетми. Нәрсә ул «йөлте», «әттек», «ыртык», «мидәт», «биншәм»? Әмма бу сүзләр дә гаҗәп бер асылташның ялтырау матурлыгы кебегрәк кабул ителәләр. Алар һич тә әсәрне аңлауга комачауламыйлар. Шул ук вакытта, ни гаҗәп, бары тик бер генә сүз миңа бөтен әсәргә башкача карарга мәҗбүр итте. Низаг бит Идегәйнең өрәгеннән көнләүдән башлана:

Елкычыдан би булган
Кобыгылның өрәге;
Өрәгеннән өстен булганда,
Аны түбән кылаек!

Нәрсә соң ул өрәк? Без бу сүзне әрвахның кабердән чыгып адашып йөргән куркыныч шәүләсе, яки бик ябык, ямьсез кеше мәгънәсендә аңларга күнеккәнбез. Дастан өрәкне башка мәгънәдә куллана—бу бәхәссез. «Өрәк»—Нурихан Фәттахның иҗекләү ысулында тикшергәндә, «аура» сүзенә аваздаш, ә мәгънәсе буенча тәңгәл. Димәк, өрәк—кешенең физик һәм психик халәтен чагылдырган кыры булып чыга һәм дастанда сурәтләнгән Йәникә шул кырны күрү сәләтенә ия. Дастанда кыр телгә алынып кына калынмый, ә аны үстерү, көчәйтү ысуллары да бирелә. Өрәкнең кешене уратып алган кырдан читтә адашып, каңгырып йөргән шәүләгә әйләнүе безнең язмышка ишарә түгелме? Татар кешесенең туган туфрагында чит, икенче сортлы кеше булып яшәве, милли таркалуы өрәкләшү түгелмени?

Тамырлары тагын бик еракка киткән бер тасвирлау бар дастанда:

Аһым жирне—күкне тотадыр,
Кутәрә алмассын, Норадын!
Анда Идегәй аһ орды,
Норадын артка егылды,
Авызы-борыны кыйшайды.

**Аһ**—борынгы мисыр мифологиясендә кешенең тәне кебек үк аерылгысыз бер өлеше, аның үлгәннән соң кала торган гәүдәләнеше. Тән жирнеке булса, аһ—күкнеке. Борынгы Мисырда гади кешенең аһы бер генә катлы, ә патшаларда ул берничә (жидегә кадәр) кат була дип исәпләгәннәр. Идегәйнең аһы шундыйлардан. Аның көче хәтта жир белән күкне тотып торырга да житәрлек итеп күрсәтелгән.

Курку белмәс, йөремсәк татар кешесен язмыш кайсы гына илләргә илтмәгән дә, ул кайда гына үзенең тамырларын җибәреп карамаган. Сөннәр, Урта Азиядә Караханилар, Мисырда Бейбарс, Һиндстанда Моголлар, Алтын Урда, ханлыклар—барысында да безнең бабайларның эзләре бит. Дәүләт тоту, ил жыю ул заман ирләренең иң көчле омтылышы булганлыктан, алар тирәсенә гаскәриләр, галимнәр, дин белгечләре, чичәннәр, ерауллар жыелган. Алар үзара берләшкәннәр, шул бергәлек беркайчан да өзелеп тормаган. Илләр жыелу белән бергә, дин һәм мәгыйшәт тә үзләштерелгән, уртак яшәешкә сыйганнары әкренләп телгә дә күчкән. Вакытлар үтү белән, язмыш агышына ияреп сүзләр дә йә беренчел мәгънәләрен жуеп, янара торганнар, үзгәреш кичергәннәр, яисә үзгәрмичә безгә аңлашылмас дәрәҗәгә житеп телдә сакланганнар. Аһ—безнең өчен миф белән бәйләнешен югалткан гади бер хис белдерү авазы булып кына калган, ә өрәк аның беренчел мәгънәсен аңлаучылар беткәч куркыныч шәүләгә әйләнгән.

Тел халыкның рухи халәтен, ирек-ирексезлеген, өмет-багланышларын, хакимлек дәрәҗәсен, хакимлеккә дәгъвасын бик төгәл чагылдыра. Уй һәм күңел—безнең бөтен гамәлләребезнең хуҗасы. Телдән төшеп калган вакыт үтү белән уйга керми башлый. Уйга кермәгән гамәл булып тормышка аша алмый. Ничек әйләндерсән дә телдән төшеп калган һәр сүз зур, яңадан табылмас югалту була инде. Дастанның үзеннән берничә мисал китерик. «Ясавыл», «тоткавыл», «иравыл», «чагдавыл», «утчагыр», «аткыюч» һәм башка гаскәр тормышына кагылышлы сүзләр дәүләтебезне югалткач, телебездән бөтенләй төшеп калганнар. Икенче төрле нәтиҗә ясарга да була—без

гаскәрсез калганбыз, аннан соң гаскәргә кагылышлы сүзләр онытылган. Соңгысы дөреслеккә туры киләрәк сыман.

Тауда йөргән бүре идем,
Талчыгыма тайлы бия жиер идем.
Уйга төшеп куй булдым.

«Уйга бату», «уй басу», «уйдан арына белмәү»—менә нинди халәт ир-егетләрне куй ясый. Кичә илләр жиер ир булсам, бүген бер гавергә кол булып яшимен—бу юлларның кинаяле мәгънәсе—тагын безнең язмыш!

Дастан геройлары уй белән эш итә белүне үзләренең иң өстен сыйфатлары санап, каты бәхәс чыкканда хәлиткеч дәлил итеп китерәләр. Атасына кул күтәргән Нурадын, сүзгә, бәхәскә хакы барын түбәндәге юллар белән белдерә:

Уй дигәй дә кыр дигәй,
Уйны баскан мырзамын!

Дәүләт югалту нәтиҗәсендә бик нык гадиләшкән, аяусыз бастырылган татар дөньясы уй һәм кыр нечкәлеген тою тәэсиренә корылган кайбер һөнәр-гадәтләрен, бәлки, әле бүгенге көндә дә саклыйдыр? Безнең бит алар белән эзлекле, житди фәнни нигездә, ихлас кызыксынганыбыз юк. Андый эшкә тотынырга безнең мөмкинлегебез булганы да юк. Сенсация эзләргә мәжбүр журналистлар, акча колы—надан экстрасенслар бу яктан татар чынбарлыгына ярдәмче түгел. Уй һәм кыр тәэсире күпкә гадирәк тә, катлаулырак та. Ул дөньяга фәнни карашларны үзгәртүгә кадәр барып житәргә мөмкин.

Дөньяның асылын аңларга омтылучы галимнәр фикеренчә, фәнни күзаллауларга борынгыларның дөньяга карашлары да сыярга хаклы. Бүгенге көндә галәмне төрле кисәкчекләрдән торган, фрагментар, күзәтүчегә бәйсез бинһаја зур, катлаулы машина рәвешендә күзаллау—фән архивына тапшырылган караш. Хәзер физиклар дөньяны бер-берсенә тыгыз бәйләнгән гаҗәп катлаулы хәрәкәт-агым челтәре дип фаразлый башладылар. Матдә эченә үтеп кереп, аның төзелешен өйрәнү, галәм киңлекләрендә бара торган шушы катлаулы агым-хәрәкәтнең серенә төшенүдәге ачышлар физикларны каты жисем төшенчәсеннән баш тартып, дөньяны уй һәм кыр агымы рәвешендә күзаллауга китергән. Алар уйны—без яши торган дөньяның аерылгысыз үзлеге, галәмне бәйләүче, үзара тоташтыручы жепләр челтәре дип исәплиләр. Дөньяны аңлау-аңлату уй аша гына мөмкин. Уй агымы фәкать өзлексез булганда гына күрү барлыкка килә. Күрү—күзәтүчегә, аның акылына, тәненә, тарихи тәҗрибәсенә, культурасына бәйле. «Идегәй» дастаны уй һәм кыр бәйләнешләрен тормышта яшәп килгән үзенчәлекле культура берәмлеге буларак ача, гамәл агымында күрсәтә.

## Хәтер һәм мәгълүмат кыры

ХАЛЫК әкиятләрендә гаҗәп тирән мәгънәле күзәтүләр бар. Әйтик, чәч бөртеге хуҗасының бәладә икәнен әйтә; агачлар куркыныч килгәндә кешене яшерә, адашкан юлчыга юл күрсәтә; ташлар сүздән хәрәкәткә киләләр; корылмаларны йомырка зурлыгындагы ташка әйләндереп һәм кире торгызып була һәм башка могжизалар. Кешенең дөньяны танып белү юлында беренче адым булган әкият бары тик киләчәк фәнә генә аңлата алачак күзаллауларны үзендә туплый алган. Шундыйларның берсе хәтер һәм мәгълүматка кагыла. Әкият дөньясында бер нәрсә дә югалмый һәм онытылмый—баскан эз дә, әйткән сүз дә, кылган яхшылык-яманлык та. (Соңыннан бу әкиятне мифик күзаллау дингә күчкән.) Бүгенге фән хәтер һәм мәгълүматка кагылышлы күп нәрсәләрне белә. Бигрәк тә компьютерлар киң таралу, мәгълүматны жыю, эшкәртү, тарату, хәтерләүнең электрон жайланмалары һәм челтәре барлыкка килү табигатьтә хәтернең чиксез-төпсез икәнлегенә ышанырга мөмкинлек бирә.

Дөньяны күзаллау, жәмгыятьне оештыру, идарә итү—мәгълүмат туплау, хәтергә таянудан башка мөмкин түгел. Кешеләрнең милләт-кавем булып оешып яшәүләрен дә хәтер һәм мәгълүмат туплаудан башка аңлатып булмый. Көч, куркыту ярдәмендә тупланган миллионлаган гавамның хәтере юк, ә милләтнең иң бәләкәе дә хәтергә, тарихка, гореф-гадәтләргә, уртак өметләргә ия була. Һөнәри осталыклар, гореф-гадәт, тел, гыйлем, тарих, дин—барысы да хәтер берәмлекләре булып, аерым кешенең

һәм милләтнең яшәешен сугарып, тәэмин итеп торалар. Милләткә сыенмаган адәм кеше булып яшәүдән туктый.

**Хәтер**—табигатьнең аерылгысыз бер өлеше. Хәтта таш та кайда ятканын, су да каян акканын, үлән дә нинди җирдә үскәнен хәтерли. Француз галиме Бенвентист билгеле бер матдәне суда 10 120 катнашмасында эреткән; фәнни күзаллаулар буенча мондый катнашмада матдәнең бер молекуласының да булуы мөмкин түгел. Ә тәҗрибәдә суның эрегән матдәне хәтерләве ачыкланган. Башка шундый күзәтүләргә таянып, кайбер галимнәр җирнең магнит кыры кебек үк мәгълүмат кыры да бар дигән фикергә килделәр.

Фәндә кешелек җәмгыяте турында сүз барганда, аның үсешен спираль белән чагыштыралар: бүген үткән юл бераздан онытыла, әмма икенче әйләнештә ул камилләшкән сыйфатта тагын кабатлана. «Идегәй» дастаны турында уйлаганда, бу чагыштыру һәрвакыт үзен сиздереп, үзенең хаклыгын күрсәтеп тора.

Дастанга таянып хәтер һәм мәгълүмат кыры турында берничә төрле фикергә килергә мөмкин. Беренчесе—дастан яттан сөйләргә тиешле әсәр буларак, сүзнең музыкасын, кеше хәтеренең нечкәлекләрен тоеп язылган. Шуңа да ул хәтерне ныгытучы, көчәйтүче махсус ысулларга бай. Икенчесе—дастан үз чорында хәтер-хәбәрнең ничек таралганын һәм ничек сакланганын сурәтләп күрсәтә. Өченчесе—Субра ерау үрнәгендә тарихи хәтер, сынамышлар кулланып мәгълүмат кырына тоташу мөмкинлеге күрсәтелгән. Хәзер һәр фикерне дә дастанның үзеннән алынган мисаллар аша карап китик.

Беренче урында хәтерләүне җиңеләйтүче алым булып, әлбәттә, көйләп, янгыратып сөйләү—рифма-ритм тора. Рифма һәм бер үк сүзне төрле мәгънәдә кат-кат янәшә куллану текстны кысарга, фикерне һәм сүз тәэсирен кинәйтергә, көчәйтергә мөмкинлек бирә:

Үзе бинен сансыз мал,  
Үзе дә белмәс икән дә.

Яки Идегәй турында:

Тауда ятты, тай бакты,  
Елкы бакты—кол булды,  
Өстендә ямар тун булды,  
Башы белән баш булды.

Үзе-үзе, тау-тай, кыр-куй, елкы-кол, баш-баш, бакты-булды сүзләре парлы кабатланып, шигырьнең эчке көй-янгырашын барлыкка китерәләр. Шигырь көе белән күңелгә үтеп керә, музыка рәвешендә хәтердә сакланып кала.

Күреп сөйләү алымы шулай ук сөйләүченең хәтерен кинәйтә, сүз тәэсирен күпкә көчәйтә. Менә сүз агымында хәрәкәтле сурәтне еш алыштырып тору белән ирешергә була. Дикъкат биреп укыганда, дастанның тоташ хәрәкәткә көйләнгән шигъри сөйләм икәнлеген аңлый башлыйсың.

Ерау әзер булсын!—дип  
Хан боерыгын биргәндә,  
Хан чабары Байморат  
Сыйпап соры бүрек киеп,

Билен тартып бер буды;  
Кыл койрыгын чарт төеп,  
Чапкын атка бер менде,  
Юрта чабып бер жилде...

Әлеге өзектә һәр юл үзара бәйләнешле тоташ бер хәрәкәтне сурәтли. Аны истә калдыру өчен атка атлануны күзаллау җитә.

Шуңа игътибар итәргә кирәк, сүз нәрсә турында гына бармасын—кешеме ул, барасы җирме, шәһәр-авылмы—кушкан исем гаҗәп оста, төгәл, ул аның бөтен кыяфәтен, сыйфатын, күләмен үзенә сеңдереп куелган. Дастандагы исем-атама бирү осталыгы—сүзгә булган мөнәсәбәттән, сүзнең күрсәтүче, анга житкерүче, вакыйгаларны үзара бәйләп торучы булуын танудан килеп чыккан. Төгәл, кыяфәтенә туры китереп сайланган атама җиңел аңлашыла һәм хәтердә озак саклана: Сары Тау, Җаек, Ык, Идел, Саба, Болгар, Казан һәм башка исемнәр әле бүген дә исәннәр, матур янгыравы белән безне һаман сокландырып торалар.

Автор атамаларны дастанның шигырь агымында тезеп санау белән генә чикләнеп

калмаган. Атамалар күп очракта үтәсе (үткән) юлның ераклыгын, төбәкләрнең табигый географик планын да күрсәтеп торалар.

Чулман буе Жүкә Тау,
Жүкә Тауның арьягы
Ышыктан аккан Ык булыр,
Аның да чыгып башына,
Даладан дала үтәсең.

Яисә:

Ай да ун көн дигәндә,
Сәмәркандтай шәһәргә
Житеп килде Норадын.

Араны төгәл билгеләү, исемнәрне урынлы, төгәл атау бу жирләрнең кат-кат үтелгән, өйрәнелгән, таныш төбәк булуына ишарә ясый. Үтелгән—һәм хәтергә сеңеп калган! Икенчедән, атамаларның үзара тоташуы, аларның йөрелгән жиргә тәңгәл янгырашы күңелдә географик карта рәвешендәге сурәт барлыкка китерә. Бабалары-бызның Гоби Чүленнән Карпат тауларына тинентен жәелгән биниһая зур киңлектә адашмыйча жинел йөри алуларының сере дә нәкъ шушы исемнәрнең йөргән жирләргә тәңгәл яңгыраштa бирелүенә һәм аларның телдән-телгә тезеп тапшырылуына бәйле.

Авылыбыз тирәсендәге тау, урман, күл, болыннарның исемнәрен күңелемнән кабатлыйм: Ар тавы, Факия юлы, Бәшәр чокыры, Бакыр тау, Чаукалык тавы, Ачы төбәге, Уксынлы кул, Ык, Әдһәм тугае, Даулы болын, Аккош күле, Тау борыны—һәм атамалар сайлау нәкъ «Идегәй» чорларындагы кебек жаваплы, сүз бәясен аңлауга көйләнгән икәнлегенә төшенәм. Безне хәзер тар бер төбәккә бикләп куйганнар. Йөрер юлларыбыз чиксез кыскарган.

Шул чор жәмгыятенә хас хәтер-хәбәр туплау һәм тарату Идегәйнең кемлеген ачыклау күренешендә тулысынча сурәтләнеп калган.

Исегездәдер, көннәрдән беркөнне Йәникә күңелендә туган көнчелек Туктамыш ханны да йокысыз калдыра. Хан үзенең якыннарыннан шик-шөбһәсенә жавап табуны, ачыклык кертүне таләп итә. Кем ул өрәге хан өрәгеннән дә көчле булган ир-егет? Бу сорау иң яшертен, иң жаваплы һәм куркыныч эшләрне башкара торган тугыз иргә бирелә. Бирелә, әмма сорау жавапсыз кала. Шикне бетерердәй, күңелне тынычлан-дырырдай сүзне әйтүче юк. Шунысы игътибарга лаек, Туктамыш хан Идегәйне тәрбияләгән Жантимергә якын кешеләргә тими. Жантимер аңа тугрылыклы хезмәт иткән һәм аңа карата шик күрсәтү—аның рухын түбәнсетү, абруен төшерү генә түгел, Туктамышның да абруен төшерү булыр иде. Моны шулай аңларга кирәктер.

Ахырда йөз туксан биш яшәгән Субра ерау, малга кызыгып, Идегәйнең кемлеген ачып бирә. Идегәйне сынау мәжлестә оештырыла. Субра ерау баштa үзен бераз бал белән «кыздырып» ала. Идегәйнең һәм киң Жанбайның сүзгә мөнәсәбәтен табында-гыларга ача да, «кемлекне билгеләү» өчен, хәзерге тел белән әйткәндә, психологик тест оештыра. Жанбайны—жанбаз—хәтергә юл куючы, Идегәйне—асыл чичән дип атый. Кемлек билгеләнгәннән соң гомерендә үзе күргән ханнарны һәм батырларны исенә төшереп атый башлый. Бу күренешләрнең тирән эчке мәгънәсе бар: кемлекне ачыклау—ул ерау өчен атарга ук чыгару булса, хәтер кырын хәрәкәткә китерү—төбәү, тиешле мәгълүматны атып алу дәрәжәсендә була.

Һәр кеше үзенең нәсел-ыруы турында мәгълүматка ия. Бу мәгълүматның үтә кыйммәт торуы дастанда ачык аңлатылган. Кешенең сыны, кыяфәте, атлап йөреше, үз-үзен тотышы, тавышы, сөйләме һәм башка күп яклары аны үткәндәгеләр белән бәйләргә мөмкинлек бирә. Кайбер очракта кемнең кемгә кайсы жире охшаган икәнне дә әйтеп булмый, ә шул кешенең нинди нәселдән икәнлекне ачык тоясың. Танып белү—төсмерләү, сиземләү аша күңелгә килә. Мәгълүмат кыры—кешенең аерылгысыз өлеше, аның гомерлек юлдашы бит.

Инде мин кеше танымам,
Әгәр кеше танысам,
Котлыкыя би улы
Идегәй ул—Кобыгыл!—

дип тәмамлый ерау чыгышын.

В. И. Вернадский ачкан тәгълимат буенча, Җир—тереклек барлыкка китергән, катлаулы бәйләнешләр белән яшәүче бербөтен организм—неосфера. Мәгълүмат алу-алмашу тереклекнең һәр төренә тормыш-көнкүреш казанында кайнап яшәү мөмкинлеге тудыра. Табигатьнең үзендә даими эшләүче мәгълүмат челтәре булуы сизелә. Чынлап та, әгәр җир сазланса, озак көттермичә анда суга яраклашкан үсемлекләр һәм тереклек барлыкка килә, су кипсә—киресенчә, коры җирне яраткан үсемлек үсә башлавын күрәбез. 1972 елгы корылыкта Казансу елгасы бөтенләй диярлек кипте һәм элекке елга төбе аллы-гөлле чәчәкләр белән капланды. Кешеләр шул гөлләр арасыннан сукмак салдылар. Үсемлекләр бернинди көтеп торуны белмичә бер җәйдә барлыкка килгән коры җирне үзенеке иттеләр. Бу без күрә алганы гына. Ә без күрмәгән микродөньяда андый хәрәкәт тагын да тизрәк һәм киңрәк бара. Галимнәр исәпләвенчә, унайлы шартлар туганда, бактерияләрнең үрчү мөмкинлеге шулкадәр зур, алар җир авырлыгына тигез авырлыкны санаулы тәүлек эчендә үрчеп барлыкка китерә алалар. Гомумән, җирнең тере өслеге (биосфера) үзе аша бинидһая күп матдә үткәреп, аны туктаусыз эшкәртеп тора. Су, кояш энергиясе ярдәмендә эшкәртелгән матдә җирнең эчке катламнарына куыла, анда басым, тыгызлык тәэсирендә ниндидер үзгәрешләр кичерә һәм тагын әйләнешкә кайта. Тереклек организмы шушы әйләнештә мәгълүмат белән дә тулыландырыла. Хайваннар бу катлаулы бәйләнештән үзләренә кирәкле мәгълүматны ала беләләр. Күчеш, юл табу күренешләре, бигрәк тә кышны җылы якларда үткәрүче кошлар мисалында, мәгълүмат кырына тоташа белүдән, дип аңлатырга да мөмкин.

Кеше табигать барлыкка китергән мәгълүмат кырыннан тыш үзе мәгълүмат барлыкка китерә һәм аны үз тормышындагы гамәлләргә җайлаштырып, җирнең тереклек катламына сизелерлек тәэсир ясап яши.

«Идегәй» дастанында сурәтләнгән мәгълүмат кырына тоташу—очраклы күренеш, яки авторның уйдырмасы түгел. Төркиләрнең бик борынгы заманнардан гаскәрдә көчле уй-кыр белән тәэсир итүче яки мәгълүмат алучы кешеләре дә булганы тарихи чыганакларда сакланган. Әбелкасыйм Фирдәүсинең «Шаһнамә»сендә 589 елда булган төркиләр һәм иранлылар арасындагы Герат сугышы турында хикәяләү бар. Төркиләр сугышта сихер кулланып, иранлылар өстенә ут һәм ук яудыра башлыйлар. Бәһрәмнең куркусызлыгы, моның күз буу икәнлекне аңлавы гына иранлыларны мәсхәрәле качудан туктата. Чыңгыз хан гаскәре турындагы истәлекләрдә дә шуңа охшаш очраклар китерелә. «Идегәй»нең аермасы шунда, дастан уй-кыр белән эш итүне сихер яки күз буу белән бәйләми, ә кешенең табигый тәэсир итә алу көченә кайтарып калдыра. Л. Н. Гумилев үзенең хезмәтләрендә төркиләрдә тарихи хәтернең өзек булуын күрсәтә. Шул ук вакытта фикерләүнең сихер, тылсым басымыннан кешенең тәэсир көчен тануга күчүе, күзаллауның төгәлләнгән, бер калыпка салынып, ниндидер юллар белән эзлекле үсә алганы турында сөйли.

Алтын Урда, аннан соңгы татар ханлыклары җимерелгәннән соң безнең тарихи хәтердә тагын ялганмас өзеклелекләр һәм бушлыклар барлыкка килгән. Тел—чагыштырмача үзүсешкә ирешкән илаһи күплек буларак, мәгънәләре онытыла башлаган сүзләрне һәм бөтенләй югалган сүзләрне дә саклап калган.

Тугыз ирең чакырткыл,
Ерауларның алдыргыл,
Сынчыларың сынаткыл,
Өлкән бер туй кылдыргыл,—

дип кинәш итә Йәникә ханәш Идегәйнең кем икәнлеген ачыклау өчен. Димәк ул вакытта ук кыяфәткә карап кешенең холкын-фигылен сынчылар ярдәмендә билгели белгәннәр. **«Ерау»** сүзе кулланыштан төшеп калган, аның төп мәгънәсе мәгълүмат кырына тоташып, ерып чыга белүче булырга тиеш. Ерауның пары «Яр салу», «сөрән салу» гыйбарәләре—хәбәр тарату мәгънәсендә бүген дә телебездә кулланыла. Дастанда ул болай яңгырый:

Азамат ир Идегәй
Анда илгә яр салды:
Дәвер кемнең дәвере?—
Идегәйнең дәвере!
Заман кемнең заманы?
Идегәйнең заманы!
Яр салдырды калага,
Яр салдырды далага.

## Вакыт һәм мәңгелек

ВАКЫТНЫ ничек анларга була? Чиксезлектән агып килүче елгамы ул, әллә туктаусыз тәүлекләрне кабатлап, әйләнеп торган сәгать угымы? Агым тизлеге нәрсәгә бәйле? Кабатланамы ул? Фантастлар вакыт дәрьясында киләчәккә, йә үткәнгә күчә ала торган корабка утырып сәяхәт итәләр дә, ә нигә без үз вакытыбыз эченә генә кереп бикләнгәнбез?

Вакыт агымы чылбыр бөжраларын хәтерләтә: көн һәм төн, ел фасыллары, туу һәм үлем—кабатланып торалар, шулай ук һәрберсе тәмамланган вакытны үз эченә сыйдыра.

Вакыт—тереклек, яшәү белән бәйләнгән. Уйлап карасаң, узган да, киләчәк тә юк, ә бүген, һәр тереклекнең яшәү вакытына бәйле бары тик шушы мизгел генә бар. Мөгаен, вакытны җирдәге тереклек барлыкка китергәндер. Салкын галәм киңлекләре өчен көн һәм төн, җәй һәм кыш, яшәү һәм үлем төшенчәләре юк бит. Үзгә табигатьле, ел фасыллары бер-берсенә охшамаган биниһая зур, чиксез киңлекләрдә даими хәрәкәттә булган борынгы бабаларыбыз вакытның нәкъ шушы үзлеген—яшәүгә бәйлелеген вакыт дип таныганнар. Иртәгә, киләчәк бар, әгәр син исән булсаң.

Алдагы көн агырга
Без барабыз, ул килмәс—

бу Идегәйнең соңгы сүзләре. Ялыктыргыч, озын, ярсу көрәш ахырында кыска гына әйтелгән әлеге сүзләр алдагы буыннарга васыять булып яңгырыйлар. Әйе, җиңү, җиңелү—тормыш диңгезендә бер тамчы гына. «Хәзер инде нишләргә?» дигән сорауга җавап гади: «Яшәргә». Яшәгәндә үткән дә, киләчәк тә югалмый. Алар—тоташ. Безнең күзәнәкләргә сеңеп, күңелдә, хәтердә саклана. Исән калырга, яшәргә! Заман, вакыт барлыкка китерергә. Яшәгән халыкның гына үз тормышы—үз вакыты бар. Вакыт—яшәү дә бит ул.

Без килгәнче ниләр булган, без киткәч нәрсәләр булыр? Бу сорауны бирмәгән кеше юктыр. Шушы сорауга җавап рәвешендә диннәр барлыкка килгән һәм аларның һәрберсе кешене үлем билгесезлегеннән чиксез бер агымга кушып үзенчә юата белә. Берләре, кешенең җирдәге гөнаһларына карап, үлгәч икенче тормыш белән—тәмугта, йә оҗмахта яшәячәгенә ышандырсалар, икенчеләре—адәм баласының тормышка, һичшиксез, нинди дә булса яна кыяфәттә кире кайтачагына ышандыралар.

«Идегәй» дастаны шушы каршылыклы тоелган ике карашны да сыйдыра алган. Моның сере гади—Алтын Урда дәүләтендә, Чыңгыздан килгән гадәт буенча, диннәр иреге сакланган. Тагын шуңа игътибар итәргә кирәк, XX гасырда коммунистлар хакимлеге чорында ирешелгән уйсыз, тоткыннарча түбәнсенеп буйсыну—Рәсәй дәүләтчелеге тудырган, башлангычы бер патша тирәсендә тупланып, талап-көчләп, яндырып-көйдереп дәүләт оештыруның имәнгеч җимеше ул. Тормыш иркенрәк аккан дәүләтләрдә гамәлдәге дин тәкъдим иткән карашлардан тыш, халыкның яшәү рәвешендә тапкан үз уй-карашлары да сакланып кала. Дастанда тәңречелек белән бәйләнгән күп йола-ышануларның яңгыравы халык күңелендә ислам динен кабул иткәннән соң да Тәңренең онытылмавы турында сөйли. **Тәңречелек**—мәҗүсилектән соң ирешелгән иң борынгы диннәрдән санала. Аның нигезендә табигатьнең өстенлеген тану, кешенең көче табигать белән үзара яраклашуда, табигать белән гармоник бәйләнеш, элемтә барлыкка китерә белүдә икәнен аңлау ята. Мәсәлән, японнарның икенче диннәре—синтоизм күп яклары белән тәңречелекне хәтерләтә. Алтын Урда цивилизациясе—табигать көчләренә, тереклеккә (атка һәм малга), җир-суга, үсемлекләр дөньясына таянып, аларга берегеп күтәрелгән цивилизация. Башкача мөмкин дә түгел—ул заман кешесе малына азык, ашарына ризык, юлда йөрергә җегәрле көчне Тәңре бирсә генә таба алган. Алланы да ул бәхәсләшеп тә тормыйча Тәңрегә тиң изге һәм мәрхәмәтле итеп кабул иткән. Һәм, бүгенге японнар шикелле, шушы очракта җан аларның кайсысына мохтаҗрак, аларның кайсы күңелгә һәм вакыйгага якынрак, телгә унайлырак шул исемне әйтеп күкләргә мөрәҗәгать иткән: ул чорда йә Тәңре, йә Алла дип икесенә дә ялварган татар. Һәм шуларның икесе дә көч-куәт, рухи җегәр биреп, адәм балаларын үзара берләштереп, якынайтып торганнар.

Бала чагында нык ислам тәрбиясе алган Норадын атасына кул күтәрә, аның күзен бәреп чыгара һәм гөнаһын хаҗга барып юачагын белдереп:

Тәңре өе Кәгъбәне
Бер әйләнсәм унармын,
Өч әйләнсәм тынармын,
Языгы белән гөнаһын
Җиде әйләнсәм йолармын,—

ди. Күпне күргән, күп яшәгән, яхшы хәтере өчен ерау исеме алган Субра карт та әгәр үзен Туктамыш хан үтерсә, «Ахирәт өйгә барырмын, янә өйгә керермен»,—дип, диннәр тәкъдим иткән ике аңлатманы бергә кушып фикерле һәм юаныч таба.

Табигать белән тыгыз бәйләнгән җәмгыять аңында кабатлана торган вакыт системасы өстенлек итә. 12 еллык терлек (хайван) календаре кертү, ел фасылларына, табигать күренешләренә багышлап теләкләр теләү, күнелле бәйрәмнәр үткәрү, төрле йолалар үтәү—вакытның кабатлануын танудан барлыкка килгән. Уртак йолаларны тиешлечә үтәп тору безнең бабаларыбызны берләштергән, җәмгыять тормышында үзара якынаю барлыкка китергән. Дастанда вакытның кабатлануы тагын да киңрәк алынган. Вакыт кешенең холкына, язмышына, җәмгыять үсешенә үрелеп үсә, анда кабатлану таба.

Астрономик вакыт, кабатлана торган (циклик) вакыт, тереклекнең эчке вакытыннан тыш әсәрдә тарихи вакыт төшенчәсе дә янгыраш тапкан. Субра ерау үзенең күргән батырларын, ханнарын вакыт турысына (тарихи вакытка) тезеп куеп сөйли. Аларның һәрберсенең кыяфәтен, гадәтен искә төшерә, бүгенге көнгә тәэсирен чамалый, бүгенге белән бәйләнешләрен эзли һәм таба. Мыскыллап:

Бездән дәуран үткәндә,
Сезгә дәуран житкәндә
Та кем калды ханнарга ...—

дип каты гына әйтеп тә куя. Дәвер, дәуран, заман—тарихи вакытның атамалары. Субра ерау хәтерендә саклануы вакыт—ул шулай ук эчке вакыт. Аның үзенчәлеге шунда, хәтердәге эчке вакыт буларак аны тизләтеп, әкренәйтеп, кайбер өзекләрен төшереп калдырып, төрле юнәлештә үтеп була. Дөресрәге, Субра ерау вакытны түгел, вакытка бәйле кешеләрне, вакыйгаларны вакыт турысына, хәтер җебенә тезә. Ә үткән вакытны аны сизеп-тоеп булмый, ул каядыр китеп югалган. Картларның: «Яшәгән дә кебек түгел, ә гомер үтеп тә киткән»,—дип уфтанулары вакытның сизелми генә югала баруын аңлаудан бит.

Кешенең эчке вакыты да тигез акмый. Вакыт тойгысы безнең яшькә, халәткә бәйләнгән. Яшьлек өчен вакыт чиксезлеккә тоташа кебек тоелса, картлык өчен комга сеңгән су шикелле генә. Эчке вакытның төрле тизлектә акканын гадәти халәттән чыкканда—ашыкканда, көткәндә, авырганда һ. б. шундый очракларда һәркем сизә. Эчке вакытны көйләү белән махсус шөгыльләнергә дә була. Йогларның йөрәк тибешен, сулышларын туктатып тора алулары—эчке вакытны әкренәйтә белүдән килә.

Вакытның тигезсез агуы, әкренәюе аның кайдадыр бөтенләй туктаган булуы мөмкин дигән уй тудыра. Бу фикерләү колачы житмәгән «кайдадырны» без мәңгелек дип атыйбыз. Дастан мәңгелектә вакытның юкка чыкканын таный. Әсәр геройлары аткан теләкләре, эчкән антлары, каһәр-каргышлары, мәгълүмат буларак, мәңгелектә саклана дип гамәл кылалар. Мәңгелектә үткән дә, бүген дә, киләчәк тә бар. Үткәндә аткан каһәр угы төбәгән кешесенә киләчәктән язмыш булып килеп кадала. Әзәл—мәңгелекнең тагын бер атамасы. Күрәзәлек итү—әзәлне күрү, ягъни мәңгелек белән тоташу, мәңгелектән мәгълүмат алуны аңлата. Көчеш халәтендәге теләк, каргыш—көчле тәэсиргә ия. Шулай ук көчеш халәтендә күрәзәлек итү сәләте дә арта. Кара Тиен Йосынчы, мәңгелек йортка күчәр алдыннан Идегәйгә атап түбәндәге сүзләрне әйтә:

Туктамыштан жик күреп,
Шаһ Тимергә барсаң да,
Ул да сиңа тураймас.
Йортыңны талап кан эчеп,
Токымыңны кол итеп,
Йортың йорттан күчереп,
Иленне жирдән аерып,
Үз кулың белән кол итеп,
Мен хәйләгә юл итәр.

Шушы кыска гына күрәзәлектә татарның бөтен язмышы чагылган. Дастанны иҗат иткән кешеләрнең ни дәрәҗәдә халык язмышын дөрес күзаллаганын аңлый башлыйсың бу юлларны укыгач. Әйе, һәр уй-гамәлнең үсеш мөмкинлеге бар. Бүген халыкны талап, алдап иртәгә ирекле, бәхетле җәмгыять төзеп булмый. Кылганнарның җуелмас эзе, тәэсире кала. Рәхмәте йә каргышы, савабы йә каһәре кала. Үткәнне оныттырып була, онытып булмый. Болай уйлаганда, Субра ерауның күрәзәчелеге дә вакыйгаларның үсеш мөмкинлеген күрү, фәнни тел белән әйткәндә—экстраполяциягә бәйле.

Гомер юлында үсеш мөмкинлеген дөрес күзалларга өйрәнү генә кешеләрне төрле афәтләрдән саклап кала ала. Табигать булсын, җәмгыять булсын алар кеше тәэсиреннән, кешеләрнең кылган гамәлләреннән җимереләләр яки чәчәк аталар. Шуңа күрә бүген дә күрәзәлек һич тә онытылган шөгыль түгел. Аналитиклар, футурологлар киләчәкне күзаллауны (күрәзәлекне) фәнни нигездә алып барырга омтылалар. Алар да үз тешләре үтмәгәндә, борынгы юрамаларга, атаклы күрәзәчеләргә мөрәҗәгать итәләр.

Нәтиҗә ясап һич икеләнмичә әйтергә була, дастан вакытны үткәннән бүгенгегә һәм киләчәктән бүгенгегә ага торган мәңгелек елгасы рәвешендә тасвирлап күрсәтә. Бу фикер шундый эзлеклелек белән шигырь юлларына үрелгән, тыңлаучы өчен аның таныш һәм аңлаешлы икәнлеге бәхәссез. Вакыт турында шундый уй булу ул хыялый уйдырма яки нигезсез адашу түгел, ә вакытны тереклеккә, аның үсешенә бәйләп караудан килә. Бодай бөртеге үзендә үткәнен дә киләчәген дә йөрткән кебек, һәр тереклек үз эченә үткән һәм киләчәк вакытны кертеп яшергән.

XX гасырның иң зур ачышларыннан берсе—астрономик вакыт агышының тизлеккә бәйлелегенә төшенү булды. Исәпләүләрдән күренгәнчә, яктылык тизлегенә якын тизлектә хәрәкәт итүче җисемдәгеләр өчен вакыт сизелерлек әкренәя. Әгәр дә без шундый кораб төзеп, яктылыкка якын тизлектә хәрәкәт итсәк, корабта үткән 30—40 ел эчендә Җирдә меңнәрчә еллар үтәр иде. Әлеге ачыш галәм кинлегендә бара торган үзгәрешләрнең вакытын ачыклау катлаулы икәнлеген күрсәтә. Чагыштырмалылык теориясенә нигез салучы Альберт Эйнштейн, тереклеккә бәйле вакытның тагын да катлаулы икәнен искәртә һәм әлегә бернинди дә математик күзаллауларга бирешмәгәнен таный.

## Яса

АЛТЫН УРДА чорын тикшерүче галимнәр Чыңгыз ханның үзеннән калган идарә итү ысулларын теркәгән кануннар җыентыгы Яса сакланмаган дигән фикердә торалар. Бу, бәлки, чынлап та шулайдыр. Ул заманнардан соң күпме утлы-давыллы вакыйгалар илләр, халыклар өстеннән җимергеч өермә булып үткән. Һәр заман үз бөеген калкытырга омтылган. Бөекләр үзләрен тарих алдында тагын да биегрәк күрсәтү өчен, үткәндәгеләрнең эзләрен бутаганнар, кырып алганнар, һич булмаса, исемнәрен кара төскә буяп, халыклар күзеннән-күңеленнән яшергәннәр.

Әмма гасырлар буе яшәп килгән идарә итү ысулы эзсез югала алмый. Идарә итүнең ничек сакланганын аңлау өчен бүгенге көнгә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Халыкка, халык милкенә мөнәсәбәт, кануннар (законнар) үтәлеше дәүләтнең идарә итү ысуллары аша тормышка ашырыла. Безнең гомер Рәсәй дәүләтенең чираттагы тетрәнүле үзгәрешләр кичергән чорына туры килде. Коммунизм идеясе гамәлдән чыгарылып, җәмгыять демократик юлга басачак һәм шул җирлектә базар мөнәсәбәтләре алга сөреләчәк, дип игълан ителде. Артык нечкәлекләренә кермичә, кичә коммунизм байрагы астында яшәгән иске Рәсәйдә һәм базар мөнәсәбәтләренә кучүче яңа Рәсәйдә нәрсәләр үзгәрде соң дигән сорауга җавап эзләп карыйк. Иске Рәсәйдә кешенең милеккә хокукы юк дәрәҗәсендә иде. Халыкның күпчелеге хәерче һәм тамак туйдыру өчен урлашырга мәҗбүр булып яшәде. Фәкать партноменклатурага кергән яки аларга хезмәт иткән кешеләр генә, биләгән урындыкларына карап, милекле булдылар. Аларның да күбесе урлашты. Яңа Рәсәйдә халыкның күпчелеге—эшсез, акчасыз, милексез калды. Шуңа бу күпчелек өчен ике генә юл кала сыман—ачтан үлү, яки урлашу, талау, алдау, сату һәм сатылу. Партноменклатурадан яңа байларга әверелгәннәр урлашуның законлаштырылган юлларын гамәлгә куйдылар.

Иске Рәсәйдә номенклатура өчен бер закон, халык өчен аның икенчесе иде.

Яңа Рәсәйдә законны санга сугу бөтенләй бетте. Өстәгеләргә урлашу өчен нәрсә кулай, шуны закон дип игълан итеп яшәү башланды хәзер.

Иске Рәсәйдә халык сүзен тыңлаган булып кына кылану, чынлыкта партноменклатура диктатурасы идарә итә иде. Яңа Рәсәйдә хакимнәр халык барлыгын бөтенләй оныттылар. Куркыту, янау, алдау—идарәнең төп ысулына әйләнде. Сүз ирегe дә күз ирегенә әверелеп, кара халыкка шәрә бот күрсәтүгә кайтып калды.

Чагыштырудан күренгәнчә, яңача идарә итү ысулы барлыкка килмәде. Киресенчә, иске ысул үзенең бөтен әшәкелекләре белән чүплектә үскән шайтан таягы сыман әрсезләнеп яңа шартларда үсә һәм чәчәк ата башлады. Идарәдә яңа ысул барлыкка килсен өчен кеше мөнәсәбәтен үзгәртергә тиеш була. Бу инде башны яра торган иң каты һәм катлаулы сорау. Моңа җавап «базис и надстройка», «материя первична», шуңа башта экономиканы үзгәртергә кирәк, аннан кеше үзеннән-үзе үзгәрәчәк. Җавап та бар, әмма Рәсәй өчен бернинди чишелеш юк кебек. Профессор Әгъдәс Борһанов Рәсәйнең бәхетсезлеге үз халкын милектән мәхрүм итүдән килә дип исбат итә. Хезмәтләрендә милек һәм мөнәсәбәт арасындагы бәйләнешне тикшереп, милексез халыкның һәр очракта люмпен, һәрвакыт тәртипсез (жизнь копейка!), мохитны, дәүләтне һәм үз-үзен җимерергә әзер торганын күрсәтә.

Идарә итү ысулы мөнәсәбәт рәвешендә телдә, мәкаль-әйтемнәрдә, дастаннарда, халыкның тәртибендә үзенең сизелерлек эзен калдыра. «От тюрьмы и от сумы не зарекайся»,—ди урыс халык мәкале тормыштагы гаделсезлек һәм хәерчелекнең котылгысыз икәнен күреп. Мәкаль ялгышмый ул. Шуңа Ясаның эзен телебездән, халыкның холкыннан, дастаннардан эзләсәк, без дә ялгышмабыз.

Татар телендә дәүләт сүзе берничә мәгънәдә кулланыла һәм һәр мәгънәсе дә унай мөнәсәбәтне белдерә: дәүләт—ил, дәүләт—байлык, дәүләт—зурлау, ирләр исеме. Татар холкындагы дәүләт кушканны үтәргә тырышу да бик еракка, халыкның үзен хөрмәт итеп яшәткән дәүләткә булган мөнәсәбәтнең хәтер чагылышы дип танырга кирәктер. «Идегәй» дастанында илдәге мөнәсәбәт-тәртип түбәндәгечә сурәтләнә:

Ялгыз йөргән юлаучы
Ям юлында ял тапкан.
Юртса юлы киң булып,
Ятса җире киң булып,
Йорт-җир әман икән дә.

Бу юллар Яса буенча идарә итү ысулының халык милкен гадел яклауны гамәлгә куйганын күрсәтә.

Чыңгыз хан кешеләрне ике төргә аера торган булган. Берләре—яхшы кешеләр. Алар ышанычлы, ихлас, тугры, нык, малга кызыкмыйлар. Һәм җаннарын саклау өчен куркып бер-берсен һәм ватанны сатмыйлар. Икенчеләре—кабахәтләр. Кабахәтлекләрен түбәндәге сыйфатлар билгели: куркаклык, сатлык җанлык, хыянәтчеллек, хөсетлелек, алар тормыш мәгънәсен мал туплау һәм үз рәхәтлекләре турында гына кайгыртудан табалар. Бөек хан үз дәүләтен беренче төр кешеләргә таянып, шулар ярдәмендә күтәргән. Ә сатлык, мал өчен кеше җанын кыярга әзерләрне юк итү гадәтен дә хак дип санаган.

Дастан каһарманнарының үз-үзләрен тотышы, көрәш максаты, кылган гамәлләре ниндидер бер канунга туры китереп идеаллаштырылганын аңлау кыен түгел. Туктамыш үзенең Чыңгыз нәселеннән булуы белән масайса (Чыңгыздан булган затыма кол Кобогыл тиңәлмәс!), Идегәй, Нурадын кешене нәсел затлылыгы гына түгел, ә кылган гамәлләре, кешеләргә карата мөнәсәбәт затлылыгы билгеләгәнен искәртеп:

«Мин бер колың түгелмен, син дә Чыңгыз түгелсең»,—дип үзләренең бу дөньяда хаклары барлыгын дәгъвалыйлар. Дастан геройлары идеал итеп алган канун, әлбәттә, Чыңгыз ханның Ясасына бәйле. Бу сыйфатларны Яса тәрбияләгән. Дастанның һәр персонажы тормышларының иң катлаулы мизгелендә үзенең кылганын Ясага куеп, чагыштырып карый. Туктамыш Нурадынны үтертүдән курка:

Җисер хатын, ятим ул,
Аксак, гарип, ярлы, кол—
Шуларның бер шәре бар,—

чөнки Яса көчсезләрне үз канаты астына алып саклый. Куып тоткан дошманы Туктамышка Нурадын беренче булып кул күтәрми:

Яшен өлкән ир икән,
Син ат, кизәк синеке!—

ди. Ясаның өлкәннәрне хөрмәтләргә кушканын истә тотып гамәл кыла. Колчура карт илне җитәкләрлек ирләрне сагынып:

Ятимнәргә—яр булган,
Колчурага—дус булган,
Аты юкка—ат булган,
Чүлләгәнгә—су булган,
Адашканга—юл булган,
Ялгызга—ясак булган,
Җәяүгә—таяк булган,
Карны ачканга—тамак булган
Идегәй ир бар икән,—

дип Яса (Ясак) сүзен Дастанга чыгара. «Ялгызга—ясак»,—ди дастан һәм Яса нигезендә социаль яклауның нинди көчле һәм ышанычлы булуын күрсәтә. Өзектән аңлашылганча—яса, ясак сүзенең мәгънәсе—ныклык, таяныч, илгә, кешеләргә—яклау, ярдәм бирүне аңлата.

Закон язылу белән ул шундук таяныч була дигән сүз түгел әле. Күпме яхшы язылган законнар, карарлар кәгазьдә генә калалар. Ясаның төп аермасы—ул гамәлгә куелып, канун рәвешендә яшәп, халыклар тормышына кереп җуелмас эзен калдырып килгән. Чыңгыз хан даһиларга хас алдан сиземләү белән, Яса үтәлешен тәэмин итәрлек көч тапкан. Ул көчне хан үрнәк була алуда күргән. Өске катламнарның, ханның шәхсән үзенең халык каршында җаваплылыгында һәм үрнәк булуында. Мәкерле һәм рәхимсез Туктамыш хан үлем элмәгенә килеп эләккәч, иле турында үкенечле кайгырып:

Хан булып ни иткәнмен?
Халыгыма, илемә,
Өлге булган мырзамын,—

дип Ясаның катгый таләбен, ханның үрнәк булырга тиешле һәм мәҗбүр икәнлеген аяныч исенә төшерә. Шулай итеп, ярсулы, кыргый күренгән заман үз карынынннан яктылыкка илтә торган ныклы сукмаклар калдырган. Әгәр ир-хатын бер-берсенә терәк була алмаса, ата—улга, ана—кызга яхшы үрнәк күрсәтә алмаса, гаилә җимерелә. Түрәләр халык турында кайгыртмасалар, чын үрнәк була алмасалар, ил тиңелтеп ил җимерелә.

Бүгенге Көнбатыш демократиясе таләпләре дә Чыңгыз хан Ясасына эчке мәгънә ягыннан әллә ни үзгәреш кертмәгән. Демократия нигезендә милекне тану өчен дәүләтнең җаваплылыгын булдыру, һөнәри осталыкларны үстерү, камилләштерү, саклау, яңа буынга тапшыру, сүз иреге, диннәр иреге, гаилә иминлеге турында кайгырту кебек Яса таләпләре җәйрәп ята.

«Идегәй» дастаны да Яса таләпләрен шигъри юлларга үреп, үз чоры каһарманнарының язмышлары аша шул бөек канун сүзен безгә житкергән.

Кыскасы, «Идегәй» дастаны данлы вә шанлы үткәнебезнең рәүшан көзгесе ул!

*Сәнгать*

# МОҢНАР ҺӘМ УЙЛАР...

КОМПОЗИТОР ШАМИЛ ШӘРИФУЛЛИНГА 50 ЯШЬ

Музыкант булмаган кешегә башваткыч ребус кебек күренгән билгеләр—ноталар үтеп чыкмаслык карурман, урман-чытырман, яисә күгәрчен җибәрсәң дә чүпләп бетерә алмаслык булып сибелгән йөзләгән-меңләгән мәрҗәннәр, алай гына да түгел, шул мәрҗәннәрдән чигелгән гүзәл калфак кашыдыр кебек тә тоелырга мөмкин. Уйнаучы, шул мәрҗәннәргә—ноталарга карап, уен коралында уйнап җибәрсә, кайсы кечерәк, кайсы зуррак, кайсы кара, ә кайберләре ак килеш калдырылган түгәрәкләрнең сихри музыкаль авазларны белдерүче билгеләр икәнлеген аңлыйсың. Кара мәрҗән, ак мәрҗән. Татар кешесе музыка дөньясын шулай сихри итеп кабул итә...

Композитор Шамил Шәрифуллинның балет, симфония, оратория һәм башка әсәрләре язылган партитура битләрен ачкалап карап утырганда менә шундый уйлар туды; әле шунысы да бар, минем кебек музыкант булмаган кеше өчен генә түгел, ә беркадәр музыкаль белеме булган, шул өлкәдә эшләп йөргән кеше өчен дә урман-чытырман ул катлаулы әсәрнең партитурасы, ә Шамил Шәрифуллин күбрәк нәкъ менә катлаулы булган симфоник музыка өлкәсендә иҗат итә. Бу уңайдан бер кызыклы «деталь»не күрсәтеп үтәсе килә: мәсәлән, композиторның тәмамланып килә торган «Йосыф-Зөләйха» балеты партитурасының бит исәбе инде ... биш йөздән узып бара икән. Менә шундый мәрҗәннәр-сәйләннәр...



Шамил Шәрифуллин чын, һәм бик тә үзенчәлекле композитор буларак, 1975 елда үзенең «Мөнәҗәтләр» исемле хор өчен язылган концерты белән аваз салды. Бу халкнең «мөнәҗәтләр» дигән сүзне әйтергә дә ярамаган елларда булганлыгын искә төшерсәк, без авторның гражданлык батырлыгын күрербез. Бу батырлыкның кыйммәте тагын шунда ки, халыкның рухи байлыгына новаторларча якын килеп, моңа хәтле без ишетмәгән-белмәгән, әмма тарих төпкелләрендә, үткән чорлар тирәнлегендә яткан авазларны яңадан тудыруында, катлаулы бизәкле монолит олы полотно хасил итүендә. Әсәрне Казан дәүләт консерваториясенең Семен Казачков җитәкчелегендәге хоры башкарды. Бу коллектив турында төрле кешенең төрлечә фикере булырга мөмкин, әмма шунысы да мәгълүм: бу хор—үзенең олы хезмәте белән классик һәм киң полотнолы милли әсәрләрне башкарырга хакы бар дигән статусны яулап алган хор ул. Хор Казанда, Россиянең көчле музыкаль үзәкләре булган Мәскәү, Петербург һәм башка шәһәрләрендә, чит илләрдә дә концертлар бирә, ә «Мөнәҗәтләр»нең бу коллектив репертуарыннан төшеп калганы юк әле.

1976 елның көзендә «Мөнәҗәтләр» киң татар җәмәгатьчелеге өчен язучыларның Тукай исемендәге клубында шул ук хор тарафыннан башкарылды. Бу концертка килгән кайбер иҗатчы алыпларыбызның исемнәрен генә атап китү дә күп нәрсә аңлата. Нәкый Исәнбәт, Бакый Урманче, Мөхәммәт Гайнуллин, Сибгат Хәким, Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов, Әбрар Кәримуллин һәм башка бик күп атаклы язучыларыбыз, композитор-

ларыбыз, артистларыбыз һәм, гомумән, бик күп музыка сөючеләребез белән Тукай клубы шыгрым тулы иде. Катлаулы биеклеккә, сихрилеккә, даһилеккә күтәрелеп иҗат ителгән һәм башкарылган, йөрәкләрдә яшертен генә вулкан булып кайнап яткан музыкаль көчнең шаулап бәреп чыгуын тыңлаучылар көчле кул чабулар, котлаулар, «афәриннәр» белән каршы алды; бу хәл халкыбыз борынгы музыкаль байлыгының ирекккә чыгуы кебек кабул ителде. Хөрлеккә, азатлыкка, үткән бөеклекне аңлауга бер зур адым иде бу. Әнә шундый чыгышлардан соң мөнәҗәт жанры турында авыз тутырып сөйләү гадәткә кереп китте; музыка белгечләре дә бу юнәлештә ачылыбрак эшли башладылар.

Шамил Шәрифуллинның икенче бер әсәреннән—инструменталь триосының (автор аны әбисенә багышлый) премьерасы шаһиты да булырга туры килгән иде. И. В. Әүхәдиев исемендәге музыка училищесенең концерт залы, тыңлаучылар шыгрым тулы. Бусында тамашачылар арасында Фасил Әхмәтовның, Ренат Еникеевның, Мирсәет Яруллинның, яшь композиторлардан Шамил Тимербулатовның, Разия Еникееваның, Фәрит Шәрифуллинның һәм башка урта буын композиторларның, консерватория һәм училище студентларының булуы күзгә бәрелеп тора иде. «Трио»ны бик тә билгеле башкаручылардан—Әлфия Бурнашева (фортепиано), Гөлфирә Сафина (виолончель) һәм Фәридә Закиржановадан (скрипкә) торган состав уйнады. Ул кичне залда тыңлаучыларның күңелләрен актарып ташлап, кара урманнарда йөрткәндәй алгысытып, кояшлы аланнарга алып чыгып, шатландырып, тагын да диңгез төпкелләренә чумдырып, сихри моң яңгырады; ниһаять, сулыш бетә дигәндә генә аннан тартып алып, әкрен генә соңгы аккорд сүнде... Тыңлаучылар бермәл айный алмыйча тордылар; залда (беркем юк диярсең!) берничә дәкыйка секундка тирән тынлык хөкем итеп алды; аннан,—әссе мунча ташына кайнар су сиптеләрмени,—өермәдәй кул чабулар, алкышлар башланды... Бу—олуг сәнгатьнең тантана итүе иде.

Мәгълүм ки, һәрбер иҗат өлкәсенең үзенә генә хас үзенчәлекләре бар: язучы, әйтик, иҗат җимешен китап нәшер итеп укучысына ирештерергә тырыша, композиторга исә хезмәтен күрсәтү өчен музыкантлар һәм тыңлаучылар кирәк. Шул рәвешчә, 1983 елда тамашачы-тыңлаучылар Казан дәүләт консерваториясенең зур концертлар залына җыелды, бу юлы Шамил Шәрифуллинның «Җыен» исемле әсәре—зур симфоник оркестр өчен язылган концерты башкарылачак иде. Гадәттәгечә, авторның иҗат принципларына хас булганча, әсәр музыкаль теленең яңалыклары, новаторлык рухы белән сугарылган иде; халык җыенының—сабан туенының гүзәл бизәкләре, картиналары музыкаль авазлар белән шундый да оста тасвирланган ки, әйтерсең лә син кешеләр һәм урындык-креслолар белән шыгрым залда түгел, чәчәкле болында таллар-куаклар, зифа каеннар арасында туганнарың, якыннарың белән тамаша карап-тыңлап утырасың... Соңыннан бу «Җыен» концерты турында да матбугатта матур-матур фикерләр әйтелде.



*Шамил Шәрифуллин студентлар арасында.*

Шамил Шәрифуллин иҗаты турында сүз алып барганда, аның җыр өлкәсендәге уңышларына күз йомып үтсәк, бу гөнаһ булыр иде. Ул җыр өлкәсенә дә яңалык алып килгән композитор. Биредә композиторның бу өлкәдә дә янәча музыкаль «телгә» ия булуын ассызыклап билгеләп үткән хәлдә, башка бернәрсәне дә искә алып китәсе килә. Сүз «Сабан туе» һәм «Син биергә мине чакыр» җырлары хакында бара. Шамил Шәрифуллинның «Сабан туе» җыры туганчы, безнең атаклы бу бәйрәмебез турында халыкныкы булып канунлашкан, «Сабан туе хезмәт туе, бәхет һәм шатлык туе», дип башланып китә торган җырларыбыз гына бар иде кебек. Хикмәти Хода, композиторның сабан туе хакында язылган җырыннан соң, бу темага байтак яңа җырлар туды. Бу яңа җырлар, бигрәк тә сабан туе бәйрәме көннәрендә, бер-берсе белән ярышып яңгырыйлар хәзер. «Син биергә мине чакыр» көе белән дә шундыйрак хәл булды. Моңа чаклы күрелмәгәнчә, биергә чакырган төрле-төрле җырлар барлыкка килде, хәтта бии белмәгән кешеләр дә биергә өндәлә, чакырыла башлады, чынлап та, халык әйткәнчә—биючегә сүз әйтмәгез, бии-бии остара.

Сибгат ага Хәким Шамил Шәрифуллинның үзенең шигырьләренә җырлар иҗат итүеннән бик канәгать иде. Атаклы шагыйребезнең «Йөгерә чәчәкләр» исемле шигыренә язылган лирик-романтик характердагы җыр бөтенләй сүрелгән күңелгә дә яшәү дәрте өрерлек көчкә ия, ул яшәү учагын кабызырлык өметләр уята ала. «Әйлән-бәйлән» көенә дә шагыйрь югары бәһа бирде. Кешеләрне бер-берсенә карата игътибарлылыкка, мөлаемлеккә, дусларча бердәмлеккә чакырган бу җырларны безнең җирлектәге бүгенге адәм баласына ишеткәләп тору бер дә зыянга булмас иде, югыйсә. Татар дәүләт Җыр һәм бию ансамбле солисткасы Флүзә Җәләлова «Сөембикә» журналында әйтеп үткәнчә, хәзер күбрәк «кан саркып торган яралы җырлар яңгырый... җырда сер калмады».

Композиторның шагыйрь Равил Фәйзуллин шигыренә иҗат иткән «Иясез шатлык» җыры да аерым игътибарга лаек. Бу җыр бик тә үзенчәлекле тавышка ия булган Регина Сәйфи башкаруында күңелләргә тирән эз салды, аның трагик яңгырашлы тавышы йөрәкне уеп-уеп ала. Шагыйрь белән композитор арасындагы иҗади дуслык нәтиҗәсендә туган тагын башка җырлар, әсәрләр дә, үзенең башкаручысын табып, тыңлаучыга барып ирешер әле дип ышанасы килә.

Композиторның «Яфрак төшкән инде юлга» исемле әсәрен алыйк. Бу көйне үзәкне өзәрлек моңсу булганы өчен генә түгел, ә бәлки якты моңсулык, яктылык биргәне өчен, гүяки көзге ак каеннар арасында, кул болгап, канат җилпеп йөрүче көзге якты рухы өчен дә яраталар.



*Шамил Шәрифуллин (уңда) композитор Алмаз Монасыйпов белән.*

Гомумән, Шамил Шәрифуллин иҗатына контрастлар хас. Фәлсәфи-дини эчтәлекле «Мөнәҗәтләр» циклыннан соң ул яп-якты, үтә дә нәфис, мәхәббәт лирикасы белән сугарылган «Авыл көйләре»н халыкка тапшырды. Бу юлы да, иң беренче булып, җырларны Казан дәүләт консерваториясе хоры башкарды, хормейстры Нурия Җураева иде. «Авыл көйләре» дә, «Мөнәҗәтләр» кебек үк, Татарстан радиосы фондына язып алынды.

Шулай, Шамил Шәрифуллин иҗаты бер төрле үлчәү калыбына гына сыймый. Шәхес буларак, ул тирән белемгә һәм бай энциклопедик мәгълүматларга ия. Мәскәүдә аспирантурада укыган елларында ана Америка индеецларының халык җырларын тыңларга туры килә. Тарихи-географик хата аркасында индеецлар дигән гомум исем белән аталып йөрүче, чынында һәрбер кабиләнең үз атамасы булган (науа, мая, кичуа һ. б.) халыкларның көйләре төрки халыклар

көйләренә бик якын булуына ул шунда игътибар итә. Ә кайбер көйләре исә хәтта ки «Мөхәммәдия» китабы көйләре белән бөтенләй дә аваздаш булып, җырларының сүзләре арасыннан «ана», «ата», «тау», «ак», «атау», «алып» һ. б. сүзләр аңлашылып тора икән. Менә шуннан соң композитор бу халыклар турында мәгълүматлар эзли башлый. «Латин Америкасы» дигән журналлардан һәм башка чыганаклардан шактый кызыклы материаллар табыла. Татар халкының «Чикамыш» исемле (җыр «Чикамыш» дип калыпланса да, сүз «чыгу» тамырыннан, кияүгә чыгу мәгънәсендә) туй җыры текстына бик нык аваздаш җырларын да таба. Сүз уңаенда тагын бер нәрсәне искәртеп үтик. Композитор Шамил Шәрифуллин татар халкының бик борынгы чорындагы яшәеш-тормышына, бигрәк тә музыкага караган хәзинәләрне, үзе табарга, алар турында академик дәрәҗәдә мәгълүмат булдырырга тырышучан кеше. Һәм... төрки-татар белән америка индеецлары музыкасының уртаклыгын ачу белән рухланып, «Чәчәк турында җыр» исемле балет музыкасы яза. Ана менә шундый «исәрлек», музыкага менә шундый бирелгәнлек хас. Соңыннан, академик Әбрар ага Кәримуллин белән танышып, үзенең фикерләре белән уртаклашкач, язылган әсәре турында да хәбәрләшкәч, бу өлкәдә (Америка индеецлары һәм төрки-татар уртаклыгы мәсьәләсендә) шактый эзләнүләр алып барырга өлгергән галим йөзендә үзенең теләктәшен һәм фикердәшен таба, тик... балет партитурасы композиторның өстәл тартмасында кала бирә. Балет кадәр балетны безнең шартларда кузгатып җибәрү, сәхнәгә куйдыру—ай-һай! авыр шул. Чөнки үзебезнеке булып саналган, Муса Җәлил исемен йөрткән опера һәм балет театрыбыз җитәкчелеге гомумән дә безнең композиторларның әсәрләрен сәхнәләштерү турында мәсьәлә кузгалгач, калын бронялы битараф калканга әйләнә. Шамил Шәрифуллинның башкару өчен чират көтеп яткан башка әсәрләре дә байтак. Моның сәбәбе артык серле түгел, бүгенге көннәрдә хәтта бер җырны халыкка чыгару өчен дә автордан (!) шактый күләмдә акча таләп ителәэ. Менә шундый безнең өчен аңлашылмаган мәсьәлә...




*Шамил Шәрифуллин фольклор экспедициясе вакытында.*

Шамил Шәрифуллин контрастлар белән эш итәргә яратучан шәхес, дигән идек. Композитор хәзерге музыка-көйләребезнең болгар бабайларыбыздан калган тамырларын шактый өйрәнгән кеше. Ул, магнитофон күтәреп, авыл-шәһәрләр буенча йөреп, халык авыз иҗатын җыеп та, теоретик яктан эшкәртеп тә, шул чордагы музыкаль картинаны күзалларга тырышучы галим-композиторларның берсе. Болгар чорындагы музыка үлчәм-метрикасын хәзергедән, татар-кытай-япон яңгырашлы үлчәмнән шактый аермалы булган дип саный ул. Әйтик, бер генә мисал. Ул әнием ягыннан туганым—туганый апам, инде мәрхүмә Мәгүзәдән (Болгар ягы кешесе) язып алган мөнәҗәтләргә хәзерге Болгариянең борынгы халык җырлары үлчәмнәренең туры килүен үзе шул илгә барып өйрәнеп кайта. Шул өйрәнүләр, экспедицияләр нәтиҗәсе буларак, «Болгар моңнары» дигән ун кисәктән торган цикл туа. Бу көйләр, әгәр музыка турында шулай әйтергә яраса, орфия кебек үтә күренмәле нәфисләр, гүзәлләр, күңелләрне бизи, сафландыра, ерак-еракларга да һәм үз күңелен төпкелләренә дә чакыручылар дияр идем. «Болгар моңнары» да Татарстан радиосы аша эфирда яңгырый.

Агымсу бер урында тормый, ага да ага ул, ә иҗатны мин агымсу белән дә чагыштырырга мөмкин дип саныйм; шул рәвешчә композитор Шамил Шәрифуллин да хәрәкәттә—иҗатта. Менә ул инде берничә ел, тирләп-пешеп, яңа балет—«Йосыф-

Зөләйха» әсәрен яза. Мина әсәрнен кайбер фрагментларын тынлап карау бәхете элэкте. Искиткеч аһәнңәргә бай музыка; биредә Синай атавы, Мисыр һәм Мавритания һ. б. экияти илләрнен сихри музыкасын, татар-төрки пентатоникасын—берсен дә чит курмисен: бер сүз белән әйткәндә, әсәр катлаулы музыкаль синтезга ия. Бөек шагыйребез Кол Гали, эзләнүчеләрнен фикеренчә, дүрт мен еллар чамасы вакыт ераклыгындагы коньяк илләрендә экияти дә, чын да булган һәм жетелеге белән илаһи рәссамнын бик зур форматтагы фантастик картиналары сыман, күнелне үзенә магниттай тартып торган вакыйгаларга шигъри сүз белән мөрәжәгать иткән шикелле, балет та шул жирлектәге музыкаль культураны искә алып ижат ителә...




Әйе, чын ижатчынын ижат колачы кин, күп тармаклы. Шамил Шәрифуллиннын Казан дәүләт консерваториясендә, музыка мәктәпләрендә педагоглык эшчәнлеген истә тоткан хәлдә (танылган композитор Риф Гатауллин, композитор һәм дирижер Рөстәм Абязов, яшь композитор Илһам Байтирәк анын укучылары), музыкантыбыз ижатынын тагын бер тармагына игътибарны юнәлтәсе килә. Сүз—композиторнын китап язып, аны бастырып чыгару эшчәнлеге хакында. Композиторнын жырлары тупланган беренче китабы 1984 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан иде. Инде бернича дистә еллар буе Шамил Шәрифуллин халык жырларын жыю, нотага салу, эшкәртү, анлатмалар, искәрмәләр язу һәм матбугатка яна китаплар әзерләү эшләре белән даими шөгыльләнә. Шуларнын берсе—тугыз йөз битле «Урта Идел буе татарларынын жырлап уку традициясе» исемле кульязмасы 1992 елда ук нәшриятка тапшырылган... Әмма...

Шулай да, Ш. Шәрифуллин кул кушырып утыручылардан түгел, 1994 елда «Борынгы халык жырлары» дигән икенче бер, юка булса да, зур форматлы китап дөнья күрә. «Мөхәммәдия» китабы көйләре, «Сак-Сок» бәете, мөнәжәтләрнен кайберләренен көйләре, «Йосыф китабы» көе, «Шәһри Болгар бәете» көйләрен эченә алган китап Казан дәүләт консерваториясе белән бергәләп чыгарылган. Ә менә «Сак-Сок» бәетенен тулы нотациясе матур рәсемнәр белән бизәлеп, Татарстан китап нәшриятында күптән түгел генә дөнья күрде. Композиторнын «Татар халык музыкасы. Балалар музыка мәктәпләре өчен программа» китабы да аерым әйтеп, тукталып китүне таләп итә. Гомумән, татар мәктәпләре, музыка белән кызыксынучы һәркем өчен дә бер хәзинә дип атап була ул программаны. Композиторнын шундый хезмәт куюын чып-чын патриотизм дип исәпләргә кирәктер, чөнки мона чаклы андый кин колачлы программанын төзелгәне юк иде әле. Программадагы бернича теманы гына күрсәтеп үтик. «... Татар халык музыкасынын үзенчәлекләре. Анын башка халыклар музыкасыннан аермасы. Милли мон, ритм, формалар формалашунын озакка сузылган тарихи юлы. Халыкнын аеруча яраткан образлары, темалары һәм сюжетлары. Кешене тумыштан чолгап алган жанрлар. Азан һәм мәжбүри гыйбәдәт догалары. Бишек жырлары. Практик юнәлешле уен жырлары (такмаклар, әйтемнәр һ. б.). Мәктәп жырлары. Шәкерт жырлары. Коръәнне көйләп уку. Хезмәткә бәйле музыкаль фольклор. Яшьләрнен уен һәм әйлән-бәйлән жырлары. Балаларнын күмәк музыкаль уеннары. Татар халык музыка уен кораллары. Халык бәйрәмнәре. Татар халкынын эпик лирикасы... һ. б., һ. б. әнә шундыйлардан.

Хәзерге вакытта композитор бу программа буенча дүрт китаптан торган «Татар халык музыкасы антологиясе»н төзи. Антологиянен беренче китабы 2000 елда нәшриятта басылып чыгачак дип көтелә. Башына төшсә, башмакчы буласын, ди безнен халык,

алда атап кителгән, дөнья күргән китаплар өчен һәм балет өстендә эшләү мәшәкатьләренен кайберләрен күтәрешер, ярдәмләшер өчен дә спонсорлар эзләргә һәм табарга туры килә авторга. Ул аларга чиксез рәхмәтле. Менә ул кешеләр: Габдрәшит Сәхипгәрәй улы Юргин (Казан), Камил Әсфәндияров (Алабуга, төзүче), Латыйпов Зиннур Йәмги улы (Казан), Айдар Зөфәр улы Шәрәфетдинов (Казан).

Рәхмәтләр әйтүне искә төшердек икән, Шамил Шәрифуллин рәхмәтләрнен ин-ин зурларын үзенен укытучыларына һәрдаим ирештереп, әйтә килә, үзенен алар алдындагы бурычын талантлы иҗат нәтиҗәләре белән үтәргә, түләргә тырыша. Композиторнын әйтүе буенча, менә анын остазлары-укытучылары: беренчесе, кызганыч ки, инде мәрхүм, бөек композиторыбыз Нәҗип Җиһанов; икенчесе, бик тә үзенчәлекле олы талант иясе Алмаз Монасыйпов; өченчесе, әле күптән түгел генә вафат булган күренекле композитор («Татар рапсодиясе»нен авторы) һәм педагог Альберт Леман.

Җин сызганып, көнен—төнгә, төнен—иртәгә ялгап, тирләп-пешеп, сәламәтлеге шактый чамалы хәлдә иҗат итүче композиторнын әсәрләре кин халык массасына барып ирешә, ирешеп тора дип авыз тутырып әйтеп булмый әле. Радиодан анын әсәрләре сирәк янгырый, өстәвенә, бүгенге көннәрдә безнен радионын, туры элемтәләр үткәрү сәбәпле, менә-менә тематик зуррак тапшырулар башланып китәргә тиеш кебек сәгатьләрдә эшләү вакыты бетә, эфир вакыты бүтән каналларга күчә... Бүгенге көн татар телевидениесе турында сүз алып барганда, житди музыкаль һәм интеллектуаль тапшырулар булу мөмкинчелеге хакында уйларга да урын калмады бугай инде. Башка илләрнен, башка халыкларнын дистәләгән телепрограммалары гөрләп эшләп тору сәбәпле, аларга нинди тапшыру карыйсы килсә, шуны сайлау мөмкинчелеге бар; безгә исә андый сайлану мөмкин булмагач, шул сәгать ярым вакытны этик-эстетик таләпләрдән чыгып сарыф итәсе лә кана... Дөресен әйткәндә, хәшәрәт дәрәҗәсендәге фильмнар безгә дә мул килеп керә. Ин аянычы—заманга иярәбез дигән булып, татар тапшырулары бөтенләй кысылып бетте, ә бит татар үзенен тарихи трагик язмышын аралап, һәртөрле замана шаукымнарына бирешмәү сәбәпле генә исән-сау калган...

Авторыбызга әйләнеп кайтып, шуны да әйтергә ярыйдыр: әсәрләренен сирәгрәк янгыравы автор характерынын шактый үзенчәлекле булуы (чын иҗатчынын кайсынын жайлы-майлы холкы булганы бар?), үзгәрмичә бертөрле калуы, кайчагында хәтта «шырпылы» булуы аркасында туган анлашылмаучылык сәбәпләре белән дә бәйледер. Тик, барыбер, талантны томалап булмый, чын әсәрләр үзенә юл яра. Музыка мәктәпләрендә, консерваториядә, педуниверситетнын музыка белеме факультетында, культура академиясендә, музыка училищеларында Шамил Шәрифуллиннын төрле характердагы вокал һәм инструменталь әсәрләре даими өйрәнелә. Димәк, традицияләр-чылбырлар бәйләме өзелми, дәвам итә. Сүзебезнен сонында композиторнын әле күптән түгел генә узган 50 яшьлек юбилее белән котлап, ана унышлар, саулык-сәламәтлек, якты, сүрелмәс иҗат офыклары теләп, Сибгат ага Хәкимнен композитор жыр иҗат иткән шигырь юлларын искә төшерәсе килә:

Йөгерә чәчәкләр офыкка,
Офыккача туп-туры.
Агыла аларнын артыннан
Хисләремнен дулкыны.

Композиторнын хисләре саекмас, иҗат дәрте үсәр-үрләр, офыклар артыннан тагын да яна офыкларга ирешер, дөньяга бертуктаусыз аваз салып, ана үзенен иҗат утын сирпеп торыр дип ышанасы килә.

... Бер төшәм дә күтәреләм кабат...
Дөньяга салмасан кат-кат набат,
Хәтере кыска, күнеле чуп-чуар,
Асыл гөлне сытып, юкса, чүп туар.

**Бикә РӘХИМОВА.**

Китап күзәтү

# ЯЗМЫШЛАРЫБЫЗ УРТАК

«Татар милләте төрле-яры сибелгән...»—еш кына әнә шундый сүзләрне ишетергә туры килә. Әйе, «Сибелә чәчәк» җырындагыча итеп әйтсәк, «Сибелә чәчәк, җилләр искәндә...» Ә безнең милләт язмышында җилләр генә түгел, гарасатлы давыллар да гел булып торган шул. Әмма «сибелгән» сүзе күбрәк чит-ят төбәкләргә китеп, яңа нигез корганнарга туры киләдер, ә Рәсәйнең күп кенә почмакларында яшәүче татарлар турында «бүлгәләнгән» дип әйтү дөресрәк булыр. Кайчандыр аларның шанлы Болгар дәүләте эчендә бергәбергә яшәгән заманнары булган лабаса. Хәлбуки, тарихка күз салсак, хәзерге вакытта Татарстаннан читтә саналган һәм Идел буе, Урал якларындагы татар-мишәр, татар-типтәр туганнарыбызның тарихи үз җирләрендә тамырланган хәлдә икәнлекләрен күрәбез.




Түбән Новгород өлкәсендәге Кызыл Октябрь, Сергач, Пильнә, Сеченов, Спасс һәм башка районнарында да күпчелек җирле халык—татар-мишәрләр көн күрә. Татарстаннан читтә булуга карамастан, үз ана телләрен, гореф-гадәтләрен, диннәрен әлегәчә саклап калган милләттәшләребез турында галимнәребез азмы-күпме язгалап торсалар да, әлегә мондый хезмәтләргә кытлык юк дип әйтә алмыйбыз. Үз туганнарыбызның тарихын, узганын вә бүгенгесен белү бик тә фарыз гамәл бит югыйсә.

Шул яктан караганда, «Нижполиграф» нәшриятында 5 мең данә итеп чыгарылган «Нижгар татарлары» («Нижегородские татары») дигән китап—кыйммәтле чыганак. Аның авторы—тарих фәннәре кандидаты, Россиянең атказанган укытучысы Мансур Зәки улы Хафизов шул төбәктә туып-үскән кеше. Без аны әлегә кадәр татар төбәкләренең тарихына караган мәкаләләр, очерклар авторы буларак белә идек. Инде менә ул әлеге хезмәтләрен бергә туплап, китап итеп дөньяга чыгарган.

Китапта Новгород өлкәсендәге татар авыллары мисалында бу як халкының Октябрь инкыйлабына чаклы һәм аннан соңгы чордагы сикәлтәле юлы, этник яктан формалашуы, бердәм татар милләте булып формалашудагы роле, Казан татарлары белән үзара бәйләнышлары турында бәян ителә. Автор үзенең хезмәтендә җирле архив материалларына, М. З.Зәкиев, А. Х. Халиков, Р. Г. Фәхретдинов, Ф. М. Хисамова, Ә. Г. Кәримуллин һәм башка галимнәрнең фикерләренә таянып эш итә, үзенчә нәтиҗәләр ясый. Биредәге очеркларда җирсезлектән, фәкыйрьлектән интеккән татар-мишәр агай-энеләрнең Октябрь инкыйлабын ачык күңел белән каршылавы, ләкин тиздән, яңа властьның аз санлы халыкларга, аларның диненә, гореф-гадәтләренә кырын каравын күреп, аннан суынуы, күп очракларда ана буйсынмавы нәтиҗәсендә килеп чыккан кискен конфликтлар турында әтрафлы итеп язылган. «Мәсәлән, ди автор, Петрякс волостеның 1926 елда булган съездында үзен бирегә җибәргән 300 сайлаучы исеменнән Исхак Хәйретди-

нов дигән делегат болай сөйли:

—Гражданнар! Совет власте безне патша власте кебек үк изә. Без докладчыдан конкрет җавап таләп итәбез: ни өчен мәктәпләрдә дин дәресләрен укыту тыела? Без бу хакта соңгы тапкыр сорыйбыз, әгәр бу юлы да отказ алсак...

Аны башка делегатлар да хупладылар. Красный Островтан Хафиз Сабитов бөтен халыкны дулкынландырган, борчыган әлеге мәсьәләне съездның көн тәртибенә кертүне таләп итте...»

Октябрь инкыйлабына хәтле татар авылларындагы үзара тату гына яшәгән халыкның большевиклар хакимияте вакытында сыйныфларга аерылуы, дошманлашуы, шул сәбәпле урта хәлле крестьяннарны да «кулак» мөһере белән тамгалап, сөргеннәргә сөрү өчен иләмсез җирлек барлыкка килүе турында ачынып яза автор. Бу урында татар халкының сөекле җырчысы Рәшит Ваһапов туган Актук авылындагы ямьсез күренешләр дә телгә алына. Ә бит шул елларда аның әтисен дә мулла булганы өчен кулга алганнар, хәләл көче белән тапкан барлык малын конфискациялəгәннәр...

Революциядән соң татар крестьяннары аеруча җык күрә. Урыс агайлары үзләренең чиркәү җирләрен бүлеп алганда татарлар сакал сыпырып кала. Чөнки мәчетләрнең җире юк. Ә хөкүмәткә икмәк тапшыру планы арткаңнан арта бара. Үз теләгең белән «артык» икмәгеңне илтеп бирмәсәң, мылтыклы комиссарлар талап алып китәләр. Җирсезлектән зарланганнарга әйтәләр: «Әнә, кулак күршеңнең, мулла-мунтагайның җирен талап алыгыз!»—диләр. Әле күңеленнән иман нуры чыгып бетмәгән татар коммунистлары халыкны бу эштән тыеп тора. Ошбу гамәлгә бармас өчен күбесе партиядән кире чыгу ягын карый. Шундый хәлне истә тотып булса кирәк, 1928 елда Сталин «авылдагы сыйнфый аерымлыкны танымаучы һәм кулаклар белән әчелешле булырга теләмәүче элементларны» каты тәнкыйтьләп чыга. «Авыл җирендә кем бөтенесенә—байларга да, ярлыларга да ошый торган сәясәт алып барырга уйлый, ул марксист түгел, ә дурак»,—дип «акыл бирә» Халыклар атасы. Шундый күрсәтмәләрдән соң, авылдагы «сәнәктән көрәк» булган түрәләрнең урта хәлле, иң тырыш крестьяннарны да, хәләл кул көче белән көн күрүче дин әһелләрен дә «кулак» исемлегенә кертүләренә гаҗәпләнәсе юк...

Әнә шундый башбаштаклыклар Түбән Новгород губернасы, Сергач өязе (хәзерге Кызыл Октябрь районы) Семочка авылы крестьяннарының күтәрелешенә һәм күпләгән кешенең каны коелуга, җаны кыелуга сәбәп була. Бу турыда Мансур Хафизов үзенең «Татар авылындагы фаҗига» («Трагедия в татарской деревне») исемле икенче китабында бик тәфсилләп яза. *(Нижний Новгород, 1999).*

Кыскасы, Мансур Хафизовның Нижгар татарлары турындагы тарихи очеркларын укып чыккач, безнең халыкның язмышы кайда да бер, уртак язмыш икән шул, дип уфтанып куясың. Уртак булмыйни?! Татар мәдәниятына Рәшит Ваһапов, Хәйдәр Бигичев, Рамил Курамшин кебек җырчы артистларны, Кави Нәҗми кебек күренекле язучыларны, Лотфулла Фәттахов кебек талантлы рәссамнарны биргән Нижгар яклары бит ул! Хәлбуки, ошбу мәҗмуга Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез тормышындагы бик гыйбрәтле тарихи сәхифәләрне ачып бирә, үзгәртеп корулар чорында бүгенге авылда узганнарның аянычлы хаталарын кабатламаска өнди.

**Шамил МАННАПОВ**

*Akademik Yaxya Abdullinğa 80 yəş*

# MİLLƏTKƏ XEZMƏT YULINDA

Tarixta keşe ğəmere mizgel genə. Keşelek barlıqqa kilgənnən birle inde bu Cirdə niçəmə-niçə buın alışınğan. Küpme illər, dəwlətlər, xalıqlar barlıqqa kilgən, alar üz çorlarında tirən ez, tarix bitlərendə üz səxifələren qaldırğan. Ləkin tərle tarixi səbəplər arqasında alarnın, kübese tarqalğan, buysındırılğan, başqa illər, xalıqlar eçendə erep yuğalğan. Əmma keşelek, yəşəyeş bertuqtausız üzgəreştə. Şul üseş belən bergə bəyləneştə hər çor üz tarixın yaza, üzençə yaza, üzenə kirək bulğança yaza. Əmma buysındırılğan, qol itelgən dəwlətlərnen, xalıqlarnın ütkən tarixları, mədəniətlərə yuq itelgən, annan sonğı çorları inde xakim dəwlətnen, millətnen mənfəğətlərennən çığıp yazılğan həm bu xəl ğasırlar buyına şulay dəwam itkən. Şulay da qayçandır üzenen məstəqil dəwlətle, yuğarı mədəniətle xalıq bulğanın onıtıp beterməgən tatar xalqı XIX ğasır axırına kilep citkəndə, üzenen şul xəle belən kileşep yəşəüdən tuqtıy. Tatar məğrifətçelege, cəditçelek xərəkəte barlıqqa kilə, uqu-uqıtu sistemasında həm dini eşlərdə reformatorlıq xərəkəte kin cəyelə. Monı berençelərdən bulıp Ğ. Qursawi, Ş. Mərcani, X. Fəyezxanof, K. Nasıyri, Ş. Kültəsi, İ. Gasprinskilar başlap cibərə, alarnın eşen Riza Fəxretdinef, Fatix Kərimi, Ğalimcan Barudi, Musa Bigief h. b. dəwam itə. XX ğasır başında isə tatar milli-azatlıq xərəkəte inde zur keçkə əylənə, tatar xalqı milli üseş yulında yana basqıçka kütərelü əçen keçle talpınış yasıy. Qızğanıçka qarşı, Oktəbr inqıylabı bu milli kütəreleşne həm anın inde yaulanğan nəticələren yuqqa çığardı həm tatar millətə millət bularaq yəşəüdən tuqtıy yazdı. Bu çorda ilebez tarixı, xalıqlar tarixı ildəge xakim partiə—kommunistlar partiəse quşqança yazıldı, xalıqlarnın men yıllıq mədəniəte, məğərife də ələge partiə küzlegennən çığıp bəyələnde. Barı tik 60-70 yıllarda ğına ğalimnərebez arasında xalqıbız tarixına, anın ütkənenə, şul çorlarnın olpat şəxeslərenen eşçənleklərenə, alarnın xezmətlərenə yanaça qarau, bəyələrgə omtılış tua başladı. «Tarixi an, ütkənne belü—millət yəşəeşenen möhim şartı. Ütkənen belməgən xalıqnın kiləçəge yuq». Menə şuşı awır eşkə alınğan ğalimnərebeznen berse, berençelərnen berse—Yaxya Ğabdulla ulı Abdullin buldı. Ul—yana fənni tikşerenülərgə, ezlənülərgə yünəleş birgən, üz məktəben buldırğan, tatar ictimağıy həm fəlsəfi fikeren, nəq menə fiker tarixı bularaq əyrənə başlağan ğalim. Yaxya ağa Abdullin həm anın şəkertlərə aldında kommunistik xakimiət çorında yuq itelgən ictimağıy fiker tarixın torğızu burıçı tordı. Ə monın əçen tarixnın ayırım etapların, andağı problemalarnın hərbersen ayırım-ayırım bik centekləp əyrənergə kirək ide. Bu burıç Ğ. İbrahimof isemendəge Tel, ədəbiat həm tarix institutında yana bülek—tatar ictimağıy fiker tarixı bülegen açarğa, kadrlar tuplarğa, alarnı üstererge—»keşe itərgə» kirəklegen kiterep çığardı. Bügen inde menə ələge bülekkə 25 yıl tulğanda, Yaxya ağanın üze oyıştırğan həm citəkləgən bülektə eşləüçe xezməttəşlərenen həm şəkertlərenen ireşkən unışları, eşləgən eşlərə belən ğorurlanırlığı bar. Çənki anın qul astında, anın yərdəme, xəyer-fatıyxası belən fən yulına kerep kitkən həm sallı-sallı xezmətlər yazğan, fənni dərəcələrgə ireşkən R. Əmirxanof, R. Mexəmmətşin, F. Soltanof, Ə. Məxmüdof, Ə. Xəyrullin, M. Yosıpof, T. Kamaloflar h. b. fəndə üz yulların tapqan həm üz süzləren əytə alğan, millətebezgə armıy-talmıy xezmət itüçe, millət yazmışı belən yanıp yəşəwçe həm tərle etaplarında milli xərəkətne əydəp baruçılar, oyıştıruçılar, millətpərwər ğalimnər bulıp citeştelər.

Yaxya ağa Abdullin tatar fəlsəfə tarixı buyınça kürenekle, tanılğan belgeçlərnen berse. Ul tatar ictimağıy həm fəlsəfi fiker tarixın əyrənüne başlap cibərgən həm tatar məğrifətçelege, anın cəditçelek xərəkəten əyrənüdə üzennən prinsipial' yana eleş kertkən ğalim. Anın bu eleşe, yanalığı tatar məğrifətçelek xərəkətenen eçtəlegen, anın fəlsəfi, ictimağıy-səyəsi, tarixi xoquqıy, estetik, etik eçtəlegen açuda açıq çağıla. Ul berençelərdən bulıp Ş. Mərcani, Ğ. Qursawi, X. Fəyezxanof, Q. Nasıyri, Ş. Kültəsilərnen mirasına sotsial'-fəlsəfi bəyələmə birə. Yaxya ağa ozaq yıllar buyına üzenen şəkertlərə belən bergə tatar mədəniəte eşleklelərenen dənyağa qaraşlarının fəlsəfi nigezləren tikşerə, tatar ictimağıy, fəlsəfi fiker tarixın başınnan başlap, bügenge kengə qədər bulğan etaplarda əyrənə. Ul

üzeneŋ «Cəditçelek, anıŋ sotsial' tabiğəte həm üseşe» (1979) digən xezmətendə tatar ictimağıy fiker tarixındağı bu qatlaulı ağımğa centekle, təple analiz yasıy həm anıŋ tatar məğrifətçelege üseşendəge urının bilgeli.

Yaxya ağa Abdullinnıŋ «Татарская просветительская мысль» isemle xezməte üzebezdə genə tügel, çit illərdə də zur qızıqsınu uyattı. Fransuz ğalime M. Kelküje, Amerika ğalime E. Lassereni əlege tikşerüne «zur əhəmiətkə iə bulğan qimmətle xezmət» dip yazdılar. «SSSRda millətlərneŋ tarixın obyektiv əyrənügə borılışnı başlağan xezmət» dip bəyələdelər. Ə G. Rorlix isə üzeneŋ «İdel buyı tatarları» digən kitabında Y. Ğ. Abdullinnıŋ bu kitabın «İctimağıy fiker tarixın bol'şeviklar qollığınnan, boğawlarınnan qotqaruda zur rol' uynağan xezmət» dip bilgeləp ütte.

Yaxya ağa Abdullinnıŋ xezmətlərendə təp urınnı kürenekle ğalim, fiker iəse Şihabetdin Mərcani alıp tora. 60 yıllarğa qədər çıqqan ədəbiatta Ş. Mərcani həm Ğ. Qursawi—dvoryan burjuaz ğalimnər, reaksion ideologlar itep kürsətelep kilende. Yaxya ağa 1969 yılda («Qazan utları», 10 san) berençe tapqır Ş. Mərcanine məğrifətçe dip atadı həm alğa taba üzeneŋ başqa xezmətlərendə inde ul üz fikeren təple, centekle analizlar aşa Ş. Mərcanineŋ də, Ğ. Qursawinıŋ da olı ğalim həm fiker iəse—filosof ikənlekləren dəlille itep rasladı. Ul şulay uq Ş. Mərcani xezmətlərен əzerləw həm bastırıp çığaruda da berençelərdən buldı. Ş. Mərcanineŋ Ə. Xəyrullin əzerləgən «Mostafadel-əxbar fi əxwali Qazan wə Bolğar» xezməte də anıŋ cıtəkçelegendə eşlənde həm anıŋ kereş süze belən dənya kürde. Şuşı aralarda Ş. Mərcanineŋ ikençe monumental' xezməte—«Wafiət əl-əslaf wə təxiyət əl-əxlaf»—ğərəpçədən tərcemə itelep basılıp çığu aldında tora. Bu da Yaxya ağa həm anıŋ şəkertlərenеŋ küpyıllıq xezməte nəticəse.

Ruxi mirasıbıznı əyrənü həm anı xalqıbızğa qaytaru təp ber maqsatqa—tatar millətenеŋ fikri koçen nığıtuğa xezmət itərgə tieş. Şuŋa kürə xəzerge milli üseş həm bügenge ideologik protsessnı fənni analizlau—küptən kətelgən, inde waqıtı bik citkən eşlənəse eşebez, burıçıbız bulıp tora. Məğərif, mədəni-ədəbi üseş, milli üzaŋ xərəkəte, dini yəşəyeş kebek problemalarnı tikşerü, alarnıŋ milli maqsatlarıbızğa turı kilgən asıl sıyfatların açu, şunı fəlsəfi yaqtan açıqlaw—bu bügenge zaman taləbe.

Soŋğı yıllarda Yaxya ağa Abdullinnıŋ ideologik tormışıbızğa sallı əleş kertkən kürkəm yünələeşe—anıŋ İslamnıŋ tarixıbızda həm mədəniətebezdə totqan rolen açıqlauğa bağışlanğan xezmətlərе. Bu bik mөhim. Çөnki tatar xalqınıŋ fiker tarixı ğəmer-ğəmergə İslam belən ürelep barğan. Bu din millətebezne yuqqa çığudan saqlağan həm tatar xalqın beterü yünələeşendə alıp barılğan tərle ezərlekləü şartlarında xalqıbıznıŋ ruxi tayanıçı bulğan. Oluğ millətçebez S. Maqsudi əytkənçə, «Millətne millət itep saqlauçı nərsə—ul millətneŋ tele həm dine». Xəzer bezneŋ aldıbızda milli asılıbızğa qaytu burıçı tora. Bu problemanı xəl itü ciŋel bulmayaçak. Berençedən, bu milli ruxıbıznı torğızu, milli bitaraflıqnı ciŋü, yəşlərgə milli tərbiə birü bulsa, ikençedən, bəten milləttəşlərebezneŋ, islamğa qaytuına ireşü, islamnıŋ əxlaqıy prinsipların millətneŋ aŋına seŋderü, alarnı ateizm səremennən qotqaru.



*Yaxya Abdullin Məxəmmət ağa Ğaynullinnıŋ yubiley kiçəsendə çıgış yasıy. 1983 yıl.*

Bu—Yaxya ağa oyıştırğan həm bügenge kengə qədər eşləgən tatar ictimağıy fiker tarixi həm islamiət bülegenen aldında torğan həm fənni yuğarılıqta xəl itelergə tieşle burıçlardan.

80 yıllar axırında həm 90 yıllar başında Yaxya ağa üzenen tatar milli xərəkətenen başında torğan şəkertlərə belən bergə Tatarstannın suverenlığı əçen kərəşkə şaqtıy eleş kertkən moğtəbər zatlardan. Əmma anı millətnen bügenge xəle, sünep baruçı milli xərəkət, anın ber-berse belən urtaq tel taba almağan citəkçelərə çın-çınlap borçıy. Tel, din həm milli berdəmlek kenə bezne unışlarğa kiterəsen tirənten anlıy, şuna kürə də ul üzenen xezmətlərendə, məqələlərendə barı tik berdəmlek, milli berdəmleknen beznen milli maqsatlarıbızğa kiterəçəgen assızıqlıy. Çөnki şul berdəmlek bulmaw arqasında beznen uzğan tarixıbızda küpme yuğaltular, faciğələr bulğanlığı ütkəndəge mirasıbıznı өyrəngəndə tağın da açığrak kürenə.

Sonğı yıllarda Yaxya ağa Abdullin sovet xakimiəte yıllarında tatar xalqı xəterennən, anın tarixınnan quılıp kilengən kürenekle cəməğət, dəwlət eşleklese, səyəsətçe, millətçe, ğalim S. Maqsudinın isemen, bay mirasın kire xalqıbızğa qaytaru buyınça da berençelərdən bulıp eş başlağan ğalim. Anın qatnaşında 1993 yılnın oktəbrendə S. Maqsudinın 115 yıllığına həm 1998 yılnın oktəbrendə 120 yıllığına bağışlanğan xalıqara konferensiələr uzdırıldı. S. Maqsudinın təp xezmətе bulğan «Milliət toyğısının sotsiologik əsəsləri» da anın citəkçelegendə tərcemə itelep «Miras» jurnalında basılıp çıqtı (1993—1994), xəzer isə elege xezmət yanadan xəzerlənep ayırım kitap bulıp çığu aldında tora. Şulay uq Yaxya ağanın S. Maqsudinın milli eşçənlegenə həm bay mirasına bağışlanğan, fəlsəfi analizlanğan, bəyələngən küləmle məqələlərə fənni ciıntıqlarda, «Şəhri Qazan», «Watanım Tatarstan» gəzitlərendə həm «Qazan utları» jurnalında basıldılar.

Yaxya ağa Abdullin—atqazanğan fən eşleklese, fəlsəfə fənnərе doktorı, professor, Tatarstan Fənnər Akademiəsenen şərəfle akademigı, Tatarstan Fənnər Akademiəsenen Ş. Mərcani isemendəge premiəse laureatı. Bөyek Watan suğışı veteranı, millətpərwər, berençelərdən bulıp tatar ictimağıy fiker tarixın өyrənünе başlap cibərgən həm şul yünələştə berniçə sallı monografiə həm 220 dən artıq fənni xezmət yazğan, ber tərkem ğalimnərgə üz qıyblasın tabarğa, fənni yulğa ayaq basarğa, ğilmi dərəcələrgə ireşergə yərdəm itkən, həm bügenge kөndə də Tarix institutının in əlkən həm xөrmətle ğalime, yəşlərçə ruxlanıp xalqıbızğa xezmət itüçe millət ulı ul.

Yaxya Ğabdulla ulı Abdullinğa 80 yəş. Ber qarasan az ğөmer tügel inde. Yaxya ağanın ğөmer yulı xalqıbız, ilebez uzğan yul kebek ük qatlaulı, sikəltələ. İl tarixında, tatar xalqı yazmışında nindi awır çorlar, waqıyğalar bulsa, ul alarnın həmməsenen də canlı şahitı, qatnaşuçısı, tarixçısı da. Tatar xalqına xas bulğan sabırlıq, tüzemlelek, eşçənlek həm, əlbəttə, kileçəkkə zur ışanıç, өmetlər bağlap yəşəw anı, nihayət, ğөmerenen in bərəkətle həm in zur unışlarğa ireşkən çorına—tatar ictimağıy fiker tarixı digən zur, əhəmiətle problemalarnı өyrənə başlauğa kiterə. Yaxya ağa bu çorda üzenen bөten barlığın—belemen, kөçen, sələtеn, təcribəsen, yoqısız tөnnəren tatar millətenə xezmət itügə bağışlıy. Bu çor ozaq yıllar buyı xөkem sөrgən kommunistik ideologiə qısalarında bulsa da, qıyu rəweştə tarixıbıznın tirən qatlamnarın kütərügə həm xalqıbıznın xəteren, milli anın uyatuğa bağışlanğan çor da ele ul.

1920 yılnın ğinwarında Teleçe rayonının Olı Kibəxuca awılında tuğan Yaxya Ğabdulla ulı üzenen xezmət yulın 16 yəştən başlıy. 1940 yılnı armiə saflarına alına, Watan suğışında qatnaşa. 62 armiə saflarında Stalingradnı saqlıy, qatı yaralana, üz teləge belən qabat safqa basa. Leningrad şəhəren blokadadan azat itüdə, Baltik buyı illəren, Pol'şanı azat itüdə, Berlinnı şturmlauda qatnaşa. İke Qızıl Yoldız ordenı, I dərəcə Watan suğışı ordenı, küp medal'lər belən büləklənə. Suğıştan qaytqaç, Yaxya ağa 1959 yılğa qədər partiə eşendə eşli, annarı fəngə tartıla: filosofiə fənnərе buyınça kandidatlıq dissertatsiəsen yaqlıy həm Qazan veterenariə institutına dotsent bulıp küçə, 1971 yılda ul Ğ. İbrahimof isemendəge Qazan tel, ədəbiat həm tarix institutına eşkə kilə. 1975 yıldan sektor mөdire, 1981—1986 yıllarda başta İnstitutnın direktor urınbasarı, ə annarı direktorı bulıp eşli. 1978 yılda doktorlıq dissertatsiəsen yaqlıy. Bu—Yaxya ağa Abdullin uzğan xezmət həm tormış yulı.

Yaxya ağanın üz süzlərə belən əytsək, ul tormışnın sikəltələ, qatlaulı yulın ütkən keşe. Əmma ul ozaq ezlənülərdən son tormışta üzenen urının taba alğan, bөten kөçen birep tatar xalqına, tatar millətenə xezmət itkən ğalim.

**Fəridə ĞAFFAROVA,**
*tarix fənnərе kandidatı.*

●

*Uquçılarıbız icatı*

# Ğəmər Sattar–Mulille

## İsemnamə

Şahnamə—şahqa bağışlau, isemnamə—isemgə,
Şahnıꞑ da bar bit iseme, ul da moxtac isemgə;
Küz aldında totam monda məğnəneꞑ ikesen də,
İseme turı kilsen dim, hərdaim cisemenə.

Şah isemle, zat isemle, hər adəm isem ala,
İsemsez tuıp cihanğa, at ala, isem ala;
Qılğan ğəməlləre belən isemen bizi ala,
Cisem kitə, isem qala, çal tarixqa yul ala.

Hiçşiksez, monda bardır ber tirən ser, tirən tılsım:
Cisem bizider isemne, cisemne bizi isem,
Adəmneꞑ qılğan eşe isemen itsə asıl yaqut,
Danın-atın çikli almastır hiçber waqıt.

## Mulile

Mulileder—qırlar ile,
Mulile—cırlar ile,
Waqıtında yawğır yawa
Həm isə səba cile;
Mulile—borınğı awıl,
Mulile—zaman ile.

Mulile—tuğan awılım,
Terəgem həm qanatım;
Mulilemne küꞑelemdə
Min mul itep yarattım.

Mulla İlem—sin bişegem,
Sin yəşlegem, mul ilem,
Sində tuıp-üskəngəder,
Küꞑelem tulı moꞑ minem.

Zəyə buyındağı awıl—
Mul tormışlı Mulile,
Əzelep, səygəngəder sine,—
Təxəllüsem—Mulille.

## Tuqaү məydanı

Nəq Qazan urtasında bar
Zur məydan—Tuqaү dilər,
Bu isemne bezgə küktən
İndergən xodaү dilər...

Tarix dəwamında tərle
İsemne yərtkən məydan,
Balıqlar rəte isemen,
Kuybışef isemen annan.

Bəyek şagırebez Tuqaү
İsemen yərtə xəzer,
Bu gəməl Tuqaүı aşa
Tatar xalqına qəder.

Şəhre Qazan xozurlana
Bar dip, Tuqaү məydanım,
Qaүttı, diep gorurlana—
Milli yəzem, təs, danım.

# İldar Qıyamof

KÜRERMEN KÜK ŞİĞRİƏTNEN ATIN...

* * *

*(Tuqaү ruxındaraq)*

Yaratmıym çellədə arış sarğayunı:
İskə təşerə ul minem qartayunı...

Arışlarnın şuşı sarı təslərenə
Bez açarğa tieş tormış sere sengən.

İnde uzsam da min Tuqaү ülgən yəştən, -
Ürnək kürsətkən yuq cırda-eştə.

Yeseninnıqıdaү minem «kəyəz» bədrəm
Yıllar uzğan sayın kəmeşləner, beləm...

İrtə-kiçləremdə min də səcdə qılam:
Ayırma tik Sazım belən, Xodam!

## Dürtyullıqlar

* * *

Bu cihannın barmı kamillege -
Dəreslege barmı son anın?!
Kemder yəşi xəkemdarlar bulıp,
Bez-qolları, bəlki, dənyanın?

### Sügenmiçə sügenü

Sügensən də əllə niçek inde,
Sügenməsən tüzər əməl yuq:

Kemnərnenḑer dungız buluınnan
Ğazap çigep yəşim min məxluq.

* * *

Yul ğazabı-gür ğazabı dilər,
Şul «ğazaplar» əllə niçek yaqın:
Kürermen kük yulda şiğriətneņ
İlham birer sılu tulpar atın!

* * *

Tıyma, keşe, yərəgenne,
Tipsen, yansın keçlerək!
Bu yanular kügərüdən
Saqlanu əçen kirək.

### Safsata tügel

Bu fikerem açış tügel,
Həm tügelder safsata.
Şaytan tayağı da, duslar,
Ni ğəcəp: çəçək ata!

* * *

Kaban küldə unaltınçı ğasır
Yoqlıy... qoçıp Kamal teatrın...

Maturlıqqa tuya belməs Tatar
Qoça Kiləçəkne-... Cir şarın.

## Rinat Nurullin

### Tormış yalqını kirək...

Oça qurğaş-ezli mişen',
Anıņ maqsatı-yərək...
Ə yərəkkə pulya tügel,
Məxəbbət uğı kirək!

Utatqıçlar ut bərkilər,
Adəmnər yana kəyrəp...

Ə keşegə ülem tügel,
Tormış yalqını kirək!

Kayta oçqıç tuğan yaqqa
Qap-qara «sandıq» təyəp...
Ə anağa tabut tügel,
İsən balası kirək!

*Безнең календарь*

# МӘХМҮД МАКСУДНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Мәхмүд Максуд—бөтен иҗат гомере буенча тәрҗемә өлкәсендә эшләгән язучыларның берсе. Аның тәрҗемәсендә дөнья һәм рус классик әдәбиятының бик күп әсәрләре татар телендә басылып чыкты.

А. Пушкинның «Дубровский» повесте, «Русалка» поэмасы, «Саран рыцарь» трагедиясе; Р. Ролланның «Кола Брюньон» романы, Г. Гейненың «Германия» поэмасы, Н. Некрасовның «Рус илендә кем рәхәт яши?» поэмасы, Гетеның «Фауст»ы, И. Тургеневның «Рудин», Низаминың «Ләйлә вә Мәҗнүн» һ. б. бик күп әсәрләр аның тәрҗемәсендә дөнья күрде.

М. Максуд бөек рус язучысы Л. Толстой иҗатын пропагандалауга күп көч куйды. Аның тәрҗемәсендә Л. Толстойның дөньякүләм атаклы әсәрләреннән дүрт томлык «Сугыш һәм тынычлык» эпопеясы һәм ике томлык «Анна Каренина» романы татар телендә басылып чыкты.

Фронтовик язучы һәм тәрҗемәче Мәхмүд Максуд 1900 елның 15 гыйнварында Саба районы Югары Кибәхуҗа авылында туа. Кышкар мәдрәсәсендә, Арчадагы ике класслы рус-татар мәктәбендә, соңрак Малмыж шәһәрендә Югары—башлангыч училище дип йөртелгән уку йортында гомуми белем ала. Мәктәп елларында үзенең беренче өйрәнчек шигырьләре һәм хикәяләрен яза башлый.

Гражданнар сугышы елларында Кызыл гаскәргә язылып, Колчакка каршы сугышта катнаша. Фронт шартларында күп кенә патриотик шигырьләр, кызылармеецларның героик образларын тасвирлаган нәсерләр иҗат итә.

1920-30 елларда ул Мәскәүдә яши. Анда Мәскәү нәшриятларында эшли, «Яшь эшче», «Коммунист» газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр була. Шул ук чорда әдип Көнчыгыш хезмәт ияләре коммунистик университетының тарих-табигать фәннәре бүлеген, аннары Мәскәү дәүләт университетының этнология факультетында әдәбият бүлеген тәмамлый.

Бөек Ватан сугышы елларында М. Максуд иҗат эшен ташламый, фронт газеталарына язышa, 1944 елны «Үч һәм нәләт җыры» исемле поэтик җыентыгын бастырып чыгара. Сугышчан хезмәтләре өчен Кызыл Йолдыз, Икенче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соңгы чорда ул очерк жанрында һәм тәрҗемә өлкәсендә актив иҗат итә.

Әдәбият өлкәсендәге иҗади хезмәтләре өчен М. Максуд 1957 елны «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләнә.

М. Максуд 1962 елның 10 ноябрендә Мәскәүдә вафат булды. Ул 1934 елдан Язучылар берлеге әгъзасы иде.

*Котлыйбыз!*

# ИҖАТ СЕРЛӘРЕН АЧУЧЫ

## ӘДӘБИЯТ ГАЛИМЕ ҺӘМ ТӘНКЫЙТЬЧЕ ФӘРИТ ХАТИПОВКА 70 ЯШЬ



«Язучыларның әсәр язу тәҗрибәсе, бу юнәлештә эшләү рәвеше, иҗатның гомум яклары һәм индивидуаль үзенчәлекләре—бик кыйммәтле иҗат серләре ул. Шулай булуга карамастан, әле күп кенә күренекле әдипләрнең иҗат лабораториясе ачылмаган килеш кала бирә...»—дип чын күңелдән борчылып яза күренекле галим һәм әдәби тәнкыйтьче Фәрит ага Хатипов үзенең «Иҗат серләре» исемле зур күләмле мәкаләсендә («Казан утлары», 5 сан, 1999 ел).

Әйе, шушы айда 70 яшен тутыручы галим моңа кадәр басылган хезмәтләрендә дә әдәбиятның мөһим һәм актуаль проблемаларын күтәрде, аларны тормышның һәм иҗатның иң җитди таләпләре югарылыгында хәл итәргә омтылды.

Актаныш төбәгенең Пучы авылында туган Фәрит ага студент елларыннан ук көндәлек матбугатта актив язышка башлый—яңа чыккан әдәби әсәрләргә һәм спектакльләргә рецензияләр бастыра. 1952 елда Казан дәүләт университетын тәмамлагач ул шунда ук аспирантурада кала, аннары «Мирсәй Әмир иҗатында уңай герой проблемасы» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. 1955-1959 елларда ул Төмән өлкәсенең Тобол педагогия институтында укыта һәм шулай ук актив иҗат итә. Ә инде 1959-1972 елларда Фәрит ага Уфа шәһәрендә яши андагы университетта укыта, татар әдәбиятының күренекле әдипләре Ә. Еники, Г. Әпсәләмов, А. Гыйләҗев һ. б. лар турында җитди хезмәтләр бастыра. «Эпик жанрлар» дигән күләмле хезмәт тә биредә языла. 1972 елда галим Казанга кайтып, педагогия институтында эшли башлый һәм үзенең иҗади эшчәнлегендә әдәбиятта геройның күңел дөньясын сәнгатьчә чагылдыруга, психологизмга аеруча зур игътибар бирә, бу хакта хезмәтләр, китаплар яза. Ул—филология фәннәре докторы.

Журналыбызның актив авторы Фәрит аганы олы юбилее белән котлыйбыз!

## *Иҗтимагый—мәдәни тормышыбыздан*

### ЯЗУЧЫ ДЕПУТАТЛАРЫБЫЗ

19 декабрьдә булып узган сайлауларда Татарстан Дәүләт Советына язучылардан **Р.Харис, Т. Миңнуллин, Ф. Галимуллин, Р.Вәлиев, Р. Миңнуллин** депутат итеп сайланды. Аларның күбесе үткән чакырылышлардагы Югары Совет һәм Дәүләт Советларында депутатлар буларак сайлаучылар мәнфәгатен яклап, халык ышанычын аклаганнар иде инде. Дәүләт Советына, шулай ук, «Сөембикә» журналының баш мөхәррире **Р. Туфитуллова** да сайланды. Каләмдәшләребезне котлыйбыз, иҗат һәм депутат эшчәнлекләрендә уңышлар телибез!

### ЯҢА МИНИСТР

Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиевнең 1999 ел, 17 ноябрь Указы нигезендә **Илдус Габдрахман улы Тарханов** Татарстан Мәдәният министры итеп билгеләнде. Үз вакытында ул Казан дәүләт мәдәният институтын тәмамлаган иде, соңрак Лениногорск, Чаллы шәһәрләрендә сәнгать өлкәсендә җаваплы эшләр башкарды. 1993 елдан Татарстан мәдәният министры урынбасары булып эшләде.

### ТЕЛЕВИДЕНИЕ ҮЗӘГЕНӘ 40 ЕЛ

Элеккеге Советлар Союзында телевидение эшчәнлегенең башлангычы 1939 елдан санала. Татарстан телевидениесе исә ике дистә елга яшьрәк—ул 1959 елда башлана. Дөрес, бер төркем энтузиаст галимнәр 1955 елда ук үзешчән төстә Радиоприбор заводында беренче тәҗрибә тапшыруларын оештыралар. Әмма Татарстан телевидениесенең чынлап эшли башлавы—1959 елда шәһәребезнең Ш.Усманов урамында телестудия төзелү белән бәйле.

* * *

6 декабрьдә К. Тинчурин исемендәге театр бинасында Татарстан китап нәшриятының 80 еллыгына багышланган китап бәйрәме булып үтте. Тантананы нәшрият директоры Д. Шакиров ачып җибәрде. Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшинның котлавын Татарстан халык депутаты Р. Миңнуллин ирештерде. Хөкүмәт исеменнән Татарстан матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары министры З. Вәлиева чыгыш ясады.

Кичәдә каләм әһелләреннән Н. Фәттах, Ә. Кәримуллин, Р. Даутов; җырчыларыбыз—З. Сөнгатуллина, Ф. Сәлахов, А. Туишева, Р. Миндияр, Камал театры артистлары—Р. Таҗетдин, Н. Ихсанова, Г. Исәнгулова, А. Хафиз, Ф. Хафиз, Р. Мотыйгуллина катнаштылар.

### ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕНДӘ ОЧРАШУ

Диния нәзарәте һәм Язучылар берлеге каршындагы Аксакаллар (Өлкәннәр) Шурасы инициативасы белән үткәрелгән бу очрашуда язучылардан Ә. Баянов, Р. Фәйзуллин, М. Хәбибуллин, В. Нуруллин, Ә. Рәшитов, Р. Гарипов, Ш. Маннапов, Р. Хафизова, С. Гәрәева, Ш. Мостафин, Ф. Зыятдинов; руханилардан мөфти Госман хәзрәт Исхакый, Вәлиулла хәзрәт Ягъкуб, Ильяс хәзрәт Җиһаншин катнашты. Татарстан Язучылар берлеге белән нәзарәт-мөфтият эшчәнлегенең кайбер мәсьәләләрен (дини рухтагы нәфис әдәбият нәшер итү, мәдрәсәләрдә укучы шәкертләргә белем-тәрбия бирү эшен яхшырту, газет-журнал редакцияләре белән элемтәне ныгыту һ. б.) координацияләү турында ике арада файдалы әңгәмә булды.

### ӘДӘБИЯТ ФОНДЫНДА

Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында Татарстан Әдәбият фонды әгъзаларының II конференциясе булды. Анда фонд идарәсе рәисе Әхсән Баянов һәм башкаручы директор Данил Салиховның ике җыен арасындагы эшчәнлек турында хисаплары тыңланды. Докладлар буенча фикер алышуда бүгенге икътисади тотрыксызлык заманында әдәбиятның, аерым алганда, каләм әһелләренең кыен хәлдә калуы, китап бастыруның моңарчы күрелмәгәнчә сүлпәнәюе янә искәртеп үтелде, киләчәктә

язучыларның иҗаты һәм көнкүреше өчен унайлы шартлар тудыру җәһәтеннән эшлекле тәкъдимнәр әйтелде.

Конференциядә Әдәбият фондының бүгенге заман таләпләренә туры китереп янартылган Уставы кабул ителде. Идарә рәисе итеп күпчелек тавыш белән күренекле шагыйрь **Гәрәй Рәхим** сайланды. Идарәнең беренче утырышында башкаручы директор вазифалары янадан драматург **Данил Салиховка** йөкләтелде.

## КҮРГӘЗМӘ ЗАЛЛАРЫНДА

* * *

Түбән Камада яшәп иҗат итүче **Әхсән Фәтхетдинов** халыкка яхшы мәгълүм. Ул—Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Монарчы да, тәгәлрәк әйткәндә, 1976, 1992 елларда Казанда аның шәхси күргәзмәләре булган иде инде. 1999 елның 7 декабрендә Казан милли-мәдәни үзәге бинасында ачылган күргәзмә үзенең колачы, оригинальлеге, жанрлар төрлелеге белән аерылып торды һәм ул сәнгать сөючеләрнең тирән ихтирамын казанды. Күргәзмә композициясенең зур бер өлешен шагыйрь Равил Фәйзуллинның кыска шигырьләре нигезендә язылган «Кабер ташлары» циклы тәшкил итә. Күргәзмә быелның гыйнвар аенда да эшләячәк.

* * *

Чаллы шәһәренең картиналар галереясендә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Нәҗип Нәкъкашның** гарәби каллиграфия күргәзмәсе ачылды.

Күргәзмә изге Рамазан аена багышлана. Анда Ислам сәнгате әсәрләре: гарәп язулы шәмаилләр, ләүхәләр һәм тугралар күрсәтелә. Анда, шулай ук, ул бизәгән китаплар белән дә танышырга мөмкин. Күргәзмәне оештыруда Чаллы шәһәре хакимияте булышлык күрсәтте.

* * *

Шәриф Камал музеенда татар халкының мәшһүр шагыйре, җәмәгать эшлеклесе, меценат-иганәче Дәрдемәнднең (Закир Рәмиев) тууына 140 ел тулуга багышланган «Күңел һәр җирдә гөл эзли» дип исемләнгән күргәзмә ачылды. Аны ачу тантанасына язучылар, галимнәр, һәм шагыйрь иҗатын сөючеләр күпләп килгән иде. Дәрдмәндкә багышланган мондый күргәзмә мәдәниятебез тарихында беренче тапкыр оештырыла. Экспонатлар Башкортостанның Милли музееннан, Татарстанның берләштерелгән Дәүләт музееннан һәм, шулай ук, Татарстан Милли китапханәсеннән алынган.

Декабрь башында шул ук күргәзмә залында Дәрдемәнднең «Агарган кыл» исемле китабын тәкъдим итү кичәсе дә булып узды.

Күренекле язучы-галим, популяр фантастик әсәрләр авторы Владимир Корчагинның 75 яшьлек юбилее уңаеннан, башкалабызның М. Горький музеенда, танылган әдәбият-сәнгать әһелләре катнашында иҗат кичәсе үткәрелде. Юбилярны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, күп санлы шәкертләре, университетта бергә эшләгән коллегалары, киң җәмәгатьчелек вәкилләре котлады.

Милли Мәҗлес рәисе, язучы Айдар Хәлим, Милли Мәҗлес президиумы әгъзалары—«Иттифак» милли бәйсезлек фиркасы рәисе, язучы Фәүзия Бәйрәмова, Әлмәт язучылар оешмасы җитәкчесе, шагыйрь һәм композитор Разим Вәлиуллин Оренбургта булып кайттылар.

Алар анда күренекле мәгърифәтче, дистәләгән китаплар авторы Мәдинә ханым Рәхимкулова белән очраштылар, мәчетләрдә, китапханәдә, татар театрында булдылар.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Фән һәм техника өлкәсендәге уңышлары өчен, Татарстан Президенты Указы нигезендә, бер төркем галимнәребез Дәүләт премиясенә лаек булдылар. Алар арасында Казан дәүләт ветеринария академиясе ректоры, ветеринария фәннәре докторы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы **Корбанов Рифат Җамал улы** һәм Казан дәүләт университеты профессоры, филология фәннәре докторы **Нигъмәтуллина Йолдыз Галимҗан кызы** да бар.

*Тышлыктагы сурәтләр*

# XVI ГАСЫР ЯДКАРЕ

XV-XVI гасырда Европада дипломатия мөнәсәбәтләрендә үзара портретлар алышу төп йолага әверелә. Хөкемдарлар теге яки бу ил белән дуслашу максатларында яисә ярәшү өчен бер-берсенә үзләренең, җитлеккән угыл-кызларының портретларын җибәрәләр. Госманлылар Империясе, Урта Азия, Иран, Италия, Польша-Литва, Мәскәү h. б. дәүләтләр белән мәдәни бәйләнештагы, сәүдәгәрләр, сәяхәтчеләр кайнап торган, янарыш стадиясе кичергән Казанга да мондый йола хас булган, әлбәттә. Һәм, табигый ки, үз чорының гүзәл ханбикәсе, акыл иясе, дипломат Сөембикәнең портреты булу ихтималы һичкемне дә гаҗәпләндерми.

Тышлыкның беренче битендәге рәсем бүгенге көнгә кадәр сәнгать белгечләре арасында җитди бәхәсләргә сәбәп булып килә. Чыннан да, чыгышы белән, һичшиксез ерак гасырлар ядкаре булган рәсемдә кемнәр һәм кайсы чор сурәтләнгән соң?

Сүз 1999 елда Милли мәдәният музеена академик А. Н. Каралинның шәхси коллекциясеннән килеп кергән борынгы картина турында бара. Күпләр аны «Сөембикә ханбикә үзенең улы Үтәмешгәрәй белән» дип фаразлый. И. Грабарь исемендәге Бөтенроссия нәфис һәм фәнни реставрация мәркәзе буяу катлавын һәм тукымасын тикшереп, рәсемнең XVII гасыр ахырында, XVIII гасыр башында ясалу ихтималын билгеләде.

Композициянең уртасында—башына асылташлардан, энҗе-мәрҗәннәрдән каелган баш киеме, парча күлмәк, авыр бәрхет камзул, кыйммәтле хәситә кигән чибәр ханым; янда, ханым алдындагы китаптан күзләрен алмый карап торучы, аның кебек үк киенгән яшь кыз бала; сулда—тәрбияче-дая; артта—асылташлар белән чиккән түбәтәй кигән ир-ат...

Укалы киемнәр кигән зифа буйлы, инсафлы йөзле, чибәр ханымның Сөембикә булуы шөбһә уятмый. Бер үк вакытта Мономах бүреген һәм Казан таҗын хәтерләткән, ренессанс чоры Европа хатын-кызларының очлы манарадай баш киеме, өс кием детальләре аның җәмгыятьтәге урынын—дәрәҗәсен күрсәтеп тора. Ә менә Сөембикә янындагы алкалы яшүсмернең дошман күзеннән яшерү өчен кыз бала итеп киендерелгән Үтәмеш булуы шикле... Бу, һичшиксез, җидесигез яшьләрдәге кыз бала! Кызчыкның Сөембикәнең беренче ире—1531-1535 елларда Казан тәхетендә утырган, аннан үтерелгән Җангали ханнан туган кызы—Маһи-Солтан, яки Шаһи-Солтан (1534-1535 еллар) булуы мөмкин. Ул М. Худяков хезмәтләрендә дә телгә алына. Шулай итеп, әсәрнең язылу вакыты 1542-1545 еллар чамасы килеп чыга, ягъни, Үтәмеш туганчы ук. Ә инде арттагы кара киемле татар аксөяге кем? Сафа Гәрәй булса, ул, шиксез, композициянең уртасында сурәтләнгән булыр иде, хан киемнәрен кияр иде. Сәргаскәр Кошчык-оглан булса, хәрби атрибутлары булыр иде. Монда исә бөтенләй башка композиция. Рәсемнең үзәгендә—мәдәни, шигъри, укымышлы, иҗади сарай атмосферасы! Һәммә карашлар тоташкан җирдә—Ананың алдында—Китап! Картинада, һичшиксез, нииндидер әсәр уку процессы. Уйланып карап торган ир затының исә заманының танылган шагыйре Мөхәммәдьяр, Гарифбәк, Колшәриф яисә башка берәр акыл иясе булуы да шик уятмый кебек.

Инде рәсемнең чоры һәм авторы турында. Рентгенограмма әсәрнең безгә кадәр килеп җитмәгән бик борынгы оригиналдан башкарылган күчермә булуы турында сөйли. Безнең фикеребезчә, әсәрнең авторы—Италия янарыш чорының профессиональ остасы. Бу фикерне картинаның Көнбатыш христиан диненә хас дүрт фигурадан гыйбарәт Канонга буйсынган «изге гаилә» («Святое семейство») тибында ясалуы да ачык раслый. Бу тип композицияләрдә, рус иконаларыннан аермалы буларак, гадәттә изге Ана, нәни Гайса сурәтләнә. Әсәрнең рухы да, андагы гуманизм, дөньявилык билгеләре дә аны Көнбатыш янарыш чоры идеаллары белән тоташтыра, урыс православиесенә хас булмаган эслүб моны ассызыклап тора. XVI гасыр рус сынлы сәнгатендә әле иконалар язу гына гамәлдә, парсуна («персона» сүзеннән) дип аталган беренче портретлар бары XVII гасыр ахыры-XVIII йөз башында гына күренә башлый. Димәк, һәм сурәтләү алымнары, һәм эслүбе, һәм төсләр уены белән без тикшергән рәсем, һичшиксез, XVI гасыр Италия рәссамыныкы. Ә күчермәне христиан динен кабул иткән татар кешесе ясау ихтималын да читкә кагарга ярамый. Басып алынган, изелгән, җир йөзеннән юк ителергә тиеш халык сәнгатен урыс иконачысы күтәрмәс иде. Бусы да бәхәссез. XVII гасыр Идел буе һәм Казан регионының төп икона мәктәбе рәссамнары—«Строгановларның» бабалары татарлардан. Аларның берсе—Аникей Федорович Строганов 1497-1570 (милләтенә хыянәт иткән өчен татарлар аның әтисен тере килеш туныйлар). Фамилия «строганый» сүзеннән.

Шулай итеп, безнең алдыбызда, Сөембикә манарасы, «Ханбикә кувшины», Казан таҗы, Мөхәммәдьяр шигырьләре кебек үк кыйммәтле мирас—сәяси, матди, мәдәни бәйләнешләр чагылышы—Казан ханлыгы чоры ядкаре. Аның мәдәни образы. Казан янарышының нуры.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
*сәнгать белгече.*

# ЯҢА КИТАПЛАР

ДӘРДЕМӘНД. **Агарган кыл.** (Постаревшая струна).—Казан: «Мәгариф» нәшр., 1999.—112 бит. Тиражы—2000 данә.




1999 ел ахырында җәмәгатьчелек татар халкының бөек шагыйрьләреннән берсе—Дәрдемәнднең (Закир Рәмиев) туына 140 ел тулуын киң билгеләп үтте. Бу китапның затлы сувенир басма булып чыгарылуы да шушы юбилей белән бәйле.

Дәрдемәнд иҗаты XX йөз башы татар шигъриятендә аерым урын тота. Анарда үзенчәлекле рәвештә XIX йөз ахыры—XX йөз башындагы мәгърифәтчелек идеяләре дә, беренче Русия инкыйлабының каршылыклары да, 1917 ел октябренә бәйле кискен борылыш та чагылыш тапкан.

**«Дәрдемәнд дигән үзенчәлекле талант төрле шигъри мәктәп һәм сәнгати эзләнүләр үрелешеннән хасил булган. Ул төрки-татар классик шигърият традицияләренә, аның тотрыклы сурәтләренә һәм борынгыдан килгән сүзлек байлыгына таяна, аларны татар сөйләм теленең сафлыгы һәм фольклорчан фикерләү белән үрә, палитрасын халык эпосына хас ритмика һәм строфика белән баета.** *(Н. Хисамов—галим, китапның фәнни редакторы).*

**«Дәрдемәнднең иҗат мирасы күләме ягыннан әллә ни зур түгел—шигырьләре мең юлдан аз гына артыграк. Шуңа күрә, аның архивының берникадәр өлеше, Гражданнар сугышы елларында урланып, чит илгә чыгарылган, дигән хәбәрләр күңелләрдә өмет уята һәм бу юнәлештә эзләнүләр алып бару теләген тудыра. Әмма иҗатының безгә билгеле булган өлеше генә дә татар әдәбияты өчен әйтеп бетергесез әһәмияткә ия һәм, һичшиксез, аның алтын сәхифәсен тәшкил итә.»** *(Р. Харис—шагыйрь, китапны төзүче һәм кереш сүз авторы).*

Сәнгатьчә бизәлгән, альбомга тартым бу китапта бөек классикның гүзәл шигырьләре татарча оригиналында (сүзлек һәм искәрмәләр белән) һәм русча тәрҗемәдә *(тәрҗемәчеләр—Р. Бохараев, Н. Беляев, С. Липкин, В. Ганиев һ. б.)* бирелә.

Китапны безгә һәм кыйммәтле истәлек итә торган тагын бер мөһим сыйфат—ана тупланган сурәт һәм рәсемнәр. Дәрдемәнднең монарчы матбугатта күренмәгән фоторәсемнәре, гаиләсен, мәсләктәшләрен үз эченә алган сурәтләр, шигырьләргә иллюстрацияләр шагыйрь дөньясын ачыграк күзалларга ярдәм итәр.

Индекс 73210



Фоат Садриев

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)